ISSN 0206—4189

# Казан утлары

2.2003



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ


*Евангелие урамы*


*Татарстан урамы*

Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.

*Хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2003

2

(964)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.
Факс — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

ЗӨЛФӘТ. Күктән күпме йолдыз карап тора. *Шигырьләр* ..... 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Тояк эзе. *Роман* ..... 10
Фәнис ЯРУЛЛИН. Юлым илтә һаман тирәнгә. *Шигырьләр* ..... 85
Барлас КАМАЛОВ. Соңгы көннәрдә. *Хикәя* ..... 90
Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Дүртьюллыклар ..... 94
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Татарның нәкъ үзе кебек. *Шигырьләр* ..... 113

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Юксыну ..... 97
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Үги ана яфраклары. *Хикәя* ..... 101

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әхәт МУШИНСКИЙ. Җан авазы ..... 117

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Дания ГЫЙМРАНОВА. Театрга гашыйк булыгыз! ..... 124
Рифат СВЕРИГИН. Аны беләбезме? *(Фәнис Яруллинга 65 яшь тулу уңаеннан)* .. 130
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Такташка кайту ..... 138

**КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА**

Ринат СОЛТАНОВ. Ханлык чорында Болак аръягы Казаны ..... 146

**ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ**

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН. Гаяз Исхакыйның сәяси карашлары ..... 150
Гаяз ИСХАКЫЙ. Дөнья әхвәле ..... 153

**ФӘН**

Хуҗи МӘХМҮТОВ. Халык афоризмнарында магия һәм яшерен тел эзләре ... 159
Корьән татар телендә ..... 165

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Әнвәр ШӘРИПОВ. Төрки сүз сәнгате кайлардан башлана? ..... 173
Юбилейлар ..... 179

**ЮМОР-САТИРА**

Морад ДУСАЙ. Алай түгел, болай ул... ..... 181
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: М. АМИРХАНОВ. Роман «Следы копыт» *(продолжение)*; рассказ Б. КАМАЛОВА «В последние дни»; стихи ЗУЛЬФАТА, Ф. ЯРУЛЛИНА, В. ФАТИХОВА, И. ГИЛЯЗОВА.
«К 75—летию народного писателя Татарстана А. Гилязова»: рассказ А. ГИЛЯЗОВА «Мать-и-мачеха» *(с предисловием Ф. Латыфи)*.
«Публицистика»: статья А. МУШИНСКОГО «Крик души».
«Литературная критика»: статья Д. ГИМРАНОВОЙ «Любовь к театру», и статья Р. СВЕРИГИНА к 65-летию Ф. Яруллина «Знаем ли мы его?», статья Г. ГИЛЬМАНОВА «Возвращение к Такташу».
«К 1000-летию Казани»: статья Р. СУЛТАНОВА «Забулачная Казань времен ханства».
«К 125- летию Г. Исхаки»: статья З. МУХАМЕТШИНА «Политические взгляды Г. Исхаки», Г. ИСХАКИ. «Состояние мира».
«Наука»: Х. МАХМУТОВ. «Магия народных афоризмов.»
Коран на татарском языке.
«Книжное обозрение»: статья А. ШАРИПОВА «Истоки тюркоязычной поэзии».
«Юмор-сатира»: М. ДУСАЙ. Забавные истории.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Хозяин оберегов». Автопортрет. Работа художника А. Фатхутдинова; поэт Б. Рафиков.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": M. AMIRHANOV´S novel «Hood´s scent» *(continuation)*; B. KAMALOV´S story «In last days»; verses of ZULFAT, F. YARULLIN, V. FATIHOV, I. GILYAZOV.
"Commemorating the 75th anniversary of national writer of Tatarstan A. Gilyazov": A. GILYAZOV´S story «Mother and stepmother» *(with F. LATIFI´S preface)*.
"Journalism": A. MUSHINSKY´S article «Soul´s shout».
"Literary criticism": D. GIMRANOVA´S article «Lova to theatren» and R. SVERIGIN´S article of commemorating the 65th anniversary of F. Yarullin «Do we know him?»; G. GILMANOV´S article «Return to Taktash».
"Commemorating the 1000th anniversary of Kazan city": R. SULTANOV´S article «Bulak´s Kazan of khan times».
"Commemorating the 125th anniversary of G. Iskhaki": Z. MUKHAMETSHIN´S article «Politicm views of G. Iskhaki», G. ISKHAKI «Word´s condition».
"Science": article of H. MAKHMUTOV «Magic of national aphorism».
Koran in Tatar language.
"Book´s review": A. SHARIPOV´S article «Sources of turk-language poetry».
"Humour-satire": M. DUSAY. Funny stories.
The diary of social and cultural life.
On our covers: «Charm´s master». Autoportrait. Work of artist A. Fatkhutdinov; poet B. Rafikov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 17.01.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8031. Заказ Я—13
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2
© «Казан утлары», 2003 ел.



## Зөлфәт

### КҮКТӘН КҮПМЕ ЙОЛДЫЗ КАРАП ТОРА...

**Кайда?**

Чор-дәверләр сискәндерә...
Еракка колак салам...
Сыкрана гел бүгенгедәй
Борынгы төрки бабам...

Чиксез дала уртасында
Ул, ташка чукый-чукый,
Безгә атап мәктүб яза...
Чүки... Туктала... Укый...

Хәбәр итә безләргә ул
Яман хәлдә калганын:
«Кайда инде хөр дәүләтем?
Кайда минем каһаным?»

Дала тын... Шаулы тарихлар,
Гасырлар йоклый анда!
Озын яллы дала аты
Чемченә, утлый янда...

Киттеме дала җиленә
Күлтәгиннең заманы?
Кайда, бабам, синең илең?
Кайда синең каһаның?

---

ЗӨЛФӘТ *(1947)—шагыйрь, «Утлы боллар», «Адашкан болыт», «Йөрәгемне былбыл чакты» һ. б. китаплар авторы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Кылә безгә ул аh-зарлар
Дәверләр кичә-кичә...
Таш язуы—бүгенгечә,
Бүгенге—кичәгечә...

Уйладыңмы, ерак бабам,
Сүзләреңнең каласын?
Дәвердән күчеп дәвергә,
Һаман үзгәрмичә бер дә
Сыкрап кабатланасын?

Пәйгамбәрме, шагыйрьме син,
Борынгы төрки бабам?
Күз яшеңә шаhит Ходаң
Һәм иксез-чиксез далаң...

Дәшә күк җилле даладан
Күлтәгиннең заманы:
—Кайда, балам, синең илең
Һәм бездән калган даның?

Булды ла бит, булды шундый көннәр! —
Яктысыннан күзләр чагылды,
Безнең сулышлардан дулкын купты,
Болытларда яшен кабынды.

Яфраклардан тамып торды тылсым,
Йолдызлардан серләр сирпелде.
Без яшәргә тиеш сыман идек—
Һичкем яшәмәгән шикелле.

Иярсез дә, йөгәнсез дә икән
Язмышның бу кыргый атлары!
Алып чапты атлар...
Кайсы гына
Офыкларга алар чапмады!

Йөгәнсез ат-язмыш...
Алдан белсә
Язган юлның кая илтәсен,
Әгәр белә калса иртәгәсен
Кемне, кайда, ниләр көтәсен—
Юл чыгармы адәм балалары?
Шуңа Ходай күзне каплаган
Һәм озатып калган
Зур Сәфәргә
Вакыт дигән бөек капкадан...

Бер адымнан ни буласын белми,
Әмма кеше атлый, юл ала.
Төпсез таңнан килеп иңгән кеше
Төпсез төнгә иңеп югала...
Мәңге яшәр бер зат булырга без
Тиеш сыман идек, югыйсә!
...Дөньялыкта шул ук үлән шыта,
Мәңгелектә шул ук җил исә...

## Чын

Бер исемсез йолдыз эзләп табып,
Бисмиллалап исем кушсаң икән!
Бер исемсез бөҗәк булып үзең,
Исемсез бер якка очсаң икән!

Йәки ерак-ерактагы суда
Йөзсәң икән дулкыннарны телеп
Һәм таң калсаң икән, шул агымның
Һич исемсез икәнлеген белеп!—

Менә ул чын яшәү булыр иде!
Хәер, әле дә мин куркып ятам—
Берәр йолдыз, мине күреп алып,
Нидер уйламыймы минем хакта?

Бик тә аптыраулы, кызганулы
Уйлар уйлап йолдыз минем хакта,
Үртәп миңа кушса бер кушамат?
...Шау йолдызлы төннәр килгән чакта

Бик артыгын кыланмыйча гына
Яшәвең дә монда ярап тора...
Әллә ниләр уйлаулары бар бит!—
Күктән күпме йолдыз карап тора...

...Галәм булсам, күкрәгемдә минем
Күчтәй гөжләп йолдыз тулыр иде...
Дөнья бераз серле булсын өчен
Алар гел исемсез булыр иде!

Сәер теләк туа бу күңелдә...
Күңел—сәер... Булмый һаман ярап!—
Үзебезне бер күрәсе килә
Җиһан булып, чиксезлектән карап!

Менә ул чын яшәү булыр иде!
Юлга юлдаш булып йөрсәң икән!
Гел исемсез киңлекләрдә калып,
Исемсез бер йолдыз эзләп табып,
Бисмиллалап исем бирсәң икән!—

Мәңге тулмас күңел тулыр иде...
Менә ул чын яшәү булыр иде!

## Асрамага биргән җан

Җан асрау, диләр... Димәк, бар икән бит
Асрамага калган җаннар да...
—Асрамага бала бирәм!—
...Шул чордагы
Бу татарны ничек аңларга?

Уйлап баксаң, ничек исән соң без?—
Гомер ышанычлы, юк васи!—
Асрамага калган татар җанын
Асрамага алды... Тукае!

Әгәр безне Тукай якламаса,
Таянырга ул да булмаса,

«Татар» сүзе бер сүгенү сүзе
Булып кала иде ләбаса!

Яуга ул калкансыз барып керде
һәм—
кылычка кылыч һаман да
Бәхетсез дә, тәхетсез дә килеш
Без адашып калган заманда.

Утызга да җитә алмаган бер
Үсмердән гел дога көтәбез.
Җирне дер селкеткән зур халыкның
Үги улы түгел микән без?

Гомере—күз ачып йому гына...
Һич калкансыз канатлы мәләк!
Мондыйларны үлем аламыни?
Тукай үлми... Тукай—гел һәлак!

Инде ниләр кыйратабыз хәзер
Тәмам күккә чөеп мактарлык?
Тукай үзе җанын асраса да
Борчымады сәер татарны.

Син нишләрсең, татар, үз-үзеңне
Җуеп барган сәер хәлләрдә:
—Асрамага халык бирәм!—диеп
Тукай рухы иңсә әгәр дә?!

Язмыш микән, әллә каргыш микән
Безнең бу татарга үч итә?—
Тукайны, бәй, нишләп үлем көтсен?—
Андыйларны һәлакәт көтә!

...Кот алынып, өнсез калмабызмы
Үзебезне беркөн танып без?
Тукай булып Тукайны да хәтта
Һәлак иткән сәер халык без...

## Болгавырда

Кавемнәр шаша акылдан.
Ил оттырыла кәрткә.
Куела халык торгига.
Милләтләр китә мәрткә.

Явызлар, эттәй талашып,
Бу илне бүлешкәндә,
«Алтынчы палата»да без,
Илебез—тилеханә.

Нинди каргышлы язмыш бу?
Адаштык болгавырда...
Калдык без шул болгавырда
Туктаусыз болганырга!

Горурланыр ил булмаса
Горурлык каян килер?—
Шәхесле була чын халык,
Шәхесле булмый өер.

Тойган Чехов—
булган хәлен
Һәм булачак хәлләрен
Гел «алтынчы палата»лы
Шыксыз тилеханәнең.

Бу мескен йортка һаман да
Сәер затлар баш булды—
Йәки ахмак, йәки тинтәк,
Йәисә палач булды.

Уянгалый кайчагында
Кот кунмас шушы йорт та!
Уяна талант һәм вөҗдан—
Җан тарта яктылыкка!

Талант сиземләнгән төшне
Албасты гел ялмады...
Әмма... күпме тончыктырып,
Тончыктыра алмады!

Димәк, бар икән бит өмет!—
Көн килер, ил савыгыр,
Тончыкмыйча исән калган
Җан нурыбыз кабыныр!

...Әгәр чын халык икәнбез
Тарихта, дөньялыкта,
Өндәү йәки сорау калыр,—
Калмас бездән күпнокта...

## Такта күпер

Яңарып кайта хәтерләр
Хәтерләр арасыннан—
Ыкның күптән агып киткән
Такта күпере сыман...

Нәкъ шул такта күпер сыман
Булмадымы бу гомер?
Тукталыр, бәлки, бу күпер,
Борылмада сөрлегер?

Ташый, ташына бу ташу.
Дер килә такта күпер...
Ныктыр күпер субайлары?
Ташкынның көче күптер?
Гел ташкын җирдә никтер...

Без дә юкка чыгарбыз бит,
Югалырбыз бит инде.
Таралган Ык күперенең
Такталары шикелле?

Күпер аккан... Юл өзелгән...
Калган яның томаны.
...Ташу алган Ык күпере
Нидер әйтмәк буламы?

Бу дөньядан аласыгыз,
Бирәсегез дә күптер...
Әмма...
Су ташый! Тарала...
Тарала такта күпер!

*2002*

❂

## Марат Әмирханов

# ТОЯК ЭЗЕ

РОМАН

* * *

Казанга кайткач, Кәшшаф Заһидәне эзләп тапты. Тәкъдиме дә бар иде.

—Конференция алдыннан гыйльми хезмәткәрләргә бер атна ял бирәләр, әйдә, курортка сызабыз,—диде.

—Эштән җибәрерләрме икән соң?—диде Заһидә икеләнебрәк.

—Ә кем сиңа эштән качарга куша? Табиб чакырт. Кешенең эче китми торамы әллә?

—Син бигрәк инде.

Әмма иң дөрес юлы шушы иде. Таныш табиб аша Заһидәгә бер атнага белешмә юнәлттеләр дә "Ак каен" ял йортына элдерттеләр.

Ял йорты шундый урын инде ул, туйда тукмак та бии дигәндәй, анда килүгә яше-карты парлашып бетә. Берән-сәрән чын ирле-хатынлылар да очраштыргалый, билгеле. Тик алар төркемдәге ак карга кебек күзгә бәрелеп торалар. Ире алдан атлар, хатыны арттан теркелдәр... Ә яңа "кавышканнар" җитәкләшеп йөрер.

Кәшшафлар кирәк кешесенә бераз акча төртеп, бер бүлмәгә урнаштылар. Чын мәгънәсендә татлы айлары башланды. Чулман буена төшәләр, урманда хозурланалар. Көннәр искиткеч матур иде.

Әбиләр чуагы шушылай да гүзәл буладыр дип белми иде Кәшшаф. Күрәсең, моңа кадәр игътибар ителмәгән. Сентябрьнең бизмәне әле җәй ягында. Кояш нурлары әни кулы сыман йомшак, шифалы. Тик суга инде барыбер бер кашык суык кергән.

Күк йөзе чишмә суы шикелле саф, пакь. Ул өрфиядәй җимешле зәңгәр шәлен бөркәнгән. Ә үзенең очы да, кырые да күренми.

Шул очсыз-кырыйсыз серле күкне иңләп пәрәвез ташкыны агыла. Күккә челтәр элгәннәр диярсең. Үзе бер могҗиза, үзе бер тамаша.

Пароход белән килгәндә "Ак каен" ничектер искәрмәстән пәйда

---

Дәвамы. Башы 1 санда.

була. Бу урында Чулман буйлап жеп шикелле сузылган тау тезмәсе кисәк кенә өзелә дә кәсле ярга әверелә. Яр катлам-катлам, әйтерсең лә, аны өстенә төрле төстәге буяулар ягып өйгәннәр. Аскы өлешендә—акбур. Аннан соры таш катламы, каткан ком, кызыл балчык... Янә таш, янә ком. Иң өстә бүлем. Монысы—кара балчык. Күр, Жирнең эволюцион үсеше нинди чорлар кичергән. Аралары гасырга гына да сыймыйдыр боларның.

Кәшшафның күзләре шушы катламнарда тоткарланса, Заһидәнең игътибары баскычка төшкән икән. "Карәле, нинди әкияти корылма",—дип Кәшшафның жиңнәреннән тарткалады.

Баскыч, чыннан да, матур иде. Ул төрле рәвешләргә кереп, ишелгән бау шикелле өстән аска кадәр сузылган. Урыны-урыны белән ял итеп алу өчен утыргычлар да көйләгәннәр. Пароходтан төшкән пассажирлар, ял итүчеләр баскыч буйлап югары күтәреләләр дә, кайсы кая таралышалар.

Заһидәгә баскыч бик охшады. Ул аннан көнгә өч-дүрт мәртәбә менеп төшә иде. Суга гына күнегә алмады. Кыр ягында үскәнгәдер инде. Каз тәпиен дә күмә алмастай нәни генә инешне исәпкә алмаганда, аларның авылында елга да, күл дә юк. Шуңа күрә йөзә дә белми. Кәшшаф аны көймәгә утырта алмый газапланды. Якын да килми, мин су читеннән генә карап торам, ди. Бик ныклап юмаларга туры килде. Анда да Кәшшафка чытырман кебек ябышты, ишкәк ишәргә дә ирек бирмәде. Ә үзе көн дә бөтен кешене шаккаттырып, тәненә чиләк белән кое суы бөрки иде.

Кәшшаф үзе кая гына бармасын, вакыты ничек кенә тар булмасын, якын-тирәдәге зиратларны карап кайтмый тынычланмый. Аны кабер ташлары кызыксындыра. Борынгы язма тарих шуларга уелган. Ул монда да бер көнен әлегә шөгыльнә багышларга ниятләде. Кызганыч, юлы уңмады. Бу якта зиратлар ташландык хәлдә икән, мал-туар таптап-изеп бетергән. Шуңа да кәефе төшеп кайтты. Кичке ашка кадәр бераз хәл алыйм дип уйлаган иде дә, клуб янындагы кешеләр төркемен күргәч, шул якка борыласы итте. Чөнки Заһидәне күреп алган иде. Кулларын буташтыра-буташтыра клуб мөдиренә нидер аңлата.

—Безнең барлык чараларыбыз да директор раслаган план буенча үткәрелә. Ә сез беркемнән сорамыйча, беркемгә әйтмичә үз белдегегез белән ял итүчеләрне жыеп, нинди лекция оештырып ятасыз,—дип чәр-чәр килә тегесе.

—Гафу итегез, мин кызыксынучыларның сорауларына гына жавап бирәм,—мин...

—Әгәр андый хокукыгыз бар икән, клубны арендага алыгыз. Ял йорты территориясендә рөхсәтсез массовый чаралар үткәрү тыела.

Инде жыелышкан кешеләр шаулаша башлады.

—Сөйләсен, тыярга хакыгыз юк.

—Безнең дә Иванов тәгълиматы турында беләсебез килә.

—Жүләр сатмагыз, чукындырырга тели ул безне.

—Тьфү, кяфер икән, имансыз.

—Теләсә-нинди сырхауны юып төшерә ди бит ул, жәмәгать.

—Ханымнар, сез ял итәргә килгәнсез, рәхәтләнеп ял итегез,—диде клуб мөдире,—моның өчен без бөтен шартларны да тудырырга тырышабыз. Аферистлар кулына эләгә күрмәгез.

—Минме аферист?—дип очып кунды Заһидә. Әмма тулы гәүдәле бу кырыс ханым курка торганнардан түгел иде. Үзенең хаклы икәнен дә бик яхшы белә иде, әлбәттә.

—Милиция чакыртканны көтәсезме?—дип Заһидәгә чекрәйде,—аңлатырлар анда кем икәнлегегезне. Сез ял итәргә килгәнсез, безнең эшкә кысылмагыз!

Заһидә дә тәмам кызган, бер сүзне дә жавапсыз калдырмый.

—Бу сүзләрне сезнең наданлыгыгыз әйттерә, томана сез.

—Соңгы кабат кисәтәм.

Кәшшаф эшнең тирәнгә керүен күреп, халыкны ера-ера эчкә узды да Заһидәне култыгыннан алды.

—Нишләвең бу, шулай ярамый бит инде.

Заһидә исә һаман үзенекен тукый. Күзләре зәһәрләнгән, иреннәре калтырый. Бүлмәгә кайткач та тынычлана алмады.

—Ит яхшылык, көт яманлык, ди. Күр инде, изеп ташлады бит, надан, ә?—дип бүлмә буйлап йөренде.

—Тынычлан, Заһидә, гаеп үзендә,—диде Кәшшаф.

—Син дә шул бүкәнне яклыйсыңмыни әле... ярдәм итәр урында... наданнар сез... Җиргә куркыныч яный, ә сез кул кушырып утырасыз.

—Нишләргә соң, өйрәт алайса.

—Белмәмешкә салынма, җәме. Янача яши башларга вакыт дип күпме тукыдым мин сиңа, колагыңа да элмәдең. Җитмәсә, мыскыл иткән була, өйрәт, имеш.

Заһидә мендәргә капланып елый башлады. Кәшшаф ни әйтергә, ни эшләргә белмичә аптырап торды. Күр, нинди көчле икән Ивановнын иярченнәре, өч-дүрт ай эчендә Заһидәне йөз сиксән градуска борганнар да куйганнар.

—Җимешем, алай ярамый бит инде, тынычлан инде,—дип Кәшшаф сөйгәненең чәчләреннән сыйпамакчы итте. Ләкин хатын сыртын гына кабартты. Үтә бер зәһәрлек белән:

—Зинһар өчен, әрми генә тор әле,—диде.

Кәшшаф кайтарып сүз әйтмәде, шыпан-шыпан гына киенде дә бүлмәдән чыгып китте. Ашханәдән соң да шактый озак йөрде. Бер-ике мәртәбә әлеге озын баскычтан төшеп менде, озаклап су коенды. Заһидәнең тынычланганын көтте. Бәлкем әле йоклап та киткәндер, иртәгә бу зилзилә үтәр, аңлашырлар.

Заһидә йокламаган иде. Кулында китап, караватка бөкшәеп утырган. Күз яшьләре кипкәнгә охшый. Әмма төс-кыяфәте әле һаман таш кебек каткан. Кәшшаф ана комачауламаска булды, урын-җирен рәтләп ятарга җыенды.

—Нәрсә, телең урамда калды мәллә?—диде Заһидә китаптан күзен алмыйча гына.

—Үзен тынычлыкта калдырырга кушасың бит.

Кәшшаф каш астыннан гына Заһидәгә күз төшереп алды. Бәлкем, татулашыргадыр исәбе? Бәлкем, яратышу өчен генә үпкәләгән булып кылангандыр? Хатын-кыз хәйләкәр бит ул.

—Туңып беткәнсең ич, җимешем,—дип Кәшшаф Заһидәне кочып алды.

—Хатынын кайнардыр, аны кочарсың.

Кәшшафның колаклары үрә торды. Чөнки моңа кадәр Заһидәнең бу хакта бер мәртәбә дә сүз кузгатканы булмады.

—Мин сине яратам,—диде Кәшшаф,—беләсең ич инде.

Заһидә усал гына итеп көлемсерәп алды да әйтте:

—Бер башыңа икәү булса, рәхәте күп, тынычы юк диләр. Менә шул вакытлар да килеп житте.

—Син бүген әллә нинди, Заһидә, үзенә охшамагансың.

—Ә нигә, дөрес түгелмени? Сөяркәне макта, хатын белән тор. Мин шундый мәкальне дә беләм әле.

Кәшшафның авызы йомылды. Ул капкынга эләккән тычкан кебек иде, кайсы якка сугылсаң да рәшәткәгә килеп бәреләсең. Кылын гына тартып каравы булган, күрәсең, капкынның ишеген Заһидә үзе ачты.

—Ярату гына аз, Кәшшаф, без фикердәшләр дә булырга тиеш. Мәхәббәт бер күнлек ул, дөрт итеп кабына да, шунда ук сүнә дә. Ә дуслык—мәңгелек.

—Мин болай да синең сулышың белән яшим.

—Мин алай димәс идем. Менә бүгенге хәлне генә алыйк: син мине якламадың. Әйтимме ни өчен?

—Әйт.

Заһидә иреннәрен бүлтәйтеп Кәшшафны сынап карап торды. Кәшшафка аның шушы халәте бик охшый иде, үбәргә үрелде.

—Туктале,—дип Заһидә башын борды,—житди сүз сөйләшәбез ләбаса!

—Яратасым килә бит, нишлим соң?

—Сез, ирләргә, шул гына булсын.

—Ярый-ярый, тыңлыйм, сүзенне сөйлә.

Инде Заһидә кәжәләнде.

—И лә, син аны барыбер аңламаячаксың, дөресрәге, аңларга теләмәячәксең. Мин арыдым инде, ятам. Син дә ят.

Кәшшаф ятагына барып ауды. Ә иртән уянганда Заһидәнең урыны буш иде инде. Йөрәге жу итеп китте, сикереп торганын сизми дә калды. Коенырга чыккандыр, дип үзен тынычландырырга ашыкты. Ләкин су чиләге урынында иде. Өстәл өстендәге язуны күргәч кенә урындыкка сыенды.

*"Кәшшаф! Минем сиңа булган хисләрем үзгәрмәде. Хатының барын да, балаң барын да баштан ук белә идем. Алар миңа киртә булмады. Мөгаен, киләчәктә дә комачауламаслар иде. Бернәрсәгә дә үкенмим. Сиңа рәхмәт кенә. Әмма мин инде элекке кебек суга төшкән чеби түгел. Шөкер, канатларым нығыды, рухым чистарды. Минем хәзер сәяркә булып кына яшисем килми. Һәм инде яши дә алмыйм. Иванов тәгълиматы бар нәрсәгә: тирә-юнь мохиткә дә, кешеләргә дә, тормышка да бөтенләй яңача карарга өйрәтте. Ләкин син минем кыйблама ышанмыйсың. Үзең дә беләсең, мин сине әлеге хак юлга керту өчен бик нык тырышып карадым. Ә син: "Әкият бу",—дип көлдең генә. Бүгенге вакыйга аны тулысынча раслады. Мин алга таба да кешеләргә Остаз тәгълиматын тарату буенча бернәрсәгә карамыйча эшләячәкмен. Ишектән кусалар, тәрәзәдән керермен, тәрәзәдән кусалар, ишектән керермен. Көчем дә, теләгем дә зур. Мин хәзер генә яшәүнең чын мәгънәсенә төшендем.*

*Дорфалыгым өчен гафу ит. Мине бимазалама. Хуш. Мин Казанга кайтып киттем.*

*Заһидә.*

*4 октябрь, 1997 ел".*

Кәшшаф язуны ике-өч мәртәбә укып чыкты. Аптырады. Иванов тәгълиматының аларга нинди катнашы бар соң? Ул Заһидәнең салкын су белән коенуына да, кар өстендә ялан аяк йөрүенә дә, Гимн жырлавына да, мохтажларга ярдәм кулын сузуына да каршы түгел ич. Кешеләргә яхшылык эшләү бик саваплы гамәл. Юк, хикмәт кичәге мәрәкәдә генә түгелгә охшый монда. Нигезендә житдирәк сәбәп ятадыр, мөгаен. Әллә бер-бер көндәше пәйда булдымы? Алай дисән, нигә аны яшерергә? Минем хисләрем үзгәрмәде дигән ич язуында. Димәк, ул хисләрдән дә өстен башка сәбәп бар.

Кәшшафның йөрәге сулкылдап алды. Аның һич тә Заһидәне югалтасы килми иде. Качып китәргә ярыймыни инде. Шунда ул менләр астыннан бер кырые күренеп торган китапны абайлап алды. Заһидә кичә кич шул китапны укып утыра иде түгелме? Онытып калдырган, күрәсең. Кулына алды. Бу—Библия иде. Юкәдә икән бит чикләвек! Кәшшаф Ивановның мәкаләләре белән танышып чыккач ук Заһидәне шул хакта кисәткән иде. Бу христиан динен таратуның бик тә мәкерле, бик тә хәйләкәр һәм астыртын ысулы түгелме икән, дигән шиген белдергән иде. Тәки хак булып чыкты бит, ә! Заһидә кулы-аягы белән каршы төште. Имеш, системаның дингә бер катнашы да юк, ул фәкать кешенең физик сәламәтлеген ныгыту, рухын савыктыруны гына максат итеп куя. Иванов дәдәң миссионер булып чыга бит әле монда. Кешегә аның ин нәзберек нәрсәсе, сәламәтлеге аша йогынты ясый. Саулыкка туймаган бәндә, әлбәттә, барысына да әзер. Башта Порфирий Корнеевичның теләсә-нинди рәвешкә керә алуына, аннан соң вакыт һәм киңлек төшенчәсенең бөтенләй булмавына, теләсә галәмдә, теләсә жирдә йөрүенә ышандыралар. Аннан соң Библия тоттыралар...

Татар белән рус арасындагы каршылык ул нигездә ислам дине белән христиан диненең каршылыгына кайтып кала. Заһидә дә менә шушы кармакка килеп эләккән икән.

* * *

Институт бинасын танырлык түгел иде. Менә мин нинди гүзәл дип көлеп тора. Стеналарны да, түшәмне дә пластик белән тышлаганнар, өр-яңа яктырткычлар элгәннәр. Бина эче зураеп, иркенәеп киткәндәй булган. Идәннәр дә баскан саен шыгыр-шыгыр килми, яңа паркет җәйгәннәр. Утырышлар залын, директор апартаментларын аеруча тырышып бизәгәннәр, атлап керергә кыймассың. Галимов тотынса, булдыра инде ул. Кешеләр арка кыздырып йөргән арада, әнә, нинди эшләр майтарып ташлаган. Галим булып ялгышкан, хуҗалык-оештыру эшләрендә күбрәк файда китерә алыр иде.

Кәшшаф кабул итү бүлмәсенең ишеген ачу белән, ирексездән аяк киеменә, костюмына күз йөртеп чыкты. Бу зиннәтле келәмнәргә, түшәмнән идәнгә кадәр сузылган ак пәрдәләргә тузан кунмасмы? Секретарь кызның: "Узыгыз, уз",—дигән тавышын ишеткәч кенә тәвәккәлләп бусагадан үтеп керде.

—Сәүбән Сәүбәнович Кремльгә чакырулы, биш минуттан артык тоткарланмагыз,—дип кисәтте аны секретарь көзге алдында күпереп торган саргылт чәчләрен сыпыргалый-сыпыргалый.

Кайчан керсәң дә көзге каршында бөтерелер бу чибәр туташ. Үз-үзенә карап сокланумы, ир-атка ярарга тырышуымы, әллә икесе дә берьюлымы? Галимов аларны еш алмаштыра, әмма һәр килгәне элеккесеннән дә матуррак була. Ничек табып өлгерә. Ул үзе дә бик ыспай, энәдән-җептән генә киенә. Инде көз тәрәзә кагуга карамастан, әнә, аксыл костюмнан. Кулмәген дә, галстугын да шуңа тәнгәл китереп сайлаган. Ул шушы чиста-пакьлеге белән купшы диңгез капитанын хәтерләтә иде.

—Алсу туташ кисәткәндер дип уйлыйм,—диде Галимов йөзен чытып, вакытым тар, үгезнең мөгезеннән тотып сөйләшик. Бу аның, йөрдең инде сукыр чебен сыман, дигәнен анлатуы иде булса кирәк. Кәшшаф үзенен сөйкемсез сөяк икәнен бик яхшы белә, әмма директор шикелле киная белән аңлашырга күнмәгән.

—Мөгезе шул, Сәүбән Сәүбәнович,—диде ул,—мин конференциядә докладымның тезисларын таратачакмын, алар инде әзер, соңыннан белмәдем дип әйтмәгез.

Галимов сирәк төкле кашларын җыерып, Кәшшафка текәлеп карап торды да, сифоннан чыжылдатып касәгә су агызды, аны ашыкмыйча гына, йотымлап кына эчте. Аннан соң сүзләрен теш арасыннан гына сыгып әйтте:

—Бу—хулиганлык, Хәмитов. Фикер алышуда катнашырсыз, әнә. Сезне кем тыя?

Кәшшафның ирен читләре метер-метер килеп алды.

—Болай бозылышып, ачуланышып сез бервакытта да максатыгызга ирешә алмаячаксыз,—дип дәвам итте Галимов,—фән, беренче нәүбәттә, дәлиллек дигән сүз ул. Сездә алар чамалы. Фаразлау белән, әнә, күрәзәчеләр шөгыльләнсен.

—Шул фаразларны дәлилләргә мөмкинлек бирегез сез миңа. Фән ул хакыйкать дигәнне дә аңлата. Ә хакыйкать бәхәстә туа. Бу Аристотель заманыннан килгән.

Алар аңлашып бетерә алмадылар, ишектән тыны-көне бетеп секретарь кыз килеп керде.

—Хәмитов, мин сезне кисәттем ич, директор чакырулы дидем... Сәүбән Сәүбәнович, сез үзегез дә инде, шулай йомшак булырга ярамый ич...

Директор жилкәләрен сикертеп куйды, янәсе, нишләсен соң ул шушындый киребеткән кешеләр белән.

Кәшшафка барыбер иде. Шуна күрә күнеленләгән түгеп калырга ашыкты.

—Ул фикер алышу дигәнегез дә минуты-секунды белән тәгаенләп куелган бит инде, нигә шулай икейөзләнергә?

—Хәмитов!

Секретарь кыз Кәшшафны эткәли-төрткәли кабинеттан чыгарып җибәрде.

Коридорның аргы башында Тәфкилев белән Әлтаф сөйләшеп тора иде. Шыр-шыр көлешәләр. Әлтаф чираттагы өр-яна мәзәген сөйли ахры. Каян табып бетерә? Ләкин Кәшшафны гаҗәпләндергәне бүтән иде. Әлтаф аның шикелле үк Тәфкилевне өнәми. Үзара сөйләшкәндә, үлән арасыннан ут йөртә торган кеше, дип әйтә. Ә хәзер, күр, ничек сайрашалар. Кыенсынып та китте. Бәлкем, шулай тоелгандыр гына. Кәефсез чагы ич.

Тәфкилев аның белән дә бик дустанә күреште. Тик, һәрвакыттагыча, сүзләрендә, үз-үзен тотышында яклану, масаю ярылып ята иде.

—О-о, кемне күрәм? Милли тарихыбызның киләчәк даһие!—дип Кәшшафны кочып алмакчы булды.

—Төрттерми генә булмыймыни соң ул?

Тәфкилевнең күзләре төймәдәй түгәрәкләнде.

—Безнеке шуннан узмый, Кәшшаф әфәнде, кая инде сезгә житү?

—Ә мин нишләгән?

—Чын ир-егет икәнсең дим, замана кешесе шундый булырга тиеш дим.

—Мин уратып сөйләгәнне анламыйм.

Тәфкилевнең күзләре янә түгәрәкләнде.

—Турысын да ярып сөйләшә алабыз, Кәшшаф әфәнде,—диде ул рәсми мөгаләмәгә күчеп,—әйдәгез, кабинетка рәхим итегез, анда тынычрак булыр.

Тәфкилев тимер шкафын дыңгырдатып ачты да, аннан бер папка тартып чыгарды.

—Мондый конфеденциальный документларны сейфта сакламасаң, төп башына утырып калуың бар,—дип Кәшшафка күз кысты. Әйтерсең лә, алар арасында ниндидер яшерен сер бар иде. Бу Кәшшафка да кызык тоелды. Түземсезлек белән папкадан нинди документ чыгар икән дип көтә башлады.

Бүлмә хуҗасы, ниһаять, бер кәгазьне алып, күзләренә якын китерде, укый башлады: "Киров районы эчке эшләр идарәсе"

Бу сүзләрне ишеткәч, Кәшшафның йөрәге чеметеп алды: әллә Аккош күлендә булган мәрәкәне институтка житкергәннәрме? Алай дисәң, заманалар үзгәрде ләбаса, демократик дәүләттә яшибез. Кешенең шәхси тормышы фәкать аның үзенә генә кагыла.

"...гуманитар институт хезмәткәрләре Хәмитов Кәшшаф Газизович һәм Бәширова Заһидә Идрисовна Аккош күлендә су коенганда,—дип дәвам итте укуын Тәфкилев,—машиналагы киемнәрен, документларын урлаталар..."

—Бу кәгазь ничек итеп сезнең кулга килеп эләкте соң әле,—дип бүлдерде аны Кәшшаф.—Ул берничек тә минем хезмәт вазифаларыма кагылмый ләбаса.

—Кайсы яктан карыйсың бит, Кәшшаф Газизович, институт үзенең хезмәткәрләре турында бөтен яктан да хәбәрдар булырга тиеш. Институт кына түгел, һәр дәүләт учреждениесе. Ә бу рәсми кәгазьне институтка җибәреп бик дөрес эшләгәннәр дип уйлыйм. Демократия йөгәнсез тай түгел ул, һәр җирдә тәртип зарур.

—Компромат дисез инде алайса.

—Компромат түгел, Хәмитов, мәгълүмат. Үзең беләсең, дөнья белән хәзер мәгълүмат идарә итә.

—Анлашылды, мәгълүматыгыз өчен зур рәхмәт. Инде китәргә ярыйдыр бит?

Тәфкилев озын нәфис бармакларын өстәлгә җәеп салды да мыскыллы бер елмаю белән Кәшшафка карап торды. Аннан соң:

—Синең тәти күбәләкләр мәсьәләсендә тәҗрибәң зур булырга охшый, җае килгәндә дусларына да өлеш чыгаргалар иденң,—дип көлде.

Кәшшаф бүлмәдән чыгып китте. Аның артыннан сейф ишегенең шакылдап ябылганы ишетелеп калды. Тәфкилев "документ"ны урынына яшерде, күрәсең.

Урынбасар әлеге язуны юри генә күрсәтмәде, әлбәттә. Күр инде, ә? Милиция дигәннәре һаман элеккечә баш очында Гали кылычы сыман асылынып тора икән ич. Барысын да теркәп бара, тиешле җиргә хәбәр итә. Баксаң, без әле һаман күзәтү астында икән. Тәфкилев ана шуны белдерде. Һәм бу факт кирәкле вакытта, кирәкле урында калкып чыгачак. Аларны узып бернәрсә дә майтара алмыйсың. Әле ярый Заһидә эштән китте, югыйсә, мәсхәрәгә кала иде.

Кәшшаф үз бүлмәсен читләтеп, Әлтаф янына өстерәлде. Аны башка бүлмәгә күчергәннәр иде. Дусты телефонга сыенган, кемгәдер мәзәк сөйли.

—Ха-ха-ха... Юк, белмәдем. Матур кыз кирәк аңа, төшенденме?

—Ярар, хуш, хәле яхшырды ди моның. Хәзер егетебез ни-нәрсәгә мохтаҗ инде? Җә-җә... и-и, иштең ишәк чумарын, дуска мохтаҗ, имеш. Яңа чибәркәй турында уйлый ул. Вәйт. Ха-ха-ха.

—Былбылдан ким сайрамыйсың, кәеф шәп синең бүген,—дип Кәшшаф почмактагы урындыкка чүмәште. Ул ватык урындык булган икән, мәтәлеп китә язды, тәрәзә янагына гына ябышып калды.

—Фу... әллә ни әйттерерсең, нигә тотасыз бу сәләмәне?

—Зиннәтле урындыкларга утырасың килсә, нәчәлникләр янына кер,—дип авызын ерды Әлтаф.

—Әле генә шуннан чыктым.

—Әлегештегез дәме? Һәм, шуны сорап торган мин җүләр. Эт белән мәченең кайчан ызгышмый торганы бар? Төкер син аларга. Монографияң өчен Алтын Урда чоры фольклорыннан менә дигән җырлар хәзерләп куйдым үзеңә. Тыңла әле:

Солдатларга бит юарга,
Хозяйский жиз комган;
Китмәс идем бу солдатка,
Батый ала, чукынган.

Имән агач—каты агач,
Каен агач—чыра агач;
Писер яза, без китәбез
Чыңгызханга ярагач.

Кәшшаф көлемсерәмичә булдыра алмады.

—Шомбай.

—Син, мөгаен, бер бик мөһим хәбәрне белмисеңдер әле,—диде Әлтаф күзләрен ялтыратып.

—Үземә кагылганын беләм, ник белмәскә?

—Мин конференция турында әйтәм.

—Нәрсә булган конференциягә?

—Конференция бер айга кичектерелә. Тәфкилев әйтте. Чит ил галимнәре үтенече белән, имеш.

* * *

Мондый гүзәл манзараны фәкать шушында гына, Хан тавы башыннан гына күзәтергә мөмкин. Кәшшафның купшылыгы белән дан тоткан Кырым бакчаларында да йөргәне бар. Искитмәле. Чын оҗмах! Ә

Кавказ? Сөңгедәй очлы түбәләре ак болытлар эченә кереп яшеренгән таулар иленен кырыс, шул ук вакытта пакь вә саф табигате берсеннән-берсе ашкынулырак хисләр уята.

Әлеге күренешне аларның берсе белән дә чагыштырып булмый. Ихтимал, ул кайсыдыр ягы белән Кырым—Кавказлардан калышадыр да, әмма бу—туган ил! Туган ил барысыннан да якынрак, барысыннан да гүзәлрәк.

Кәшшаф өченче көн инде нәкъ шушы вакытта, нәкъ шушы урынга килеп баса. Бүген дә сонармады. Тын. Чәч бөртеген селкетерлек тә жил исми. Кояш шәфәкъ челтәрен ал төскә манган. Ә үзе шундый ук ал төстәге түгәрәк гәүдәсе белән әкрен генә офык артына төшеп бара. Кечерәйгәннән кечерәя. Ул кечерәйгән саен, шәфәкъ киңәя, жителәнә.

Үз гомерендә мондый озын һәм кояшлы көзне хәтерләми Кәшшаф.

Кояш баеган чакта гына була торган энгер-менгер. Кайдадыр эт өрә, сыер мөгри. Ара-тирә болында утлап йөрүче атлар кешнәп куя. Күнелдә исә монсулык. Үтеп баручы көннен монсулыгы, гомернен башка бервакытта да кире кайтмаячак мизгелләре белән хушлашу монсулыгы.

Көннәр генә түгел, айлар, еллар, гасырлар бер-берсен алыштыра. Кояш аларның барысына да шаһит. Иртән тан белән ул жир йөзен балкытып, яна көнгә фатиха бирә. Монсулык чигенә, күнелдә анын урынын киләчәк көн мәшәкатьләре билəп ала.

Бирегә аны археолог Рамил Сәмигуллин чакыртып китерде. Ул монда казыну эшләре алып бара. Конференциянен кичектерелүе ярап куйды үзе.

Алтын Урда турында гасырлардан-гасырларга күчеп йөрүче галелсез уйдырмаларны аз гына булса да какшату өчен Кәшшаф әллә нинди корбаннарга да барырга риза булыр иде. Күпме шулай вәхши тамгасын тагып йөрергә мөмкин инде. Ата-бабаларыбызнын рухы алдында оят. Мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыккач, Алтын Урда үз чоры өчен гадәти тормыш белән яши. Алай гынамы, урта гасыр цивилизациясенә искиткеч зур өлеш кертә. Кайчандыр шайтан таяклары гына чайкалып утырган кыргый далаларда нинди матур шәһәрләр калкып чыга: Гөлстан, Сарай, Ак Сарай, Ак Мәчет, Балыклы, Актүбә, Шәһәр әл-Жәдид, Ак Кирмән.

Урта гасыр авторларынын карталарын һәм Алтын Урданын археологиясен өйрәнүчеләр бу дәүләттә чама белән йөз кырыктан артык шәһәр булган дигән фикердә торалар. Алтын Урданын географиясен һәм топонимиясен өйрәнү татар халкынын этник тарихын ачыклауда бик зур урын тота. Шуна күрә Кәшшаф бу юнәлештә дә тикшеренү эшләре алып бара. Әйтик, XIII—XIV гасырларда Кара дингез буендагы Днестр култыгынын уң як ярында Ак Кирмән порты урнашкан булган. Шушы ук чорда Кырымда, Кара дингез буенда Инкерман, Керменчуг кебек татар калалары үсеп чыккан. Әлеге атаманын Урта Идел буенда таралуы да мәгълүм. Кайберләре бүгенге көнгә кадәр шушы исемне йөртә.

Алтын Урданын мәдәни жәүһәрләре үзе бер могжиза. Кәшшафнын Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәре урынындагы эзләнүләрдә катнашканы булды. Анда культура катламы гажәеп бай. Мәсәлән, селдон дип аталучы мәшһүр кытай фарфоры жиргә көрәк тыккан саен диярлек килеп чыга.

Зәнгәр һәм фирүзә төсендәге ялтыравык йөгертелгән бизәкле керамика гомумән бик сирәк очрый. Монда ул бар. Кәшшафнын әле дә хәтерендә, як-ягына балык гәүдәле, аждаһа башлы әкияти ерткыч жанвар рәвешендә ике тотка беркетелгән алтыннан коелган бер касәгә мөкиббән булып, кулында әйләндергәләп тора иде, анын янына Федоров атлы археолог килеп туктады.

—Шәп бит, ә?—дип Кәшшафнын жилкәсенә кулын салды ул.

—Искиткеч! Карыйм да йөрәгем сыкрый, безнен буын нәрсә калдыра сон?

—Калдырабыз, ник калдырмаска? Инкубатор чебешләре сыман бер-

берсенә охшаш шәһәрләр, бернинди сәнгати кыйммәте булмаган ширпотреб савыт-саба, Калашников автоматлары.

—Үзбәк ханның алтын саплы хәнҗәре аларның бөтенесен алыштырыр иде.

—Үзбәк хан дигәннән, хак булса, аның тәхете Британия музеенда саклана, имеш.

—Инглизләрнең кулы озын, ә без булганыннан да файдалана белмибез...

—Нәрсәне файдалана белмибез?—дип кистереп сорады Федоров.

Кәшшафның бик тирәнгә кереп сөйләшәсе килми иде. Чөнки аны борчыган мәсьәлә рус галимнәрен кызыксындырмый. Дөресрәге, аның аларга хаҗәте юк.

—Алтын Урданың матди культура калдыкларын сез, Владимир Степанович, предмет, объект буларак кына өйрәнәсез.

—Ә аны тагын ничек өйрәнергә соң?

—Мин үзем, мисал өчен, хәзерге татар халкының этник тарихына бәйләп өйрәнүне мәгъкуль күрәм.

—Сезне аңламассың, берегез уңга тарта, берегез—сулга.

...Кояш, ниһаять, бәллүенә кереп чумды. Җиргә эңгер-меңгер пәрдәсе инде. Бу Кәшшафның ин яраткан вакыты. Нәкъ менә шушы вакытта аның хыял канатлары үсеп чыга. Ул тәэссоратлы кеше. Бу сыйфаты ана тарихи вакыйгаларны җанлы итеп күзалларга булыша. Ниндидер фәнни гипотезага алынганчы ул иң элек аның эчтәлеген "сәхнәләштерә", бер жепкә тезә. Менә әле хәзер дә күңеле белән 1255 нче елга чигенде.

...Кырлач. Җиргә төшкәнче төкерек туна. Җил дала буйлап кипкән кылганнарны куып йөри. Коры салкын тәннәрне бөрештерә, үтәли үтеп керә. Хан йортында көне-төне учак яна. Ишек саен пар сакчы. Сөнгеләренә таянып, тораташ булып катканнар. Керфекләре дә селкенми.

Сартак ханның вафаты таудан ишелеп төшкән кар кебек көтелмәгәндә булды шул. Ике генә ел патшалык итеп калды мәрхүм. Инде менә яңа патша. Бәрәкәт әле үзенең хәленә күнегеп җитә алмый. Чөнки тәхеткә аның абыйсы Туданны әзерләгәннәр иде. Ана башка булса да бер атадан ич, якыннар. Кан анадан түгел, атадан килә.

Сарай әһелләре нигәдер тәхеткә Бәрәкәтне утырттылар. Исеме Бәркәгә әйләнде.

—Баһадур Батман улы Сәхи,—дип оран салды баш сакчы. Шул ук мизгелдә ишектә Баһадурның карсак гәүдәсе пәйда булды.

—И, бөек хан, даның күкләргә ашсын! Сиңа хезмәт итү минем өчен ин зур бәхет!

Ирен очларыннан шушы ятланган сүзләрне очырды да Баһадур башын яраны ягына борды. Тегесе шундук кулындагы күн капчыгын ханның аяк астына ыргытты.

—Бу нәрсә?—дип сорады Бәркә.

Баһадур җавап биргәнче иң элек сирәк тешләрен ыржайтып кычкырып көлде, билендәге кылычы дер-дер килеп торды.

—И, бөек хан! Болар синең иң зур дошманыңның колаклары. Иран юлыннан тотып алдык. Улы Туданны тәхеткә утыртмаганга үч итеп, Иран патшасы Хулагуны кодаларга ниятләгән. Ат койрыгына тагып аунаткач түзмәде, гаебен таныды.

Бәркә тетрәнеп китте. Әмма йөзенә чыгармады. Хан каты бәгырьле була. Ул дошманын кызгана алмый.

—Сиңа, Сәхи баһадур, хезмәтең өчен алтын саплы кылыч, яраныңа хан утарыннан ат бүләк итәм,—диде Бәркә.—Ә капчык монда калсын.

Бәркә соңыннан качырып кына әтисе хатынының колакларын җиргә күмдерде...

Кәшшаф Урда ханнары арасыннан, Батудан соң, нигәдер Бәркә ханны якын итә. Саф күңелле, самими һәм гадел итеп күз алдына китерә ул аны. Урта бармак шикелле төз гәүдәле, чибәр йөзле, биек

мангайлы, көч-гайрәте ташып тора торган ир-егет! Бу сыйфатлар, мөгаен, татар канының дәвамыдыр. Чыңгыз ханның җәмәгате татар затыннан булган ләбаса.

Ходай нәкъ менә Бәркә ханга үз дәүләтендә Ислам динен тарату вазифасын фарыз кылган. Югыйсә, әтисе Бату хан мәҗүси булган, абыйсы Сартак—христиан. Ә ул исламны сайлады.

Хамат хакиме әл-Мүвәйед үзенең елъязмасында болай дип яза: “Бәркә Шәмсетдин әл-Бахырзи ярдәмендә Ислам динен кабул итте һәм мөселман булып киткәч, әл-Бахырзига ышанычнамә юнәлтте—патшалык җирләрендә комачаусыз үз максатларын тормышка ашыру мөмкинлеген бирде. Ләкин әл-Бахырзи монардан баш тартты. Бәркә күрешергә дип әл-Бахырзи янына китте. Шәех Бәркә ханга Ислам динен ачыктан-ачык таратырга кушты. Бәркә Ислам динен киң таратты, бар җирләрендә мәчетләр һәм мәдрәсәләр төзеде, галимнәрне һәм хокук белгечләрен үз күрә башлады, алар белән дуслашып китте...”

Кәшшаф кайтканда барысы да йоклый иде инде. Аларның берсе дә, шул исәптән Кәшшаф та, иртәгә нинди зур куаныч, нинди аяныч бәхетсезлек көткәнен белми иде.

Археологик казыну эшләренең үз кануннары бар. Иң беренче таләп—игътибарлылык! Чөнки һәр учма балчыкны иләк аша үткәрергә кирәк. Урын сайлау да бик мөһим. Татарстан бу яктан, шөкер, ким-хур түгел. Тарих һәр ташында диярлек үзенең эзен төшереп калдырган. Иренмичә өйрән, тикшерен генә. Шул ук вакытта бу җиде кат җилегеңне суыра торган бик авыр хезмәт тә. Киноларда гына ул археологларны, геологларны романтиканың ал төсенә манып сурәтлиләр.

Әлбәттә, алым саен уныш килми. Кайчак җәйләр буе чокынып та буш кул белән кайтасың. Әмма бер сөенеч бу борчу-йончуларны юа да төшерә. Рамил Сәмигуллин төркеме исәбендә дә фәнгә зур өлеш керткән ачышлар байтак. Шулар арасында аеруча танылу китергәне Болгар миче булгандыр, мөгаен. Бу табышны ата-бабаларыбызның намусын, йөзен аклау дисән дә хата булмас. Югыйсә, Русиянең гыйльми даирәләрендә болгарларны кимсетү, аларны ярымкыргый халык итеп күрсәтергә тырышу тенденциясе яшәп килә иде. Болгар җирендә табылган зиннәтле савыт-сабалар, керамик әйберләр Урта Азиядән китерелгән, имеш, җирле халык томана, надан булган, имеш.

Тора-бара башка җирләрдә дә савыт-саба ясауга бәйле шундый ук мичләр табылды.

Бу урында әлегә әллә нәрсә майтарганнары юк. Кәшшафның килүендә дә фәтва булмады. Алай да бераз юанып китим инде, диде. Ачык һавада физик эш белән шөгыльләнү үзе бер ял ич. Рамилләр дә көннәр бозылганчы гына дип торалар, сезон тәгалләнә.

Урыны җайлы үзе. Авыл янындагы тауның сөзәгрәк урынын сайлаганнар. Тау югарыга таба ялангачлана бара, корыган үлән арасыннан пеләш баш кебек таш кисәкләре генә ялтырап күренеп тора. Авыл көтүе шушыннан уза. Тауны сукмаклары белән кыршаулап бетергәннәр. Кәҗәләр китмиләр дә, көннәр буе шунда эзләнәләр.

Рамил мангаен җиңе белән сыйпап алды да күрәгән җиргә калады. Күрәкнең сабы гына диярлек утырып калды. Ходай аңа көчне кызганмаган, мул биргән. Тыгыз тәнле, нык бәдәнле кеше. Җәйгә чыккач кырдан кайтып керми, ә кышкы озын төннәрне китапханәдә үткәрә. Төпле фикерле, киң карашлы галим. Татар тарихына Болгар тәрәзәсе аша гына карамый. Кәшшаф белән дә шул җирлектә дуслашып киттеләр.

—Хатынымның чәчүргечена тагу өчен генә булса да бер борынгы тәңкә табып бирермен дигән идем, киләсе елга кичектерелә инде,—диде ул егетләренә күз кысып.

—Без аның ялчысыма әллә, үзе эзләп тапсын,—дип көлеште тегеләре.

—Күч, Кәшшаф абый, археологиягә, төкер меңъеллык китап тузаннарына,—диде Салих исемлесе.

—Мин риза,—диде Кәшшаф,—тик бер шартым бар: казып тапкан хәзинәнең өчтән бер өлешен үземә бирәсез.

—Вакланма, тулы килеш ал,—диде Рамил.—Безнең барыбер куяр урын калмады инде, алтын-көмеш эчендә ауныйбыз.

—Булды, мине археолог дип исәпләгез,—диде Кәшшаф,—бисмилла әйтеп тотынийк алайса, мин карун кеше, мина күп кирәк

Бертын сүзсез генә эшләделәр. Һәркем үз шөгыле белән мәшгуль. Кәшшаф белән Харис казый. Рамил белән Салих алар кубарган катламнарны тикшереп, балчыгын читкә өя баралар. Барысы да китап кушкан тәртип буенча башкарыла, үзенә күрә конвейер. Ләкин әлегә сөяк-санактан гайре игътибарга лаек бернәрсә дә күренми. Элекке Бөек Шәһәрдән түбәндәрәк урнашкан Ак Кирмән дип аталган бу җирләрдә борынгы корылмалар бар дип фараз кылына. Моннан болгарларның сәүдә юлы үткән, имеш. Үзенең хәрби-стратегик әһәмиятен югалтса да, Ак Кирмән Урда чорында да шул ук вазифаны үтәгән. Тик әлегә эзенә генә төшә алмадылар, серен бик тирәнгә яшергән, каһәр.

—Перекур,—дип кычкырды Рамил тавышын рота старшинасыныкына охшатырга тырышыбрак.—Оправиться!

—Әле ярый, искә төшердең, командир, югыйсә, чалбар төбе чылана иде,—дип көлде Салих.

—Теленә салынма, бар, кәҗәләрне куып кил,—диде Рамил,—бәладән башаяк, җә без казыган чокырга мәтәлеп аякларын сындырырлар.

—Берочтан сөтләрен дә сау,—диде Харис.—Кәҗә сөте бик файдалы бит ул.

Салих кулына чыбык алып, такмаклый-такмаклый кәҗә куарга китте.

Кәҗәмнең сөте болак, эче ылак,
Тиресе кап, мөгезе сап.
Шуларның барысын бергә җыйсаң,
Менә чыгар сина ат!

Йорт хайваннары арасында кәҗә иң каргалганы: бур да, кутыр да, кортлы да, хәйләкәр дә, тискәре дә. Дөньяда нинди начарлык бар, барысы да беркә үзенә. Ә ул әйткәнне колагына да элми, сакалын селкетеп урлашуын белә. Алай гынамы, менә шушы мут кәҗә авыр чакта кешегә ярдәмгә килә, сөте белән мохтаҗларны ач үлемнән саклый. Куй юк җирдә, кәҗә—Габдрахман түрә, дигән ич бабаларыбыз да.

Кәҗә иң популяр хайвани зат, ул хәтта бик күп халыкларның фольклор герое ишәктән дә уздырып җибәрә. Шуклыгы, мутлыгы, тәвәккәллеге, кыюлыгы ягыннан аңа өстен чыгучы юк. Татар халык авыз иҗатында да аның үз урыны бар. Ул мәшһүр Таз белән бер тамырдан. Икесеннән дә көләләр, икесен дә мыскыллыйлар. Һәм икесен дә үз итәләр.

Кәҗә хәтта ботаника, астрономия, география кебек төгәл фәннәргә дә үтеп кергән. Әйтик, Кәҗәмөгез йолдызлыгы бар. Кәҗә гөмбәсе дигән гөмбә бар. Кәҗә имчәге, Кәҗә сакалы, Кәҗә мөгезе, Кәҗә чәчәге—болары үсемлекләр. Элеккеге тәмәкечеләр Кәҗә сыйрагын бик яхшы хәтерлиләр: гәҗит кәгазен бүрәнә сыман итеп төреп, уртадан бөгеп, тәмәке тутырып ясаган төрем. Кәҗә маен чыгару, Кәҗә тоягы күрсәтүләр. Кәҗә билеты, кәҗә бәясе... Саный китсәң, очына чыгармын димә.

Кәҗәләр Салихның чикне бозуын өнәп бетермәделәр, ахры, муеннарын турайтып хәрәкәтсез калдылар. Нишләргә, кайсы тарафка юнәлергә? Моның өчен башлыкның әмере зарур. Ә ул үз хокукларын мөгезе ярдәмендә яуларга күнеккән. Сөзешергә бик маһир. Әле дә Салихтан күзен алмый. Бер-бер охшамаган гамәл кыла-нитә калса, ташланырга да күп сорамас.

—Сыртыңны ярганны көтәсеңме әллә, ычкын корчаңгы,—дип, Салих чыбыгын болгады.

Бикәчләре алдында бу хурлыкка түзәме соң тәкә? Мөгезләрен

сөнгедәй турайтып, центнерлы гәүдәсен искәрмәстән Салих ягына ыргытты. Салих бу һөҗүмне көткән иде, шуна күрә читкә тайпылырга өлгереп калды.

Тәкә әле һаман яман уеннан кире кайтмаган иде, күрәсен, баскан урынында дүрт аякларын да берьюлы күтәреп сикергәләп алды да, койрыгын чәнчеп, тагын һөҗүмгә хәзерләнде.

—Юк инде, корчангы, хәзер минем чират,—дип Салих тәкәгә таш белән бәрде. Таш шакылдап мөгезгә килеп тиде. Эчендә жаны булган сугыш чукмары шушы мыскыллауларга түзеп тора ди, көт. Тәкәбез бөтен көчен жыеп, янә бер ыргылды. Салих шундук жиргә ауды. Ләкин Кәжә батыр үзе дә таеп китте, ахры, аяк астындагы зур гына таш кубып аска тәгәрәде.

Бу тамашаны күзәтеп торган археологлар көлешә-көлешә "Орыш кыры"на ашыктылар.

—Икенче Ватерлоо сугышы булды бу,—диде Харис,—Напалеоннан ким каршылык күрсәтмәден, Салих.

—Кәжә, алайса, Кутузов инде, Напалеонны ничек тиз чүктерде, ә?

—Егетләр, монда карагыз әле, мин дөрес күрәмме икән, борынгы тәнкәләр ич бу!—дип үзен-үзе белешмичә кычкырып жибәрде Рамил.

—Тәкә койган коймаклар гына ул,—дип көлде Харис.

—Чынлап әйтәм, егетләр. Мине чеметкәләп карагыз әле, төш кенә түгелме бу? Егетләр!

—Менә чәчүргечкә тәнкә дә булды,—диде Салих.—Кәшшаф абыйның бәхете түбәсеннән ашкан.

Ул һаман Рамилне шаярта дип уйлый иде. Кәшшаф та жирдә чәчелеп яткан тәнкәләрне күреп алды. Юк, Рамил ялгышмый иде. Ләкин нинди тәнкәләр бит? Тарихи кыйммәтләре бармы, фәнгә хезмәт итәрлекләрме?

Кәшшаф бер тәнкәне жирдән алып, учына йомарлады. Тәне чемердәп китте, кан тамырлары буйлап нинди дер өшеткеч суык таралды, гүя күнеле узган гасырларның рәхимсез чынбарлыгы белән тоташты. Ул чакларда һәр үсеш баскычы сугыш-орышлар белән үрелеп барган ләбаса! Цивилизация кан кою исәбенә яуланган.

Алар чын-чынлап хәзинәгә тап булдылар, монысы хак. Хәзер инде чама белән генә булса да, аның кыйммәтен билгеләргә кирәк. Бу яктан Рамилнен күзе үткен. Борынгы әйберләрне ул иң элек авызына кабып, тәмен татып карый. Һәм нәрсәнен нәрсә икәнен әйтеп бирә. Әле дә бер тәнкәне теш арасына кыстырып, теле белән аның кытыршы өслеген ялмап алды.

—Юк, бу Һиндстан солтаннары суккан динар түгел. Алтыннан бөтнек тәме килә. Моның тәме башка. Жизгә дә охшамаган. Жиз пул XIII гасырда күп йөргән

Рамил ризыкларның сыйфатын тикшерүче дегустатор шикелле олы бер ләззәт белән тәнкәне авызында әвәләде. Шунда ук аңлатмасын да бирә, әйтерсең лә, студентларга лекция сөйли.

—Алтын Урда утыз ике шәһәрдә акча суккан. Берничәсе Болгар жирендә дә булган. Әһә, серенә төшендем мин моның, егетләр. Жир астында озаграк яткан. Шуна күрә аныклавы авыррак. Көмеш тәнкә! Жужи дирһәме булырга тиеш

Башкалар ышанырга да, ышанмаска да белмичә житәкчеләренең һәр сүзен йотып алардай булып тыңлыйлар. Йөзләре житди, уен-муен, шаяртулар бетте.

Бу әлеге составның беренче табышы. Моңа кадәр китаплардан гына укып белгән, кинофильмнардан гына күргән могжиза!

Әйе, могжиза. Чөнки хәзинә очраклы нәрсә. Аны алдан тәгаенләп булмый. Бу бәхет эше. Әнә, Апас районында табылган хәзинә фән дөньясында нинди зур жанлану уятты. 25 мең көмеш дирһәм! Ул әлегә кадәр Алтын Урда табышларының иң зурысы санала. Галимнәр XIV

гасырда Туктамыш хан исеменнән сугылган тәнкәләр дип фаразлыйлар. Моннан алда Тәтеш районында да шундый хәзинә табылган иде. Бу үзе дә Алтын Урданы танымаучыларга бик саллы исбатлама.

Археологлар дәртләнеп китеп, ял итәргә дә туктамыйча өч-дүрт сәгать җир казыдылар. Кәҗәләр аларның тыз-быз кайнашуларын тау башыннан күзәтеп торды. Башлык үз-үзеннән канәгать иде. Шулай булмыйча, бикәчләренә җил-яңгыр тигертмәде ич.

Капкан саен калҗа булмый, тырышулары уңыш китермәде. Хәер, әле бу урынны ныклап тикшерәсе, өйрәнәсе бар. Анысы киләчәк эше. Ә хәзер кечкенә генә мәҗлес үткәреп алсаң да гөнаһ булмас. Шулай хәл иттеләр. Кеше гомерендә мондый вакыйгалар бик сирәк була. Салих хәзинә табылган урында табын әзерләде. Бу эшкә маһир ул. Алыш-биреш, сый, таныш-белеш дигәндә аңа куш. Менә дигән итеп башкарып чыга.

—Әфәнделәр, табын әзер,—диде ул, ресторан официантлары рәвешенә кереп,—утырышыгыз!

—Акрын, дустың ишетмәсен,—дип бармак янады Харис,—табынны туздырып китәр.

Табынның яме зур балчык савытка өеп куелган табылдык тәнкәләр иде. Дөрес, күрер күзгә әлләни шаккатмалы түгел. Яшелле-зәңгәрле тутык, каткан балчык белән капланган яньчелеп беткән нәмәстәкәйләр шунда. Юлда тап булган кеше типкәләп кенә китәр иде. Ә монда белгечләр утыра. Алар өчен борынгы әйбер энҗе-мәрҗәннәреңнән дә бәһалерәк. Борынгы бүгенгене киләчәк белән тоташтыра, инсаниятнең яшәеш кануннарын дулкын өстенә бәреп чыгара. Борынгылык—ул тылсымлы көзге. Кеше анда үзенең үткәндәге чын йөзен күрә, кылган гамәлләренең асылын тәгаенли. Тәүбә итү өчен дә, үкенеч-юаныч өчен дә үткәненне белү зарур.

—Мин, дуслар, мөхтәрәм тәкәбезгә "Көмеш мөгез" дигән исем кушарга һәм әлеге хәзинәнең таныкламасында моны мәңгеләштерергә дигән тәкъдим кертәм,—диде Рамил.

—Ә мине?—диде Салих уены-чыны белән бергә,—мин кәҗә куарга бармаган булсам, хәзинә әле булса, җир куенында күгәреп ятар иде.

—Кәҗә куарга син, Нәҗмиев, минем кушу буенча бардың түгелме соң?—диде Рамил.

—Дөрес,—дип мөһер сукты Харис.

—Һәрвакыттагыча инде, эш мина килеп төртелсә, барысы да ишелеп төшә...

—Әлегә без баш герой хакында гына сүз алып барабыз, Нәҗмиев,—диде Рамил,—мин "Көмеш мөгез" өчен тост тәкъдим итәм.

—Афәрин.

—Яшәсен "Көмеш мөгез!"

Кәҗә тәкәсе, шулай итеп, мәҗлеснең кадагына әйләнде.

Тост әйтүчеләр кәҗә турында күргән-белгәннәрен искә алдылар, аның гел яхшы ягы турында гына сөйләделәр, тискәре сыйфатлары да уңайга әверелде. Чират Кәшшафка житте. Ни әйтергә, башына ник бер юньле уй килсен? Чөнки бала чактан ук кәҗәләрне күрә алмый иде ул. Ник дисәң, күрше әбинең кәҗәсе бакчаларына кереп җәфалый иде. Әнисе кәҗәне түгел, аны гаепли, бакчаны сакламагансың дип битәрли. Дөресе дә шулай иде инде, дус-ишләрең белән рәхәтләнеп су коенып, комда кызынып ятканда нинди кәҗә каравыллау ди ул.

Соңыннан үчен дә кайтарды анысы, үкенечкә калдырмады. Иптәшләре белән кәҗәне абзарга алып кереп, артыннан борчаклары коелганчы койрыгын кыстылар. Тик аңа карап, мөгезбай барыбер бурлыктан бизмәде.

—Моннан соң беркайчан да кәҗәләрнең койрыгын боргычламаска сүз бирәм,—диде ул.—Һәм дә "Кәҗә бәете"н ятларга йөкләмә алам.

Тост барысына да ошады. Кызмача кеше кызлар кебек бит ул, ишек келәсеннән дә кызык таба.

Тик көлүнен чамасы да була шул анын. Бүген көләрсен, иртәгә еларсын, ди. Шулай булып чыкты да.

Рамил аны тан белән диярлек уятты. Кичә сон ятылды, озаграк йокларбыз дип килешкәннәр иде. Шуна күрә Кәшшаф сәгатенә күз төшерде дә икенче якка борылып ятты. Рамил дә әмәлен тапты, дустынын йөзенә су койды. Кәшшафнын торып утырмыйча чарасы калмады.

—Нәрсә бар, нигә бимазалыйсын,—диде ул күзләрен уа-уа.

—Хәлләр бар монда, Кәшшаф, кинәшергә кирәк.

Ишек алдына чыктылар. Көн үзгәргән иде. Һава авызы пешкән егет кебек. Күк йөзен каплап алган болыт менә-менә бүселеп төшәр сыман. Салкынча. Төньяктан искән ачы жил пыран-заран килеп, ниһаять, көзнен хокукларын урнаштырып йөри.

Кәшшафнын беләгендәге бала йоннары кабарып чыкты.

—Жә, нинди ашыгыч сүзен бар, сөйлә,—диде.

Рамилнен кәефе дә төн эчендә бозылырга өлгергән көн шикелле карангы иде. Йөзе чытык.

—Табыллдыкны басканнар...

Кәшшафнын калтырануы көлүгә әверелде.

—Тапкансын шаяртыр нәрсә, сез әллә тагын өстәлегезме?—дип дустын күз карашы белән өттереп алды.

—Мин чынлап әйтәм, Кәшшаф, илле дирһәм тулмый. Биш йөздән дүрт йөз илле генә калган.

—Ярар инде, житте, барыбер ышанмыйм!

—Синен белән дә уйнап сөйләшмиләр!

Рамилнен кырыс тавышы Кәшшафны сискәндереп жибәрде.

—Чынлапмы?

—Чынлап.

Берара тын гына басып тордылар.

—Бәлкем, коелып калганнардыр,—диде Кәшшаф.

—Борыным белән жир сөрдем, тикшермәгән жирем калмады.

—Бәлкем, егетләрнен берәрсе шаярткандыр? Кичә бик күнелле утырдык бит,—дип Кәшшаф һаман үзенекен тукыды.

—Үзен әйтмешли, бу шаярта торган нәрсә түгел, Кәшшаф, мин егетләргә үземә ышанган кебек ышанам.

Кәшшафнын ике күзе дүрт булды, әйтерсен лә, искәртмәстән янагына китереп чәпәделәр.

—Си-н-н, нә-ә-рсә, мин-нән кү-ү-рәсенме әллә,—диде тотлыга-тотлыга.

—Табыш турында әлегә бездән башка беркем дә белми. Акт та төзелмәгән, рәсмиләштерелмәгән дә.

—Гаебенне танырга вакыт бар димәкче буласынмы?

—Гафу ит, әлбәттә, тик...

Рамил муенын боргалап алды. Ана дусты белән әлеге темага сөйләшү бик авыр иде. Анлашмыйча да булмый. Бу шәхси мал түгел, йомып кала алмыйсын.

—Егетләр шикләнә.

Әһә, мина каләр кешеләре белән сөйләшеп чыккан икән инде, дип уйлап алды Кәшшаф. Димәк, фикерләре уртак.

—Кемнәр инде ул егетләр дигәнегез, Рамил Фәесханович, исемнәрен әйтеп сөйләшегез,—дип Кәшшаф рәсми тонга күчте.—Мин бу гаепне гайбәт аша гына кабул итә алмыйм. Дәлилләрегезне китерегез!

Рамил бүртенеп чыкты, чөнки анын дәлилләре юк, сүзе фәкать фаразларга гына корылган. Башлыча бу Салих сүзләре. Мәжлес вакытында тарихчыбыз тәнкәләрне кулыннан төшермәде, ач күзләрен шуларга багып утырды, диде.

Чыны да шулай. Кәшшаф гашыйк иде бу борынгы ядкярләргә. Кулларында уйнатып кына калмады, ул аларны тешләп-тешләп тә карады әле...

—Сез, Рамил Фәесханович, ни сөйләгәнегезне үзегез дә белмисез, ахры. Тарихта ядкярләрнең хуҗасы фәкать тарих үзе генә. Үзен галим дип санаган кеше бервакытта да аларга кул сузарга җөрьәт итмәячәк

Кәшшаф сүзләрен мылтыктан аткандай койды да, капкадан чыгып, тау ягына таба китеп барды. Кичә кичтән казыган җирләрне, утырган урыннарны җентекләп карап чыкты. Ләкин бернәрсә дә тапмады. Әллә дөрес санамадылар микән соң? Алай дисәң, кат-кат ничә куллдан үтте ул тәнкәләр, аерым-аерым да, бергәләп тә. Юк, ялгышу мөмкин түгел. Нинди әкәмәт соң инде бу алайса? Башка сыймаслык хәл, валлаһи. Әллә бөтенләй әрләнкөзән ише киек-җанварның мажараларымы? Була ич андый хәлләр. Дөрестән дә! Моны тизрәк Рамилгә җиткерергә кирәк. Ана да үпкәләп булмый. Аптыраган кеше колагын кискән песи шикелле ич ул, кая барып сугылырга урын тапмый. Ә җавапны аңа тотасы.

Кәшшаф үзенең әрлән-көзән фаразын шундый охшатты, хәтта чынга ук саный башлады. Тынычланып китте.

Көн дә яхшырган сыман булган. Болытларның итәкләре җыелган бераз. Ара-тирә, әнә, күк йөзе дә ачылып-ачылып ала. Бәлки әле көн дә рәтләнер?

Кәҗәләр нәкъ кичәгечә тау итәгендә чемченеп йөриләр иде. Башлыклары да бик кәттә күренә. Як-ягына ялт та йолт карангалап кына тора. Менә ничек каравылларга булган хәзинәне!

Кәшшаф юлны кыскартып, сукмак буйлап түгел, турыдан элдертте. Моның өчен ике тау арасындагы ерганакны кисеп үтәргә кирәк. Ул инде корыган. Күрәсең, язгы ташу вакытында шаулап-дуамалланып ала да, соңыннан тына. Ерганакның кайбер урыннары бик нык ашалган, ярлар хасил булган. Эче тулы эреле-ваклы таш, кәс, чүп-чар—ни генә юк.

Кәшшаф сөзәк урын эзләп, югарырак күтәрелде. Шунда ул бер кешене абайлап алды. Кирпеч суга ахры дип уйлады нигәдер. Монда балчык әйбәт, үзле. Кирпеч өчен менә дигән. Килгән көнне үк бик кызыккан иде. Чөнки малай чагында кирпеч сугарга ярата иде. Кешеләргә дә, үзләренә дә. Бик охшый иде аңа әлеге шөгыль.

Янарган хатирәләр аны шул якка тартты. Якынайган саен, әлеге кешедә таныш чалымнар да шәйләнгәндәй була башлады. Кәшшаф адымнарын ешайтты. Бәрәч, Салих түгелме соң бу? Шул ич. Ә нигә ялгызы гына? Яңа урын сайладылар микәнни? Димәк, дирһәмнәр табылган!

—Әй, Салих!—дип кычкырды Кәшшаф шатлыгыннан.—Рамилләр кая?

Куркуыннан Салихның кулындагы төргәге төшеп китте. Кызыл балчык өстенә Туктамыш хан суктырган тәнкәләр коелды. Кәшшаф үз күзләренә үзе ышанмыйча шып туктап калды. Бу елгыр егетнең нинәрсә белән шөгыльләнүе аңына акрынрак барып җитте. Аннан соң үзен тота алмады, йөгереп килеп ярдан сикереп төште дә Салихның изүеннән эләктереп алды. Менә кайда икән ул сасы көзән!

—Их, син, нәфес корты, ничек итеп тарихи мираска кул сузарга батырчылык иттең, син, кабахәт.

Салих Кәшшафка караганда күпкә яшь тә, күпкә көчле дә иде. Ләкин кул күтәрмәде. Үгетләргә тотынды.

—Кәшшаф абый, тавыш куптарма, пожалысты, икебезгә бүләрбез, эчне тишмәс, дөньясы шул хәзер.

—Ах, син әле шулаймы?

Кәшшаф җан ачуы белән Салихның касыгына типте. Тегесе пычкы тигән кура шикелле җиргә ауды.

—Аһ...

Кәшшаф киеменә береккән үзле балчыкны каккалады да туры олы юлга таба атлады. Рамил белән очрашуның хаҗәте юк иде инде. Соңыннан ишетеп белде, Салих археологияне ташлаган, хәзер нindiдер бер алыш-биреш фирмасын җитәкли, имеш.

* * *

Заһидә көнеленен тузынган чакларында пәйда була торган хыялый Ак бабайны чын йөрәктән Порфирий Корнеевич дип кабул итә башлады. Мефодий исә анын бу ышанычын төрле-төрле дәлилләр белән куәтләп, ныгытып торды. "Учитель үлемсез, ул теләсә-нинди кыяфәт-сурәткә керә ала",—дип тукуын белә. "Бу һич тә мистика түгел, чөнки без үзебез дә илаһи көч тарафыннан сайланып алынган югары акылга ия шәхесләр",—дип тә өсти.

Заһидә Кәшшафны да шул юлга кертергә өметләнеп йөри иде. Шуна күрә ял йортында килеп чыккан низагны да бик авыр кичерде. Хәер, бәлкем әле татулашып китәрләр, Кәшшаф та акылына килер, башына тай типмәгән лә.

Заһидә һаман теләктә. Ул һәркөнне төнге сәгать уникеләрдә балконга чыгып баса да кулларын күккә сузып, мәрткә киткәндәй озак кына оеп басып тора. Бу анын Остазга табынуы. Шулай табына торгач, сизелеп тәненә нур инә башлый. Кан тамырлары буйлап ниндидер рәхәт дулкын таралуын тоя, жаны тынычланып китә. Бу минутта ул үзен галәмдә очып йөргәндәй хис итә, гүя жаны тәненнән аерылып чыккан да Остаз рухынын бер якты нурына әверелгән.

Әлеге халәт өч-дүрт кенә минут дәвам итә, әмма шул вакыт эчендә жанын да, бәдәнен дә аклыкка төренеп кала.

Заһидә хәзер завод-фабрикалар урнашкан шау-шулы районда яши. Шулай да тавыш артык бимазаламый. Чөнки йортлары урамнан эчкәрәк кертеп салынган. Каршыда—агачлык. Колач житмәс карт өянкеләр, ширпыдай төз чыршылар, зур-зур ябалдашлы ак тирәкләр... Кайчандыр монда парк булган. Күптәннән инде ташландык хәлендә. Тик ташландык паркнын да үз матурлыгы бар икән. Аны вак кошлар үз иткән. Кызыл түшле сары песнәк, мәсәлән, шушында гына бала чыгара, ди.

Заһидә халатын алып, балкон читендәге калакка элде дә, кулларын ян-якка жәеп, хозур бер кыяфәттә сын булып катты. Шәрә тәнен салкынча жил сыйпап узды. Күкрәге саф һава белән тулды.

Менә ул агачлар өстендә асылынып торган ак болытны күреп алды. Шәһәр утлары аны үтәли яктырта иде. Башта ул биниһая зур филгә охшаш иде. Бераздан филнен аяк-куллары, колак яфраклары кушылып, бербөтенгә әверелде.

Болытнын бу рәвеше дә озак сакланмады. Кыска гына бер мизгелдә Ак бабай сурәтенә керде. Заһидәнен халаты аяк астына төшеп уралды. "Остаз",—дип пышылдады.

Ак бабай кар йомарламына әверелеп, тәгәри-тәгәри китеп барды. Болыт урынында йолдызлар гына жемелдәшеп калды.

Заһидә Ак бабайны көтми иде әле. Димәк, тикмәгә генә пәйда булмаган. Бер-бер мөһим хәбәр житкерүе инде анын. Бу, һичшиксез, Кәшшаф белән бәйле.

Заһидә эшкә баруга институтка шылтыратты. Кәшшафны урынында юк, диделәр. Ниндидер экспедициягә киткән, имеш.

Заһидә радиода әлегә өйрәнчек кенә. Ул дикторлар төркемендә беренче адымнарын ясый. Эфирга да чыккалый. Жә, бер-бер диктор авырып китә, жә, кемдер сонга кала. Шундый жайлы вакытларны үзе дә сагалап кына тора. Тавышын ошаталар.

Серле ул микрофон дигәннәре. Кайбер кешеләрнен тавышын купшы кием шикелле матурайтып жибәрә. Тавышын ишеткәч, очрашып сөйләшәсе килә башлый. Икенче берәүләрнен тавышы исә микрофонда табигый төсмерләрен дә югалта. Ләкин тавыш бу катлаулы шөгыльнен бер ягы гына. Дикторга әле тагын бик күп сыйфатлар зарур. Болар арасында ин мөһиме, мөгаен, кыюлыктыр. Чөнки студиядә син ялгызын, алдында фәкать микрофон гына. Режиссер да, оператор да әмерләрен микрофон аша гына житкерә. Мондый катгый шартларны һәр кеше дә күтәрә

алмый, буталып, саташып бетәләр. Заһидә, әйтерсең лә, микрофон белән туган, этелмәде дә, төртелмәде дә, эфирга беренче мәртәбә чыкканда ук тигез тавыш белән сөйләп китте. Дөрес, ул һава торышы турындагы мәгълүматны гына укыды. Әмма кемнең кем икәнлеге беренче сүзеннән үк беленә ич аның.

Заһидә кечкенәдән үк радиога мөкиббән иде. Сәгатьләр буе тыңларга әзер иде ул аны. Аннан соң башына буш чиләк кия дә, радиодагы апа булып сөйләнеп йөри: "Тыңлагыз, тыңлагыз, Казан сөйли. Мәскәү вакыты белән..." Бер генә нәрсәне башына сыйдыра алмый иде кечкенә кызчык, Казан сөйләгәч, нигә Мәскәү вакыты соң ул? Казанның үз вакыты юк микәнни?

Радиода бөтен гадәттән тыш хәл шимбә-якшәмбе көннәрдә була. Ял—ял инде ул, барысын да алдан көйләп-җайлап бетерү мөмкин түгелдер. Ул көнне дә диктор ханым, сырхауладым, дип шылтыраткан. Шуңа күрә тиз генә Заһидәне чакыртып алдылар. Янә бер нәрсә беленде: татар телендә укыласы хәбәрләр "сыеграк" икән. Газеталардан карап бирәр саллы гына социаль яңалык өстәргә куштылар. Заһидә күңеленә яткан бер информацияне үзе тәрҗемә итеп, тапшыруга чәпәп тә куйды. Укуын да әйбәт укыды.

—Ярыйсы, ярыйсы,—диде баш мөхәррир.

—Бу Тукай премиясенә тиң,—дип көлде режиссер.

Баш мөхәррирнең мактау сүзенә саранлыгы бөтен радиога билгеле иде.

Дүшәмбе көнне Тукай бүләген "күрсәттеләр" Заһидәгә. Радиокомитет башлыгы Гозәеров иртүк якшәмбе көнне эшләгән төркемне чакыртып алды. Иреннәрен чәйнәрдәй булып утыра, йөзе кара янган. Үзе бертуктаусыз чәчләрен ышкый. Исәнмесез юк, хәлегез ничек дип сорау юк.

—Казылык турындагы информацияне кем әзерләде?—дип бакырды. Заһидә рәиснең кызу канлы кеше икәнен ишетеп белә иде. Баксаң, тупас та икән әле.

—Бәширова,—дип төртеп күрсәтте баш мөхәррир.

—Әйе, мин,—дип хуплады төркем җитәкчесенең сүзен Заһидә,—бик актуаль информация. Казылык-ит ише ризыкны әлек халык мең бәла белән Мәскәүгә барып юнәтә иде, хәзер хаклары төшли.

—Хөкүмәтнең эшен күрә белергә кирәк!—дип йодрыгы белән өстәлне төйде Гозәеров,—ә без монда, панимаешь, ялган таратабыз!

—Алайга китсә, хөкүмәтнең ул яхшы эш нәтиҗәләрен халык үз җилкәсендә тоярга тиештер ич инде,—дип бәхәскә керде Заһидә.

Тәҗрибәсез кеше шулай инде ул, дөнья гаделлек—дөреслектән генә торырга тиеш дип саный.

Оператор кыз Заһидәнең аягына басты, бу аның, башлык белән сүзгә кермиләр, дип кисәтүе иде. Ләкин соң иде инде, әйтеләсе әйтелде. Гозәеровның күзләренә кан йөгерде.

—Аягың керсә, башың кермәгән, акыл биреп утырган буласың, панимаешь...

Бу юлы ул нигәдер өстәлне тынычлыкта калдырды, бушатыгыз бүлмәне дигәндәй кулын гына селтәде.

Тагын бер сәгатьтән Заһидәгә шелтә бирелү турында боерык эленеп тора иде инде. Соныннан ул боерыкны үзара көлешеп, "казылык боерыгы" дип йөрттеләр. Баш мөхәррир аны яклап ник бер сүз әйтсен. Югыйсә, Заһидә әлеге информацияне аның фатихасы белән эфирга чыгарган иде. Шуннан соң ул кешегә карата ихтирамы бетте.

Шушы вакыйгадан соң ике көн үткәч, аның янына Мефодий килде.

—Ак бабай белән очрашу миңа һәрвакыт ниндидер җинеллек алып килә иде, бу юлы бөтенләй киресенчә булды,—дип зарланды Заһидә.

—Учитель безнең бәягә мохтаҗ түгел, Заһидә ханым,—диде Мефодий,—хәлбуки, Ул сиңа бик тә күңелле хәбәр җиткерергә дип күренгән булган.

—Нинди хәбәр икән ул?

—Сәяхәткә әзерләнегез, Заһидә Идрисовна,—дип елмайды Мефодий. Ләкин анын елмаюы сакал-мыегы арасында йотылып калды.

—Нинди сәяхәткә, Мефодий Евлампиевич?

—Яна тәгълиматнын ватаны—Бугор якларына чыгып китәбез.

Бу хәбәр Заһидәнен күнеленнән хәтта Кәшшафны да йолкып атты.

* * *

Порфирий Корнеевич Иванов гомеренен сонгы елларын Украинада, Луганск өлкәсенен Верхний Кондрючий дигән авылында үткәргән. Кыш язга авыша башлагач, мөритләре һәр елны Хәтер көннәре үткәреләр. Халык төрле төбәкләрдән җыела. Авыл бу вакытта Сорочи ярминкәсен хәтерләтә. Мунчаларга кадәр куна кертәләр. Остазнын җәсәде күмелгән изге җирдә өстенә су бөркү ивановчылар өчен хаҗ кылу белән бер. Бу гамәлнен тагын бер тәэсир көче шунда, суны өстенә Порфирий Ивановичнын хәләл җефете, турылыклы шәкерте, үзе дә Остазнын ярдәме белән генә аякка баскан Валентина түти бөрки. Остаз кешеләрне су коендыруны үзе исән вакытта ук Валентинага ышанып тапшыра. “Бу анын тормыштагы ин югары һөнәре,—ди,—Табигать хаерхак санаганнардан без икәү генә, мин һәм Валентина”.

Калын гәүдәле, көчле куллы бу ханым, өлкән яшьтә булуына да карамастан, үзен бик хөр тота. Ерак-ерак җирләрдән чир-сырхауларын кудырырга килгән бәндәләргә анын килеш-килбәте, йөз-кыяфәте дә унай тәэсир итә иде, күрәсен.

Заһидә дә әлеге сәяхәткә зур өметләр баглады. Иванов тәгълиматына табынучылар арасында төрле кеше бар. Тән сихәтен кайтаручылар да, җан тынычлыгы эзләүчеләр дә. Заһидә үзе беренче урынга рухи пакьлекне куя.

Монда ул һәр нәрсәдән яшерен мәгънә эзләп, һәр нәрсәгә мөкиббән булып йөрде. Остазнын ихатасында үсеп утырган агач-куаклар да, әнә, күрше-күләннекеннән күркәмрәк икән; кар юрганы да калынрак, чистарак та. Җемелдәүләре үк үзгә.

Ни гаҗәп, бу авылда чыпчыклар күп икән. Өерләре белән чыр-чу килеп очалар-очалар да электр чыбыкларына килеп куналар. Бермәл бөрекле кодачалар шикелле чыпчык-чыбыгым булып кукраеп утыралар.

Бу тикмәгә түгел дигән нәтиҗә ясады Заһидә, әрвахларнын җаннары шулай кош сурәтенә кереп очып йөрилер әле. Алар арасында, мөгаен, Остазнын җаны да бардыр. Их, тотып аласы иде дә, учка утыртып, тын өрә-өрә җылытасы иде.

Валентина түти анын бу күтәренке халәтен бер җөмләсе белән кыеп төшерде.

—Бераз гына бушыйм әле, агу сиптерәм мин аларга,—диде чын ачу белән. Заһидәнен, әйтерсен лә, кулыннан ин кадерле бүләген тартып алдылар, елап җибәрә язды. Кансызлык ич бу!

Валентина алай уйламый иде. Гомумән, бу минутта ул фәкать бер генә нәрсә турында кайгырта: ничек тә күбрәк кеше коендыру.

—Нәрсә катып калдын, якынрак бас,—дип кычкырды ул Заһидәгә.—Күрмисенмени, күпме кеше көтә!

Заһидә үзе дә сәгатьтән артык чират торып керде. Аннан артта да халык чылбыр булып сузылган.

Заһидәнен болай да уалырга гына торган нәзберек күнеленә җитә калды, бөтенләй сыгылып төште. Ул монда мен бәлалар белән вәхши сүзләр ишетергә түгел, бәлки Остаз йөргән сукмаклардан йөреп, үзенен рухын баетырга, анын ин якын кешесе булган хәләл җефетеннән фатиха алырга дип килгән иде. Чыпчык агулый, имеш. Шушындый тузга язмаган сүзне сөйләргә ярыймы сон инде. Әллә сынап каравымы? Анысы да бик мөмкин. Әнә, илаһи затлар элек гади кием киенеп базарларда, кеше күп җыела торган башка урыннарда мосафир кыяфәтендә йөргәннәр ич.

Халыкның фикерен, уй-хыялларын, гамәлләренең гаделлеген, тугрылыгын өйрәнгәннәр. Кем дошман, кем дус, кем халык өчен тырыша, кем куштан— барысын да үзләре ачыклаган, кеше сүзенә ышанмаганнар.

Заһидә бу табышына чиксез куанды. Ана элеккечә үк авылдагы һәр нәрсә тагын тылсымлы булып күренә башлаган иде инде. Әмма кич температурасы күтәрелеп, урын өстенә ауды. Мичтәге куз шикелле кып-кызыл булып ята. Бераздан коса башлады. Мефодий җүләр кеше сыман ишекле-түрле йөреп сөйләнде.

—Мин бик шат Заһидә Идрисовна, сырхавыгызны тәки җибәттек бит. Шулар чыга, сөенегез! Татарларда чөйне чөй белән чыгаралар, дигән әйтем бар, хәзер сиңа урамга чыгып салкын су белән коенырга кирәк.

Заһидә кузгалырга чамалап карады, булдыра алмады.

—Булышыгыз, кызлар,—диде Мефодий,—җитәкләп алып чыгыгыз.

Ләкин Заһидәнең капчыкка әверелгән гәүдәсе буйсынырга теләмәде.

—Бераз хәл алсын, алайса,—дип кашларын җыерды.

Ул нинди дер йомыш белән урамга чыгып китте. Шуны гына көткәндәй Заһидәне Иванов системасына кодалаган Татьяна исемле хатын аның янына килеп чүгәләде.

—И, мәрхәмәтсез,—диде ул ярымпышылдау белән,—гап-гади салкын тию авырулары да була ич әле бу дөньяда. Ана барысы да бер. Алайга китсә, кайбер кешегә коену бөтенләй ярамый.

—Гөнаһ алма өстеңә,—дип ыңгырашты Заһидә. Чөнки ул үзе дә салкын су бөтен авыруларга да дәва дип уйлый иде. Мефодий аны шуңа тәмам ышандырды.

—Сиңа ничек тә иртәгә иртән аякка басарга кирәк,—диде Татьяна.— Монда калмассың бит инде, билетлар көндезге поездга алынган.

—Ни әйтергә дә белмим инде... хәлем юк

Татьяна сумкасыннан дару алып, Заһидәнең авызына каптырды.

—Төнгә тагын эчерермен, ә хәзер йокларга тырыш, бик яхшы дару,—дип, Заһидәне башыннан аягына кадәр юрган белән каплады.

—Мефодийга су коенды дип әйтермен,—диде.

Заһидә күзләре йомылганын да, саташуларын да белмәде. Ул уянып киткәндә иртә иде әле. Кешеләр барысы да мыш-мыш килеп йоклый. Ара-тирә чикерткә тавышлары да ишетелеп китkәли. Бала чаклары хәтеренә төшеп, күңелен татлы да, сагышлы да моң биләп алды. Чикерткә тавышын күптәннән ишеткәне юк иде инде.

Бераздан ул үзенең манма су эчендә ятканын тойды, эчке күлмәге борып сыгарлык булып чыланган. Әмма тәне җиңел. Даруларның ана әле болай җиңеллек биргәннәре юк иде, гел аллергия белән интегә иде. Татьянага рәхмәт, каян тапкан шушындый сихәтле даруны.

Заһидә башындагы япманы сыдырып төшерде. Йөзен йомшак салкынча һава сыйпап узды. Шундый рәхәт булып китте. Шактый вакыт ләззәтләнеп ятты. Ята-ята ашыйсы килә башлады. Тереләм, ахры, дип сөенде. Букчасыннан капшанып авызына ипи кисәге капты. Юк, үтми, каһәр, нәфесе ниндидер ят ризык сорый. Чир галәмәтедер инде. Берничә минуттан тагын шуны тоеп алды, аның күңеле балан бәлеше тели икән ләбаса! Күршеләре Бәнат карчык баланчы иде. Язга чыккач та өй кыегы астында балан бәйләмнәре асылынып торыр иде. Әнә шул баланнар һич уйламаганда Заһидәнең күз алдына килеп басты. Пешмәгән килеш тә тәлгәшләреннән өзеп-өзеп ашарга әзер иде ул аларны.

Шуннан соң күп тә үтми укшырга тотынды. Торып су эчкәч бераз басылган кебек булса да, барыбер бетмәде, юлда ике тәүлек буе интекте.

—Син көмәнгә узгансың бит кызый,—дип кисәтте аны Татьяна.

—Миннән тагын бала табу,—диде Заһидә,—кысыр булганга Ходай чирне өеп биргән дә инде.

Татьяна кашык чаклы гына кечкенә учлары белән аксыл чәчләрен сыйпаштырып торды да әйтте:

—Син ирләрне еш алыштырасыңдыр, әйеме? Үзең чибәр, үзең тол.

Заһидә Бәнат карчыкның баланы шикелле кып-кызыл булды. Ул йөрәк хәлләре турында ачыктан-ачык сөйләшергә күнмәгән. Ир-атлардан да ике генә кешене якыннан белә. Берсе—Гаффар, икенчесе—Кәшшаф. Хәзер тегесе дә, монысы да юк инде. Ә бу чикерткә көмән хакында сафсата сата. Каян булсын ди? Ул жин эченә жил өргәннән генә балага узган Мәрьям ана кебек изге зат түгел лә.

—Алайса сина әле хатын-кыз тәме йөгермәгән икән,—диде Татьяна зәңгәр күзләрен томырайтып.—Шулай да гинекологка сугылып чыгарга кинәш итәр идем.

—И, Танечка, укшыган саен бәби алып кайта торган булсам, миндә алар бер көтү булган булырлар иде инде,—дип көлде Заһидә.

Балан бәлеше ашагач та Заһидәнең укшуы басылмады. Һәм ул кайсы ягы беләндер элеккеләреннән үзгә иде: укшыта да күнелне болгата башлый. Үзе моны яхшыга юрый, организмның чистарынуы дип саный. Ул аралашкан даирәдә табибларга мөнәсәбәт тискәре. Бу аның үзенең карашлары белән дә тулысынча тәнгәл килә. Ләкин әлеге очракта Татьянаның кинәшенә колак саласы итте, аны бу адымга нииндидер эчке бер аваз этәрде.

Хатын-кызлар табибы урта яшьләрдәге бер яһүдә ханым иде. Зур, калын гәүдәле. Ә йөзе мөлаем, кап-кара озын керфекләре астындагы чем кара күзләреннән ниндидер ягымлылык сирпеп тора. Заһидә аны бер карауда ошатты.

Гинеколог бик жентекләп карады, барысы турында да тәфсилләп сораштырды. Заһидә һич тартынмыйча жавапларын бирде. Ун-унбиш минут эчендә алар арасында дустанә мөнәсәбәт урнашты. Сара (табибәнең исеме дә чын яһүдчә иде) әледән-әле ак кулъяулыгы белән дымланган күзлекләрен корыткалап алгалый.

—Сезнең көмәнегез булырга охшый,—диде ул Заһидәгә сагаеп кына. Заһидә мондый хәбәрне көтмәгән иде, әлбәттә, югалыбрак калды.

—Бу әле фараз гына, төгәл мәгълүмат кан анализыннан соң тәгаенләнәчәк,—диде Сара.

—Мине иремнең туган-тумачасы "Кысыр кәек" дип мыскыл итә иде,—диде Заһидә,—сез ялгышасыз булыр.

—Гаепнең иремгездә булуы да мөмкин иҷ. Аның тикшерелгәне булдымы соң?

—Мин ана әйтеп карадым, тыңламады.

Бу хәбәр аны тәмам чыгырыннан чыгарган иде. Тиз-тиз генә жыенды да: "Мин сезнең янга башка көнне килермен",—дип бүлмәдән чыгып китте.

* * *

Бала табу—хатын-кызның төп вазифасы. Бәгъзеләр, Аллаһы Тәгалә хатын-кызны фәкать шуның өчен генә яраткан диләр. Ихтимал бу дөреслеккә туры да киләдер. Чөнки кысырлыкны дин дә, кешеләр үзләре дә элек-электән үк кабул итмәгәннәр. Кысыр хатыннан кыртлаган тавык артык, ди халык мәкале. Баласыз хатыннар үзләре дә: "Атым ирле, буем ярлы",—дип зар кичергәннәр. Ләкин кысырлыкны бераү дә теләп алмый. Гаилә коруны хатын-кыз әүвәл нәүбәттә бала белән бәйли. Бу хис ана сөте белән бирелә. Пәйгамбәребез дә үзенең бер хәдисендә: "Аләмнең жимеше—бала",—дип тәкрарлап калдырган.

Заһидәләр авылында баласыз хатын юк иде. Әти-әнисе аның үзен дә: "Улын-кызыннан унарсын",—дип үстерде. Курчаклы уйнарга яраткан кызның баласы күп булыр, имеш. Курчакларны ул үзе ясый иде. Дәфтәр кәгазен эчен куыш калдырып көпшә рәвешендә төреп бәйли дә, шуна күлмәк тегеп кигезә, яулык бәйли, карандаш белән авыз-борын, күзләр төшерә. Менә сина курчак! Көннәр буе шулар белән эш-мәшә килә иде.

Тик гоманлаулар гына раска килмәде. Кияүгә чыгып, бер ай үтте,

ике, биш... тугыз, ә ул һаман буш. Урамда бала арбасы тоткан әниләрне күргәч, көнләшүеннән йөрәге өзелеп төшәр хәлгә җитә иде. Сүз иштерсәләр, кешедән качып сәгатьләр буе йоммый түгә иде. Акрынлап күнекте тагын. Һәм бала турындагы садә хыялларын күнеленнән йолкып ташлады. Яшь балаларны сөйми башлады, алар анын ачуын гына чыгара иде.

Табибәнең сүзләре аны янә әлеге ул яратмаган дөньяга кайтарды. Төнен керфек тә какмый үткәрде. Сара бу хәбәрне ана житкереп бик зур хата ясады. Табиб кеше имеш-мимешләр белән сөйләшергә тиеш түгел. Моны кемсә чынга алырга да мөмкин ич! Эрләмәгән, сугылмаган дигәндәй...

Заһидә бу бәйләнчек уйлардан арыну өчен ниләр генә эшләп карамады. Бәлки, йокы алыр дип, берничә тапкыр менгә кадәр санап карады. Файдасы тимәде. Аннан соң күнеленнән белгән жырларын жырлап чыкты. Ләкин бала турындагы уй саннарны да жимерде, жырларны да ерып керде. Еллар буе тырыша-тырмаша жиде кат жир астына күмгән кимсенү хисләре янә баш калкытты.

Бала, бала, бала!

Заһидә мәктәптә укыганда үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөри иде. Барыннан да элек нәфис сүз остасы буларак танылды. Сәхнәдән Муса Жәлил, Фатих Кәрим, Һади Такташ кебек шагыйрьләрнен лирик поэмаларын яттан укый иде. Халык шылт та итми тынлый иде: көләләр дә, жылыйлар да, елмаялар да. Чөнки Заһидә образга керә белә, һәр сүзнен, һәр шигъри табышның эчке мәгънәсен тоемлый, аны түкмичәчми тынлаучыга житкерә иде. Тавышы да матур, бизәкле, үзенә тартып, жәлеп итеп тора. Ул бигрәк тә Такташнын “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасын яратып башкара иде.

Ана—бөек исем.
Нәрсә житә ана булуга!
...Хатыннарнын бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда.

Шушы канатлы сүзләрне укыганда тәне калтыранып-калтыранып китә, үзен баласын күкрәгенә кыскан яшь анадай хис итә иде.

Бу хатирәләр дә янарып китте. Хыяллары каурый болытлар сыман кабарды. Үзен шул чиккә кадәр китереп житкерде ки, хәтта баласына исем дә эзли башлады. Ул, әлбәттә, кыз бала тудырачак. Кыз тапканга ай туган, ди. Бер күркәм кыз жиде улга тора бит ул. Ә анын кызы, һичшиксез, матур, акыллы булачак, шәфкатьле булачак, үзен бик яратачаклар. Шуна күрә исеме дә жисеменә туры килерлек булсын. Матур исемнәр күп анысы. Әйтик, Гөлшәһидә, Гөлчәчәк, Гөлжәннәт. Халык үзенен йөрәк парәсен гөлгә тинләгән, гөлгә охшаткан. Нур сүзенә башланган исемнәр дә күнелгә ятышлы. Нурсолтан, Нурсылу, Нурсөя... Нурсолтан—татар тарихында билгеле шәхес. Гәүһәршад та милли тарихыбызда үз эзен калдыра. Анын кызы да, Аллаһы боерса, ким-хур булмас.

Хәфазә дигән исем дә аңа бик якын. Бу исемне элек мәртәбәле, укымышлы затлар йөрткән. Заһидәнен әтисе ягыннан бер ерак туганы да Хәфазә исемле булган. Әле үктәбер инкыйлабына кадәр үк Казанда кызлар мәктәбе тәмамлаган. Совет чорында Үзбәкстанда яшәгән, зур дәрәжәләргә ирешкән, имеш. Заһидә бу өзелгән туганлык жепләрен ялгарга күптәннән хыяллана иде. Әлегә жае гына чыкканы юк.

...Заһидә күзләрен йомганда шәһәрдә беренче трамвай кузгалган иде инде. Әмма кыска гына йокысы да шундый ук уй бураннарында узды. Төшендә ул кызын күрде. Түгәрәк битле, калын иренле, зур күзле бик мөлаем бала. Сахра болынында хозурланып йөриләр, имеш. Кызы яшь колын кебек һич тә тик тормый, йөгерә-йөгерә чәчәк жыя, үләндә ауный.

—Хәфазә, әйберенне авырттыра күрмә,—дип Заһидә кызын тотып алмакчы булды.

—Син нәрсә, әнием, мин Нурсолтан ич,—диде кызы ирennәрен турсайтып,—Хәфазә... юк Хәфазә монда

Заһидәнең башы чатнап китте: Хәфазәсе кая икән соң? Гәүһәршады да күренми...

—Кызым, апаларыңны чакыр, су коенырга алып барам,—диде Заһидә.

—Минем апаларым юк, мин үзем дә юк,—диде кыз һәм кулларын җәеп күбәләк шикелле болын өстеннән очып китте. Бара-бара аккошка әверелде. Йөрәк өзгеч сагышлы тавыш белән кычкыра-кычкыра баш очында әйләнде дә күздән югалды

* * *

Ниһаять, гинекологка күренәсе көн дә килеп җитте. Заһидә кыюсыз гына бусагадан атлап керде. Сара аны елмаеп-көлеп каршы алды.

—Мин сезне чын күңелемнән котлыйм, Заһидә Идрисовна,—диде,—чыннан да, сезнең балагыз булачак!

Ул йөгереп килеп Заһидәне кочаклап алды. Ә Заһидә ни әйтергә дә белми: еларгамы, көләргәме?

—Мин шундый җүләр инде, Заһидә Идрисовна, гафу итегез,—дип тезеп китте Сара,—барыгыз, бар, тизрәк әтисеннән сөенче алыгыз.

Заһидә бу сүзләрдән сискәнеп китте. Ул соң Кәшшафны бөтенләй исеннән чыгарган икән ләбаса! Баланың бәхете—әти-әнисенең тигезлегендә. Ятимнең бусагасы алтын булса да ятим инде.

Дөрестән дә, Кәшшаф ни әйтер бит әле? Ул гаиләле кеше, улы бар. Чит хатыннан баласы булуын өнәп тә бетермәве ихтимал. Ир-ат шулай бит ул, үзенә кирәк вакытта синсез яши алмыйм, дип авыз суын корыта, ә җавап бирер чак житкәч, куак артына поса. Ир-атка бала түгел, сөяркә кирәк. Дөрес, Заһидә Кәшшафка андый дәгъва белдерә алмый. Алар бернинди дә вәгъдәләр бирешмәделәр. Яратыштылар гына.

Бу яратышу гомер буе дәвам итәр сыман иде. Ләкин тормыш елга түгел, бер эздән генә акмый. Кирегә киткән чаклары да күп була. Ул үзе дә үзгәрүчән холыклы кеше. Бервакыт имче Маһинурны да "әни" дип йөри башлаган иде ич. Маһинурны Мефодий алмаштырды. Хәзер ул аны Кәшшафтан да өстен күрә.

Тик инде боларның мәгънәсе бетте. Уртада фәкать Кәшшаф кына торып калды. Чөнки ул күкрәк астында бөреләнеп килүче баланың атасы! Ничек итеп житкерергә ана бу хәбәрне? Ничек кенә аралары салкынаймасын, Кәшшаф баласы буласын белергә тиеш. Заһидә баласының әтисе фамилиясен йөртүен теләр иде. Монда инде бөтен мин-минлекләрне, борын чөюләрне онытырга туры киләчәк. Тау Мөхәммәд янына килми икән, Мөхәммәд үзе тау янына барырга тиеш була. Һич тә укасы коелмас. Кем белә, бәлки Кәшшаф үзе дә аны бер күрергә интизар булып йөридер? Горурлыгы гына тота булыр.

Заһидәгә дә, Кәшшафка да горурлык пәрдәсен ертырга туры килмәде. Алар көтмәгәндә урамда очраштылар. Заһидәнең колхоз базарыннан кайтып килеше иде. Кулында зур чәчәк букеты. Диләфрүз исемле дикторның туган көне, төш вакытында нәни генә мәҗлес буласы. Әле вакыт бар. Шуна күрә ашыкмый гына атлый.

Көне дә матур иде. Җиргә акрын гына кар төшә. Җиһан гүя нинди-ләр талгын дулкын өстендә тирбәлә. Тыныч, рәхәт. Табигатьнең бу илаһи тотрыклылыгы аны да үз кочагына алды. Иртә-кичен йөрәген кимереп торган хәвефле уйларын, әйтерсең лә, кар күмеп китте. Ул игътибар белән үткән-сүткән кешеләрне күзәтә. Ник бер борынын салындырган кешене күрсен?! Көләләр, шаяралар, елмаялар. Хәер, монда гаҗәпләнәсе дә юк, чөнки күбесе студентлар. Яшь чакта авыз йомылып тормый ич ул.

Пушкин урамыннан уңга каерылып, үр менгәндә ул Кәшшафны күреп алды. Дипломатын бармак очына гына элеп, җинел-җинел адымнар белән аңа каршы килә. Беркемгә игътибар итми. Заһидәне дә килеп

бәреләәязгач кына абайлап алды. Шып туктады. Күзләрен әлҗе-мәлҗе китереп, Заһидәгә төбәлде.

—Әллә танымыйсыңмы?—дип елмайды Заһидә,—исән-сау гына йөрисеңме?

—Исәнен исән,—диде Кәшшаф каушавын күрсәтмәскә тырышып,—тик мин соңарганмын, ахры.

Аның чәчәк букетына ишарә итүе иде.

—Соңларсың да, алай бик сангa сукмый йөрсәң.

—Хәтерем ялгышмаса, мин түгел, син мине ташлап качтың. Ни язганнарыңны хәтерлисеңме соң?

—Үпкән-кочкан җилгә очкан, әллә кайчангылар белән битәрләмәсәң дә була инде.

Кәшшафның күзләре һаман да чәчәк бәйләмендә иде.

—Ә бу купшы букет?! Анысы да әллә кайчангымы?

Заһидә чыркылдап көлеп җибәрде.

—Әллә күнеленә тияме? Борчылма, бүләк чәчәге генә, Диләфрүзнең туган көне. Базардан кайтышым.

—Теге карга тавышлы диктормы? Әйт әле син аңа, интектермәсен әле тыңлаучыларны. Халыкны радиодан биздереп бетерә бит инде.

—Монысы туган көн тостына туры килми инде, Кәшшаф әфәнде, житәкчелек хәл итсен.

Сүз арты сүз чыкты. Тәмам дуслашып, татулашып саубуллаштылар.

Җомга көнне Кәшшаф Заһидәнең ишеген шакыды.

Заһидә җыйнак кына, әмма зәвыклы итеп табын әзерләгән иде. Бер помидор, ярты баш суганнан да менә дигән салат ясый белә ул. Хикмәт ашамлыкның муллыгында түгел, хикмәт аз тәгамны да матур итеп чын йөрәктән тәкъдим итә белүдә. Заһидә шуның остасы инде. Өстәвенә, һәр хуҗабикәнең аеруча яратып пешерә торган бер ризыгы була. Заһидәнең таҗ ризыгы—бәрәңге! Дөрес, бәрәңгегә мыскыл белән караучылар да бар. Бәрәңге әйтә, имеш: “Алып баруын барам инде, хуҗакай, алып кайтуыма ышандыра алмыйм”. Бу, әлбәттә, ачлык ел галәмәтләре. Заһидә кебек осталар кулына керсә, бәрәңге дә “йодрык каләрле, йомры гәүдәле, ак тәнле” затлы ризыкка әверелә дә куя.

Бер карасаң, бернинди авырлыгы да юк кебек үзенең. Тирән эчле олы табада Заһидә иң элек мул гына итеп май чыжлата. Аннан соң шуна икегә ярылган зур-зур бәрәңгеләр тезә дә, өстен ябып утка куя. Бәрәңге кызара, бүртенә, кабара, тагын әллә нинди рәвешләргә керә. Шушы вакытта ук икенче табада шундый ук ысул белән эре-эре кисәкле ит кыза. Тәмләткечләр үз чиратларын көтеп утыралар. Лимон, суган, сарымсак, төрледән-төрле үләннәр, кара җимеш, соус.

Кәшшаф әнисенең итәгенә ябышкан иркә бала шикелле Заһидәдән тотам да калмады, гел артыннан ияреп йөрде. Ул кухняга чыкса, кухняга чыга, өстәл әзерләсә, өстәл янына килеп баса, кочып ала... Заһидәдә генә ул кайгылар юк. Күңелендә һаман шул бер уй: көмән! Ниләр генә уйлап бетермәде инде бу хакта. Башта курыкты, аннан соң шатлык килде, бераздан—битарафлык. Хәзер исә ирсез бала табуны зур гөнаһ дип саный башлады. Ә иң дөресе, эшнең тоткасы—Кәшшаф кулында. Аның белән аңлашу бик күп борчулы мәсьәләләргә ачыклык кертәчәк. Бүген шуның ифрат та уңайлы вакыты.

—Бәрәңгем әзер,—диде Заһидә,—утырышыйк, суынган бәрәңгенең тәме дә китә, йөзе дә калмый.

Кәшшафның үз утызы утыз.

—Мин сине бик сагындым, Заһидә.

—Әле генә исенә төштемени? Элегрәк кайда идең соң син?

—Үзең әйтмешли, узган эшкә салават, Заһидә. Минем сине югалтасым килми...

Бу сүзләр Заһидә көткән сүзләр иде, эреп китте. “Мин дә сине яратам”,—дип Кәшшафның куенына елышты.

Кызыктыргыч бәрәнге табада чыжылдап-чыжылдап торды да күмере беткән паровоз шикелле тынып калды.

Яратышунын кайнарлыгы кимүгә тагын Зәһидәнен борчулары кайтты. Инде нишләргә? Ничек сүз башларга? Кәшшаф дөрес анлармы? Баш тартса, нишләрсен...

Кәшшаф үз-үзеннән канәгать калды. Шөкер, көч-куәтенә сүз тигезерлек түгел. Инде ашап-эчеп алсан да зыян итмәстер, мөгаен.

—Җылытып алыйм сон,—диде Зәһидә.

—Борчылма, жимешем, болай да бик һәйбәт шуа.

Кәшшаф сыпырта гына, ваграк бәрәнгеләрне чәйнәп тә тормыйча уптым-илаһи гына йотып жибәрә. Зәһидә ана көнләшеп карап торды: бар сон кайгысыз-хәсрәтсез кешеләр.

—Бирән Әхмәдулланын билбавы булмаса, корсагы шартлый ди, булды бу, жимешем, бик тәмле булды, рәхмәт. Кая шунын өчен үзенне бер "әп!" итим әле,—дип Кәшшаф сөйгәненә үрелде.

Зәһидәгә дә сүз кыстырырга жай чыкты.

—Корсагын борынына житеп килә инде, кайчан бәби алып кайтырсын икән,—диде.

Кәшшаф шыркылдап көлеп жибәрде. Мәзәк сүзгә үзе дә өлеш кертергә булды. Кичә генә Әлтаф аны Тау ягыннан язып алып кайткан бер фольклор үрнәге белән таныштырган иде. Көне буе көлешеп йөргәннәр иде. Зәһидәгә шуны сөйләсе итте, сүз сөрешенә дә туры килеп тора икән.

—Ә син, беләсенме, Жәмилә исемле бер йөремсә кыз кияүгә чыгып вакытыннан алда бала табуын ире Мокытка ничек анлаткан?

—Сөйлә сон, сөйләгәч белермен.

—Мокыт хатынына акаеп караган да сораган, имеш: "Бу нинди эш бу, әкәм-төкәм, өч айдан бала алып кайталар димени?" Жәмилә бер каушамыйча әйткән:

—Нигә мона исен китә сон әле синен, картым,—дигән,—менә үзен исәпләп бак: ике куш ай, бер буш ай, үткән ай—бер ай, туган ай—ике ай, туасы ай—өч ай. Менә була тугыз ай.

Мокыт ике-өч көн аптырап йөргән. Аннан сон хатынынын каршына килеп баскан да: "Тугыз ай булып чыкмый бу",—дигән. Жәмилә күзен дә йоммыйча тезеп киткән:

—Алай чыкмаса, син аны болайрак исәплә: син алганга өч ай, мин барганга өч ай, март, апрель, май—менә сина тугыз ай!

Мокыт үзе тынычланган-тынычлануын. Тик күршеләре: "һай-һай, кәләшнен шәбенә туры киллен",—дип котырталар икән. Мокыт бу юлы хатынына аяк типкән, имеш. Жәмилә иренә карап-карап торган да, аны кызганып:

—Жаным, мин иртә тапмадым, син үзен мине сон алдын,—дигән.

Кәшшафнын әлеге тозсыз кыйттасы Зәһидәнен атналар буе жыелган борчуларын, үпкәләрен, кимсенүләрен барын бергә куптарып ташлады. Көтмәгәндә жене бәреп чыкты.

Сикереп торды да өстәлдәге ашамлыкларны ашъяулыгы-ние белән идәнгә эшереп төшерде. Бәрәнгеләр, ит калдыклары, ипи кисәкләре идән буенча сибелде.

Бу шулай тиз булды ки, Кәшшафнын канәгать йөзендә әле елмаю чаткылары да сүнәргә өлгермәгән иде. Ә Зәһидәнен күзе-башы тонган, менә-менә өстенә ташланыр сыман.

—Сина барам дип торган кеше юк әле монда,—дип кычкырды,—үз баламны үзем карармын!

Кәшшафнын аптыравы арта гына барды: нинди алу-бару, нинди бала? Гап-гади мәзәккә дә шулай ярсырга ярамый ич. Алай дисән, икенче тапкыр бит инде бу. Ял йортында да әйберләрне чәчеп ташлаган иде. Авыруы холкына тия, күрәсен.

—Тынычлан, жимешем, күнелөнә якын алма, мәзәк кенә ич ул,—дип Кәшшаф сөйгәнен тынычландырырга тырышты. Зәһидә дә үзен

кулга алган иде инде. Кәшшафка озак кына сынап карап торды: әйтергәме-әйтмәскәме? Алай да жөрьәт итеп сорады:

—Балабыз булса, син миңа өйләнер идеңме?

Кәшшафның күз алдында ике Заһидә. Беренчесе—әле генә ашамлыкларны идәнгә тартып төшергән дуамал Заһидә. Икенчесе—караватчитенә чүмәшеп утырган мескен Заһидә. Боларның кайсысына ышанырга? Әлеге сорауның бер-бер эчке мәгънәсе бармы? Баласы булмый ич аның. Ул сүз авызына нинди сәбәп белән килеп кергән?

—Галимлекне ташлап, муллалыкка керергәдер бәлки,—дип, Кәшшаф әлеге сорауны уенгарак борып жибәрмәкче итте.—Аларга ирек.

Заһидәгә үзенең хәлен тыныч кына, турыдан-туры уртага салып аңлатырга кирәк иде, әлбәттә. Ничек тә уртак тел тапкан булырлар иде. Ләкин бер киреләнә башласа, чыгымчы аттан да яманрак шул ул. Әле дә кашлары жимерелде, берара иреннәре тартышудан сүзен әйтә алмый төртелеп торды.

—Аһ, си-и-н, шу-у-лаймы, м-мыскыл и-тәсеңме?

—Җимешем, шаяртам гына ич инде, ярар инде.

Ләкин Заһидә аны тыңламый иде инде.

—Сынау өчен генә әйткән идем, бар, хатының янына элдерт, потың бер тиен,—дип Кәшшафның киемнәрен өстенә ыргытты.

Кәшшафка жыенудан башка чара калмады. Ләкин ерак китә алмады, капка янында аны Заһидә куып тотты.

—Әгәр шулай китеп барсаң, башка күзенә кырып салырга да булмам,—диде үтә бер ачыну белән.

Инде Кәшшаф киреләнде.

—Юк инде, жимешем, мин сиңа малай-шалай түгел,—дип эре-эре атлап юлын дәвам итте.

Заһидә бүлмәсенә керде дә ятагына ауды. Үзе үкси, үзе сөйләнә: "Нинди гөнаһларым бар соң минем? Ни өчен миңа гына төшә соң бу кайгы-хәсрәт? Инде нишләргә, кая барып бәрелергә, кемгә сыенырга?"

Бераздан аның тавышы тынды, әллә йоклап китте, әллә уй биләп алды, кыймшанмыйча да ята, хәтта ут сүнгәнен дә сизмәде.

Бүлмә эче караңгыланып калды. Тын. Борылып бетмәгән краннан күнелгә шом салып тамчы тама: тып-тып, тып-тып... Әйтерсең лә, баш түбәсенә кемдер чүкеч белән кундырып-кундырып ала.

Сәгать тугызны сукты, унны... Тамчы бернәрсәгә карамыйча тама да тама. Заһидә, мөгаен, иртәгә чаклы башын күтәрмәстер инде. Әнә, мәче баласы шикелле йомарланып беткән мескенем.

Юк, Заһидә читтән караганда гына йоклаган кебек күренә иде. Бер генә минутка да күзләре йомылып карамады. Ул әсир иде. Уй әсире. Яман уй уяр, үз башыңны жуяр, ди. Уй кешенең зиһенен чуалта, акылын ала.

Ихтимал, ут кабынмаса, Заһидә һаман шул килеш уйларына буталып яткан булыр иде әле. Гөлт итеп кабынган электр уты аны сискәндереп жибәрде. Урыныннан сикереп торды да кабалана-кабалана идәндә чәчелеп яткан ризыкларны жыярга тотынды. Аннан соң бу эшен ярты юлда калдырып, суыткычны киереп ачты. Актарынырга керешге. Озак актарынды. Ниһаять, карасу төстәге бер шешә тартып чыгарды.

Шешә ярым буш иде, калган сыеклыгын стаканга агызды. Тирән итеп сулыш алды да тәжрибәле әлкәш шикелле стаканны бер сулышта тамагына аударды. Йөзен чытып торганнан соң үз-үзенә әйтеп куйды:

—Менә булды бит, ә син курыккан идең.

Заһидә инде хәзер нишләргә дигәндәй як-ягына каранып алды. Ятып торыргамы, утырып көтәргәме—бу кадәресен тәфсилләп житкермәгән икән. Ул кинофильмнардагы шикелле барысы да күз ачып йомганчы була дип гөманлаган иде. Әлегә бер үзгәреш тә тоймый кебек.

Заһидәнең башына кылт итеп "Остаз" дигән уй китереп бәрде. Ул ничек кабул итәр аның бу гамәлен? Хуплармы, кире кагармы? Тиздән

алар очрашачак ич инде. Ин дөресе, Гимнны жырлау. Остаз аны һаман жырларга кушкан. Гимн үлемсезлеккә мәдхия!

Люди Господу верили как Богу,
А он сам к нам на землю пришел.
Смерть как таковую изгонит...

Заһиданен эчен кинәт кенә нидер сызып узды. Әйтерсен лә, үткен пәке тиеп китте. Куркуыннан йөзе кәгазь шикелле агарып катты. Иреннәре арасыннан: "Әнием, үләм, әнием " дигән куркыныч сүзләр пышылдап чыкты.

Авырту дулкын-дулкын булып тагын ике-өч мәртәбә кабатланды. Заһидә елан сихерләгән куян хәлендә иде. Елан инде авызын ачкан, менә-менә йота башлар төсле.

Әнисе Заһидәгә балачакта ук догалар өйрәтә иде. Аллага ышанып үсте ул. Анын бу көйләнгән тормышын чир килеп кереп кенә чуалтты.

Көтмәгәндә Заһиданен догасы кайтты. Кечкенә чакта еш кына эче авырта иде. Әнисе шул вакытта уку өчен әлеге доганы өйрәткән иде. Шул дога хәтеренә килмәсенме!

Ләкин хәл догадан узган иде булса кирәк. Заһиданен янә эче кузгалды. Бу юлы йолкып-йолкып алгандай булып авыртты. Хәле китте, башы әйләнергә тотынды. Егылып китүдән стена гына саклап калды. Чын курку шунда килде. Каян көч тапкандыр, әче тавыш белән кычкырып жибәрде.

—Үләм, ярдәм итегез!..

Заһиданен тавышын кирпеч стена үзенә йотты. Аны берәү дә ишетмәде. Чөнки күршеләре иң тәмле, тан йокысы белән йоклыйлар иде әле. Ишеткән очракта да коммуналь йортта андый тавыш-гауғаларга игътибар итмиләр. Мажаралар монда булгалап кына тора.

—Уф, эчем, эчем кисә.

Заһидә өстерәлеп коридорга чыкты да күршесенен ишеген дөберdәтергә кереште. Бүлмә эчендә кемнендер сукранган тавышы ишетелде.

—Кем бар анда, нәрсә кирәк?—диде.

—Нина, бу мин, Заһидә, скорый чакыр әле... Нина, пожалысты... Үләм...

Заһидә эченен януына чыдый алмыйча идәнгә сузылып төште.

—Хәзер, күгәрченкәем, түзәргә тырыш. Ходай йортына барырга өлгерербез әле,—дип сөйләнә-сөйләнә Нина Заһиданен баш астына халатын йомарлап тыкты да, телефон трубкасына үрелде.

Ашыгыч ярдәм машинасы тиз килеп житте.

Табиб өлкәнрәк яшьтәге кеше иде. Ул сораштыра, төпченә башлаганчы ук Нина ана уксус шешәсенә төртеп күрсәтте. Тегенен йөзе жыерылып менде.

—Күптәнме?—дип сорады.

—Мине уятуына ун минутлар тирәсе.

—Тизрәк, машинага!—дип әмер бирде табиб.

Заһиданe коткарып калдылар.

—Бәхетенә, доза житенкерәмәгән, югыйсә, дөнья белән хушлаша иден,—диде табиб.

Бу дуамаллыгы, акылсызлыгы өчен үзе дә бик борчылды Заһидә. Үз-үзенә кул салган кеше ин гөнаһлы кеше. Элек андыйларнын мәетен зиратка да кертмәгәннәр.

Әмма ин үкенечлесе, баласын югалту булды. Уксус та, салкын тиюдән файдалы дип Татьяна Бугорда эчерткән антибиотиклар да яралгыны тәмам эштән чыгарганнар иде.

Ана аборт ясадылар.

* * *

Кәшшаф соңгы ике көндә чын мәгънәсендә үзенә ял бирде. Чөнки конференциягә кагылышлы мәшәкатьләр инде төгәлләнде дисән дә була. Чыгышының да соңгы вариантына нокта куйды.

Ял дигәне аның өчен мунча чабыну һәм чаңгыда йөрүдән гыйбарәт иде. Хәер, болар аның болай да ярaткан шөгыльләре. Мунчага ул атна саен йөри. Һәр шимбәдә иртәнге сәгать сигездә Болак буендагы мунчаның ишек төбенә барып баса. Иң беренче булып керә. Мунча җене кагылган кешеләр нәкъ менә шушы, иртәнге вакытта йөриләр. Еллар буе. Шуна күрә бер-берсен якын беләләр, дуслашып беттеләр инде. Бу танышлык мунчага үзенә бер ямь өсти. Узыша-узыша мәзәк сөйлиләр, дөньясын онытып көлешәләр. Атна буе җыелган рухи киеренкелек кер белән бергә юыла да төшә.

Кәшшаф пиннекне үзе хәзерли. Урманны аркылыга-буйга таптаса таптый, әмма үзенә охшаган каенны барыбер таба. Пиннекне июнь урталарында, яфраклар ныгып өлгергәч, ләкин картайганчы бәйләргә кирәк. Моның өчен Кәшшаф бер тапкыр да чәчәк атмаган агачларны сайлый. Сындыра башлаганчы иң элек яфракның өске ягын ялап та карый әле, җыерчыклы түгелме, янәсе. Пиннек нәфис, чабынганда тәнне иркәләп торырлык булырга тиеш.

Мунча мәсьәләсендә менә шундый нәзберек җан Кәшшаф. Бу юлы ул үзе генә иде. Чөнки шимбәгә кадәр әле тагын ике көн бар. Мунчада кеше күп түгел. Пары да мул. Ләкин нигәдер мунчаның ләззәтен тоймады. Күзгә бәрелеп торучы сәбәбе дә юк кебек. Соңыннан гына төшенде, чит кешеләрне күтәрә алмый икән ич: кайсысы артык кычкырып сөйләшә, кайсысы кирәк-кирәкмәгәнгә дә су чәчә, душта озак тоткарлана. Үзеннекеләр түгел инде.

Мунчадан ук күнеле төшеп кайтты. Әмма чаңгы шуу барысын да оныттырды. Көне кояшлы иде, якты, дымык. Зәңгәр күлгә сыенып утырган ялгыз йорт торбасыннан чыккан төтен җеп белән тартылгандай төп-төз. Тирә-якта шундый ук төзгә каткан чыршылар тезелешеп киткән. Аларның кызгылт-сары кәүсәләре кояш нурларында җем-җем килә. Кар каткан ботакларда бала йодрыгы чаклы гына кызыл түшле кошчыклар чыркылдаша.

Таныш урыннар. Кәшшаф мондагы һәр сукмакны белә. Әнә, теге төтенле йорт яныннан үткән юлдан китсәң, түгәрәк аланга килеп чыгасың. Дөрес, әле тау төшәсе, берәр чакрым чамасы барасы бар. Күлнең уң ягында да мондагы шикелле үк аллы-гөлле булып нарат агачлары балкып утыра. Аргы очта исә бөтенләй башка манзара. Анда аклык дөньясы. Бөтен нәрсә ак төскә манылган. Ак каен, ак кар, күктә ап-ак болыт челтәрләре...

Юл шома, чаңгылар үзләреннән-үзләре элдертә, колак төбендә җилләр уйнап тора.

Каенлыкка килеп чыккач, Кәшшафның күзләре чагылып китте, әйтерсең лә, күк капусы ачылды. Ян-якларында хур кызлары тезелешкән. Бизәкле көянтәләрен иннәренә асып, бер генә мизгелгә хозурлыкта калганнар.

Акка Ходай җак. Ак төс—шат төс. Татарның яраткан төсе. Пакьлек аклыктан башлана. Агъәби, акъегет, ак тастымал, ак оек... Болар борынборыннан килә. Алтын Урда чорыннан. "Идегәй" дастанына гына күз сал.

Җаектан ашу Актүбә,
Актүбәгә менгәндә...

Әле аның Каргалысы да, Эләге дә бар. Уел, Кыел... Болар безнең ата-бабаларыбыз гомер кичергән төбәкләр. "Татарның тулы йорты". Ул бу хакта язып та чыккан иде. Көлделәр генә. Тәфкилев исә ел йомгакларына багышланган җыелышта: "Бездә дастанны нигез итеп тарих

язучы агач галимнәр дә бар",—дип исемен атамыйча гына аңа төрттереп алган иде. Хәер, андый төрттерүләргә күнекте инде ул.

Кәшшаф уйларыннан арынырга теләгәндәй кулларын җәеп чаңгы өстендә чүгеп-чүгеп алды. Шундый рәхәт. Ул рәхәтнең хәтта тавышы да ишетелә сыман. Кар шулай әсәрләндерә аны. Бәлки, шуңа күрәдер дә кыш ана башка ел фасылларына караганда охшыерак төшә.

Ә менә "Идегәй"дә кар юк. Кызганыч. Туктамыш Алтын Урда ханы, югыйсә. Ә бу дәүләтнең бер канаты Сыр-Дәрья чикләренә кадәр җәелсә, икенче канаты Иртеш, Тутал елгаларын үз ышыгына ала. Болгар, Сарай, Җаек, Идел...

Бату хан, мисал өчен, көнбатышка яу чапканда кырык хатыны арасыннан түгел, бөтенләй читтән, ятимә кыпчак кызы Йолдызны сайлый. Хәрби сәяхәткә алып чыккан җиде сылукайның иң яктысы Йолдыз була. Кем белсен, утрак тормышлы Алтын Урда дәүләтенең барлыкка килүендә Йолдыз шикелле кыпчак мөслимәләренең дә йогынтысы булгандыр. Бату иленә кайтып китмәгән, бабасы Чыңгыз хан васыятенә тугры калып, мөстәкыйль дәүләт оештырган. Һәм ул аның теләгеннән тыш татар дәүләте булып үзгәргән. Тарих шулай ул. Аның үз законнары, барысын да үзенчә актарып ташлый.

Кәшшаф уйларына бирелеп, чаңгыларының түбәнгә юл алуын сизми дә калды. Исенә килгәндә кар көртенә чумган килеш ята иде инде. Бер чаңгысы бөтенләй аягыннан ычкынган, икенчесе агач ботагы арасына кереп кысылган. Кәкресе дә кыелып төшкән. Бер читтә аунап ята. Шулай була ул әлсерәп йөрсәң.

Кәшшаф урыныннан торып, киемнәрен каккалаган җиреннән хәрәкәтсез калды. Аның яныннан гына бер кыз үтеп бара иде. Җор телле, күрәсең.

—Нәрсә, агай, тез буыннары тотмыймы әллә?—дип, җиз тавышлары белән кычкырып көлеп җибәрде.

Кәшшафның ачуы кабарды.

—Мин агай булсам, син әби, йөрмә әле монда эчне пошырып,—диде.

Ул арада тау башында бер көтү чаңгычы кызлар күренде. Выж-выж итеп узып киттеләр. Алдагысы Заһидәгә охшаган, дип уйлады Кәшшаф.

Заһидәне дә шушында чаңгы шуарга өйрәтте ул. Баштагы мәлне ике адымга өч тапкыр егыла иде, үзеннән-үзе "бозау" дип көлә иде. Соңга таба шактый шомарды. Ә бу кышта әле бергәләп чаңгыга басканнары да юк. Әллә нишләде Заһидә. Ордым-бәрдем, чакма таш шикелле очкын чыгарырга гына тора. Соңгы очрашуда, әнә, ниләр генә майтармады.

...Их, чаңгысы әрәм булды. Узган ел гына алган иде.

* * *

Конференциянең беренче көне бәйрәм төсендә узды. Күрешүләр, кочаклашулар, танышулар, җилкә кагышулар. Ах-ух. Шулай булмыйча, бу, мөгаен, дөнья яралганнан бирле татар галимнәренең беренче мәртәбә шушылай җыелышып очрашуыдыр. Сөйләшеп сүз бетми, карашып күз талмый. Өстәвенә, конференциягә җәмәгатьчелек вәкилләре, журналистлар да бик күп килгән иде. Телевидение, радио. Яктырту лампалары балкый. Бу көнне институтның Актлар залы кино төшерү мәйданын хәтерләтә иде.

Нәкъ сәгать унда түрдәге өстәл артына институт директоры Галимов белән министр Сабиров кереп кунаклдылар. Берсе түп кебек юан, икенчесе чырадай юка. Кәрлә кеше биек ишектән иелеп керер, ди. Шуның кебек һәр икесенең дә күкрәкләре дугадай киерелгән. Кыяфәтләре кыз сорарга килгән яучыларныкыннан ким түгел.

Галимов олы бер канәгатьләнү белән залга күз йөгертеп чыкты да

тамагын кырып куйды, тавышын җайга салу иде ахры. Аннан соң микрофонны үзенә таба шуыштырып, залга мөрәҗәгать итте.

—Әфәнделәр... кхе... кхе

Алдан тамак кыруның файдасы тимәде. Күрәсең, кирәгеннән артык дулкынланган иде директор. Тавышы күзгә әтәчнеке кебек чәрелдәп чыгу өстенә, бер минут чамасы ютәлләп тә торды. Сабиров тоттырган стаканнан су йоткач кына рәткә килде. Югыйсә, бик тәэссоратлы итеп башлап җибәрмәкче иде ул конференцияне. Төне буе шул хакта уйланып, төрле-төрле вариантларны күңеленнән кичереп яткан иде. Бик озак баш ватканнан соң "Әфәнделәр вә ханымнар" вариантына тукталган иде. Бу мөрәҗәгать институтта рәсми рәвештә беренче тапкыр яңгыраячак. Әлегәчә "иптәшләр" өстенлек итеп килде. Аның чыгышыннан соң "әфәнделәр вә ханымнар" эрасы башланачак. Үзенә күрә революция. Ихтимал, кемнәрдер инглизларның "ледилар һәм джентельменнар" үрнәгендә зыялы җәмгыятьтә хатын-кызга беренче булып мөрәҗәгать итәләр дип тә әйтерләр. Җавап әзер: мөселман дөньясында һәрвакыт ир-ат алдан йөри. Ул бу нечкәлекләрнең барысын да тәфсилләп уйлап куйган иде. Сабиров белән дә килештергән иде. Көтмәгәндә шушы каһәр суккан ютәл ашына таракан булып төште, яңалыкның тәэсир көчен зәгыйфьләндерде.

—Әфәнделәр вә ханымнар!

Без бу күркәм җыеныбызны янача үткәрергә булдык.

Галимов күз кырые белән генә Сабировка карап алды, бу аның барысы да тәртиптә дип әйтүе иде. Тегесе аны хуплагандай җиңелчә генә башын кагып куйды.

—Торгынлык чорындагы кебек купкешелек президиумнар сайлап тормабыз. Мөхтәрәм президентыбыз безгә котлау җибәргән. Әйдәгез, шуны тыңлап үтик. Сүз Татарстан Республикасы Президентының котлавын уку өчен хөкүмәтебезнең министры Ильяс әфәнде Сабировка бирелә.

Сабиров трибунага бару юлында тукталып калды. Чөнки зал эченнән бер тавыш яңгырады:

—Регламент буенча бер тәкъдимем бар, мөмкинме?

Башлар тавыш килгән якка борылды. Бу арыш сабаклары шикелле тере чәчле, пыялаларына карасу төс йөгертелгән зур күзлекле, шома йөзле кеше Төркия галиме Җансай Хаммат иде.

—Президент котлавыннан соң.

Галимов өчен иң мөһиме, президент котлавы иде. Чөнки ул ана күп көч түкте.

—Мин регламент буенча,—дип һаман үзенекен тукыды Җансай Хаммат.

Зал аны яклап гөжләп алды.

"Тәкъдимен әйтсен"; "Җансайга сүз бирегез"; "Демократия"...

Галимов буйсынырга мәҗбүр булды. Җансай җәт-җәт атлап микрофон алдына килеп басты. Кашларына төшкән чәчләрен учы белән маңгай читенә сыпырып куйды да әйтте:

—Мин җыеныбызны Коръәннән башларга дигән тәкъдим кертәм,—диде.—Бисмилла белән башланган эш бәрәкәтле булыр.

Галимов коелып төште. "Әфәнде"се каян килеп кая китмәгән, әмма мондый ук тирән үзгәрешләргә әзер түгел иде әле ул. Килешенмәгәннитмәгән дигәндәй. Институт бинасында нинди Коръән ди ул? Мәчеткә барсыннар, әнә, Коръән тыңлыйсылары килсә... Ул үзе генә бу мәсьәләне хәл итә алмый. Сабиров та чарасыз кыяфәт белән президент котлавын күкрәгенә кыскан килеш мөнбәр катында басып тора. Гүя Җансай аның кулыннан котлау кәгазен тартып алырга ниятли иде.

Зал янә купты.

—Коръән!

—Коръән!

—Без мулла чакырмадык,—дип котылмакчы булды Галимов.

—Безнең арада Коръән укый белүчеләр бар,—диде Җансай Хаммат.

Шушы сүзне генә көтеп торгандай микрофон янына озын буйлы, кара тут йөзле бер яшь кенә ир-егет чыгып басты. Шунда ук институтның иләннән түшәменә кадәр атеизм исе сеңгән залын тетрәндереп, Коръән укый башлады.

Халык мәйданнардагы шау-шулы митингларга, мәчет манараларыннан яңгыраган азаннарга күнегеп бара иде инде. Әмма дәүләт учреждениесендә, гыйльми институтта Коръән яңгырату—монысы кеше ышанмаслык хәл иде.

Коръән моны язгы ташкын кебек диварларны билән алды. Зал мөкиббән китеп тыңлый. Галимов белән Сабиров кына судан чыккан мәче шикелле шәлперәеп төштеләр. Туктатыргамы бу галәмәтне, аллә белмәмешкә салыныргамы? Тавыш-тынсыз гына үтеп китәрме, җавап бирергә туры килмәсме? Дингә ирек анысы, ләкин дә бит дин башка, дәүләт башка...

Нишлисен, һәр икесе дә Коръәнне дәүләт гимнын хөрмәтләгәндәй аягүрә басып тыңладылар.

—Күрегез инде бу Гобәй белән Хөбәйне, бичарага калдылар бит,—дип пышылдады Әлтаф Кәшшафның колагына.

—Теленне тый...

Кәшшаф программаны күздән кичереп утыра иде. Ул бөтенләй үзгәргән. Докладчылар, чыгыш ясаучылар нигездә татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсендә Галимов теориясен яклаучылар. Ул үзенен фамилиясен дә таба алмады. Шулай ук археолог Рамил Сәмигуллин да, татар шәҗәрәләренен атасы Мазһар Мөхәммәтҗанов та исемлектә юк иде. Димәк, ял иттерәбез дигән булып, башка юнәлеш тарафдарларын конференция эшеннән тулысынча читләштергәннәр.

Ашыгыч рәвештә нәрсәдер эшләргә, ниндидер чарасын күрергә кирәк иде. Әгәр хәзер авыз йомып калсаң, кәкре каенга сөяп кенә калмаслар, кадаклап ук куярлар. Һәрхәлдә, ятып калганчы атып калу мәслихәт.

Кәшшаф муенын ата каздай алга сузып, залдагы кешеләр арасыннан дусларын эзләде. Сонгарак калып килгәннәр иде, күрәсен, Рамил дә, Мазһар да ин арттагы рәттә утыралар иде. Язу язды да шул тарафка җибәрде. Мазһар тиз кабынучан, шырпы гына сыз. Рамилнен холкы бөтенләй башка. Басынкы, акрын, сүзен уйлап кына әйтер. Теге вакытта хәзинә тәнкәләре югалу мәрәкәсе белән аралары бераз суынып торган иде торуын, тик ул озакка бармады, анлаштылар. Бер бетле кәҗә өчен бөтен көтүне гаеплегә чыгарып булмый ич инде.

Язу ияләренә барып иреште ахры, Мазһар ат ялыдай озын чәчле башын чайкый-чайкый кулын изи башлады. Ул чыдый аламы соң, үзләре янына чакырды. Залдагы шау-шудан файдаланып, Кәшшаф алар янына күчте. Әлтаф: "Ә мин",—дип авызын бүлтәйтеп калды.

—Әйдәгез, бойкот йөзеннән конференцияне ташлап чыгып китәбез,—диде Мазһар. Бу тәкъдим анын үзенә бик ошый иде булса кирәк, канәгатьләнүеннән кулларын угалап алды.

—Тсс, акрын,—диде Рамил.—Белегез, мин конференцияне ташлап чыгарга җыенмыйм.

Мазһар ана шундый зәһәр итеп карап алды ки, керфекләренә ут кабына язды.

—Сатлык...

—Җә, җә!

Кәшшаф дусларын тынычландырырга теләп, берсенен аркасыннан какты, икенчесенен кабыргасына төртеп алды.

—Ә үзеннен тәкъдимен ничек соң?—дип сорады Рамилдән.

—Мин өчебез исеменнән белдерү белән чыгарга кинәш итәм.

—Бик яхшы,—диде Кәшшаф.

—Бу эшне синен үзенә тапшырабыз,—диде Рамил.

—Барыбер абзыйның мыегын чуалтып алырга кирәк иде,—дип

үзенекен сукалады Мазһар.—Әнә, читтән килгән кешеләрдән үрнәк алырга кирәк.

Кәшшаф микрофон янындагы чиратка барып кушылды.

—Без, бер төркем галим,—диде ул үзенә сүз бирелгәч,—конференция Болгар теориясенә генә өстенлек бирергә җыена, дип саныйбыз. Алтын Урда тарафдарларын турыдан-туры дискриминацияләү бара.

Галимов барлы-юклы юмор сәләтен эшкә җикте.

—Нәрсә, Болгар дәүләтен җимергән, безнең ата-бабаларыбызны кыерсыткан баскынчы татар-монгол явын яклаучыларны уч төбендә йөртергә кинәш итәр идегезме әллә?—дип залның ким дигәндә елмаюын көтте. Тик нияте барып чыкмады. Кәшшафның җавабы да җитди иде.

—Шәрыкның мөхтәрәм акыл иясе Мөхәррәм Фәйзи Тугай,—диде һәр сүзенә тирән мәгънә салырга тырышып,—сез яу дип тамга суккан татар-монголларга бөтенләй башка бәя бирә. Ул Чыңгыз Япон, Кытай дингезләреннән Хәзәр дингезенә кадәр яшәгән бөтен төркиләрне бер байрак астына туплады,—дип күрсәтә.—Сез, ихтимал, Чыңгызның Алтын Урдага катнашы юк, диярсез. Бар. Алтын Урда аның васыяте буенча төзелгән.

Галимов шунда ук Кәшшафның капкасына туп тондырды.

—Әгәр баскыннарны прогресс рәтенә кертәсез икән, ни өчен соң ул чакта руслар агрессор?—дип Кәшшафка бакты.

—Моның икесе ике нәрсә, Сәүбән Сәүбәнович,—диде Кәшшаф,—беренче очракта зур төрки дәүләт оеша, икенчесендә төрки дәүләт тармар ителә.

Бу чәкәләшүне туктату өчен Сабиров сүзгә кушылырга мәҗбүр булды.

—Әфәнделәр, демократия демократия белән, әмма конференцияне дә башларга вакыт,—диде шаяртыбрак,—бәхәсләр булды, бар, булачак та. Әйдәгез, алар турында цивилизацияле алымнар белән сөйләшик. Программа нигезендә.

Җыен, ниһаять, үз эзенә төште. Өчлекнең белдерүе дә, Кәшшафның җитди нигезләмәләре дә конференциянең өстә расланган тәртибенә үзгәреш кертә алмады. Шаулашсалар да, кул күтәргәндә барыбер директор сүзеннән чыкмадылар. Шул ук вакытта бу инде тоталитар режим вакытларында үтә торган фәнни җыеннардан бик нык аерылып тора иде. Гади бер гыйльми хезмәткәрнең җәмәгатьчелек алдында директор белән бәхәскә керүе үзе үк зур алга китеш ләбаса! Әйтик, Кәшшафны берәүләр хуплады, икенчеләре ирен кыйшайтты. Тик ни генә булмасын, ул конференциянең популяр кешесенә әверелде. Җансай Хаммат та узып барышлый кулын кысып китте.

* * *

Беренче көн шул рәвешле узды. Ыгы-зыгысы да, уен-көлкесе дә, танышу-белешү мизгелләре дә, ризасызлыклар да—барысы да булды. Инде тынычландылар шикелле. Әмма ул кызыл авызларны узындырырга ярамый. Ирек куйсаң, алар фәнне мал утарына әйләндереп бетерәчәкләр. Дөрес, чебеннән дулап тәрәзәне ватканы юк. Ләкин дә саклык һич тә зыян итмәс.

Иртән Галимовны тагын да хәтәррәк вакыйга көтеп тора иде. Фатирыннан сәгать сигездә үк чыгып китте. Урынбасарларына, бүлек мөдирләренә дә иртәрәк килергә кушкан иде. Оештыру эшләренә кагылышлы барлык мәсьәләләрне дә иртәнге саф баш белән янә бер мәртәбә карап чыгу иде исәбе. Шөкер, бу яктан аның тәҗрибәсе зур, күршегә керәсе юк.

Гадәтенчә, институтның киң ишеген киереп ачып эчкә узды. Ярата иде ул институтны, анда үзе урнаштырган тәртипне ярата иде. Хәзер менә ишек уемында аның гәүдәсе пәйда булуга, вахтер хәрбиләрчә үрә

катып, аны сәламләячәк, төннен ничек узуы хакында кыска гына белешмә бирәчәк. Шуннан сон Галимов ирен очлары белән генә жинелчә көй сызгыра-сызгыра икенче катка менеп, кабинетына юнәләчәк. Очраган бер кеше баш иеп сәлам бирәчәк, хәерле көн теләячәк.

Ә бүген, башка көннәрдән үзгә буларак, вахтер аны борчулы кыяфәт белән каршы алды. Үзе дә ниндидер ят ис сизгәндәй борыннарын жыерды.

—Харис, ни булды?—дип сорады.

—Иптәш директор, анда, вестибюльдә,—дип пышылдады вахтер ниндидер әйтергә ярамаган сер житкергәндәй.

—Аңлатыбрак сөйлә!—дип тавышын күтәрде Галимов.

Ул арада анын янына Тәфкилев килеп басты.

—Са-а-ба-кы,—диде ул бөтен ачуын интонациясенә салып.

—Кем сабакы, нигә әле сез бүген барыгыз да Эзоп теле белән сөйләшәсез?—диде Галимов. Анын кәефе тәмам кырылган иде инде.

—Кем булсын инде, Хәмитов!

Чеметеп алган шикелле Галимовнын йөрәге сызланып алды. Тан тишеге белән тагын ни-нәрсә майтарды икән инде ул мокыт? Сүз дәгъвали булыр, мөгаен. Ябышкак...

—Көн тәртибе кабул ителде, мин аны боза алмыйм, хакым юк, аңлыйсызмы, хакым юк!—дип кычкырды чыгырыннан чыккан директор.

—Ул ачлык игълан иткән,—дип, ниһаять, Тәфкилев мәсьләгә ачыклык кертте.

—Ачлык?!

Галимовның ияге салынып төште. Ләкин үзен шундук кулга алды. Жебеп төшә торган вакытмы соң? Тагын ярты сәгатьтән кешеләр килә башлаячак. Халыкара скандал ич бу!

—Кайда утыра?—дип сорады Галимов кискен бер нәтижәгә килеп.—Кая ул?

Галимов йодрыкларын төйнәп, шул якка юнәлде. Аралыкка житкәч туктап, берара Кәшшафны читтән генә күзәтеп торды. Кәшшаф канәфигә чумып утырган иде. Шунда гына эре хәрефләр белән ниндидер язулар язылган плакат бар. Күрәсен, таләпләрен шунда теркәгәнлер. Догага талган хәзрәт кебек оеп утыра. Янына Галимов белән Тәфкилев килеп баскач та килеш-килбәте үзгәрмәде.

—Сез мине түгел, институтны, бөтен татар галимнәрен мыскыллыйсыз,—диде Галимов.—Әгәр жаныгызда аз гына булса да ихтирам дигән хис бар икән, алып ташлагыз бу язуларыгызны, туктатыгыз ачлыкны! Мәсхәрә! Гыйльми даирәдә үзеннең хаклыгынны дәлилләр белән исбатлыйлар.

Тәфкилев музыкантларныкы шикелле озын бармаклары белән Галимовнын жилкәсенә орынгандай итте. Янәсе, юлдан тайпылмагыз, безгә бәхәсләшергә түгел, кешеләр килгәнче вестибюльне бушатырга кирәк. Галимов аны бик тиз аңлап алды, шундук тактикасын үзгәртте.

—Мин сезгә, жаен табып, соңгы пленар утырышта ничек тә сүз бирергә тырышырмын, Хәмитов,—диде,—зинһар, институтны мәсхәрәгә калдырмагыз бу кыланышыгыз белән.

Кәшшаф директорнын йөзенә күтәрелеп карады. Көлемсерәгәндәй итте. Күр, абзабыз мескенләнә дә белә икән ич!

—Мин сездән сүз сорамыйм,—диде ул,—мин без шөгыльләнгән фән юнәлешен рәсми тануны таләп итәм.

Тышкы авыр ишекнен ачылып ябылганы ишетелде. Кемнәрдер сөйләшә-сөйләшә баскычтан менде. Галимовнын башына кан бәрде: берүк бу якка гына борыла күрмәсеннәр!

Теләге кабул булды, узып киттеләр.

—Үтенәм,—диде Галимов.

Тәкәббер, үзен генә көйләтергә өйрәнгән, кешеләргә баш очыннан гына карарга күнеккән һавалы Галимов авызыннан әлеге сүзнең ычкынуы гадәттән тыш хәл, искитәрлек зур түбәнчелек иде.

Кәшшаф исә бу сүзнең чын күнелдән әйтелүенә ышанмады. Көлү, мыскыл итү дип кабул итте.

Алар анлашырга өлгермәделәр, вестибюльгә песи кебек йомшак кына басып, Җансай Хаммат килеп керде. Әйе, килеп керде. Чөнки вестибюль дип йөртелсә дә, ул институт бинасының уң канатында стенага уеп ясалган зур гына бүлмә. Ишеге генә юк. Аны бик матур итеп җиһазладылар. Очрашулар өчен, ял итү өчен бик күркәм урын. Үзе аулак, үзе тыныч.

Җансай адашкан иде булса кирәк. Тик таныш йөзләрне абайлап алгач, тынычланды. Аның болай да Галимовны күрәсе бар иде. Университетның борынгы китаплар китапханәсендәге кайбер кульязмалар кызыксындыра иде аны. Исәбе, бүген төштән соң шунда барып эшләп алу иде. Галимовтан булышлык сорарга ният иткән иде. Ә Кәшшафны ул кичә пленар утырышта ясаган белдерүе, конференция рәисе белән булган полемикасы буенча исендә калдырды. Якыннанрак танышырга кирәк, дип күнеленә беркетеп куйган иде. Аңа үз фикерен яклый белүче тәвәккәл кешеләр ошый. Ул үзе дә бәхәскә керүдән тартынмый. Төрекләр аны "Тискәре татар" дип йөртәләр, әмма шул сыйфаты өчен ихтирам да итәләр.

—Әссәламегалейкүм, хәерле иртә, әфәнделәр, исәнмесез,—дип ул тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды.

—Вәгалайкем әссәлам,—дип сәлам кайтарды Тәфкилев,—хәерле иртә.

Галимов бөтенләй каушап төшкән иде. Кәшшаф та шундый ук хәлдә иде. Арада иң тапкыры Тәфкилев булып чыкты. Сөйләшеп торган арада җәт кенә Кәшшафның "Ачлык программа"сын алып, шкаф артына яшереп куйды. Яңа дусларының бу дулкынлануларын Хаммат конференция мәшәкатьләренә аударды. Халыкара җыен уздыру һич тә уен эш түгел.

—Гафу итегез, комачауладым, ахры,—диде Җансай кыенсыныбрак.

—Юк-юк, ни сөйлисез сез, без... болай гына...

Галимов Җансайның кулыннан эләктереп алды да озак кына селкеп торды. Аннан соң итәгенә ут капкандай вестибюльдән чыгып йөгерде. Бүлмәсенә керүгә диванга ауды. Секретарь кыз ай-вай килә башлаган иде дә, аны бик коры тотты.

—Шәфкать туташын чакыр, тизрәк,—диде. Аннан соң:—Кеше күрә күрмәсен,—дип өстәде.

Бер-ике укол алып, дарулар эчкәч кенә игә килде Галимов.

Кәшшаф үзе дә иләс-миләс хәлдә иде. Ни-нәрсә булганын аңышмыйча да калды. Тәфкилевнең сүзләре генә аны айнытып җибәрде.

—Син неудачник,—диде ул русчалатып,—булдыксыз. Шуңа күрә башкаларны күрәлмыйсың, көнләшәсең. Конференция беткәнче генә ачуынны чыгармый торсаң була иде ич инде. Бу—намуссызлык.

Тәфкилев ниндидер җирәнгеч нәрсәдән арынырга теләгәндәй ыспай костюмын сыпыргалап алды да сәхнәдәге артист шикелле тык-тык басып китеп барды.

Кәшшаф ачлык урыны итеп сайлаган кәнәфиенә чумды. Башын тотып, шактый ара уйланып утырды. Чыннан да, ул булдыксыз бәндә. Тәфкилев дөрес әйтә. Ни кырганы бар соң әле аның? Гомере үзенә урын яулау белән үтә. Гыйльми эш белән шөгыльләнәсе урынга ул кемнедер фаш итә. Ник соң әле һаман аның тәгәрмәченә генә таяк тыгалар? Димәк, кешеләр белән уртак тел таба белми, димәк, сайлаган юлы, юнәлеше башкаларны кызыксындырмый. Бәлкем, барысына да төкерергәдер? Диссертациясенә дә, монографиясенә дә. Татар тарихының язмышы шул, күрәсең, аңа элек тә баш калкытырга ирек бирмәгәннәр.

Мәгәр куанырлар иде Тәфкилевләр. Хәмитов гыйльми банкрот дигән нәтиҗә дә чыгарып куярлар иде. Һәм бу Кәшшафның алар өчен иң майлы калҗасы булыр иде. Ихтимал, ачлык мәсьәләсендә чыбыкны артыграк та бөгеп җибәргәндер, әмма болай ансат кына чигенергә тиеш түгел ул. Остазы Ашказарский да хупламас иде аның бу гамәлен.

Ачлык игълан иткәнен кешегә белгертергәме-юкмы? Жансай аны-моны анышмады кебек. Галәти кинәш-табыш дип уйлады булса кирәк, төпченеп тормады. Әйдә, аларча булсын инде. Рамилләргә дә серне соныннан гына чишәрдер ахры, нигә безнен белән килештермәден дип үпкәләүләре бар. Ул сюрприз ясамакчы иде, барып чыкмады бит, нишлисен.

Кәшшаф коридорга чыкты. Кешеләр жыелыша иде инде. Төркем-төркем оешып гәп коралар. Тирә-як гөж килеп тора.

Ул бер төркемгә дә кушылмыйча алашкан каз шикелле кая барып бәрелергә белмичә аптырабрак торды. Бу шат, көләч йөзләр анын китек күнеленә ямау була алмый иде. Бүлмәгә кереп бикләнүдән дә яхшысы булмас дигән карарга килде. Шунда Әлтафны күреп алды. Янында Мазһар да бар. Әлтафынын авызы ерык, күзләре чабыш атыныкы шикелле ялт та йолт килә. Ул кеше арасында үзен судагы балык шикелле хис итә. Ояла да белми, тартынмый да. Шаяра, көлә, мәзәк сөйли. Әле дә шаран ярды:

—Кәшшаф әфәнде, рәхим итегез, бөтен жиһанга сибелгән татарларны дисбе шикелле бер шәжәрә жебенә теркәгән зур галимебез Кара хужа! Космополит, дөнья гражданины!

Кара хужа Мазһар Мөхәммәтжановнын кушаматы. Бу анын беренче тапкыр археографик экспедициягә чыккач аяк баскан авыл исеме. Яшел Үзән төбәгендә. Борынгы, тарихлы авыл. Авыл уртасында агып яткан кечкенә генә елга ярында Алтын Урда дәверендә гамәлдә йөргән татар тәнкәләреннән торган хәзинә күмелгән булган. Ул тәнкәләрнен кайберләре бер үзешчән тарихчыда сакланып калган. Әмма авылда тәнкәләрдән тыш бер атна эчендә йөздән артык кулъязма китап таптылар. Шунда ук Казан ханлыгына бәйле Кара хужа нәсел шәжәрәсе фрагментларына да тап булдылар. Үтәк шәжәрәсе дә әлеге экспедиция вакытында кулга керә. Бик нәтиҗәле сәяхәт була ул. Шуна күрә Мазһар аны әле дә ике сүзнен берсендә телгә ала. Әлтафка жай гына чыксын, кушаматны тагып та куйды.

—Жалантайнын теле ачы, жабага тайнын бете ачы ди, күрсәтәм әле мин сина күрмәгәненне, жыр корты,—диде Мазһар.

Ул үзе Адәм пәйгамбәр шикелле мәһабәт гәүдәле кеше. Үлчәп карасан, буе да төп төгәл алтмыш аршын булырдыр, мөгаен. Яшь чагында спорт белән шөгыльләнгән. Әле дә артык-портык жире юк, буй-сыны коеп куйган кебек. Әлтаф анын янында маймылга охшап тора. Биле, арт саны, жилкәсе—барысы берочтан. Йөргәндә дә ян-якка янтаеп йөри. Мазһарнын шуна төрттерүе иде. (Жалантай үрдәк кебек йөри торган зәгыйфьрәк кешене анлата.)

—Бергә—бер,—диде Әлтаф,—яратам тапкыр кешеләрне. Инде гыйлемлегенне дә сынап карыйк, шәжәрәдән башканы беләсенме икән? Мин башлыйм, син тегәллә:

—Үзенә, гаунатик, юк чис,
Проклятый, сабаке, пис
—Тоташ йир казадыр ул бис,
Корытмаклыр, абыстай ла.
—Сыман кеби утын-тукмак,
Селәгәе агар—супляк
—Кочаклаган булыр, дупляк,
Тәнен хурлап, абыстай ла!

—Афәрин,—диде Әлтаф башын артка чөеп,—абыстайларны Кандалыйдан ким күрмәгәнгә охшыйсын.

Бу уенга Рамил Сәмигуллин гына катнашмады. Ул мондый буш сүзләрне өнәп бетерми. Әле дә: "Кешедән оялыр идегез,—диде,—халыкара фәнни конференция ләбаса. Башкаларга колак салыгыз әнә..."

—Күп ноктлар белән сөйләшмә,—дип бүлде аны Әлтаф,—жир казып йөри-йөри кыргыйланып беткәнсен инде син, Тарзанга әйләнгәнсен.

Алар яныннан җил-җил атлап Тәфкилев узып китте.

—Түрәләрне каршы алырга ашыга,—диде Мазһар,—безгә дә кузгалырга вакыт.

Дөрестән дә, җилем көпшә шикелле сузылган тар коридорның югары очында Сабировның чалтин балыктай нәзек гәүдәсе күренде. Ешеш атлый, әйтерсең лә, артыннан куып китәләр. Ә үзе килә-килешкә очраган кешеләргә кулын биреп уза. Кәшшафлар янында исә бөтенләй туктап калды.

—О-о, оппозиция, сәлам-сәлам.

—Ялгышасыз, Ильяс Хәбирович, оппозиция түгел,—диде Кәшшаф,—без татар халкының имгәнгән тарихын төзәтергә теләүчеләр генә.

Сабировның юка иреннәре дерелдәп куйды.

—Ну, җилкәгез су күтәрми дә инде, егетләр, шаяртам гына ич инде. Сезгә кем каршы соң? Бик рәхмәт, бик игелекле эш эшлисез. Каршылыклар, аңлашылмаучылыклар булыр инде ул. Диалектика!

Әлтаф та түрәгә җорлыгын күрсәтергә ашыкты.

—Диалектика—беренче блюдо, марксизм—закуска, дарвинизм—дессерт.

Сабиров Әлтафның мәзәген кабул итмәде, ахры, Кәшшаф ягына таба борылды.

—Кәшшаф Газизович, бу мәшәкатьләр узгач, сезнең белән очрашып сөйләшергә планлаштырып торам, вакыт җитте дип уйлыйм,—диде.

Сабиров артыннан җептәге энә шикелле тотам да калмый тагылып йөргән Тәфкилев куырылып төште.

Төшкә кадәр утырышны Җансай Хаммат алып барды, аны Мәскәү галиме Әдһәмов алмаштырды. Докладчыларның һәммәсе алдан хәзерләнгән текстын үтемле итеп укып чыгарга тырышты. Кайсысы моңа иреште, кайсысы—юк. Залда авызларын ачып, иснәп-иснәп тә алгалый башладылар. Астыртын гына сәгатьләренә күз төшергәлиләр, тәнәфес җиткәнне көтәләр. Тәнәфестә дусларың белән аралаша аласың, чәй-кофе тәкъдим итәләр. Телисең икән, ял бүлмәсенә рәхим ит.

Кеше шундый нәзберек җан инде ул, бертөрлелектән бик тиз ялыга. Югыйсә, конференция турында ничәмә-ничә ай сайраганнар иде.

Шулай да кичке якта залда бер җанлану булып алды. Аңа Тәфкилевнең чыгышы сәбәп булды. Аның фикеренчә, Идел—Урал төбәгендә этносларның берсе китеп, икенчесе килеп тормаган, бары аларның гомуми атамалары гына алмашынган. Бу шуның белән аңлатыла: төрле чорда хакимияткә төрле кабилә вәкилләре килгән, хакимияттәге кабиләнең исеме киң мәйданга чыккан, халкын да шул исем белән йөртә башлаганнар. Татар атамасы болгар чорында басып алучылар тарафыннан көчләп тагылган. Татар дигән халык Болгарга үзе түгел, исеме генә килгән.

Беренче булып Румыния галиме Мәхмүт Әхмәди бәхәскә ташланды.

—Җәмәгать,—диде ул кулларын бутый-бутый,—нинди тылсымлы халык булган соң ул "татар" дигәннәре. Әкияттәгечә, күзләре бар, үзләре юк, үзләре бар, күзләре юк. Япон диңгезеннән Хәзәр диңгезенә кадәр арада төрки-татар теле хөкем сөрә, ә Тәфкилев әфәнде татар юк, булмаган, дип тәкрарлый. Теле бар—халкы юк. Халкы—болгар, теле—татар. Бик кызык теория кайсыдыркы.

Монысы беренчедән. Икенчедән, Идел—Урал төбәгендә яшәгән халыкның мокытлыгы шаккаттыра мине. Чын-чынлап җебегән авызлар. Хакимияткә килгән берсе аларга үз исемен таккан. Ләббәйкә генә дип торганнар, күрәсең. Ләкин...

Мәхмүт гәүдәсен турайтып залга карады, янә кулларын буташтырып алды.

—Ләкин, җәмәгать, ә нигә алар монгол исемен алмаган? Ауны монголлар оештырган ич. Чыңгыз—монголлар башлыгы. Хәзерге тарихчыларның исбатлавынча, татарларны алар көчләп үзләренә буйсындырган.

Логика буенча, болгарлар татар исемен түгел, монгол исемен алырга тиеш иде.

Минем уемча, проблеманың ачкычы нәкъ менә шушы сандыкта ята да инде. Әлеге дә баягы, Япон дингезеннән Хәзәр дингезенә кадәрге илаһи зур мәйданда төрки-татар халкы яшәгән. Монголлар аларны йотар хәлдә булмаган.

Төрки телле татарларның булуы турында IX гасырда ук кытайлар язып калдырган. Урта Азия галиме Мәхмүт Кашгари, Персия тарихчысы Әл-Гардизилар да бу теманы читләтеп үтмәгәннәр. Шунысын да әйтик, Хива ханы һәм тарихчысы Габдел Гази мәгълүматларына караганда, татарларны Көнчыгыш Аурупада, аерым алганда, Венгриядә, Русьта, Идел буе Болгарстанында монгол басып алуына кадәр ук яхшы беләләр, аралашып яшиләр. Алтын Урда дәүләтендә исә татарларның монголлардан сан ягыннан күпкә артык булуы инде бәхәс тудырмый. Моны рус тарихчылары Татищев белән Карамзин да таный. Сонарыбрак әлеге фикергә археолог Веселковский, күренекле татар тарихчысы Сәфәргалиев та килеп кушыла. Лев Гумилевның төпле ачышлары әлеге теориянен нигезен тагын да ныгытты. Күренә ки, Алтын Урда—татар дәүләте. Шул ук вакытта аның канатларында казахлар, сартлар, башкортлар һ. б. халыклар да булган, билгеле.

Мин мәсьәләне бераз гына гадиләштерәм, әлбәттә, әмма хакыйкать шул сандыкка салынгандыр дип уйлыйм. Татар теле мона дәлил. Минем Осман империясе вакытында Төркиядә тупланган төрле язма чыганаклар белән танышканым бар. Татар ханнарының ярлыкларын аңлау өчен, мәсәлән, тәржемә кирәк түгел. Борынгы татар әдәбияты ялкяре "Куман мәҗмугасы" бу фикергә иң көчле дәлил.

Татар теле Алтын Урдадан соң чүпләнә башлый, шуннан соң ныклап гарәп-фарсы йогынтысына эләгә. Бу—факт. Монда, һичшиксез, ислам диненең дә роле зур. Ислам, бер яктан, тотрыклылык, рухи бөтенлек, үсеш алып килсә, икенче яктан, телне чүпләүгә юл ача.

Мәхмүт Әхмәди сүзен тәмамлап урынына барып утырды. Зал бермәлгә тын калды. Ул мондый сүзләргә күнекмәгән, бирелә мона кадәр фәкать рәсми сәясәткә туры килә торган нотыклар гына яңгырады. Татарны һаман болгар эчендә әвәләделәр, күрә торып чикләрен кистеләр, олылыгын инкарь иттеләр.

Галимов әледән-әле пеләш башын кулъяулыгы белән корытып-корытып ала. Ул Сабиров белән янәшә алгы эскәмиядә утыра. Янында ук башка түрәләр. Борчылалар булыр. Иң вак илэктән үткәреп тә ни кадәр чүп чыга бит, ә? Хәер, чит илдән килгән галимнәр ни әйтмәс? Ана карап гомуми юнәлешне үзгәртеп булмый ич инде. Алар бүген—монда, иртәгә—тегендә.

Шулай да болгарчыларга һөҗүмнең иң җиллесе алдарак булган икән әле. Бу инде сиңа урындагы өч-дүрт бөртек "узгынчы татар" гына түгел. Тенденция. Шунысы белән куркыныч та. Тамчы да бит тама-тама ташны үтәли тишеп чыга.

Тәнәфестән соң мөнбәргә өстәл астыннан гына тәгәрәп чыккандай туп шикелле йомры гәүдәле бер кеше килеп басты.

—Мин чуваш язучысы булам,—диде ул саф татар телендә.—Ямаш атлымын. Рөхсәт итсәгез дә, итмәсәгез дә сөйләячәкмен. Чөнки мин заявкамны алдан ук язмача җибәргән идем. Нигәдер җавапсыз гына калдырдылар.

—Сөйләсен,—дип кычкырдылар залдан.

—Рәхим итегез,—диде Әдһәмов.

Ямаш аксыл керфекләре аша залга карап алды да тук тавыш белән сөйләп китте.

—Мин төрки тарихыннан азмы-күпме хәбәрдар,—диде ул,—тарихи әсәр язарга да ниятем юк түгел. Әлегә мәгълүматлар туплау белән мәшгульмен. Татарлар арасында үзләрен болгар дип йөрүчеләр шактый

күп. Мөгаен, күпчелектер дә әле. Тик бу дөреслеккә туры килми. Болгар—ул чуваш. Телебез дә, гореф-гадәтләребез дә, үз-үзебезне тотышыбыз да туры килә. Тырыш, үҗәт, үзсүзле, булдыклы халык булган безнең бабаларыбыз. Хәзерге чувашларга да шундый ук сыйфатлар хас. Тискәрелек, туң мангайлык та бар, инкарь итәргә ярамый. Мин 1902 елда Ашмаринның Казан университеты типографиясендә басылып чыккан "Болгары и чуваши" китабынын төп положениеләре белән килешәм. Татар галимнәренең болгарга тулы монополиясен кире кагам. Мин Шиһабетдин Мәрҗани белән дә болгар-чуваш мәсьәләсендә килешә алмыйм. Ул аны бик җинел аңлата, кабер ташларындагы чуваш сүзләрен очраклык дип кенә күрсәтергә омтыла. Чувашлар, имеш, ислам диненә әле кереп, әле чыгып буталып йөргәннәр. Алай гынамы, кайбер татар галимнәре "чуваш" төшенчәсен этноним булудан бигрәк, "кара халык", "түбән сыйныф вәкиле" мәгънәсендә дә шәрехлиләр. Чынында чуваш "Суаз" исемендәге болгар кабиләсенә карый. Әлеге атама гарәп илчесе Ибн Фадлан язмаларында да телгә алына. "Чуваш" этнонимы үзатама. Бу—бәхәссез. Аннан соң, "ясаклы чувашлар"—ни рәвешле XVII йөзнең икенче яртысыннан "ясаклы татарлар"га әверелгәннәр. Моны ачыкламыйча торып, Урта Идел буенда барган катлаулы этник процессларны күзаллау мөмкин булмаячак.

Шунысын да әйтергә кирәк, болгарлык өчен тарткалашу күптәннән килә. Бу гаугалы ызгыш учагына беренче шырпыны XIX гасырның алтмышынчы елларында атаклы миссионер Н. Ильминский сызган диләр. Хикмәт шунда, чувашлар, марилар, мордвалар, удмуртлар мәҗүсилекне ташларга теләмәгәннәр, христиан динен кабул итүгә бик нык каршы торганнар. Алай гынамы, татарлар тирәсенә тартылып, ислам диненә унай карый башлаганнар. Менә шунда ике арага кара мәче җибәрү зарурлыгы туа. Һәм Ильминский аны җибәрә дә. Ләкин бу һич тә Ильминский коры җирдән көймә йөрткән дигән сүз түгел.

Ямашның үзенә дә эләкте, билгеле. Ябырылдылар гына, наданлыкта, тупаслыкта, тагын әллә нәрсәләрдә гаепләделәр. Тик шулай да, әйтәсе әйтелгән иде инде. Сүз чыпчык түгел, аны оясына куып кертеп булмый.

Кәшшафка конференциядә рәсми рәвештә сүз бирделәр. Матавыклана торгач, тәки үзенекен итте. Аның чыгышы доклад сыйфатында теркәлде. Димәк, үзгәртелмичә фәнни җыентыкларда да басылып чыгачак.

Ул Алтын Урданың татар дәүләте булуын, бүгенге татар халкының Алтын Урдада яшәгән халыкларның турыдан-туры дәвамчысы икәнлеген тарихи фактлар нигезендә дәлилләргә тырышты. Ни гаҗәп, Ямаш фикере белән аның фикере охшаш иде. Дөрес, ул болгарны чувашка гына кайтарып калдыруга каршы. Әмма болгар татарның бер кечкенә кыйпылчыгы гына. Безнең бабаларыбыз—татарлар. Исемнәре дә татар, үзләре дә татар.

—Тарих кемгәдер ошамаска да мөмкин, шулай ук ул яратуга да мохтаҗ түгел. Иң мөһиме, тарихлы булу,—дип төгәлләде сүзен.

Ошаттылар. Тәнәфес вакытында килеп-килеп кулын да кыскаладылар. Җансай Хаммат рус тарих фәненең ни өчен татарларга начар мөнәсәбәттә булуы турында сорашты. Кәшшаф чыгышында әлеге мәсьәләгә тукталып: "...рәсми тарих фәненең зур тырышлыгы нәтиҗәсендә татарны Болгар чорында калдырдылар",—дигән фикерне ассызыклаган иде.

Үзе тоткынлыкны кичермәгән кеше тоткынлыкның ни икәнен аңламый бит ул. Җансай да рус дәүләтенең диктатын, империяне саклауга юнәлдерелгән сәясәтен төшенеп җиткерә алмады ахры. Аның урынына, якынлашып киттеләр. Чит ил галимнәре янында бөтерелүчеләр болай да хәттин ашкан иде. Чөнки һәркемнең нинди дә булса берәр бай чит ил фонды исәбенә йә сәяхәткә чыгасы, йә нинди дә булса бер эш эшләп каласы килә. Галимов булып Галимов та алар алдында тәлинкә тота.

Җансай Хаммат аны кунакханәгә чакырды.

Кәшшаф пошаманга төште: күчтәнәч-фәлән алып барыргамы, алып

барсаң, ни-нәрсә алып барырга? Галәттә, чит илдән килгән кунакка түбәтәй бүләк итәләр, чәкчәк белән сыйлыйлар. Тик бу көннәрдә аларга бүләк иткән түбәтәйләрдән кибет ачарга булыр иде, мөгаен. Чәкчәк ашап та авызлары балланып беткәндер.

Чит ил кешеләренең ни яратканын белә ул, әлбәттә. Борынгы әйбергә мөкиббән алар. Андый хәзинә Кәшшафта юк. Булса да кулыннан ычкындырмас иде.

Озак кына... баш ватканнан соң Кәшшаф, ниһаять, Такташның Мохтар бабае шикелле бик гали чишелеш тапты. Куеныңа бер шешә коньяк кыстырды да, чакырган җиргә юнәлде. Ир-ат лабаса алар!

Җансай Хаммат "Болгар" кунакханәсендә яши иде. Ул Кәшшафны якты чырай белән каршы алды. Өстендә зәңгәр төстәге озын халат, аны кин билбау белән путалап куйган. Башында—фәс. Аягына бизәкле йомшак башмаклар элгән. Чын төрек бәе. Бүләк түбәтәйләр тәрәзә төбендә өелеп тора.

—Рәхим итеп узыгыз, Кәшшаф әфәнде,—дип, Җансай кәнәфидән урын тәкъдим итте.

Кәшшаф өске киемен аскы катта ук салып менгән иде. Шешәсе—куен кесәсендә. Инде аптырашта калды: чыгарыргамы—юкмы? Хамматның үз буфетында да шешәләр күренә. Ләкин берсе дә башланмаган. Бигрәк тә шул сагайтты. Бәлкем, бөтенләй кулланмыйдыр? Алай дисәң, ничек итеп бу шешәләр буфетка кунаклады икән соң?

Кәшшаф кесәсендәге шешәсен күкрәгенә кыскан хәлдә хуҗа күрсәткән урынга утырырга мәҗбүр булды. Шулай итеп, бүләк бирүнең унайлы мизгелен кулыннан ычкындырды.

Кәшшаф алдан ук күнеленнән татар тарихына кагылышлы шактый темаларны барлап куйган иде. Алтын Урда чорын өйрәнүче буларак, әлбәттә, беренче чиратта игътибарны шуңа юнәлтәчәк. Җансай үзе дә әңгәмә вакытында: "Алтын Урда татар милли тарихының нигезе. Аны яшереп калдырып та, кире кагып та булмый",—дигән иде.

Кәшшаф бик акыллы кыяфәт белән шул хакта сүз кузгатты. Ләкин Җансай аның сүзен күтәреп алмады.

Радиодан соңгы хәбәрләр тапшыралар иде. Конференцияне дә бик зурлап телгә алдылар. Җансай Хаммат исеме дә яңгырап китте.

—Бик матур тавышлы диктор,—диде Җансай,—иртә-кич аның сөйләгәнен көтеп алам.

Кәшшаф чак-чак кына: "Ул минем сөйгәнем",—дип әйтеп ташламады.

Радиодан Заһидә сөйли иде. Кәшшаф репродукторны кочаклап алыр хәлгә житте. Бүген ук барып гафу үтенәм, дип күнеленә беркетеп куйды.

Кәшшафны горурлык хисләре биләп алды. Онытылып китеп шешәсе дә хәтереннән чыкты хәтта, искәртмәстән күзе төшкән иде, аһ итте, пинжәк кесәсеннән теге мәлгуньнең борыны тырпаеп тора икән ич. Җансай күреп алмасын дип ул аны җәт кенә эчкә төртте.

—Сез докторлык диссертациягезне тәгаллисезме әле?—дип сорады Җансай.

—Ул минем нигездә әзер инде,—диде Кәшшаф,—кайбер өстәмәләр генә кертәсе бар.

—Әгәр хезмәтегезне Төркиядә китап итеп бастырып чыгарсак, ни әйтер идегез?

Кәшшафның теле аңкавына ябышты. Бу аның хыялланырга да җөрьәт итми торган теләге ләбаса! Чит илдә басылып чыккан язмалар аеруча бәһале йөри.

—Бу, Җансай әфәнде, күктән ингән бәхет булыр иде,—диде Кәшшаф.

—Сизеп торам, сезнең тема күпләрнең тамагына сөяк булып утыра монда. Ә үзе бик мөһим, татар тарихында борылыш ясаучы тема. Без дә читтә калырга тиеш түгел дип беләм. Мин сезне шул турыда киңәшү өчен чакырган идем.

Кәшшаф маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен жине белән генә сыпырып төшерде, кесәсеннән кульяулыгын алырга да онытты. Шешәсе дә һаман башын калкытып жанын үртәп тора ичмасам.

—Мин бик рәхмәтле булыр идем,—дип дәвам итте Кәшшаф,—ләкин...

—Сездән хәзер тиз арада кульязманы тиешле кондициягә житкерү сорала. "Ләкин"нәрсез генә эшлик.

Җансай Хаммат сәгатенә күз төшерде дә:

—Намаз укыр вакыт житкән икән, Кәшшаф әфәнде,—диде.

Ул эчке бүлмәгә кереп китте. Радио да сүнде. Кәшшафның оялулары, жир астына кереп качар хәлгә житте. Күренекле галим, профессор намазга бассын әле. Ә ул әлифне таяк дип тә белми. Дин ягыннан чеп-чи надан.

Җансай намазын тәгәлләп чыкканда да уйга батып утыра иде әле.

—Гафу итегез, Кәшшаф әфәнде, сезне талчыктырдым, ахры. Килүегезгә рәхмәт, әле тагын хәбәрләшербез.

Бу саубуллашу иде инде. Күрәсең, ул Кәшшафны аңа карата үзенең ихтирамын белдерү өчен генә чакырган иде. Хәер, ихтирам гынамы соң? Тәкъдим! Тәкъдимнең дә нindie әле! Безнекеләр булса, бер йөк сүз чыгарырлар иде. Әллә нинди төрләр катына чакырып бетерерләр иде, ничәмә-ничә кәгазь яздырырлар, анкеталар тутырттырырлар иде.

Кәшшаф китәргә әзерләнгәч кенә телефон шылтырады. Җансай бу шылтырауны көткән иде булса кирәк, трубкага ике куллап үрелде.

—Җансай Хаммат. Тыңлыйм.

Бераздан аның йөзе чытылды, кашлары бергә кушылды.

—Мин сезне аңламыйм, татарча сөйләгез,—диде ул үртәлеп,—яисә инглизчә, немецча да мөмкин, төрекчә...

Күрәсең, телефон чыбыгының аргы очындагы кеше һич тә телләр белгече түгел иде. Җансай трубканы Кәшшафка сузды.

—Булышыгыз әле, зинһар, мин русча начар беләм.

Трубкада: "Мина велели вам позвонить",—дигән хатын-кыз тавышы ишетелде. Нindiдер ипигә ягылган бал шикелле татлы, үзле тавыш. "Мин дә берни аңламыйм",—дип, бүлмә хуҗасына текәлде Кәшшаф.

—Мәгъшука булырга тиеш,—диде Җансай,—түләүле кыз.

Кәшшаф үз колакларына үзе ышанмыйча бермәлгә аптырап калды. Мәгъшука дигәннәре шул фәхишә була түгелме соң инде? Юк, юк, бу мөмкин түгел! Шушындый мәртәбәле галим шундый түбәнчелеккә төшәме соң? Үзләре буташтырадыр. Алай бик тәти кирәк икән инде, аны соң түләмичә дә табып була ләбаса! Җансай Хаммат кебек чибәр, таза бәдәнле, бай кешегә берәү түгел, унысы тагылыр, сызгыр гына.

—Мина приттиме?—дип сорады баллы тавыш иясе,—мадам әйтте, что все улажено. Сез Джансай Хаммат, так ведь? Третий этаж. Люкс.

—Син мөселман кызымы?—дип сорасы итте Кәшшаф үз чиратында.

—А какже? Чистокровная татарка, и говорить беләм.

—Ул сезнең турында хәбәрдар,—диде Кәшшаф Җансайга,—килсенме?

—Чакырыгыз!

Кәшшаф танышының күзенә күтәрелеп карарга да кыймыйча урыныннан тормакчы булды. Җансай кулын изәп, аны кире утыртты.

—Мәгъшука килсен әле,—диде,—ана минем таләпләремне житкерерсез.

Ишек шакыдылар. Бусагада билдән түбән бияләй чаклы гына итәк япкан төз сынлы, кыссаң өзелеп чыгарлык нечкә билле чибәр кыз күренде. Гәүдәсе гүя аяклардан гына тора, зифа камыш кебек озын, матур аяклар! Сайлый белгән төрек татары, авызыннан сулар килерлек.

—Я, мин—Алсу,—диде кыз Кәшшафка текәлеп. Сез Хаммат, да?

—Мин—Җансай Хаммат,—дип, бүлмә хуҗасы кызның алдына килеп басты.

—Милый, угости матурынны вином,—дип кыз Җансайга сыланмакчы итте.

—Нәрсә әйтә ул?—дип сорады тегесе.

—Шәраб белән сыйларга куша...

Жансайның йөзләре үзгәреп китте.

—Мин мөселман өммәтендәге кеше, мин шәраб эчмим! Кешеләрне дә шәраб белән сыйламыйм!

Кәшшаф жариягә шул сүзләрне житкерде. Кыз ирennәрен бүлтәйтеп Жансайның чәчләреннән сыйпады.

—Начар малай... иди, милый, иди, мин прощаю.

—Күземнән югалсын, әйт, башка бимазалап йөрмәсен,—диде Жансай.—Ялкытты инде ул мине. Шаһит булырсыз. Мин аны юри сез барында чакырдым.

Кәшшафның өстеннән авыр йөк төшкәндәй булды, жинел сулап куйды. Югыйсә, әллә нәрсәләр уйлап бетергән иде бит.

Жансай елмаеп башын иде. Кәшшаф тиз-тиз генә киенде дә саубуллашып бүлмәдән чыгып китте. Ә урамда ыгы-зыгы. Кичке шәһәр үзе бер матур тамаша бит ул. Шакы-шокы килеп йөргән албасты—трамвай да кичен ниндидер зиннәтле карета кебек күренә. Әнә, нурлы тасма сузып куйган шикелле рельслар ялтырый, реклама такталарыннан тирә-юньгә аллы-гөлле төсләр көлтәсе сибелә.

Кәшшаф кунакханәнең текә баскычыннан шушы мавыктыргыч манзараны күзәтеп торды. Ә үзенең күз алдында әле һаман Жансай Хаммат янында бөтерелүче чибәр кыз. Башка сыймаслык хәл бит, валлаһи. Хатын-кыз әйбер шикелле үзен сатып йөрсен инде. Менә нинди икән ул капитализм?! Хәтта интим мөнәсәбәтләр дә алыш-бирешкә корылган. Табигый хажәт һөнәр баскычына күтәрелгән. Профессионализм, имеш!

Кәшшаф үзе дә гөнаһсыз түгел анысы. Бу жәһәттән ана Америка галиме Джонсонның сүзләре ошый. Хатын-кызларга мөрәжәгать итеп ул болай дигән: "Ә нигә ир-атны тыярга? Кирәкми. Йөрсеннәр. Хыянәт һич кенә дә начар кимчелек түгел. Аннан фажига ясарга ярамый. Хыянәт—ир-егетләрнең канында. Ул табигатьтән килә. Аларга хәтта берьюлы бернечә хатын-кыз да ошарга мөмкин. Иң мөһиме, шулар арасында сез аның иң яраткан хатыны булып калыгыз. Шул гына".

Кәшшафның күнелендә Мөхәммәд пәйгамбәргә кагылышлы бер вакыйга да уелып калган.

Мөхәммәд пәйгамбәр хатыны Хәдичәнең үлем түшәгендә әйтә:

—И, Хәдичә, син теге дөньяга киткәч, көндәшең булачак бит,—ди.

Кызы Мәрьям әтисен битәрли, үлем түшәгендә шундый сүзләрне әйтергә ярамый ич инде. Мөхәммәд әйткән:

—Хәдичәнең бик күп яхшы сыйфатларын беләм. Ә менә көндәшләреннән көнләшер иде микән, шуны ачыклыйсым килде,—дигән.

Пәйгамбәребезнең бу сүзләре мөселман ирләренең офыкларын шактый киңәйтә. Димәк, көндәшләр тоту хәрәм гамәлләрдән саналмый. Ләкин фәхишә белән кәнизәк арасында жир белән күк аермасы...

Кәшшафны уйлар дөньясыннан колгадай бер озын буйлы кеше тартып чыгарды.

—Шырпың юкмы?—дип жилкәсенә орынды. Кулында—папирос.

—Мин тәмәке тартмыйм шул,—диде Кәшшаф. Тегесе үз алдына мыгыр-мыгыр сөйләнеп китеп барды.

Кәшшаф та кешеләр төркеменә кушылды. Яхшылабрак багып караса, Ямаш белән ингә-иң атлыйлар икән ләбаса. Бер-берсенә карашкач, кычкырып көлеп жибәрделәр.

—О-о, Бату хан!

—Болгар бәк, сезме бу?

—Көлмәгез, Кәшшаф әфәнде, бес татардан Болгарны барыбер тартып алачакбыс. Сесгә Алтын Урда житмәгәнме?

—Тәртибегез ничек булыр бит әле?

Ямаштан хәмер исе килә иде. Кәшшафның куллары үзеннән-үзе күкрәк кесәсенә үрелде. Коньяк урынында иде. Күңеленә кытык йөгерде.

Әллә соң түбәтәй астын Ямаш белән генә жылытып алыргамы? Әле ярый, Жансай Хамматка чыгармады, хур була иде мәгәр. Кайчакта мәсьәләне кыюлыктан битәр сабырлык хәл итә. Шушы ике сәгать эчендә ниләр генә булып үтмәде. Әйтсән, кеше ышанмас.

—Кая барыш болай?—дип, Кәшшаф танышынын кылын тартып карасы итте.

—Йөрергә чыккан идем әле, университет тирәләреннән урап кайтыйм дидем, укыган жирләр бит.

—Ашыгыч эшегез юк, димәк.

—Мондый очракта мин Галиәсгәр Камалнын "Уйнаш" пьесасындагы баш герой сүсләрен кулланам. Ә ул болай ди: "Ашыгу шайтан фигыле".

—Алайса, әйдәгез, берәр кафега керик, сөйләшеп утырырбыз.

—Рәхмәт. Бик рәхәтләнеп. Ләкин алдан ук кисәтеп куям, минем кесәдә жилләр уйный. Кичә дуслар белән бөтен байлыкны пыран-саран китереп бетергәнбес.

Ямаш иске чүпрәк кебек унган керфекләрен челт-челт йомгалап, чепек күзләре белән Кәшшафка текәлде. Ул хәзер Кәшшаф кире уйламаса ярар иде дип борчыла иде.

Алар чиркәү ишегалды аша Островский урамыннан Бауман урамына турыга бәреп чыктылар. Каршыда гына кафе. Шунда керделәр.

Коньякны күргәч, Ямашнын күзләре майланды. Шешәне кулында әйләндергәләп, язуларын кат-кат укып чыкты. Аннан сон:

—Самкуганга күнгән чуваш авысына бу сатлы эчемлек батып бетәрме икән?—диде.

—Затлы әйбер эчне тишмәс диләр

—Исегес китмәсен, Кәшшаф әфәнде, чуваш шундый кирегә каткан бәндә инде ул. Коньяк белән сыйласагыс да, мин үз фикеремнән кайтмаячакмын. Чуваш болгарнын дәвамчысы. Мин генәме сон? Әнә, Гаяс Исхакый да "Инкыйрас"ында сонгы татар болгары Жәгъфәрне жан тәслим кылдыра.

—Пүлне умный сүләр сүлисен, Ямаш, әллә сон син чувашмы?—дип көлде Кәшшаф.

Ямашнын калын иреннәре жәелеп китте.

—Тостлар әйтешеп тормыйк,—диде Кәшшаф,—эчтән генә багышлыйк.

—Мин чәкештереп эчәргә күнеккән,—диде Ямаш киреләнеп.

Чәкештерделәр.

Коньяк башларына бәрде. Кыенсыну бетте, кыюлык килде. Кәшшаф үтә бер кызыксыну белән залны күзәтеп чыкты. Зал тулы иде. Анын игътибарын уң як почмактагы ике кешелек өстәл артында утыручы урта яшьләрдәге бер пар жәлеп итте. Хатыны тач Заһидә. Кәшшаф башта аны чын-чынлап Заһидә дип уйлады, эче жу итеп китте. Күзләре күнеккәч кенә үзенен ялгышканын аңлады. Бу ханымнын йөзе озынчарак иде, килеш-килбәте дә мактанырлык түгел. Заһидәгә житәме сон, гәүдәсе балдак аша үткәрерлек ич анын.

Гашыйкларнын бер кешедә гаме юк. Кулларын кулга тотынышып, бер-берсенә мөкиббән китеп карашып утыралар.

Кәшшаф кисәк кенә урыннан сикереп торды да ишеккә таба юнәлде.

—Сес кая? Тагын берәр рюмка чыга әле монда!

Кәшшаф Ямашнын сүзләрен колагына да элмәде. Күнелендә фәкать Заһидә генә иде. Нишләп соң әле ул шушы гомер сөйгәне янына бармады, хәлен белмәде? Үпкәләде, имеш. Чибәр ханымнар шулай холыксыз була инде, пыяла касә белән бер. Уалмасын дисән, кадерләп саклап учында гына йөрт. Ә ул кулыннан төшереп жибәрде.

Хәмер, кафедагы Заһидәгә охшаган ханым Кәшшафнын күнелендәге хисләрен өскә сыгып чыгарган иде. Саташып трамвайдан бер тукталыш алдан төшеп калганын да сизмәде хәтта. Озак кына Заһидә яшәгән йортны таба алмыйча интекте. Йорты нәкъ шул. Ә фатиры туры килми.

Бер мәртәбә килеп бәрелде ишеккә, ике. Шакыган саен ишекне бер яшь кеше ача. Аның да түземлеге бетте, ахры, соңгы шакуында Кәшшафның изүеннән эләктереп алды да тезе белән эченә типте.

—Исән чакта ычкын моннан, әлкәш,—дип кычкырды.

Кәшшафның ана карап кәефе төшмәде. Күңелендә элеккечә моң иде.

Кашларына карасам,—
Каләмнән пәйда булгандай,
Күзләренә карасам,—
Күгеннән пәйда булгандай;
Каршыннан торып карасам,—
Каһәрдән пәйда булгандай,—
Буйларына карасам,—
Нурдан пәйда булгандай.

Тиздән, бик тиздән алар очрашачак, сөешәчәк.

Кәшшаф барган җиреннән әсәрләнеп туктапып калды. Аның алда булачак яратышу мизгелләрен күңелендә озаграк саклыйсы килә иде.

Шундый ашкынулы уйлар белән Кәшшаф, ниһаять, таныш ишекне шакыды. Йөрәге дерт-дерт килә. Менә хәзер күк капусы ачылачак һәм...

—Кем бар анда?—дигән тавыш ишетелде.

—Бу мин, Кәшшаф.

Ишек ачылып китте. Бусагада йөзен сакал-мыек баскан бер кеше күренде. Күзләре генә ялтырап тора. Кәшшаф артына чигенде. Нишләп йөри бу убырлы Заһидә фатирында? Шул хакта сорамакчы иде дә өлгерә алмыйча калды, әлеге җөнтәснең артыннан Заһидә үзе калкып чыкты. Заһидәнең күзләре салкын, битараф иде.

—Мефодий, бу Кәшшаф Газизович Хәмитов, син аның турында беләсең инде,—дип Заһидә әлеге ир кешегә мөрәҗәгать итте.

—Саумысыз, Кәшшаф Газизович, исән-имин генә йөрисезме?—диде Мефодий дигәннәре. Тавышының төсмеренә караганда ул елмая иде булса кирәк, әмма сакал-мыек арасыннан бернәрсә дә беленмәде.—Учитель безне шәфкатьлеккә, миһербанлыкка өйрәтә. Җир йөзендәге кешеләр бер-берсенә туган.

Кәшшафның күзләре Мефодийның аякларына төште. Табаннары йөз яшьлек ташбака кабырчыгы шикелле калын, тупас, кытыршы иде. Бармаклары тырпаеп тора, тырнакларының кайсы китек, кайсы кәкре. Нигә син дип мөрәҗәгать итә бу сасы адәм Заһидәгә? Ул әле Мефодийның Казандагы Иванов җәмгыятенең житәкчесе икәнен белми иде. Заһидәнең: "Надан ул, ана Остаз тәгълиматы хакында сөйләп теленне әрәм итмә",—дигән сүзләрен ишеткәч кенә башына уй йөгерде: секта кешесе ич бу!

Менә нәрсәдә икән хикмәт? Теге вакытта Маһинур сихерче башын әйләндергән иде, инде бу сакалбай бөтереп алган. Тегесе "әни" иде, монысы, алай булгач, "әти"дер инде.

Йомшак агачны корт баса ди, Заһидәне ничек тә бу бәладән йолып алырга кирәк. Никадәр тизрәк булса, шулкадәр яхшырак.

—Безнең Заһидә белән сөйләшәсе, аңлашасы серләребез бар, сез, иптәш-кем, зинһар өчен, җыеныгыз инде,—диде Кәшшаф әле һаман каккан казык шикелле баскан урынында каткан Мефодийга мөрәҗәгать итеп. Аның өчен Заһидә җавап бирде.

—Мефодий минем ирем!

Кәшшафның борын төбендә шап итеп ишек ябылды.

* * *

Галимовның монарчы буразнадан чыкканы булмады. Бу юлы да ул үз кеше икәнен исбатлады. Өстәгеләр өчен иң мөһиме шушы. Милләтнең язмышы хакына хәтта аерым теорияләрне көн тәртибеннән алып ташларга

да мөмкин. Бу һичшиксез үзен аклаячак кына. Бигрәк тә татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсендә бердәмлек зарур. Болгар теориясе рәсми теория булып торды, тора һәм киләчәктә дә торыр. Кайчандыр гаделсез рәвештә берегеп калган татар исеме болгар нәселе өчен хурлык. Тора-бара бу исем бөтенләй кулланыштан төшеп калырга тиеш. Тик бу сәясәтне бик акыллы алып бару сорала. Каш ясыйм дип күз чыгаруың да бар. Моның өчен, билгеле, бик ныклап җәмәгатьчелекне хәзерләргә кирәк. Шуңа күрә аның доклады хәзерге заман милли татар тарихында зур вакыйга буларак кабул ителергә тиеш. Дөрес, конференциянең ачылу тантанасы алдан уйланганча килеп чыкмады. Төрек татарларының Корьән белән тыкшынуы, алтынурдачыларның сүз көрәштерүе аркасында аңлашылмаучылык булып алды. Ләкин акрынлап тәгәрмәч үз эзенә төште, хәтта Хәмитовның ачлык игълан итәргә маташуын да нәкъ вакытында йома алдылар. Ташламага барырга туры килде, әлбәттә. Ләкин бер зыян да юк, андый хәлләр булгалый инде ул.

Докладын башта татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсендәге төрле агымнарга анализ ясаудан башларга дип ниятләгән иде. Конференциянең барышы әлеге юлның көтелмәгән нәтиҗәләргә китерү ихтималы барын күрсәтте. Әлеге варианттан баш тартырга туры килде. Чөнки аны бу юнәлешләрне кысу дип уйлаулары мөмкин иде. Шул ук вакытта аларны белмәмешкә салышып, шома гына үтеп китәргә дә ярамый, нәрсәнең нәрсә икәнен белеп торсыннар. Югыйсә, Хәмитовның чыгышын да, археограф Мөхәммәтҗанов чыгышын да колакларын торгызып тыңладылар.

Мөхәммәтҗанов исә шәҗәрәләргә таянып, Идел—Урал һәм Кырым татарларының бер үк компонентлардан оешуын исбатларга азапланды. Ә бу болгар теориясенең тамырына балта чабу белән бер. Нугай Урдасының варислары булып бүгенге татарлар, казахлар, каракалпаклар, кыргызлар, үзбәкләр, Кырым татарлары тора, имеш. "Дастане Чыңгыз" әдәби ядкярендә әйтелгән, имеш. Ул дастан XVII гасырга карый, аны әле ныклап тикшерәсе бар. Ә болгар кая? Алар да шул ук нугайлар шикелле борынгы халык ләбаса!

—Идел—Урал буенда татар дигән халык яшәмәгән.

Шушы сүзләрне әйтте дә Галимов күзлеген борын очына шудырып, бермәл залга карап торды: ничек кабул итәрләр? Ул алтынурдалылар шаулашыр дип көткән иде. Тик, ни гаҗәп, урыннарыннан сикереп торучы да, реплика ташлаучы да булмады. Сайра, әйдә, сайра, ни сайрыйсыңны беләбез, дигәндәй битараф кыяфәт белән утыра бирәләр. Бу хәл Галимовның мин-минлегенә сукты, доклады кызыксыз икән дип уйлаулары бар ләбаса!

—Болгар теориясен алга сөрүчеләр дә, алтынурдалылар да бүген татар исемен йөртүче халыкны җирле халык дип тәкрарлыйлар,—дип дәвам итте ул сүзен,—алар элек-электән шушы төбәктә яшәгәннәр, шушында көн күргәннәр. Беренче карашка, бу тезиста бернинди дә каршылык юк сыман. Ләкин беренче карашка гына. Алтынурдалылар болгарны татар халкын формалаштыруда гади бер компонент итеп кенә саныйлар. Ә без иң төп компонент дибез, шуны исбатлыйбыз да. Мәсәлән, һади Атласи, Михаил Худяков кебек танылган тарихчылар болгар-татар атамасын кулланганнар. Татар түгел, болгар-татар! Бу бик мөһим нәрсә. Татар атамасын баскыннар үзләре яулап алган һәр халыкка көчләп такканнар. Бәхетләренә, кытайлар да, гарәпләр, фарсылар, славяннар да тора-бара аннан баш тартканнар. Иманым камил, Кафтау артыннан очраклы рәвештә генә килгән бу исем төркиләргә дә берекмәгән булыр иде. Әлеге үзатаманың русларда киң кулланылышы гына комачаулаган. Мәгълүм булганча, руслар казакъларны да, кыргызларны да, әзәрбәйҗаннарны, үзбәкләрне, башкортларны, карачайларны да татар дип йөрткәннәр. Бәла шуннан килә. Югыйсә, без монда бүген корыны бушка әйләндереп, бәхәсләшеп тә утырмаган булыр идек.

Зал, ниһаять, жанланып алды. Галимовнын теләктәшләре кул чапты. Кул чабучылар арасында Әлтаф та бар иде. Рамил Кәшшафка ым какты, кара әле дустыбызга, директорга ләббәйкә итеп утыра түгелме?

Кәшшафнын бернәрсәдә дә гаме юк иде. Галимовнын сүзләре дә колагына керми, кул чабуларны да ишетми. Кичәге хәлләрдән әле булса арына алмый иде ул. Заһидәнен кияүгә чыгуы йөрәгенә хәнҗәр калагандай тәэсир итте. Кемгә дисен әле, бер сукбайга, бакча карачкысына! Яратам, син минем беренче мәхәббәтем дип, сайраган булган иде.

Бер хатыннын хәйләсе кырык дөягә йөк булыр ди. Аздыра да, төп башына да утырта хатын-кыз. Алданганынны сизми дә каласын. Бозык маржа. Сөяркә тоткан хатын белән сөт өсте ялаган хатын бервакытта да ул гадәтләрен ташлый алмыйлар ди ич.

...Галимов, ниһаять, үзенен төп фикерен житкерде: "Халкыбызнын этник тамыры борынгы чорга, скиф чорына барып тоташа",—диде.

Янә кул чаптылар. Ләкин бу барыбер Кәшшафны уята алмады. Анын күз алдында һаман Заһидә: үбешергә генә яратылган купшы иреннәр, учка керәм дип торган йомры ияк һәм менә шушы гүзәл яр инде аныкы түгел. Бу коточкыч хакыйкатьтән Кәшшафнын эче сулкыллап-сулкыллап китә. Һай, авыр да икән көнчелек хисен күтәрү. Ул синен һәр күзәнәгенә сенә икән, аннан берничек тә арынып булмый икән. Их, Заһидә, Заһидә... Дөрес, кемдер әйткән: "Хис хыянәтне белми. Ул үсә, югала, үзгәрә генә",—дигән. Ләкин эчен-тышын хис белән тулган бер вакытта бу сүзләр юаныч була ала димени?

Мәгарәнен дә ишеге була. Кеше нинди генә авыр хәлгә калмасын, аннан чыгу әмәлен табарга тырыша. Тормышка ашарлыкмы-юкмы, дөресме-ялганмы—барыбер тырмаша. Өмет этәрә аны бу адымга. Тора-бара Кәшшафка да ачыш килде: Заһидә аны сыный гына ләбаса!

Шушы уй аны тынычландырып жибәрде. Саллы-саллы дәлилләр дә тапты. Ә алар өстә генә яткан булып чыкты. Ә ул, башсыз, бер гаепсез Заһидәгә әллә нинди нахак бәлаләр тагып маташты. Алтын ул Заһидә! Анын шикелле хатын-кыз доньяда юк.

Мефодий турында да белеште Кәшшаф. Йортсыз-нисез бәндә икән. Бүген бер мөритендә туктала, иртәгә—икенчесендә. Дөрес булса, ивановчылар доньяви гамәлләрне танымыйлар ди. Яратышу, якынлык кылуны шәһвәт дип кире кагалар, имеш. Әхлакый бозык кеше икенче тапкыр доньяга усал жанвар сурәтендә килергә мөмкин, янәсе.

Заһидәнен көйсезләнүләре, гадәттә, чире баш калкыткан вакытка туры килә. Андый чакта юктан гына гаеп таба, чит куллан бернәрсә капмый, бозыклык ризык белән керә, ди. Хәер, бу аш-суга гына кагылмый. Берчак шулай эшкә барганда каршысына капылт кына велосипедчы килеп чыга. Заһидә куркуыннан кычкырып жибәрә. Халык жыела. Кемдер ашыгыч ярдәм машинасы чакырта. Ләкин анын кирәге булмый. Велосипедчынын да гаебен таба алмыйлар.

Шуна да карамастан, ул әлеге вакыйганы айлар буе теленнән төшермәде. Сөйләгән саен яналыклар барлыкка килә, мона кадәр күләгәдә калган төгәллекләр калкып чыга. Ахыргы чиктә ул шул очраклы хәлне үзенен тормышына һөжүм итү дип бәяләде.

Сонгы вакытта ниндидер мыштыклы кеше барлыкка килгән иде.

—Мине үтерергә жыеналар,—диде Заһидә яшь аралаш.

—Сөйләмә булмаганны,—дип ачуланды Кәшшаф.

Заһидә бәхәсләшеп тормады. Кәшшафны тәрәзә янына алып килде.

—Әнә, каршыдагы биш катлы кирпеч йортны күрәсенме?—диде. Күрәсен. Яхшы. Хәзер шул йортнын сул катында бастырып куйган шырпы кабы кебек тырпаеп торган тар йортны тап. Таптынмы? Инде тар йортнын уннан икенче тәрәзәсенә игътибар ит.

—Ялтыраган тәрәзәне әйтәсенме?

—Бик ансат таптын, әйеме?

—Жә...

—Менә шул тәрәзәдән көн саен кичке ун белән унбер арасында мине бер кеше күзәтә. Мылтыгы да бар.

Кәшшафның башында күп-күп сораулар туды. Әйтик, шушындый ерак арадан ул кешене ничек күрергә мөмкин? Ә мылтык? Аны, мөгаен, бинокль аша да күреп булмыйдыр? Ләкин бу сораулар Заһидәнең ачуын гына кабартачак иде. Шуңа күрә сорашып тормады.

Бераздан Заһидә тагын шул хакта сүз кузгатты. Милициягә бардым, язма аңлатма калдырдым, диде. Кәшшаф ни әйтергә дә белмәде. Бик яхшы булган, дип кенә куйды.

Кәшшаф мылтыклы кеше кыйссасы шуның белән тәгәлләнде дип йөри иде. Ялгышкан икән. Беркөн Заһидә аның янына институтка килде. Борчулы иде.

—Әллә бер-бер күнелсезлек килеп чыктымы?—дип сорады Кәшшаф.

Заһидә, кыяфәтенә караганда, шактый күз яше түккән булырга охшаган иде.

—Мине һаман сагалыйлар, милициянең файдасы тимәде, бер-ике ай гына булса да миңа күченеп тора алмассыңмы?—диде,—өемдә ир кеше барлыгын күрсәләр, туктарлар иде.

Бу көтелмәгән тәкъдим иде. Күченеп килү—бу инде Дәрига белән аерылышу дигән сүз. Ә ул мондый кискен борылышларга әзер түгел иде әле. Ничек итеп Заһидәне рәнҗетми генә әлеге тәкъдимне кире кагарга? Әнә, күзләрен мөлдерәтеп карап тора. Ышана. Өметләнә.

—Мине командировкага җибәрәләр,—диде Кәшшаф ышандырырлык саллы сәбәп табуына сөенеп,—урап кайткач уйлашырбыз

Заһидә бер сүз әйтмәде, өстәл өстендә ачкыч бәйләме калдырып, саубуллашмыйча да тырт-тырт басып чыгып китте. Димәк, Кәшшафка уйланырга мөмкинлек калдыра, таякны тоткан урыныннан гына сындырырга ашыкмый.

Инде хәзер аның өендә чит кеше. Ул анда кем сыйфатында яши? Ир сыйфатындамы? Сөяркәме? Ир дә түгел, сөяркә дә түгел. Чөнки бу мәхәббәт канунныарына каршы килү булыр иде. Заһидә фәкать аны гына ярата. Ярата! Яратмаган хатын-кыз, ике-өч ай гына булса да бергә яшик, дип ялыныр идемени? Хәтта ачкычларын да калдырып китте бит. Димәк, әлеге мылтыклы кеше дигәнең, чыннан да, дөреслеккә туры килә. Ә ул сөйгәнен яклап кыл да кыймылдатмады, хәтта ышанмады да. Заһидәгә исә күз күргән кешесенә мөрәҗәгать итүдән башка юл калмаган. Һәм менә нәтиҗәсе. Мефодий тән сакчысы булып ялланган.

Кәшшаф үзен шушы фаразга ышандырырга тырыша иде. Чөнки ул аңа охшыйрак төшә, өметкә юл калдыра иде.

Кәшшаф көн саен иртә-кич Заһидәнең телефон номерын җыя. Һәрвакыт трубканы Мефодий ала, әйтерсең лә, аның шылтыратканын сагалап кына тора. Заһидәне сорасаң, кем, нәрсә, дип төпченә башлый. Берсендә фамилиясен әйткән иде: "Ул сезнең белән сөйләшергә теләми",—дип трубканы куйды. Кәшшафның күзенә төне буе йокы кермәде. Әллә нинди тузга язмаган планнар корып бетерде.

...Мефодий базарда йөри, имеш. Ялт та йолт карана, күренеп тора, ауга чыккан. Кәшшаф сиздерми генә аны сагалап йөри. Исәбе, бурлык өстендә тоту, бөтен кеше алдында мәсхәрә итү. Моны, билгеле, Заһидә дә күреп тора. "Куеныңа кара елан керткәнсең, мин аны алып ташладым, син азат",—диячәк ул Заһидәгә. Шул сүзләрне әйтер дә, төп төз басып китеп барыр. Заһидә аннан тотам да калмас. "Гафу ит, җанаш, мин гаепле",—дияр...

Кәшшаф мәрхәмәтле кеше, ачу тота торганнардан түгел. Билгеле инде, кичерәчәк.

Иртә белән Кәшшаф тагын шылтыратты. Трубканы бу юлы да Мефодий күтәрде. Аның тавышыннан тынчыган күл исе килә иде. Кәшшаф җирәнеп борынын җыерды. Аннан соң: "Сасы дуңгыз, Заһидә янында эзең булмасын",—дип кычкырды.

Карт мәхәббәт тә яна мыек чыгарган малай кебек сөйләшә ди. Кәшшафның хәле дә шул чама иде. Инде нишләргә, нинди чара күрергә? Бәлкем, хат язып карарга дыр?

Кәшшаф балаларча самими ышаныч белән, Мефодийның чын йөзен ачса, Зәһидә аны өеннән куып чыгарыр, дип ышана иде. Сакал аллап-йоллап ышанычка кергән, куйса Кәшшаф кына әлеге акылсызлыкка чик куя ала. Алай гынамы, бу аның бурычы! Соныннан Зәһидә үзе үк рәхмәт әйтәчәк.

Кәшшаф бүлмәсенә бикләнеп көне буе хат язды. Яза да ертып ташлый, яза да ертып ташлый, чүп кәрҗине кәгазь белән тулды. Ошамый гына, нишлисең. Хатта Зәһидәне кимсетә торган сүзләр булырга тиеш түгел, шул ук вакытта җаен китереп, чеметеп тә алгаларга кирәк. Ябалак күрсәң, атып ал, яманнан җаныңны сатып ал, ди. Хәзер менә шуна калды.

Иртәгәсен Зәһидәгә түбәндәге эчтәлекле хат китте.

*"Зәһидә!*

*Әгәр бу хатым сиңа борчу китерсә, гафу ит. Ләкин мин башкача булдыра алмыйм. Чөнки сиңа куркыныч яный. Син Иванов тәгълиматы канаты астына яшеренгән монафыйклар, сектантлар кулында. Алар сине үз дәрәҗәләренә төшерергә телиләр.*

*Мефодий—аферист, сукбай. Ул синең акылыңны томалаган. Тарихта моның мисаллары күп. Андыйлар хәтта патша сарайларында да булган. Распутинны хәтерлә.*

*Аңламыйм, ничек әләктең син бу җәтмәгә? Ислам дине аларны кабул итми. Аллаһы Тәгаләгә якынаю өчен безнең үз динебезнең мөмкинлекләре дә бик зур ләбаса! Болай гөнаһка батып бетәсең бит. Әти-әниең гадел, саф, чиста яшәп, бу дөньядан китеп барганнар. Беринди дә Иванов кирәк булмаган аларга. Хәзер, мөгаен, җаннары синең өчен борчылып изалана торгандыр. Аңлыйсыңмы шуны?*

*Син абруйлы кеше. Аларга шундый абруйлы кешеләр кирәк тә. Рухи камилләшүеңнең мөмкинлекләрен ходай синең үзеңә дә өеп биргән, югыйсә. Нинди матур фәлсәфи шигырьләр яза башлаган идең. Кит шул юлдан, йөрмә җыен юк-бар белән буталып.*

*Күршеләреңнән, танышларыңнан, туганнарыңнан оялыр идең. Синең ише асыл хатын-кыз өчен өйдәш ир-ат белән яшәү үзе бер мәсхәрә ич. Әгәр инде шундый ихтыяҗың бар икән, юньлерәк кешене сайларга иде.*

*Үзеңне кызганып куйдым әле, сине телефонга да якын җибәрмиләр, ахры. Чөнки, мөселман-мөэминнәр арасында хәл белешү фарыз санала, дип шылтыратып караган идем, аферист-өйдәшеңнең блокадасын өзеп булмады. И, гарьләндем шуңа. Их, мәйтәм, Хәмитов башың белән нинди көннәргә калдың бит, дим. Сине күрәләтә кире кагалар, кимсетәләр, түбәнсетәләр, ә син кешедән калган калдыкка ымсынып, арбаның бишенче тәгәрмәче булып йөрисең. Кая синең горурлыгың? Уян, дим, акыл белән яшәргә вакыт!*

*Ихтимал, ялына бу дип уйларсың. Юк, бу ялыну түгел. Бу—мәхәббәт! Ә мәхәббәт өчен көрәшергә кирәк. Һәм мин көрәшәчәкмен! Ничек итеп? Әлегә уйлап бетермәдем. Әмма вәгъдә итәм, уйлармын.*

*Миңа бер нәрсә аңлашылмый—син миннән киткән очракта аны турыдан-туры әйтергә тиеш идең. Намуслы кешеләр шулай эшли. Мин сине намуслылар рәтендә йөртә идем.*

*Димәк... Хәер, монысын киләчәк күрсәтер. Хәзергә хуш.*

*Кәшшаф. 17 гыйнвар, 1997 ел."*

* * *

Астыртынның кылган эше беленмәс, күргән төше юралмас, ди. Кәшшафның да тумыштан килгән мыштымлыгы әлеге әйтемгә бик тә туры килә. Әнә, Аккош күлендәге мажаралардан соң, Зәһидә белән янә очраша башлавын тәки хатынына белгертмәде. Югыйсә, хатын-кыз үзе

дә төлкенең төлкесе, галимнәрнең әйтүенә караганда, хатын-кызда иң көчле үсеш алган тойгы—ул сизгерлек тойгысы. Хәтта ир-атның ни-нәрсә уйлаячагын да алдан белеп тора ди хатын-кыз заты.

Шул мина кырыннан Кәшшаф хәвеф-хәтәрсез генә үтә алды. Ул вакытында эштән кайтты, күчтәнәчләр ташыды, хатынына чәчәкләр бүләк итте. Тәүфыйк иясе инде, башын үләннән дә түбәнрәк иеп йөрде. Гаебен ярлыкый, янәсе. Шунын белән хатынынын уяулыгын эретте. Дөрес, ирен гафу итсә дә, Дәриганың йөрәге әрнүле иде. Ул дөнья дип, бала дип, ир дип жан атып йөргән бер мәлдә, хәләле кәзинәкләр белән әвеш-тәвеш килсен әле? Ана болай да авырга туры килә. Чырышлыгы белән, чыдамлыгы белән генә алдыра, инде күптән юл читенә очырган булырлар иде. Ул аралашкан даирәдә син хатын-кыз дип тормыйлар.

Дәрига дәртле хатын. Тик, ни хикмәт, Кәшшаф һаман шушы кирле-мырлы сырхау Заһидәне үз итә. Шуна күрә сөяркәсе барлыгын белгертмәс өчен хатынына элеккегә караганда да игътибарлырак булырга тырыша.

Бервакыт Кәшшаф командировкада булып кайтты. Озак та йөрмәгән иде, югыйсә. Дәригасы сусапмы-сусаган. Төне буе тынгы бирмәде. Кәшшаф борылып кына ятар иде, юк, ярамый, Заһидә янында бер кич кунып кайтуынны сизүе бар. Ул әле киләчәк тормышының ничек тәгаенләнәсен үзе дә белми. Заһидә аны чуалган жеп шикелле бутап ташлады. Анын кабат калкып чыгуы исә бөтенләй тар-мар килү дигән сүз булыр иде.

Дәриганын күнеле булды. Ә таң алдыннан йокы бүлмәсенең ишеген уллары Кәрим киереп ачты да:

—Әтием, әниемә тимә, елатма әнине,—дип шыңшырга тотынды.

Шым булдылар. Бала йокы аралаш әнисенең ләззәтләнүен елау дип кабул иткән, күрәсең.

* * *

Кәшшаф һич уйламаганда тотылды. Гадәте буенча ул Заһидәгә язган хатының күчермәсен алды. Тик баш чуалган чакта барысын да уйлап житкереп була ди мени? Хатны онытып язу өстәле өстендә калдырган. Тузан суырткыч белән өй жыештырып йөргәндә Дәрига аны ялгыш идәнгә очыртып төшерде. Анын төпченә торган гадәте юк, ләкин менә мин дип үзе күзгә керергә торган язуга ничек битараф каласың ди инде?

Укыды. Укыды да келәм өстенә жәелеп тә төште. Үкереп тузан суырткычы эшли, ә ул яшь түгә-түгә ирен сүгә. Кырык алдар. Күпме вакыт күзгә төтен жибәреп йөргән. Фәхиш. Ә ул анын тасма теленә ышанды, бөтен гаепне Заһидәгә аударды. Ялгышкан икән. Башлап йөрүчесе дә Кәшшаф үзе икән. Сөйрәлчек. Мәхәббәтем өчен көрәшәчәкмен, имеш. Мескен. Каян килгән Ромео? Молодец, Заһидә! Төпсез арбага утырткансын. Шул кирәк ул хыянәтчегә. Ни-нәрсәгә ана ташландык ир? Сынык-санак белән туеныр га хәерчеме әллә ул. Берне түгел, унны табар. Ым гына как, күтәреп алырга торалар.

Алдакчы. Жебегән. Ул бу әшәке фатирда бер генә минутка да кала алмый. Әниләренең өе зур. Тора-бара фатир да юнәтер. Юк, хәзер инде ул элекке шикелле ир намусын саклап тормаячак. Үчен кайтарачак әле, Аллаһы боерса, кайтарачак!

Тузан суырткыч дөбер-шатыр эшли. Дәрига әйбер жыя. Идән чүп-чар, кием-салым белән тулды. Фатир эче яу үткәндәй тар-мар килде.

—Менә шулай, Кәшшаф әфәнде, борын күтәрерлеген юк, ташландык ир син хәзер. Ике тапкыр ташландык. Сөяркән дә баш тарткач, хикмәтен ташка үлчим генә димәк ки. Терсәгенне тешләрдәй булырсын да, буен житмәс. Бусагама килеп егылачаксың әле. Кәрим диячәксен. Менә сина Кәрим!

Дәрига йодрыгын төйнәп, кулын селкеп торды. Ләкин барыбер

ачуы басылмады. Нишләсә дә аз кебек тоела иде ана. Йөгереп барып Кәшшафнын китапларын, папкаларын пыран-заран китереп ташлады, әле һаман бугазына пычак тигән бозау шикелле гырылдап яткан тузан суырткычны тибеп очырды, чынаякларны берәм-берәм идәнгә тондырды.

Юк, жаны тынычланмый гына бит. Бераз уйланып торганнан сон, ниһаять, хатны идән уртасына этеп китерде дә өстенә йомышын йомышлады.

* * *

Рекрутларныкы шикелле кыска чәч йөртә башлагач, Дәрига бөтенләй башка рәвешкә керде. Аны бакыр төсенә буятып жибәрде. Итәкләре дә кыскарды, ботлары да ачыла төште, гәүдәсенен һәр уемы, һәр бөртеме ярылып өскә калыкты. Жилкәсенә үтә жете төстәге, чакрым ярымнан ук күзгә бәрелеп тора торган киемнәр кунаклады.

Шушы кыяфәтенә, килеш-килбәтенә тәнгәл рәвештә үз-үзен тотышы да үзгәрде. Аны явыз күзләрдән саклаучы аурасы жуелып юкка чыкты. Ялтыр баш үсмерләр дә сүз кушарга тартынмыйлар иде инде.

—Чибәркәй, утыр машинага, ожмахка алып барам.

—Обойдешься...

—Әйдә, синен әле андыйны күргәнен юк.

—Селәгәеннне сөрт башта...

Мондый сүзләрне ул үзенә бер канәгатьләнү белән әйтә. Тегеләре дә үпкәләми, ыржаеп көләләр генә.

Дәриганы кулга төшерергә йөргән базар кортлары бу үзгәрешне гайре табигый хәл дип кабул иттеләр. Болай да ак карга булып озак йөрде. Өергә керергә вакыт. Ләкин берсе дә һөжүмгә күчмәде, аулакка тарткаламады. Монын өчен базарны кулында тотучы Баш түбәнен хәер-фатихасы зарур. Анарда хан вәкаләте, үзенә сыендырамы, башкага бүләк итәме—анын эше. Кагыйдәне бозсан, муенынны гына борып ташлыйлар. Дәрига үзе Баш түбәне бер генә мәртәбә күреп калды. Утыз яшьләрдә булыр. Дык-дык итеп үкчәләренә басып йөри икән. Көнчедер, мөгаен. Чибәр димәс иде. Табак шикелле жәлпәк битенен нәкъ уртасында чобан кадәрле генә кечкенә борыны тырпаеп тора.

Бер көнне анын янына Такыр баш килеп туктады.

Дәрига кызып-кызып сату итә иде. Теле телгә йокмый, мактапмы-мактый тауарын.

—Бу кершән гаять тә актив биологик компонентлар нигезендә Франциядә ясалган. Мәскәүдә дә бер генә фирма алдыра аны. Мина зур танышлык белән генә жибәреп торалар. Бәхетегез. Алла Пугачева да шушы кремнан файдалана, Наина Ельцина да, кызлары да. Телевизордан күргәнсездер, ничек яшәргән. Пугачеваны әйтәм. Операция ясаткан дисезме? Ясатса сон. Операция үзенә, кершән үзенә. Хакы кыйммәт булмыйча тегә. Франциядә эшләнгән ич ул. Актив биологик компонентлар нигезендә... И, кадерлеләрем, егетләр карасын дисән, акча дип тормыйсын...

—Әй, каян әле, ычкыныгыз моннан,—дип Такыр баш кешеләрне төрткәли башлады.

Дәриганын күзләре шакмакланды.

—Нишләвен бу, бичура, гер белән арт чүмеченә тондырганны көтә-сенме?

—Тузынма, абыстай, мин сина яхшы хәбәр китердем,—дип авызын ерды Такыр баш.

—Мина хәбәр кирәкми, мина акча кирәк, ә син мина акча эшләргә комачаулыйсын.

—Бу акчалы хәбәр, абыстай, ха-ха-ха...

—Булмагае, табанынны ялтырат, сатунын кызган чагы.

—Хатыннарга күк төймә тоттырасын мәгәр.

—Анысы нәрсә тагын?

—Надан син, абыстай, укытучы башын белән күк төймә тоттыруны

да белмисең. Минем дәү әнинеке кадәр дә белемең юк икән. Элек ике хатынлы бер кеше булган, имеш...

—Юк, юк, ике хатынлы кеше турында ишетәсем дә, тынлыйсым да килми...

—Үзеңә кагылдымы әллә?

—Кагылды шул.

—Кагылса да сөйлим, сине мәдәни яктан агартырга кирәк ич инде. Бер хатынын икенчесеннән ныграк сөюенә ышандыру өчен ир боларның һәрберсенә берәр күк төймә тоттырган ди. "Бу тылсымлы төймә, берүк көндәшеңә күрсәтмә",—дип яшереп тотарга кушкан. Ике хатыны каршысына килеп: "Кайсыбызны ныграк яратасың?"—дип сораганда ул: "Күк төймәм кемдәдер, минем күнелем шундадыр",—дип җавап бирә икән. Хатыннарның һәрберсе ире үзен генә ярата дип, эчтән куанышалар икән.

—Шуннан?

—Шуннан шул. Син дә бит әнә нинди дер тузга язмаган актив биологик компонентлы француз кершәннәре хакында лаф орасың. Андый термин гомумән юк, була да алмый, бу—абсурд.

—Ә син каян беләсең, бәлкем бардыр?

—Медицина институтында укыган кеше мин, абыстай.

—Карап-карап торам да, иртәдән үк түбәтәй астын җылыткан, ахры, син, бичура, сайрыйсың гына.

—Әйтәм ич яхшы хәбәр алып килдем дип.

—Әйтсәң әйт инде алайса, сузма.

—Босс сине төнгә үзенә чакыра. Бар, хәзер кайт, төзән, ясан, машина белән килеп алырмын. Ошарга тырыш.

Дәрига ике дә уйлап тормастан кулындагы калькуляторны Такыр башка тондырды. Тегесе сыгылып төште, чөнки калькулятор очлы кырые белән аның кашын уеп алган иде.

—Мин сезгә фәхишә түгел,—дип кычкырды Дәрига,—мин гаиләле кеше.

Такыр баш кан баскан күзләрен акайтып, Дәригага ысланы.

—Босс булмасамы, кулыңны кыскартыр идем мин синең.

Тагын бер-ике көннән Дәриганы базар идарәсенә чакырттылар. Нинди гаебем бар икән, дип коелып төште. Күршеләре дә пошаманга калды. Бу арада касса аппаратлары булмаганнарның урыннарын алабыз дип яныйлар иде. Хөкүмәт карар кабул итәргә җыена, имеш. Янәсе, вак сәүдәгәрләр налогтан качалар. Болай да эшләгәннәренең яртысы төрлетөрле түләүләргә китеп бара. Сәүдәгәрләрне савым сыеры итәрләр иде. Сүздә барысы да базар яклы, гамәлләре генә капма-каршы. Сатучыларны берәм-берәм чакырып кул куйдырталар икән дигән хәбәр дә таралды. Шуңа күрә Дәрига идарә ишеген курка-курка гына ачты. Секретарь кыз компьютерга ябышкан жиреннән күтәрелеп карады да эшеннән аерылмыйча гына: "Сез Дәригамы?"—дип сорады. Унай җавап алгач, керергә мөмкин дигәндәй ым какты. Дәригага куркыныч булып китте.

—Сезне көтәләр анда,—диде секретарь кыз хатынның аптырабрак торуын күргәч,—кабинетка узыгыз.

Болайга китсә, бу касса аппаратын чынлап торып юнәтми дә булмас, дигән карарга килде Дәрига, митинг ясыйбыз дип йөриләр дә йөрүен, файдасы тимәс аның.

Кабинет эченә кергәч, Дәрига янә аптырап калды. Чөнки директорның бүлмәсен ул бик зур, соңгы мода буенча җиһазланган офис итеп күз алдына китергән иде. Баксаң, тавык кетәге кадәрле генә икән. Мебельләре дә иске, кыршылып беткәннәр. Бердәнбер күзгә күренерлек нәрсә—"Сони" телевизоры иде.

Шушы хәрәбә арасында заманча киенгән ике мәһабәт ир-ат утыра. Берсе—директор, икенчесе—Түбә. Дәрига ишектән керүгә, директор урыныннан купты. Алдан килешеп куйганнар иде, күрәсең.

—Мин урнаштырып керим әле,—дип чыгып ук китте.

Дәрига барысына да төшенде. Аны бирегә Түбә чакырткан икән, касса аппаратларының монда бер катнашы да юк.

—Утыр,—диде Түбә коры гына.—Эчәсен килсә, салып эч, монда һәркем үзен-үзе карый.

Түбә баш бармагын тырпайтып, кулы белән һава пәрдәсен ертты. Мондый кыланыш ана килешми иде. Кукәй күмәчедәй тулы аксыл йөзе, борын астындагы каз мамыгы шикелле кабарып торган йомшак төкләре аны, киресенчә, ярдәмчесез юаш үсмер кебек итеп күрсәтә иде.

Такыр баш әләге буенча чакырган инде бу, дип уйлап куйды Дәрига.

—Утыр, нәрсә катып калдың,—дип чекрәйде Түбә.

Дәрига артын урындыкка терәде.

—Якынрак кил, минем кеше ашый торган гадәтем юк.

—Сез нигә минем белән шулай тупас сөйләшәсез. Без таныш та түгел ич әле,—диде Дәрига ачуы чыгып.—Минем һәр минутым акча тора.

Түбәнең иреннәре сорау билгесе рәвешенә керде.

—Менә компенсация!

Ул кесәсеннән бер төргәк акча чыгарып, Дәригага сузды. Аннан соң өстәде: "Дөрес тукылдыйсың, акча санаганны ярата".

—Мин бу акчаны кабул итә алмыйм,—диде Дәрига.—Мин эшләп алырга күнеккән.

—Аванс дип исәплә, эшләрен алда әле.

Мине сөяркә итмәкче, дип уйлады Дәрига. Чукынып китсен дөньясы, әллә ризалашыргамы? Ул бит инде хәзер берәүгә дә бәйле түгел, дөрт ягы кыйбла. Гаилә терәге жимерелде. Кәшшаф үз алдына типтерә. Юллары мөгаен, кушылмас та инде. Ә гомер үтә. Ул тегеләй дә үтәчәк, болай да үтәчәк. Бу шома бит белән аның пычагы май өстендә йөзәчәк. Әнә, бер пачка акчаны уйламый да чыгарып салды ич.

Түбә искәрмәстән аны кулыннан тотып алды да үзенә таба тартып китерде. Озак кына күзләренә карап торды. Аннан соң:

—Венерик авыруларың юкмы?—дип сорады.

Дәриганы бу турыдан бәреп куелган сорау аптырашта калдырды. Аңлашу "яратам", һичьюгы "ошыйсың" дигән сүзләрдән башланырга тиештер ич инде.

Түбә шифоньер янындагы кечкенә өстәлдән ике касәгә шәраб агызып алып килде.

—Әле бит танышмадык та, синең исемең ничек соң?—дип сорады Дәрига.

—Ну, Таһир,—диде тегесе моның нинди әһәмияте бар соң дигәндәй иренеп кенә.

—Мин Зөһрә булам инде алайса,—дип чытыкланып көлде Дәрига. Аның бу чүмәләнең хисләрен кузгатып жибәрәсе, авызыннан берәр жылы сүз суырып чыгарасы килә иде. Таһир котып бозыннан да салкынрак иде. Алай булгачтан, нигә дип башларга соң бу уенны?

—Нәрсә өчен эчәбез соң?—диде Дәрига. Ул әле һаман Таһирны ачыктан-ачык сөйләшүгә этәрмәкче була иде.

—Шимбә көнне тусовка, әзерлән, калганын шунда аңларсың.

* * *

—Жә, товар үтәрлекме?—дип сорады базар башлыгы.

—Абыстай, борынгы заман,—дип иреннәрен кыйшайтты Таһир.

—Депутатка шундыйлар охшый.

—Шуңа тырышу ич инде. Күзләре нәкъ ул теләгәнчә.

—Һәм автостоянка кулына выжт итеп үзе килеп керә.

—Депутатны мин ничек кенә жайламадым инде.

Таһир авызына бер касә шәраб агызды да илән сайгакларын шыгыр-шыгыр китереп, бүлмә буйлап йөрештереп алды. Тәрәзә каршысына басып, урамны күзәтеп торды.

—Абыстай үзенә күрә генә түгел, Зөһрәң булырмын,—дип сайрап маташа анда...

—Сине яшь малайлар үтләтә башлаган, ахры.

—Мине хәзер бары автостоянка гына кызыксындыра. Һәм ул минеке булачак!

Таһир йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты. Пыяла касә туп шикелле бәргәләнеп торды да идәнгә төшеп челпәрәмә килде.

* * *

Дәриганың моңа кадәр тусовкаларга йөргәне булмады. Тусовканы да шул ук мәҗлес дип уйлый иде. Бактың исә, мәҗлес аның бәләкәй генә бер өлеше икән. Бу—майларына чыдаша алмаучы акча капчыкларының типтерү урыны. Тамашасы да, мунчасы да, уеннары да, кызлары да—барысы да бер түбә астында. Мафия яшәп калырга тырыша, гомеренең һәр минутыннан ләззәт табарга омтыла. Мәгәр эшем кешеләре инде. Ашаганда да, мунчада да, туалетта да, хәтта мәгъшукасы белән сөешкәндә дә колаклары асулы, телефон һәрвакыт әзер тора. Телефон капкынга эләккән тычкан чинавына охшаш чәрелдек тавышын чыгардымы, барысы да онытыла, уендагы шикелле комар бизгәге тота башлый үзләрен.

Тусовканы шәһәрдән читтә, урман эчендәге өч катлы матур бинада оештырганнар иде. Алдан сөйләшкәнчә, Таһир Дәриганың өенә машина җибәрде. Тәрәзәләренә пәрдәләр эленгән зур "Мерседес". Чәче кыркулы әзмәвердәй бер егет сүзсез генә арткы ишекне ачып, аны салонга утыртты. Үзе дә аның белән янәшә чүмәште. Юл буена авызыннан бер кәлимә сүз чыкмады. Ялт та йолт каранып баруын белде, сакчы иде, күрәсең. Дәрига дулкынлана иде. Алда аны ни көтә? Ризалашып дөрес эшләдеме? Башын ашамаслармы? Үз халәтен үзеннән яшерер өчен генә егеткә сорау бирде.

—Әле ерак барасымы?

Аның тавышын бу шома автомобильгә елышкан җил үзенә йомды, тавышы бик мескен булып чыкты. Ишетмәде бугай дип, тамагын кырыбрак янә соравын кабатласы итте.

—Әле ерак барасымы?

Җавап кайтаручы булмады. Бер дә харап икән. Дәрига сакчыга сырты белән борылып утырды.

Җем-җем җемелдәгән утлары белән шәһәр артта калды. Шофер аргамагының дилбегәсен бушата төште, ахры, тизлек бермә-бер артты. Каршыга килүче автомобильләр менә-менә өскә килеп менәрләр дә, изеп китәрләр кебек. Дәрига күзләрен йомды.

Ниһаять, килеп җиттеләр. Егет аны утырткандагы шикелле үк илтифат белән ишекне ачып чыгарды. Шунда ук Таһир басып тора иде. Әлеге чит-ят дөньяда ул Дәриганың бердәнбер таныш кешесе. Шундый якын, үз булып тоелды, йөгереп барып кочаклап аласы килеп китте.

Ә Таһир, гадәттәгечә, телефонга береккән иде. Ул буш кулын Дәригага изәде, сәламләве идеме, бераз сабыр ит диюеме—аңышмады. Телефонның аргы очындагы кеше якыны иде булса кирәк, авызы ерык. Сөйләшүе дә аерымачык ишетелеп тора.

—Китсәнә, булмаганны,—дип, Таһир шаккатуын белдерде.

...

—Ә ул?

...

—Ничек инде, бу мөмкин түгел, братан?!

...

—Во дают. Әллә Анталиядә "Санта-Барбара"ны күрсәтмиләрме?

...

—Гуд бай!

Таһир телефонын кесәсенә шудырды да Дәриганы күз иләгеннән үткәрде. Әмма аны-моны әйтмәде.

Алар тышкы яктан ук келәм түшәлгән баскыч буйлап икенче катка күтәрелделәр. Бөтен җир ялык-йолык килеп тора. Түшәмдә затлы люстралар, стена тулы картина. Барысы да төп нөсхә. Бәяләре дә куелган. Сатылалар, күрәсең. Кая карама, алтын-көмеш. Ишекләр фотоэлементка корылган, килеп басуга, үзләреннән-үзләре ачылып китәләр. "Сим-сим ишекне ач", дип тә торасы юк. Монда килеп эләккән кеше бернәрсәгә дә бернинди көч куймый, теләгенне теләп тә өлгермисең, ул инде үтәлә дә. Дәрига: "Их, бер генә йотым су эчәсе иде", дип уйлап бетермәде, каршысына шикәрдәй ак күлмәк кигән бер озын егет килеп басты. Кулында көмеш поднос. Анда эчемлекләр.

—Сезгә нинди су?—дип сорады ул һәм тезеп китте: җиләк-җимеш суы, минераль, абрикос, лимон, кокос.

—Чишмә суы бармы?—дип сорады Дәрига кызык өчен генә.

—Рәхим итегез.

Алар яныннан аяк тиресе ян-якка салынып төшкән кәтүк гәүдәле бер кеше узып китте.

—Чао, Банзай!—дип сәламләде аны Таһир үзенә бер сәер игътибарлылык белән.

—Чао!

—Банзай алтын унитаз иясе,—диде Таһир көнләшүен яшермичә.

—Үзенне бел,—диде Дәрига,—әнә, муенындагы алтын чылбырын тиренне бүсеп тора.

Син нәрсә беләсен сон базар корты дигәндәй Таһир кулын гына селтәде. Бу мохиттә кешенен урыны акча, алтын, асыл ташлар, затлы автомобильләр белән бәяләнә. Әйтик, "алты йөзле" мерседесын юк икән, "яна татар" статусына өмет тә итә алмыйсын. Моңа әле тагын бик күп нәрсә өстәлә: дәрәҗәле сөяркә, бультерьер токымлы эт, Рембрандт картинасы, Канар утрауларында вилла, Джакузи, "Версаче" костюмы. Аеруча алтыннан коелган унитаз бәһале. Унитаз иясе өчен бернинди киртәләр дә юк. Банзай менә шундый абруйлы кешеләрнен берсе икән.

Таһир Дәриганы зур гына бер бүлмәгә алып керде.

—Син үзенне тәртипкә китерә тор, абыстай, капкалап алсан да була, әле вакыт бар,—диде Таһир.—Минем хуҗаны күреп сөйләшәсем бар.

Дәриганың бүгенге эскәктән сон тагын да нәзекләнеп калган кашлары ак мангаенда яшендәй ялтырап алды.

—Нинди хуҗа ул тагын, мине син чакырдын түгелме?—дип Таһирга кадалды.

—Мин чакырмадым, кодаладым гына,—диде Таһир.

—Моны ничек анларга?

—Кодалау кодалау инде ул, аны башкача анлап булмый.

Дәрига атылып ишеккә килеп бәрелде. Ул бикле иде.

—Чыгар мине, югыйсә тавыш куптарам,—дип буылды.

—Монда кешене кеше ишетми,—диде Таһир исе дә китмичә, теләсән күпме кычкыр.

—Бу намуссызлык, Таһир,—дип кайтып төште Дәрига.—Мин сон, җүләр, үзен гашыйк булдын дип йөри идем бит. Ә син мине сатарга алып килгәнсен. Үтенеп сорыйм, зинһар өчен мине кайтарып җибәр. Мин саф-пакь хатын. Ирем белән ачуланышканга үч итү генә иде бу. Зинһар өчен... Таһир... Телисенме алдына тезләнәм...

—Сон инде,—диде Таһир.

Дәрига кыргый мәче шикелле искәртмәстән Таһирнын өстенә сикерде, үткен тырнакларын анын итләч муенына батырды. Тешләре белән колагына үрелде. Тик морадына гына ирешә алмады, Таһир бер селтәнүдә аны идәнгә бәрде.

—Әнчәк, муенынны борам бит.

Ул, әлбәттә, янавын ике дә уйламыйча гамәлгә ашырыр иде. Тик Дәрига инде Депутатка сөйләшенгән. Депутат үзе әле уен залында,

рулеткада бәхетен сыный, кичке ашка түтәй катына керәчәк. Автостоянкага документларны да алып килгән. Таһир, озакламас, үзенең алтын унитазын булдырыр. Шуна күрә абыстайны җайлау-майлау хәерлерәк. Катырак җилкенде, ахрысы, алай-болай имгәнә күрмәсен, югыйсә, планнары челпәрәмә киләчәк.

Дәрига янә ыргылмакчы иде, Таһир кулларын артка каерып, сөлге белән бәйләп куйды да җайлап кына кәнәфигә утыртты.

—Псих... нәрсә котырган эт шикелле ыргыласың?

—Ә син хатын җәмәй, мыегың да юк бит синең, гермофродит несчастный... Ычкындыр минем кулларымны! Хәзер үк!

—Тагын тузынмассыңмы соң?

—Синең шикелле албастыга ничек көчем житсен ди минем?

Дәрига хәйлә бөрмәсенең авызын чиште. Чөнки усаллык белән бернәрсә дә майтара алмаячагы көн кебек ачык иде. Аңа ничек тә Таһирны хәйләләргә, йомшак җәеп, катыга утыртырга кирәк. Ул барыбер бу шайтан оясыннан качачак!

—Аю, кулларымның тиресе суерылып төшә язды,—дип чыраен сыткан булды Дәрига.—Хатын-кыз бик нәзберек зат ул, май күбәләге шикелле...

—Дөрес тукылдыйсың, абыстай, мин хатын-кызлар белән эш итә белмим шул. Һәм теләмим дә...

—Әллә сөйгән кызың да юкмы?

—Мина яшь малайлар ошый! Ха-ха-ха!

Дәрига телсез калды. "Зәңгәр" икән ич бу, хайван. Ә ул аңа кайсы ягы беләндер ошый башлаган иде инде. Үзе коры булып күренергә тырышса да, ниндидер сөйдергеч сөяге бар кебек иде.

Менә сиңа сөйдергеч сөяк? Каберең якын булмасын бу хәшәрәтләргә. Исән-сау котылса, алар ягына борылып та карамас иде каравын.

—Ә син, абыстай, борчылма,—диде Таһир,—мина рәхмәт әйтәчәксең әле син. Кесәң тулы акча булыр. Базарда катып-калтыранып торуларның нәрсә икәнен беләм мин, үземнең дә башымнан үтте. Депутат әле көчендә, бик пар килгәнсез...

Таһир үз сүзеннән үзе кызык табып, буыла-буыла көләргә тотынды. Монын башында шөрепләре җитеп бетми, ахры, дип уйлап куйды Дәрига, җыен манкорт.

Таһир ничек кисәк кенә көлә башласа, шулай ук кисәк кенә туктады да. Туктауга куен кесәсеннән телефонын тартып чыгарды.

—Алло, администрация. Депутат бүлмәсенә сак куегыз.

Дәрига Таһирның кулларына барып ябышты.

—Зинһар, каравылчы чакыртма инде.

—Минем эшләрем бар, сине саклап утыра алмыйм.

—Әйттем ич инде, башка чәбәләнмим, дидем.

—Ышанырга буламы соң?

—Була!

—Кара аны!

Таһир бармак янады. Дәриганың да күнеленә икеләнү корты керде. Әллә соң ул Депутат дигәннәре белән очрашып карарга мы? Бай кеше, ди ич, бөтенесе аның алдында баш ия, ди. Тернәкләнеп китәр иде, бәлки. Мөстәкыйль булу өчен дә байлык зарур. Зур байлык! Депутатны шул максатта файдалану һич тә зыян итмәс иде. Ул инде тамгалы, болар аны җиңел генә ирекккә җибәрмәячәк. Ул карышып бер хикмәт тә чыгара алмаячак. Ачуларын кабартсаң, отыры үчләнерләр, шул булыр. Алайга китсә, кайберәүләр "крутой" егетләрнең артыннан үзләре йөриләр. Аның да укасы коелмас. Аннан китереп, куркып башлаган эшнең ахыры хәерле була, диләр. Бәлкем, болар, чынлап та, ходай кушуы буенча эшләнәдер? Ходайдан аңа бирелә торган бер форсаттыр? Атынны урлаткач, абзарны бикләүдән фәтвә юк. Үкенергә туры килмәгәе. Күтеннәрлек булгач, килмәскә генә иде, аны берәү дә ирексезләмәде.

Дәрига ишекне төртеп карады. Бикле булса, ниятлим, дип күнеленә беркетеп куйды. Ишек бикле иде.

—И, алдакчы тәре!

Дәрига ярдан суга ыргылган йөзүче шикелле йөгереп килеп ятакка сикерде. Ул язмышын хәл иткән иде инде. Ятакта бераз тәгәрәгәннән соң, үзен рәткә китерергә тотынды. Депутат агаебызның селәгәе аксын әле.

Ванна бүлмәсе тулысынча көзге белән тышланган иде. Түшәмдә дә, идәндә дә, стеналарда да, хәтта ишектә дә көзге. Беравык Дәриганың башы әвеш-тәвеш килеп торды. Кая карама, үзеңне күрәсең. Әйтерсең лә, зур сәхнә уртасында анадан тума килеш басып торасың.

Унитазы алтын микән? Юк, унитаз алтыннан коелмаган иде. Әмма искиткеч дәрәҗәдә чиста һәм шома. Бик затлы булырга тиеш.

Алтын унитаз турында Дәриганың беренче мәртәбә ишетүе. Француз короле Людовик XVI нын төнге чүлмәкләре хакында укыганы бар. Алар бик зиннәтле фарфордан ясалган булган.

Күрәсе иде, нинди була икән ул алтын унитаз? Алтын унитазга утыру өчен арт шәрәфләрең дә алтын булырга тиештер бит әле. Анысын ничек коярга?

Дәрига кычкырып көлеп җибәрде. Йә хуш, боларын күрдек, өсталләре нинди икән. Таһир капкалап алырга ярый диде бит.

Таһир урап кергәндә Дәрига кырын ятып телевизор карый иде. Кулында шәраб бокалы, алдында—кабымлыклар.

—Күрәм, абыстай, вакытны заяга уздырмыйсың,—диде Таһир гаҗәпләнебрәк. Ул мондый үзгәрешне көтмәгән иде. Болай булгач, эш пешәчәк, Депутатның да кәефе шәп күренә. "Берәр сәгатьтән бушыйм, шуна кадәр ханымның күңелен күрә тор",—диде.

—Күңел ачу өчен киллек ич,—диде Дәрига күзләрен уйнаткалап,—кавалер гына ышанычны акламады, өстән бикләп качты.

—Зарланма, абыстай, алай үзеңне бик күрсәтәсең килсә, киттек бию залына.

Бию залында кеше шактый иде инде. Ярымкарангы. Вакыт-вакыт оркестр мөнбәренә куелган яшелле-кызыллы лампалар гына бер кабынып китә, бер сүнә. Бар янында да ут пыскый. Тик ул тычкан күзе чаклы гына, үзеннән артмый. Ләкин бу башта гына шулай тоелган икән. Күз ияләшә төшкәч, биюче парларның йөзләре дә, үзләре дә шактый ачык күренә башлады. Дәрига иң элек игътибарын хатын-кызларга юнәлтте, усал каенана күзәтүе белән киемнәрен энә күзеннән үткәрде. Ул үзе кара төстәге кичке озын күлмәктән иде. Күлмәге гәүдәсенен төзлеген, зифалыгын ассызыклап тора. Затлы күлмәк! Шулай да ул аны театрга киеп барырга кыймас иде. Ник дисән, аркасы, муены, күкрәге тулысынча ачык, кылдай нечкә тасмада гына асылынып тора. Өстәвенә, як-якта, ян башына кадәр тирән ерыклары бар. Атлаганда озын шәрә аяклары күренеп-күренеп китә. Хатын-кызлар бу фасонны үзара "ир-атны әсир итү" фасоны дип йөртәләр.

Ә монда? Ничек итеп тәнне ачарга мөмкин, шулай ачканнар. Күлмәк дигәннәре билдән түбән һәм күкрәк турындагы ике ямаулыктан гына гыйбарәт. Иң затлы әйберләре, мөгаен, аякларындагы туфлиләрдер. Боларына тел-теш тидерермен димә. Алтын унитазга торырлык.

—Ну, абыстай, көндәшләреңне тикшереп бетердеңме инде?—дип сорады Таһир мыскыллы елмаю белән.

—Каян беләсең минем тикшергәнне?

—Сез хатын-кызлар барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән.

—Чыбык түгел, кабырга,—дип төзәтте Дәрига,—Адәм галәйһиссәлам кабыргасыннан яратылганбыз без, Таһир әфәнде, изге кабыргадан.

—Кабыргадан булмагае, хатын-кыз минем өчен буш урын ул, ноль.

—Син тумыштан шулаймы, әллә рәхәтлеккә чыдый алмыйча аш төрләндерү генәме бу?—дип сорады Дәрига.

—Күп белсән, тиз картаерсың, абыстай.

Дәрига тагын бер сәеррәк нәрсәгә игътибар итте. Хатын-кызларның бер ише башкалардан бик нык аерылып тора. Берәүләрнең арт саны күәс чиләгедәй, икенчеләренең түшләре сыер имчәгенә тиң. Таһир төпченгәнне бик өнәп бетермәсә дә, Дәрига бу хакта сорамыйча түзә алмады.

—Син үзең дә шулар сыңары,—дип көлде Таһир.

—Әйттең сүз...

—Депутатың аңлатыр әле.

—Депутатның алтын унитазы бармы?—дип төпченүендә булды Дәрига.

—Нәрсә, әллә мин сиңа шпионмы?

—Депутат аның кушаматыдыр инде, әйеме?

—Башымны әйләндермә әле!

Дәрига зур кызыксыну белән очрашуны көтә башлады. Килешкилбәте ничегрәк икән? Таһир: "Комы коела башлаган",—дип көлгән булды анысы, бәлкем, ирештерүе генәдер? Аннан соң, өлкәнрәк яшьтәгеләр арасында да яхшы сакланган кешеләр күп бит ул. Шадра гына булмасын. Дәриганың иң сөймәгәне шадра ир-ат. Жирәнә ул алардан. Яшьләргә дә исе китми. Жыен әлкәш, жыен наркоман. Ни үзләренә, ни кешегә. Әнә, чүмәлә шикелле Таһир хатын-кызлардан инде ваз кичкән.

Шулай да, Депутат ни өчен Дәриганы сайлады икән? Аларның соң күрешкәннәре дә юк ич. Аннан соң, 16-18 яшьлек кызлар байларның муенына үзләре асылынырга торалар. Монда да күп күренә яшь-жилкенчәк. Сәбәбен беләсе иде. Бар аның сәбәбе, бар! Теге Шомбай әйтмәгән була. Шуның сүзе буенча бит инде бу ботка. Читтән торып саткан мәлгунь. Товарга әйләндек тәки...

—Әйдә, тамакны чылатып алабыз,—диде Таһир. Официант сагалап кына торган диярсең, биегән жирләренә килеп тә житте.

—Рәхим итегез, нинди эчемлек телисез? Коньяк, виски, аракы, ром...

—Коньяк.

Таһир подностан ике бокал алып, берсен Дәригага сузды.

—Тот, абыстай!

Нәкъ шушы мизгелдә кемнеңдер кулы Дәриганың шәрә аркасына килеп сарылды да, шуып аска ук төшеп китте. Дәрига чырылдап кычкырып жибәрде, бокалы идәнгә төшеп ватылды. Бер селтәнүдә ул әлеге кулдан арынды, күзләреннән ут чәчеп, артына борылды. Ә анда ап-ак чәчле, кибән башыдай очлы иякле, юка иренле Дон-Кихот Ламанчскийга охшаган алтмыш яшьләр тирәсендәге бер озын буйлы кеше басып тора иде.

—Во, блин, менә бу күзләр!—диде ул Дәриганың тыпырчынуына игътибар да итмичә.

—Заказ буенча,—диде Таһир.

Бу Депутат иде. Ул Дәриганы кулыннан эләктереп алды да яктыга алып чыкты.

—Ямь-яшел, во блин.

Дәриганың күзләре, дөрестән дә, кемнекенәдер охшап, яшел иде. Күрәсең, кайсыдыр ерак буында чит кан кушылган булган. Һәм ул геннар Дәригага кадәр килеп житкән. Дәрига, ниһаять, төшенде. Бу ак чәчле абзаң яшел күзле хатын-кызлар белән мавыга икән. Монда шулай ук зур түшле яки арт саны олы туташ вә ханымнарны коллекция итеп жыючылар да бар икән. Таһир тәре аны тәки шушы шакшы уенга китереп тыкты.

—Әйдә, куышыбызга кайтыйк,—диде Депутат.—Миңа Ләбиб дип дәшәрсең...

Дәрига Таһирны эзләп, ян-ягына карангалады. Ләкин аннан жилләр искән иде инде. Сатлык жан...

Депутат ана сагыздай ябышты.

—Ләбиб, үтенеп сорыйм, кулларыгызга ирек куймагыз әле, мина бик уңайсыз.

—Мина шулай ошый,—дип Ләбиб кырт кисте. Бу аның монда барысы да мин дигәнчә булыр дип кисәтүе иде. Күңәргә туры килде.

—Во, блин, мин сина гүзәлкәемнен фотокарточкаларын күрсәтмәдем бит әле,—дип, ниһаять, Депутат беразга гына булса да Дәриганы тынычлыкта калдырды.

Ул озын ботлы фәхишәләренне күрәсем килеп тормый әле, дип уйлады Дәрига, хәйвани затка әверелеп беткәнсез инде, бер хатын-кызны кочып тора, икенчесен мактый. Мәнсез.

Депутат кесәсеннән блокнотын чыгарып, аны шүрәленеке шикелле озын, нечкә бармаклары белән сыйпаштырып алды. Дәрига ярылырга житеште. Кәшшаф болай ук булдыра алмас иде, дип бүген беренче мәртәбә ташлап киткән ирен хәтеренә төшерде.

—Башта, блин, коллекция өчен сине сурәткә алабыз, аннан соң гүзәлкәйне карыйбыз,—диде Депутат.—Утка якынрак бас.

Ул берничә мәртәбә фотоаппаратын чыжылдатып алды.

—Хәзер алдыма утырсан да ярый.

Депутат блокнот эченнән берничә фотосурәт тартып чыгарды.

—Во, блин, класс!

Сурәттә машина иде. Гавана сигарасы шикелле озын, очлы башы бераз жиргә түнтәлебрәк тора. Өстенә су сипкәннәр диярсен, буявы ялык-йолык ялтырый. Кап-кара төстәге зиннәтле машина.

—Шәхси заказ, блин, шәпме?

Дәрига көлеп жибәрде. Менә нинди гүзәлкәй турында сүз барган икән? Ә ул көнләшүеннән шартлый язды.

—Искиткеч машина!—Дәрига Ләбибнын муеныннан кочып, иреннәреннән үбеп алды.—Искиткеч!

—Монсы, блин, мен чакрым үткәннән сон алынган сурәт. Берәр үзгәреш күрәсенме?—дип Ләбиб ана икенче фотоны тоттырды.

—Мина калса, матурланыбрак та киткән әле. Беләсенме, ни өчен?

—Әйт, ни өчен?

—Ана синен жан жылын, рухын кереп оялаган.

—Во, блин, дөрес бит. Машина минем өчен яшел күзле хатын-кызлардан да өстенрәк. Берегез дә машинага тормый сезнен. Кара син анын, блин, килеш-килбәтенә. Машина белән, блин, фәкать гарәп елгырлары гына тиңләшә ала. Рәсемгә ул туктап торганда төшереп алынган. Шушы хәлендә дә нинди мәһабәт ул. Ә машинанын гүзәллеге хәрәкәттә ачыла. Юлда машина бөтенләй үзгәрә, башка рәвеш ала. Гәүдәсе зифаф кичендәге кәләшнеке шикелле әле кабара, әле сузыла, әле тыгызлана, әле бушана... Ә түше? Чибәр туташларныкыннан һич тә ким түгел. Күр, ничек киерелеп алга бәреп чыккан! Тотып карыйсы, сыйпыйсы, каппыйсы гына килеп тора...

Акылы ягыннан да машина уздыра. Иртән ул әниләргә генә хас йомшаклык белән: "Бәхетле көннәр насыйп булсын, хужам",—дип каршы ала. Жылы, йомшак кәнәфигә кереп чумасын да кулындагы ачкычын белән кабызу жайланмасын тоташтырасын. Моторга шундук жан керә. Анын тигез тавышы колакка аһәнле музыка булып ишетелә. Күңел кети-кети килә башлый.

Машинамы? О-о, машина! Бар дисән—бара, тукта дисәң—туктый. Ашыкмаска кушсан, тизлеген киметә. Кичектергесез шөгыле бар икән—коштай оча.

—Ләбиб, сез шагыйрь икән ләбаса!

Депутатка мактау ошады, куллары янә эзләнә башлады. Дәрига карышмады.

—Ятыйк,—дип пышылдады.

—Башта мине уят әле,—диде Ләбиб,—киемнәренне салып ташла.

—Мин оялам, утны сүндерик.

—Юк!

Ләбиб Дәриганы ярты сәгать чамасы утын пүләне шикелле әйләндергәләде. Бер арада көченә килеп, кабалана-кабалана шөгылен башкарды да, җәелеп йоклап китте. Дәрига аны назлап та, төрткәләп тә карады. Уянмады. Гырылдавы-гырылдау. Аннан соң көзгеле ваннада өстенә салкын су коеп, кузгалган дәртен басты.

Уйга калды. Нишләргә? Бу сөрхәнтәйне саклап төн үткәрмәс бит инде. Үзләрен үзләре белмичә хатын-кыз чакырган булалар бит әле. Гарьләнмиләр дә.

Әллә сызаргамы? Каравылга Депутат озаттырырга кушты дияр. Үзе кая дип сорасалар, ял итә, бимазаламаска кушты, дияр. Алтын унитазлары, көзгеле ванналары белән кадалышып бетсеннәр. Тик ядкяр итеп нидер калдырырга кирәк бу Дон-Кихотка. Сагынып сөйләрлек булсын.

Дәриганың маңгаена эреле-ваклы сырлар ятты. Күп тә үтми, авызын каплап, пырхылдап көлеп җибәрде. Депутатның өстәлгә салып куйган алтын балдагын үрелеп алды да тагын пырхылдады. Каян башына килде, шәп нәрсә уйлап тапты бит, ә? Тукайның Былтыры гына түгел инде бу сина.

Дәрига иплән кенә Ләбибнең өстендәге одеалын бер читкә каерып куеп, әлеге алтын балдакны аның җиде үлем белән үлгән ирлек әгъзасына кигерде.

* * *

Депутат озак кына төшләнеп ятты. Имеш, дошманнары аны бәйләп ташлаганнар. Шундый каты итеп кысканнар ки, буыннары гөбе шикелле кабарып чыкты. Ә үзләренең хәбәрләрендә дә юк, тешләрен ыржайтканнар. Араларында яшел күзле бер пәри кызы да бар.

Чыдар әмәле калмады Ләбибнең, гәүдәсе шартлап ярылырга житте.— Аһ... аһ...

Ул шушы авыр тойгы белән күзләрен ачты. Җә, Ходам, нигә шул кадәр авырта соң аның тәне? Бот арасына кул тигезмәле түгел, уттай яна. Әллә пычак кадаганнар инде.

Ләбиб куркынып кына шунда бакты. Исе-акылы китте: әгъзасы өреп тутырылган шар шикелле кабарынган иде. Төбендә нидер ялтырый. Балдак түгелме соң? Теге яшел елан эше бит бу! Блин!

Ләбиб телефонга ябышты. Озак та үтми ашыгыч ярдәм машинасы килеп житте. Балдакны пычкы белән кисеп алдылар.

* * *

Иртәгесен Дәрига үз вакытында базарга килеп житте. Анда аны Таһир көтеп тора иде инде. Йөрәге тота язды хатынның, аяклары кургаш булып катты. Түбәнең йөзе кырыс иде, кашы-күзе жимерелгән. Кәҗә маен чыгара инде бу дип уйлап алды Дәрига. Үзенчә аклану хәйләсен дә табып куйган иде. Бер-беребезне охшатыштык, яратыштык. Шаяртып кына мин аңа шушы призны кигездем. Эчтек, исерештек Ләбиб мине озатып калды...

Таһир ачулы булып кылана гына иде. Әнә, ирен читләре мелтмелт итеп куя. Түземлеге бетте, ахры, көлеп җибәрде.

—Ну, абыстай, Депутатны хур иткәнсең бит, ә?

Дәриганың эченә җан керде, димәк, бу вакыйганы шаярту дип кенә кабул иткәннәр. Югыйсә, Таһир үзен болай тотмас иде.

—Артык яратудан,—дип тәгаллек кертте Дәрига,—бер чуваш та яратуына чыдый алмыйча баласын килегә салып төйгән ди бит.

—Күзгә төтен жибәрмә, абыстай, җәме? Бәхетең, автостоянка хәзер минем кулымда. Син безнеке инде. Бу кругтан чыгуы бик авыр.

Дәрига дәшмәде. Дәшеп ни файда, барыбер үзләренекен итәчәкләр.

Кырт кешеләр. Байлыкларына да ышанып бетмиләр кебек. Чөнки байлык аларга көч куймыйча янгыр булып яуды. Ана алар әзер түгел иде әле. Нишләргә? Кая куярга? Ничек тотарга? Уенчык кибетендәге бала шикелле әле монысына барып ябышалар, әле тегесенә. Күпчелек байлыкны типтерү, тәтәйләр тоту, машина арты машина алмаштыру дип кабул итә. Шуның белән бергә, байлыкның түмен дә татып өлгерделәр инде. Ифрат та татлы нәрсә икән ул байлык. Аны кулдан ычкындыру үлем белән бер. Шуна күрә атышалар, суешалар, барысы да шуннан килә.

Дәрига менә шул дөньяга борын тыкты.

* * *

Конференция татар тарихчыларын берләштерү буенча үзенә йөкләнгән бурычны өлешчә генә үтәде. Мәгълүм мәсәлдәгечә, тарих арбасын берсе суга, икенчесе күккә, өченчесе җиргә таба өстери иде. Дөресен генә әйткәндә, бу мөмкин дә түгел. Ут белән суны ничек кушасын ди? Һәрберсе үз теориясен генә хак дип санаган, фәкать үзенекен генә таныган галимнәр төркем-төркем булып аерылышып беттеләр.

Болгар теориясе тарафдарлары, билгеле инде, иң ишлесе. Халык болгарны Ислам... динен кабул итү белән бәйли. Шуна күрә күпләр үзләрен турыдан-туры болгар нәселе дип саный. Ә татар-монгол аларның күнеленә канечкеч вәхши булып сеңеп калган. Монысы инде "тәрбия" җимеше.

Казандагы берничә галимне исәпкә алмаганда, фәкать бер генә шәхес әлеге постулатка кизәнергә җөрьәт итте. Бу мәшһүр тарихчы Лев Гумилев, шагыйрь Анна Ахматованың төрмәләрдән башы чыкмаган улы. Гумилев татар-монгол игосын бөтенләй инкарь итә, еллар үткәч кенә китереп чыгарылган уйдырма дип тәкрарлый. Мона ишарә итүче чыганаклар элек тә булган анысы. Тик аларга юл бирмәгәннәр, кысып тотканнар. Монгол чорында, әйтик, рус кнәзләре, дәүләтләре үз иркендә яшәгән. Ясак исә кергән байлыкның нибары уннан бер өлешен генә тәшкил иткән. Хәзер булса иде бу законнар!

Гумилев белән очрашу Кәшшафның иң зур хыялы иде. Петербург журналисты Даут Әминев булышлыгы белән ул очрашу әзерләнә дә башлаган иде инде, галим ризалыгын да биргән иде. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, юлга чыгар алдыннан гына телеграмма килеп төшмәсенме: "Гумилев авырый, очрашу кичектерелә". Шуннан соң озак та үтми, газеталарда аның вафаты хакында некролог басылып чыкты.

Мыштым гына эшләп ятучылар да булган икән. Кичә Кәшшафка дусты Рамил бер журнал тоттырды. "Асларына кызыл карандаш белән сызылган юлларга игътибар ит әле",—диде. Борынгы елъязмаларны, кулъязмаларны, физика, математика ысуллары белән өйрәнеп, тикшереп, шундый нәтиҗә чыгарганнар: кенәз Иван Калита (Мәскәү патшалыгын бар иткән зат), Батый хан, Рим Папасы Иннокентий III бер үк шәхес, имеш. Кешелек тарихында шушы өч исем белән йөргән бәндә XIV гасырда Көнбатыш Аурупаны "Бөек Мангул" явы белән басып алган да Италиядә Ватиканны оештырган, имеш.

Бу физика-математика фәннәре докторы, академик, Мәскәү университетының кафедра мөдире Анатолий Фоменко белән шул ук университетның өлкән фәнни хезмәткәре Глеб Носовский фаразы.

Һичкайчан, һичкемнең башына килерлек хәл түгел, югыйсә. Батый хан—Ватикан. Хәер, зур ачышларны хәзер тузга язмаган аралыклардан эзлиләр ич. Эзләсеннәр. Фәнгә бу файда гына китерәчәк.

—Иртәгә митинг буласы, барабызмы?—дип сорады Рамил. Ул үзе бер җыенны да калдырмыйча йөри. Татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе Марсель Нәҗипов аның якташы, икәве дә Себердән, Түмән ягыннан. Дустына терәк булмакчы, күрәсең. Ләкин үзенең бер мәртәбә дә чыгыш ясаганы юк, читтән генә күзәтеп тора. Охшаш дигәннән, Әлтаф та

Себердә туып үскән кеше. Тик ул митингларны кабул итми. Хәер, Кәшшаф үзе дә шау-шуны өнәп бетерми. Анда сөйләнгән сүзләрне дә җилгә очкан буш сүзләр дип исәпли. Картлар әйткәндәй, сүздән сүс талкып булмый. Әмма сүз халыкны күтәрә, дигән караштa торучылар да күп. Ихтимал, дөрестер дә.

—Миндә митинглар кайгысы юк,—диде Кәшшаф,—ял көнне кер юам.

—Дәрига һаман йомшармыймы?—дип сорады Рамил.

—Заһидә баштан чыкмый әле монда, җүләрләнәм бугай инде.

—Бүтән ир белән яшәгән хатын ни-нәрсәгә сон сина, анламыйм...

—Шулай икәнен мин үзем белмим дисеңме? Бик беләм. Тик үтер, оныта алмыйм. Баштан бер генә секундка да чыгып тормый.

—Ә Дәрига? Кәрим?!

Кәшшаф битараф кына җилкәләрен сикертеп куйды. Аның белән бу темага сөйләшүнең мәгънәсе юк иде инде. Шуна күрә Рамил сүзне янә якшәмбе көнне булачак митинг темасына борды.

—Ленин бакчасы тукталышында очрашырга сүз куешыйк. Соңыннан берәр кафега кереп тамак та ялгап алырбыз.

—Шулай дисәң генә инде...

Апрельнең уртасы гына булуга карамастан, кояш шактый тузынып алды. Юл читенә өелгән кар көртләре мәңге бетмәс сыман иде. Шушы ике-өч көн эчендә шинеп, тыны чыккан шар рәвешенә керделәр дә калдылар. Җыерчыкларында хәзер чүп-чар гына утырып тора. Боз сөңгеләре белән мәрәкә. Төн чыкканчы гаскәриләр шикелле кәрнизләрне уратып алалар. Җыештыручылар сукрана-сукрана иртән иртүк аларны кырып йөри. Соңгы көннәрдә Кабан күленең бозы да кабартма шикелле бүртенеп китте.

Яшьләр ашыга-ашыга җылы киемнәреннән арындылар, күбесе яланбаш. Өй кыекларында чыпчыклар яратыша...

Һәм, һич көтмәгәндә, Суык бабай эле үзенең хуҗа икәнен белдерде. Усал җил кайдадыр Каф таулары артында посып утырган болытларны куып алып килде. Тотынды тузгытырга, тотынды тузгытырга, төн чыкканчы җирне кар белән тутырды. Ләкин шушы бер карыш калынлыгындагы кар астыннан да яз исе бөркелеп чыга. Егетләр-кызлар, әнә, бер-берсенең муенына кар салышып уйный башладылар, чыр-чу, шаяру-көлү. Бу инде, ничек кенә тартышмасын, Кыш бабайның көннәре санаулы гына калды дигән сүз иде.

Театр мәйданында хәл бөтенләй башка. Кырыс, горур, тантаналы музыка янгырый. Кешеләр бик җитди күренә, һәрберсе үзен татар милләтенең вәкаләтле илчесе, ышанычлысы итеп саный. Яз, бөреләр, кар—болар вак нәрсә, милли хәрәкәткә кагылмый.

Галимҗан Ибраһимов татарның эчке халәтен бер җөмләгә сыйдырган: «Татар дөньяда тора, ашый, йоклый, әмма яшәми», дигән. Арттырумы? Билгеле, арттыру. Ә асылы хак. Чөнки биш гасыр тулар-тулмас вакыт эчендә татарның менталитетын тәмам үзгәрткәннәр, тынлаучан тешләк затка әвереллдергәннәр. Ул кайчандыр тагын Алтын Урда дәрәҗәсенә күтәрелә алырмы, моны әйтүе кыен.

Кәшшафның уйлары дуамал иде.

—Әссәламегаләйкем, хөрмәтле милләттәшләр!—Мәйдан буйлап Нәҗиповның хөр тавышы тәгәрәде.

—Азатлык!

Йодрыклар төйнәлеп, югары күтәрелде.

—Азатлык! Азатлык! Азатлык!

Коммунистлар вакытындагы партия җыелышларындагы шикелле митингларның да даими ораторлары бар. Аларның барысы да исемле. Бер ише президент, икенчеләре координатор, рәис, спикер... Һәрберсенең үз оешмасы.

Менә микрофон алдына чыра йөзле, күзләре эчкә баткан юка

гәүдәле кеше чыгып басты. «Суверенитет» җәмгыятенең вице-президенты дип тәкъдим иттеләр.

—Бу агайның ни сөйләсен алдан әйтеп биримме?—диде Рамил, һәм Кәшшафның җавабын да көтеп тормыйча тезеп китте: «Җәмәгать, безгә кичекмәстән түбәндәгеләрне эшләргә кирәк: беренчесе, үз акчабызны булдыру, икенчесе—таможня ачу, чикне ябу, өченчесе—Берләшкән Милләтләр Оешмасына әгъза булып керү. Суверенитет башкача була алмый...»

Чыннан да, вице-президент нәкъ шушы сүзләрне кабатлады. Кәшшаф гаҗәпкә калды, сөйләүчеләрнең бу үзенчәлегенә игътибар иткәне булмаган икән.

—Нәрсә, попугаймы әллә ул?

—Халык аннан шушы сүзләрне көтә,—диде Рамил. Ул хаклы иде. Митинг алкышларга күмелде.

Митингның сәер хәлләре моның белән генә бетмәде әле. Баксаң, Казан ханлыгының җимерелүенә фәкать Иван Грозный гына сәбәпче икән. Теттеләр тетмәсен. Ә популяр җырчы Вафирә Гыйззәтуллина "Россия Федерациясенең атказанган артисты" таныкламасын бөтен халык алдында ут төртеп яндырды.

—Минем Россия белән бернинди алыш-бирешем дә юк. Долой!—дип кычкырды.

Шулвакыт алар янына Нәҗипов килеп туктады. Аның гадәте шундый, митингны башлап җибәрә дә, халык янына төшә. Аралаша, сөйләшә, фикерләрен белешә. Кәшшаф белән алар күптәннән таныш. Көндәлек тормышта ул басынкы холыклы, аз сүзле кеше. Кайгысы бар сыман һаман борчулы кыяфәттә йөри. Көлгәндә дә авызын ачмыйча, тыныч кына көлә. Өстәвенә, этенебрәк сөйләшә. Менә шушы кеше милли хәрәкәтне җитәкли. Беренче карашка, бу урында ут борчасы шикеллерәк башка берәү булырга тиеш кебек. Ләкин, уйлана торгач, әлеге табигый сайланышның бер дә очраклы булмавына төшенде Кәшшаф. Зирәк, сабыр, акыллы кеше генә милли хәрәкәт дигән утлы ташкынны янгынга әйләнүдән саклап кала ала. Милли хәрәкәттән—милли фаҗигагә бер генә адым. Әле Нәҗипов белән дә шул хакта гәпләшеп алдылар.

—Милли хәрәкәт өйрәтелмәгән тай кебек ул, шулай булмаса, аның хаҗәте булмас иде,—дип калын пыялалы күзлеге аша әңгәмәдәшләренә моңсу гына карап куйды Марсель.

—Бигрәк маңгайга бәреп сөйлиләр бит, күп нәрсәләр дөреслеккә дә туры килми,—диде Кәшшаф.

—Бисмаркның тирән мәгънәле сүзләре бар,—диде Нәҗипов.—Ул: «Революцияне гениилар хәзерли, фанатиклар гамәлгә ашыра, ә җимешләре белән адәм актыклары файдалана»,—дигән. Без, мөгаен, фанатикларына карыйбыздыр. Җимешләрен җыйганда инде безне катнаштырмаячаклар.

Нәҗипов гаепле кеше сыман ирен очлары белән генә елмаеп, йомшак кына атлап үз юлына китеп барды.

—Марсель бик намуслы кеше, хәзерге заманның шакшы сәясәтенә яраклаша алмас ул,—дип, Рамил үзенең шиген белдерде.

—Җайлашыр, ник җайлашмасын, депутат булып сайланды ич әле,—дип каршы төште Кәшшаф.—Себер татарларымы? Һе, алар...

—Себер татарларына ни булган, нәрсә дип алар исеме белән авыз чайкарга уйладың әле,—дип Рамил дә кабынып китте.

—Әлтафны кая куясың?

—Нигә, директор урынбасары булу гаеп эшмени?

—Юк, гаеп эш түгел,—диде Кәшшаф,—тик ул икенче лагерьга чыкты. Без аның белән ун ел бер сүз сөйләдек! Хәзер Галимовча сайрый. Кайберәүләр, алар электән үк әшнә иде, кешегә генә күрсәтмиләр иде, диләр.

—Моны әле дәлилисе бар...

Көтмәгәндә Галимов Алтын Урда төркеменә кергән Әлтаф Гази-

зуллинны үзенен урынбасары итеп куйды. Ике арада нинди сөйләшү булгандыр, бу берәүгә дә мәгълүм түгел. Шулай да бик тиз арада Әлтаф дусларына сырты белән борылды. «Исәнме—исән», шунын белән вәссәлам. Әгәр кеше сөйләгәннәр дөрескә чыкса, шушы узган ун елда ул Троян аты ролен башкарган булып чыга ләбаса! Шымчы! Барысын да түкмичәчми житкереп торган димәк.

Дуслар башлаган сүзләрен тәгәлләп бетерә алмадылар, мөнбәргә яна төркем менеп басты. Кулларында—плакатлар: «Без—болгарлар», «Татар көчләп тагылган исем», «Республикабыз—Болгар республикасы» ...Кычкырышалар, йодрыкларын селки-селки биешәләр.

—Паспортларны алмаштыру кампаниясе башлыйбыз,—дип оран салды озын муенлы бер кеше.—Киләсе якшәмбедә нәкъ шушы вакытта татар исеме язылган паспортларны яндыру акциясе үткәрәбез.

Озын кулларын югары күтәреп:

—Яндырабызмы?—дип сорады.

Җавап ул теләгәнчә иде.

—Яндырабыз!

—Яндырабызмы?

—Яндырабыз!

—Бер төркем хөрәсән галимнәр болгар юк, татар гына бар, дип икърар итәләр. Төп дәүләтебез дип Алтын Урда дәүләтен күрсәтмәкче булалар. Дөрес түгел! Долой, Хәмитов! Долой Сәмигуллин! Долой, Ашказарский!

—Сызыйк моннан,—диде Рамил,—йә, бу инквизаторлар тотып учакка салырлар.

Кәшшафны учактан битәр, чыгып сөйләүче әлеге озын муенлы кешенең хәбәрдарлыгы гаҗәпләндерде. Каян белә ул кайсы тарихчының нинди тема белән шөгыльләнгәнен? Хәер, бер караганда, мона аптырыйсы да юк. Соңгы вакытта газета-журналларда татар халкының килеп чыгышына кагылган күп кенә популяр мәкаләләр дөнья күрде. Милләтчеләр—укымышлы кешеләр. Тик алар һәр мәгълүматны үз кысаларына тартып кертәләр. Бернинди икеле-микеле фикерләргә юл калдырмыйлар: син йә дус, йә дошман.

Берничә көннән Кәшшафның фатир адресына хат килеп төште. Конверты ук игътибарны җәлеп итәрдәй, ыспай, күркәм. Әллә хөкүмәт хаты инде? Юк, хөкүмәтнекендә махсус билге була. Затлы үзе, хәлле кеше җибәргәнгә охшый. Кем икән, аның танышлары арасында байгуралар юк шикелле. Бәлкем, Дәригадыр? Ташлап киткәннәренә шактый вакыт узды ич инде. Ә аның улын бер мәртәбә дә барып күргәне булмады. Оят! һәм андый теләге дә уянмады. Заһидә хәтта Кәримне дә күңеленнән төртеп чыгарды.

Кәшшаф әлеге тәти конвертның бер башын ертып төшерде дә, эченнән икегә бөкләнгән шундый ук затлы бер кәгазьне суырып чыгарды.

Нәрсә бу? Рәсемме? Плакатмы? Бер-бер реклама проспектымы? Аерым фирмалар рекламаларын почта аша да җибәргәлиләр. Алай дисәң, аңлатмасы булыр иде.

Кәшшаф баш сөягенә яшен угы кадалган бу сурәтне нишләтергә дә белмичә кулында әйләндергәләп торды. Таныш сурәт. Зур көчәнешле электр тогы үткән җирдә кисәтү ролен үти ул. Сак булыгыз, сезгә куркыныч яный! Болай булгач, Кәшшафка да яныйлар булып чыга түгелме соң? Телеңне тыймасаң, сине дә шундый язмыш көтә дип кисәтәләрдер, мөгаен.

Әллә бөтенләй шаярту гынамы? Аның кемгә кирәге бар. Шулай хәл итте Кәшшаф. Ләкин вакыйгалар куерып китте. Әлеге хат шуларның хәбәрчесе генә булган икән.

Республиканың бер рәсми гәҗитендә кыска гына хат басылып чыкты. Себердән язган, Исмәгыйлев Габсаттар исемле, Тубыл каласы кешесе. Менә аның тексты.

«Минем ата-бабаларым үз теләкләре белән Түбән өлкәсенә Идел

буеннан көченеп килгәннәр. Мона каләр татарлар арасында бернинди низаг булмады, бергә-бергә яшәдек. Сонгы вакытта гына нигәдер безне бүлә башладылар. Баксан, Себер татарлары үзләре бер милләт икән, аларның Казан татарларына бернинди бәйләнеше дә юк икән. Динебез, гореф-гадәтләребез, телебез, денебез бер дигәндәй... Мин үзем аерма күрмим. Анлатып бирсәгез икән».

Шушы самими һәм эчкерсез хатка гәҗиттә Гуманитар фәннәр институты директоры урынбасары Әлтаф Мәхмүт улы Газизуллинның җавабы урнаштырылган иде. Теоретик стильдә язылган шактый шома җавап. Аның билгеләп үтүенчә, Себер татарлары шул төбәкнең төп җирле халыкларыннан санала. Аларның токымы, ягъни төркиләр бу җирләрдә бик борынгыдан төпләнеп яшәгәннәр. Себер татарларының үзләренә генә хас характерлары, этник үзенчәлекләре, культуралары формалашкан. Ин мөһиме, Себер татарларының үз дәүләтчелеге булган. Ә бик күп галимнәрнең уртак фикере буенча, дәүләтчелек теге яки бу халыкның милләт буларак төп сыйфатын тәшкил итә икән.

Димәк... Юк, юк, Аллам сакласын, Әлтаф Мәхмүтович турыдан-туры «Себер татарлары мөстәкыйль милләт» дигән нәтиҗә чыгарырга ашыкмый. Нәкъ шул урында ул «иштәк»ләр турында, болгар компонентының Себер татарлары формалашуында катнашуын раслаучы тел һәм ономастик материалларның юклыгы турында җәелеп, уйлануларга чума. Янәсе, тел охшашлыгына гына карап, халыкларны бер-берсенә кушарга ярамый. Әйтик, украин, белорус, рус телләренең тамыры бер, ә өчесе өч милләт. Татар һәм башкортлар хакында да шул ук сүзләрне әйтергә мөмкин. Хәлбуки, Ризаэддин Фәхретдин татар белән башкортны бер халык дип карый. Хәтта бер телдә сөйләшкән халыклар да төрле милләткә карый. Инглизләр, мәсәлән, әмерикәннәр...

Кәшшафның ачуы алкымына җитеп кабарды. Күр син, кара йөрәкне. Ашаган табагына төкергән нәмәстә. Эче тулы мәкер икән. Астыртын гына Себер татарлары мөстәкыйль милләт дигән теорияне алга сөрә бит бу. Җайлап кына, иплэп кенә укучыны шундый нәтиҗә ясарга этәрә. Хәйләкәр төлке. Болайга китсә, мишәрләр, типтәрләр, нугайлар, кыпчаклар да бүленеп чыгарга тиеш буламы? Бу чын мәгънәсендә милләтне таркатуга юнәлдерелгән провакация ләбаса. Димәк, киләчәктә пакь канлы болгарлар токымыннан булган Казан татарлары үзләре генә торып калачак.

Ай-һай, мона Әлтаф үзе генә җөрьәт итә алыр иде микән?

Себер татарлары мәсьәләсе әле генә калкып чыккан бәхәс түгел, билгеле. Ул һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Г. Миллер, мәсәлән, үзенең «Себер тарихы» дигән хезмәтендә Казан һәм Себер халыклары арасындагы династик, сәяси һәм этнокультур элементләр турында кыйммәтле мәгълүматлар китерә. Тюрколог А. Самойлович тел материаллары нигезендә «Ука—Идел—Кама—Тобол мәдәни-географик төбәге» дигән гипотеза белән чыкты. Р. Кузеев һәм И. Моисеева кебек галимнәр исә Себер татарларының «мөстәкыйль» этник үсеш юлы үтүе турындагы концепцияне турыдан-туры кире кагалар.

Күпләргә «иштәк» этнонимы тынгы бирми. Аерым галимнәр «иштәк»ләрне Идел—Урал татарлары белән Себер татарлары арасындагы арадашчы буын дип саныйлар.

«Себер» атамасы үзе үк Идел Болгарстаны һәм Көнбатыш Себер халыкларының этник якынлыгын күрсәтеп тора. Әл-Гомәри, мисал өчен, Алтын Урда составына «Сибирь—Ибирь» өлкәсен дә кертә. Аны әле «җир», әле «Себер иле» дип атый. Соңрак «Ибирь—Сибирь» Ибн-Гарәпшах тарафыннан да искә алына. Русларда—«град Сибирь». Барлык очракларда да атамаларның нигезендә «Себер—Сибирь» («Ибирь—Ибирь» аның варианты гына) сүзе ята. Аны кайберәүләр «Сывыр—Сыбыр», «Сыпыр» дигән халык атамасыннан барлыкка килгән дип карыйлар. «Ибирь—Сибирь» өлкәсенең исеме татар телендә «ыбыр—чыбыр» дигән җыйма сүз рәвешендә сакланып калган.

Сүз дә юк, ачыклыйсы мәсьәләләр бихисап. Фактик материаллар житми. Ләкин Себер татарларының тел ягыннан Идел—Урал татарлары белән бер диалекталь системага (Көнчыгыш диалекты) керүе турындагы теорияне инде тулысынча исбатланган дип санарга мөмкин.

Шулардан хәбәрдар була торып, Әлтаф бер-берсен аңламаучы инглизләр турында юри сүз куерта, мәсьәләне гадиләштереп күрсәтергә омтыла. Янәсе, исең китмәсен иске чикмәнгә, бездә анның янасы да бер тиен.

Кәшшаф төн утырып әлеге мәкаләгә каршы контр мәкалә язды. Ә иртәгесен, эш башланганчы ук, редакциягә юнәлде. Ленин дамбасын жәяүләп чыкты. Казансу инде күптән боздан арынган икән. Су диңгез кебек жәелгән, кызыну—су коену урыннарындагы ком яткылыгында да дулкыннар йөгерешә. Елга эчендә болындагы чүмәләләр шикелле балыкчы көймәләре тезелешкән. Тал-тирәкләр яшел юрганнарын ябынган.

Вакыт тәгәрмәче бернәрсә дә карамый, әйләнә дә әйләнә. Туган көне дә житеп килә икән ич әнә. Хәзер инде анның туган көне берәүне дә кызыксындырмый. Элек кенә ул, чиратка салып бетерә алмый иде. Дәрига үзенә хәзерләнә, Заһидә үзенә. Кадерле чаклары бар иде.

Нәшрият бинасы жиде жил уртасында утыра. Пырдымсыз Жилбикә тукталышка житәрәк Кәшшафның да эшләпәсен очыртып алып китте. Бераз уйнаткалап йөртте дә бер чатлы-ботлы агач кәүсәсенә китереп каплады.

Кәшшаф ачулы кыяфәт белән эшләпәсенә үрелде. Шуны гына сагалап торгандай Жилбикә янә эшләпәне бөтереп алды. Бу юлы аны күккә үк чөйде. Берара баш очында әйләндерде-тулгандырды да, дамбаның аргы ягына чыгарып, Казансуга илтеп ташлады. Тукталыштагы кешеләргә тамаша булды.

Кәшшаф шул кызу белән мөхәррир бүлмәсенә барып керде.

Мөхәррир калын гәүдәле, купшак йөзле бер кеше иде. Кәшшафны елмаеп-көлеп каршы алды, урын тәкъдим итте. Килүенең сәбәбен белгәч тә килеш-килбәтен үзгәртмәде, кычкырып көлеп жибәрде.

—Демократия заманы икәнне исегездән чыгармагыз, Кәшшаф әфәнде...

—Демократия татар милләтен таркатып бетерергә дигән сүз түгел бит әле ул.

—Кызык кеше сез, Кәшшаф әфәнде, элек ирек бирмиләр дип дәгъва белдерәләр иде, инде тыегыз дисез. Моны ничек аңларга соң?

—Мин тыегыз димим, фән дөньясында компетентлык дигән нәрсә дә бар бит әле. Газизуллин, мисал өчен, татар халык жырларын өйрәнүче фольклор белгече. Әлеге анлатманы тарихчы бирсә, күпкә отышлырак булыр иде дип әйтүем.

Мөхәррирнең елмаерга хәзерләнгән йөзе капылт кына житди кыяфәткә керде. Иреннәре кысылган гармун күреге сыман жыелды, карашы кырысланды.

—Безнең газета хөкүмәт газетасы,—диде ул үтә бер житдилек белән,—рәсми юнәлеш тота торган газета. Газизуллинга килгәндә, ул мәртәбәле институтның директор урынбасары. Шулай ук рәсми кеше...

—Себер татарларын сез аерым милләт дип саныйсызмы?—дип бүлде аны Кәшшаф.

—Аңлатмада андый билгеләмә юк!—дип кырт кисте мөхәррир.

Бәхәсләшүнең мәгънәсе юк иде. Бу редакциядә төп рольне авторның тоткан вазифасы, дәрәжәсе уйный икән. Һәм шунысы да ачык, бу кеше мөхәррир урынында утырганда анның язмаларына әлеге басмада урын бирелмәячәк. Чөнки анын ни исеме, ни дәрәжәсе юк. Шуңа күрә бу көләч егетне нәни генә чеметеп алсаң да зыян итмәстер, мөгаен, дигән карарга килде Кәшшаф.

—Сез ничә класс бетердегез?—дип сорады ул чыгып китәргә жыенгач. Тегесе күзләрен чалшайтып аңа текәлде.

—Белемегез нинди?—дип кабатлады Кәшшаф.
—Университет! Аспирантура! Ә нигә кирәк булды әле бу сезгә?
—Болай гына, без үз житәкчеләребезне белергә тиеш лэбаса.

Мөхәррир төртмә сүзне аңламады. Рәсми оешмалардан килгән күрсәтмәләр буенча яши-яши тойгы куәсен җуеп бара иде, күрәсең.

Эшләпә мажарасы яхшылыкка булмады. Кәшшафны башка редакцияләрдә дә колач жәеп каршы алмадылар. Дөресрәге, мәкаләсенең нинди максат белән язылуын белеп алуга борыннарын жыердылар. Бер редакциянең дә институт, аның житәкчелеге белән каршылыкка керәсе килми иде. Татар милли тарихының исеме үк куркыта кешеләрне. Ник дисәң, аның белән кызыксыну кешеләргә мона каләр фәкать кыйналу, эзәрлекләү генә алып килде.

Кәшшаф һичнинди чарасы калмагач, үзенең шау-шулы чыгышлары белән дан тоткан бизнесмен Ишкәев нәшер итә торган "Телеграф» исемле шәхси гәжиткә мөрәжәгать итте. Ул рус телендә чыга. Шуна күрә мәкаләне тәржемә итеп алып килергә куштылар. «К вопросу о сибирских татар» дигән исем куеп, мәкаләсен ул икенче көнне редакциягә илтеп тапшырды. Озак тотмадылар, жомга санында, мәкалә укучыларга барып иреште. Гәжиттә аның мәкаләсе «Заместитель директора Гуманитарного института Газизуллин ратует за самостоятельную нацию сибирских татар» дигән баш астында басылган иде. «Болай үтемлерәк»,—дип аңлаттылар редакциядә.

Институт гөж килде. Әле мондый конкрет исеме белән йөзгә бәреп әйтелгән чыгышларның матбугатта күренгәне юк иде. Башлыча читләтеп, төрттереп әйтү ысулын хуп күрәләр иде галимнәр. Галимов, мәсәлән, «узгынчы татарлар» дигән тезмәне үз итә. Ләкин бервакытта да бу «узгынчы татарлар"ның шәхесләрен матбугатта ярып салмый.

Кәшшаф үзенең мәкаләсендә Себер татарларының жирле халык икәнлеген инкарь итмичә генә аларның гомум татар халкының бер аерылмас өлеше булуын, ә Себер татар теленең әдәби телнең көнчыгыш диалект икәнен мисаллар белән дәлилләде.

Арттырып жибәргәнен ул мәкалә чыгып, кайтавазы үзенә таш булып атыла башлагач кына төшенде. Ләкин эшләнәсе эшләнгән иде инде. Кем белсен, Әлтаф әлеге аңлатма-жавабын Кәшшаф шикелле кайнар башларны котырту өчен язгандыр бәлки?

Кәшшаф үзенә бер жирсенү һәм түземсез борчылу белән Әлтафның жавап гамәлен көтә башлады. Бергәләшеп әлек Галимовның күпме гайбәтен саттылар.

Хәзер ул аның урынбасары, уң кулы. Галимов—Тәфкилев—Газизуллин—институт алар кулында. Аңлашыла ки, фән белән дә алар житәкчелек итә.

Әлтаф аны кабинетына чакырып алырга тиеш иде. Югарыда утыручылар, кагыйдә буларак, хезмәткәрләре белән аралашуның шушы сыналган алымын сайлыйлар. Бу очракта инде бер генә дөреслек, житәкче дөреслеге генә өстен чыга. Әлтаф та башка камырдан изелмәгәндер, шәт, түрә киеменә күнеккәндер.

Кәшшафның гөманы акланмады. Көннәрдән-бер көнне Әлтаф аның бүлмәсенә үзе килеп керде. Мона каләр алар кинәшмәләрдә генә очрашкалыйлар иде. Баш кагып исәнләшәләр дә, шуның белән шул. Әлтаф институтта халык авыз ижатына бәйләнешле юнәлешкә житәкчелек итә. Шуна күрә турыдан-туры аралашырга туры килми. Ә шәхси дуслык ничектер үзеннән-үзе сүнде.

Әлтаф элеккечә күренергә тырышса да, ул элекке түгел иде инде. Килеш-килбәте үк башка, байларча. Өстендә буй-буй сызык төшкән өр-яңа кара костюм-чалбар, ап-ак күлмәк, модалы кызыл галстук, бармагында алтын балдак. Авырайган, шомарган... Күрәсең, каз итен дә коймакка төреп, каймакка манып ашый.

Иске дуслар бер-берсенә карашып, тынып калдылар. Әлегә Кәшшаф

та, Әлтаф та дуслык чиген үтеп чыгарга кыймый. Шул ук вакытта күнелгә төйнәлгән бу шеш тишелмичә дә кала алмый. Ул инде тулган.

—Аккош сөтенне чыгар эле,—диде Әлтаф, ниһаять,—тамакны чылатмыйча сүз ябышмаска охшый монда.

Бу бүлмәгә кергәндә ул әйтәсен тиз генә әйтермен дә чыгып китәрмен дип уйлаган иде. Юк, элекке дустың белән күзгә күз карашып аңлашу җинелләрдән түгел икән.

Кәшшаф өстәл өстенә бер шешә хәмер чыгарып утыртты. Сүзсез генә ике стаканга яртышардан артыграк итеп агызды. Калдык-постык кабымлык та табылды. Әлтаф аның һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтеп торды, әйтерсең лә, Кәшшаф бик җаваплы лаборатор эш башкара иде.

—Син начальник кеше, авызың затлы эчемлекләргә күнгәндер, бигайбә,—диде Кәшшаф.

—Юк сүз сөйләмә,—дип туктатты аны Әлтаф, —әйдә, тотып куй.

Йөзләрен дә чытмыйча стаканны бушаттылар. Әлтаф кесәсеннән сигарет кабы чыгарып, аны шактый ара кулында әйләндергәләп торды. Аннан соң берсен алып авызына капты. Кабызды. Бу юлы аның хәрәкәтләрен шундый ук дикъкать белән Кәшшаф күз астыннан үткәрде.

—Син тартмыйсың инде,—диде Әлтаф.

—Үзең дә ташлаган идең түгелме?

—Синең мәкаләңнән соң тагын суыра башладым менә... —Бу әлеге очрашуның мәсләгенә кагылышлы беренче җөмлә иде. Кәшшаф чирканчык алмыйча гына суга сикергәндәй куырылып китте.

—Кызганмый гына тагын тамыз әле,—диде Әлтаф.

Читтән карап торучы булса, мөгаен, бу ике әшнә рәхәтләнеп кәеф-сафа корып утыралар икән дип уйлар иде. Чынлыкта исә, икесенең дә күнел җепләре җәя җебедәй тартылган, аз гына кагылып алсаң да өзелеп китәр иде. Тик алдан кайсысының түземлеге бетәр? Башта кем баскан камыр бүселеп чыгар?

—Гыймай бабай аракысы, ахры,—диде Әлтаф,—чишмә суы шикелле, авызда ачысы да калмый.

—Беләсең бит инде, мин фәкать Чистай хәмерен генә кулланам...

Җәя җебе тагын да тартыла төште, әмма өзелмәде. Әлтаф Кәшшафның ычкынып китә язуын белмәмешкә салынды.

Алар икесе дә хәмернең башка бәрүен көтәләр иде. Ул чагында кыюлык килер, тел дә ирек алыр иде. Артык дулкынланудан ахры, хәмернең һичнинди тәэсире сизелмәде.

—Озын сүз бозау имезә ди, җыеп кына әйткәндә, бурычыңны кайтардың, минем сина, синең мина бирәсен юк,—диде Әлтаф. Соңгы мизгелдә генә ул мәсьәләне куертмаска кирәк дигән нәтиҗәгә килгән иде.

—Уратмый гына сөйлә әле,—диде Кәшшаф,—беләм ич инде, «Телеграф"та чыккан мәкалә тамагына кылчык булып кадалды. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә...

—Кирәкми, дәвам итмәсән дә була,—диде Әлтаф,—эш шунда, синең диссертациягә кагылышлы шикаятькә кул куючылар арасында мин дә бар идем.

Әлтаф, ниһаять, еллар буе күкрәгеп тырнап торган иң мөһим сүзне әйтте.

Кәшшаф өнсез калды. Шушы бер минут эчендә биш мәртәбә туңды, биш мәртәбә эреде. Башында диссертация яклау артыннан йөргәндәге вакыйгалар чуалышып алды. Күпме авырлыклар кичерде ул, күпме кыйналулар аша узды! Барыбер сират күперен үтеп чыга алмады, утлы упкынга бәреп төшерделәр. Һәм шушы кара көчләрнең берсе—ул вакыттагы дусты Әлтаф! Башка сыя торган хәл түгел ләбаса бу?! Кешеләр ни өчен бер-берсенә карата шундый мәрхәмәтсез икән соң?

Кәшшаф баудан ычкынган усал эт шикелле өстәл янында аякларын чалыштырып басып торган Әлтаф өстенә ыргылды.

—Эһ, син сатлык жан, үләт...

Ул Әлтафның күлмәген умырып төшерде, пинжәгенен сәдәфләрен койды. Тегесе дә берешә торганнардан түгел. Себер якларында үскән гайрәтле егет. Өстәвенә, Кәшшафтан күпкә калынрак. Алай да маташтыра торгач, бер жаен китереп, Кәшшаф аны идәнгә екты. Әүмәкләшеп киттеләр.

—Житте,—диде Әлтаф мышный-мышный,—уеннан уймак чыкмасын.

—Әле син шулаймы, моны уен гына дип уйлыйсыңмы? Күрсәтәм әле мин сиңа күрмәгәненне, хыянәтче.

Тагын әүмәкләштеләр. Ниһаять, бер заман капчык кебек икесе ике почмакка тәгәрәде. Бераздан Кәшшаф телгә килде.

—Күпмегә сатылдың?—дип сорады.

—Мин сатылмадым, үчемне генә кайтардым,—диде Әлтаф.

—Үч! Сөйләп торган була... Нинди үч ди ул вакытта безнең арада? Ахирыләр идек ич.

—Син миннән Дәриганы тартып алдың.

Кәшшаф тиле кеше кебек дуамал көлү белән көләргә тотынды. Сүз булмаганда сүз булсын, ата казыгыз күкәй саламы, дип сорады ди берәү. Түбәтәе кыйшайган, ахры, бу лыгырдыкның. Дәригаларлагы май бәйрәме мәжлесенә Әлтаф үзе кодалап алып барды ич. Әле дә хәтерендә, авылга кайтам, әни авырып тора икән дип, аяк терәп каршы торган иде Кәшшаф. Чарасына куймады, әйдә дә, әйдә, желегенә төште тәки, тыңларга туры килде. Әгәр шул вакытта үз дигәнендә торган булса, шәхси тормышы бөтенләй башка юлдан кереп киткән булыр иде. Гаилә бәхете татып яшәр иде. Заһидә кебекләр белән дә чуалып йөрмәс иде. Хәзер, әнә, ярык тагарак янында утырып калды. Мәгъшукасы әллә нинди бер сакаллы чувашны йортка кертте, хатыны ташлап китте.

Уйлап баксаң, барысы да шул бәйрәм мәжлесеннән башланды ич...

—Иске авыздан яңа сүз, син нәрсә, саташтыңмы әллә?—диде Кәшшаф уйларыннан арынып.

—Юк, нишләп саташыйм ди, саташмадым,—диде тыныч кына Әлтаф,—син минем планнарымны челпәрәмә китереп ташладың.

Чыннан да, Әлтаф Дәригага өмет баглый иде. Дәриганың әтисе Каюм абзый белән алар бер авылдан. Аз гына чыбык очлары да бугай әле. Каюм солдатны яралангач Казан госпиталенә кайтаралар. Шунда ятканда Сәмига исемле шәфкать туташы белән таныша.Өйләнешәләр. Себер егете, шулай итеп, Казанда төпләнеп кала.

Әлтаф авылдашы янына килеп йөри, әтисенең сәламнәрен житкереп тора. Шунда, әлбәттә, зифа камыштай буй житкереп килгән кызга да күз төшерми калмый иде. Ләкин Дәрига бервакытта да Әлтафны үзенә тиң егеткә санамады, абыйсы, туганы сымаграк күрә иде ул аны. Гомумән, Дәрига егетләргә карата бик таләпчән булып үсте. Шул сәбәпле чак кына утырып та калмады. Ә аңа озын буйлы, кара чәчле, житди кыяфәтле, ыспай егетләр ошый иде. Ул, әлбәттә, спортчы булырга тиеш, көчле, гайрәтле. Әнисе: «Кызлар көтәр санатны, булмаса сөяр солдатны»,—дип көлә иде үзеннән.

Әлтаф Дәриганың һәр адымын диярлек күзәтеп йөрде. Кыз көлде, шаярды, ләкин мөнәсәбәтләр генә үзгәрмәде, күңелен ачмады. Әлтаф үзе дә өметен өзә башлаган иде инде. Әмма Дәриганың авылга китүе сүнгән өметкә жан өрде. Чөнки Әлтаф белә, анда зыялы кызларның үз ишләрен сайлау мөмкинлеге юк дәрәжәсендә. Башлыча укытучы кызлар шофер, тракторчы кебек егетләрнең кулына килеп эләгәләр. Ә Дәрига аларга баш бирмәячәк, ул шәһәр кызы. Хәзер Әлтафның жәтмәсенә керәчәк тә керәчәк инде.

—Мин Дәригага зур өметләр баглап йөри идем,—диде Әлтаф.

Кәшшаф аптырап калды. Бу аның башына да кереп карагач уй түгел иде. Әйе, Әлтаф соң өйләнде. Аның гаилә хәлләре хакында сөйләргә яратмаганын да белә Кәшшаф. Күпме дус булып йөрделәр, ә бер мәртәбә

дә хатыннары белән кунакка йөрешмәделәр. Чакырсаң да килмәс өчен мең сәбәп табар иде.

—Аш атканга син таш аттың...

Алар әле һаман чалкан яткан килеш сөйләшәләр иде. Әлтафның әлеге сүзе күңеленә тиде булса кирәк. Кәшшаф урыныннан сикереп торды.

—Ә нигә син миңа шул вакытта кисәтмәдең?

Әлтафның йөзе кыйшаеп китте.

—Акылың кыска икән, мәҗлескә чакырганда ук: «Дәрига тамгалы, нәфсеңне сузасы булма»,—дип киртләдем бит, оныттыңмыни?

—Шаяртадыр дип уйлаганмындыр. Аннан китереп, миндә кыз кайгылары юк иде ул көнне. Иртәгесен иртүк әни янына кайтып китәргә тиеш кеше идем ич мин.

—Һәм тавык кетәгенә кереп тә чумдың...

Бу дилбегә буе озын сүз Кәшшафның тешенә тия башлаган иде инде. Аны көне буе сузарга мөмкин. Әмма нокта куярга вакыт.

—Алай бик кыз кирәк булгач, нигә көчле-көчле безнең икебезне генә калдырып чыгып киттең соң?—диде Кәшшаф. «Мин дусларны озатып кергәнче беркая да китмисен»,—дигән сүзләрең әле дә колак төбемдә чыңлап тора. Ә үзең олактың, кире әйләнеп кайтмадың.

—Мин кайттым, соң иде инде...

Әлтаф үпкәләгән бала сыман иреннәрен турсайтып тәрәзә ягына борылды. Чыннан да, ни дип ул аларның икесен генә калдырып чыгып китте соң? Шуның өчен әле булса үзен гафу итә алмый. Күреп торды лабаса, Кәшшафны күрүгә Дәриганың күзләрендә ат тоягы эзләре уйнаклый башлады. Ә ул кунаклар артыннан йөрде, хуҗа, янәсе. Алар үзләре генә дә китә алалар иде ич. Юк, озатырга чыкты. Хәтта трамвайга утырып та ике-өч тукталыш сөйләшеп барды. Кызып алса, шундый гадәте бар инде аның, кешегә кандала кебек ябыша...

Әлтаф урап кайтканда өйдә ут сүнгән иде инде. Бик озак ишекне дөбердәтте, ачучы булмады. Тәрәзәгә килде. Аларының да капкачы ябык иде. Берсенең ярыгыннан чыбык тыгып тәрәзә пыяласын сыдыргалап та карады. Ишетмәделәр. Ул, әлбәттә, үтемлерәк адымга да бара алыр иде. Әйтик, ишекне каерып ыргытырга була иде, тәрәзә капкачларын умырып ташлау да берни тормый. Тик кулы бармады. Бу Дәриганы мыскыл итү булыр иде. Кыз арыгандыр, йоклап киткәндер дип уйлады һәм иртәнгә кадәр көтәргә кирәк дигән карарга килде. Вокзал күршедә генә, бер-бер почмак табылыр әле, шунда черем итеп алыр.

Әлтаф йокысыннан уянып, үзен-үзе тәртипкә китергәнче кояш шактый югары күтәрелде. Көн кичәге шикелле үк салкынча иде. Шыксыз. Җил вокзал мәйданы буйлап бәйрәмнән калган кәгазь чәчкәләрне пыран-заран китереп куып йөртә. Урам буш. Халыкның кайтасы кайтып, китәсе китеп беткән иде, күрәсең. Бәйрәм фатирларда дәвам итә. Алда әле башланмаган ике ял көне көтеп тора.

Әлтаф кыюлык өчен бер касә сыра эчте дә Дәригаларга таба атлады. Бүген ул бернәрсәне дә яшермичә ачыктан-ачык сөйләп бирәчәк. Дәрига, чык мина кияүгә, диячәк. Ким-хур булмассың, галим кеше җәмгыятьнең каймагы ул, диячәк.

Аның Кәшшаф турында уйлыйсы килми иде. Ул кайтып киткән булырга тиеш. Авызы-борыны салынган инде, әлбәттә. Үпкәчән ул. Ярар, көйләрбез, беренче мәртәбә генә түгел. Монысы вак мәсьәлә. Тәкәббер, мин-минлеге ташып арткан Дәриганы ничек иярләргә—менә монысы мәсьәлә генә түгел, теорема. Аннан соң, Дәрига андый-мондый гына туйга да ризалык бирмәячәк. Абыйсы ярдәм итәр әле, мөмкинлеге зур, колхоз рәисенә акмаса да тама бит ул...

Сыра кичәге хәмергә утлы ялкын өстәде, хыялы колмаклы чүпрәдәй кабарды. Шул кабарынган хыял канатларында Әлтаф койма янына очып килде. Ә өй тирәсе тып-тын, берниндн хәрәкәт-фәлән сизелми дә. Дәрига

әле йокысыннан уянмаган, күрәсен. Чистый эштән чыккан икән. Шулай булмыйча, кунаклар килде дә китте, жыю, юу, жыештыру анын жилкәсендә калды. Әлтафка да жиң сызганып булышырга иде дә, йөрде бит кеше көен көйләп. Кәшшафнын кыюлыгы житмәгәндер. Мокыт. Иң беренче эш итеп ул Дәригадан гафу үтенәчәк...

Анын татлы уйларын Босснын калын тавышы өзде. Әлтафнын колаклары үрә торды. Эт хужасын сизеп өрә. Бу анын сәламләве. Димәк, өйгә жан кергән. Күп тә үтмәде, Дәрига күтәрмәгә чыгып басты. Киенгән-ясанган. Каядыр баруы булса кирәк. Сонга калды, каһәр. Хәер, зыян юк, бергәләп тә барырга була ич.

—Босс, урынына!—дип әмер бирде Дәрига. Чөнки тегесе буыла-буыла өрә башлады. Монын сәбәбе дә шундук ачыкланды, ишек уемында Кәшшаф күренде. Әлтаф егылып китмәс өчен аркасы белән коймага сөялде. Барысы да ачыкланды, алар төнне бер түшәктә үткәргәннәр. Мыштым булып кыланган гына икән хәйләкәр. Ике яклы пычак! Астан уя, өстән жуя. Сатлык! Теге кәнтәен күр, ничек сырпалана.

Дәрига Кәшшафны үзе янынннан тотам да жибәрми, энәдәге жеп шикелле тагылган. Шул тагылган килеш алар көлешә-көлешә Идел буена төшеп киттеләр. Әлтаф бур кеше сыман агач куагы ышыгында яшеренеп калды. Алар күздән югалуга, ишек алдына бәреп керде. Котырынган күзләре белән нindидер тотар әйбер эзләде. Исәбе—тәрәзәләрне кыру иде. Шунда койрыгын болгап, ана текәлеп карап торган Боссны күреп алды. Эт аны таный, шуңа күрә ялагайлана.

—Теге уйнашчыларны өзгәләп ташларга иде сина,—диле Әлтаф.

Ул өйгә бәреп керде (ачкычнын кайда икәнен белә иде). Күзләре иң беренче урын-жиргә барып төртелде. Урын-жир бик ыспай итеп, бик матур итеп жыештырылган иде. Гомумән, барысы да тәртиптә, кай арада житешкәннәр диген. Парлап эшләгәннәрдер инде. Бу ачышы Әлтафнын ачуын тагын ла көчлерәк итеп кузгатып жибәрде, үзен-үзе белешмичә кулына эләккән бар нәрсәне идәнгә тондырырга тотынды. Ватар савыт-саба беткәч, тегү машинасын чәсен чәскә аерып ташлады. Чират Кәшшафнын гармунына житте. Ул аны үтә бер ләззәт белән ботарлады. Аннан сон бөтен ватык әйберне одеалга төрде дә бәдрәф базына тондырды. Босска чебен агуы салды.

...—Синен Дәриганы яратуын турында бервакытта да белдергәнен булмады,—диде Кәшшаф,—мине коега төшкән мулла хәлендә калдырдын син. Хәзер...

Кәшшаф төртелеп калды. Ул, без Дәрига белән яшәмибез, дип әйтмәкче булган иде. Ләкин әйтмәде, кире уйлады. Алар сон рәсми рәвештә аерылмадылар ич. Дәрига үпкәләп өйләренә кайтып китте. Бары шул гына...

—Туйдан сон дөмбергә, ни мәгънә?

—Шулай итеп, син сарык тиресе ябынган бүре кыяфәтенә керден инде...

Кәшшаф күз кырые белән генә Әлтафка карап алды. Йөзе, һәрвакыттагыча, ачык ишек кебек иде. Иреннәрендә, күзләрендә бернинди усаллык билгеләре шәйләнми. Күрсән, анын килеш-килбәте эчке халәтенә туры килми. Жаны кискәләнгәндә дә йөзенә чыгармый. Бәгыре каты икән мәгар. Ун елдан артык бер кашыктан диярлек ашадылар, ә бернәрсә сиздермәде.

—Костюмны эштән чыгардын, мин хәзер кеше күзенә ничек күренәм инде,—диде Әлтаф.

Эчке дошманлыкнын әлеге дә баягы акылга, талантка кагылышлы ягы да бар иде. Белеме буенча Әлтаф үзе тарихчы. Аспирантураны да тарихчы буларак үтте. Ә менә диссертациясен татар халык жырлары темасына язды. Чөнки саф тарихи темага теше үтмәде. Хәтта ул ана тотынмады да, белә торып, муенына бау салмас бит инде.

Кәшшаф башка. Анадан кыйшык туган бәндәне тезгә салсан да

турайтып булмый ди. Ул да нәкъ шул. Кире беткән. Диссидент, имеш.

Ин гаҗәбе шул, кешеләр андыйларны ихтирам итә, аларга хөрмәт белән карый. Хәтта галимнәр үзләре дә. Җыелышларда, конференцияләрдә үтереп салалар, мөнбәрдән төшкәч, ялагайланып кулын кысалар. Янәсе, бигайбә, бу протокол өчен генә. Галимов та күп нәрсәгә күз йома, югыйсә, кискенрәк тә була алыр иде.

Әлтаф кеше кулы белән эш йөртергә күнеккән. Ул ачыктан-ачык конфликтка керүне өнәп бетерми. Әле дә кабарган энәләрен оясына шудырды.

—Теге вакытта Дәригаларнын өендәге әйберләрне тар-мар итүче дә син алайса,—диде Кәшшаф ачусыз гына.

—Мин,—диде Әлтаф.—Боссны да мин агуладым.

—Куркыныч кеше син, Әлтаф, үчле.

—Син үчле түгелме?

* * *

Кәшшафны йокысыннан нindидер аһәңле тавыш уятты. Бермәл, каян килә бу тавыш, дип ярымсаташу хәлендә ятты. Әлтаф белән кичәге аңлашу аны тәмам изгән иде. Бераздан ул күзләрен ачты. Әлеге тавыш радиодан килә икән. Бервакыт Дәрига белән әнисе янына авылга кайткач та шушына охшаганрак дулкынлану кичергән иде. Ул чакта әлеге тавыш юксыну, сагыш, ярату хисләрен бар көченә кабызып җибәргән иде. Шул ук көнне җыенып китеп тә бардылар. Чөнки Заһидәне кайтып күрмәсә, ул аны мәңгегә югалтыр сыман тоелган иде.

Бүгенге тавыш аңарда андый тойгы уятмады. Югыйсә, шул ук тавыш. Бу Заһидә иде. Шундый ук ягымлы, матур тавыш. Ә йөрәге ашкынып типми иде, күңеле битараф калды. Үзе дә шаккатты. Моңа кадәр Заһидәнең рухы, шәүләсе Гали кылычы кебек һәрвакыт баш өстендә асылынып тора иде. Бүген ул алардан азат. Шундый җиңел, шундый рәхәт!

Күз алдына Заһидә түгел, улы Кәрим килеп басты. Ул гүя: «Әтием сагындым, минем янга кил»,—дип әйтә иде.

—Бүген үк барам, мин дә сине сагындым,—диде Кәшшаф. Аның бите буйлап яшь бөртекләре агып төште.

* * *

Кәшшаф—төн кошы. Ана илһам төн уртасында килә. Дәртле сөяркә шикелле еш кына ул аны йокысыннан уята. Дөрес, тарихи язма шигырь түгел, күңелдән ургылып чыкмый. Кайчак кечкенә бер тәгъбирне исбатлау өчен генә дә дистәләгән китап укырга, күп күләмдә фәнни-тикшеренү эшләре алып барырга туры килә. Нindидер нәтиҗәгә киленгәч тә борчу-икеләнүләр бетми.

Хәзер дә шундый мәле. Алдында карасы да кибәргә өлгермәгән билгеләмә. Ул түбәндәгедән гыйбарәт:

«Болгарның татарлар тарафыннан ассимиляцияләнүе, йотылуы XIV гасыр азагына—XV гасыр башларында тәмамлана. Гомумән, Болгар дәүләте, аның бай матди һәм рухи мәдәнияте, болгар этносы гомумтатар тарихын, татар суперэтносын баетуга шул тарихның урта гасырлардагы чоры, шул этносның бер компоненты буларак өлеш кертә».

Бу бик житди билгеләмә. Аны яклаучылар да табылыр, билгеле, ә өнәп бетермәүчеләр, мөгаен, тагын да күбрәк булыр.

Чыннан да, ашыгып-кабаланып чыгармадымы ул бу нәтиҗәне? Киләчәк буыннар аны фәнни нигилизмда гаепләмәсләрме, ата-бабаларыбыз хәтере разый-бәхил булырмы?

Әле аның тагын бер колакка ятып бетми торган җөмлә теркисе бар. Менә ул: «Болгар музей-саклагычындагы экспонатлар Алтын Урда

мәдәният һәйкәлләренә карый. Әйе, Кара палата да, Кече манара да, Төрбә калдыклары да, керамикадан эшләнгән сууткәргеч торбалар да, барысы да, барысы да. Хәтта үсеп утыручы кызыл бүрекле чәнечкеле шайтан таяклары да Алтын Урданыкы. Риваятьләргә караганда, татарник (руслар бу үсемлекне шушы исем белән йөрткәннәр) татар-монгол гаскәре атларының тоягыннан коелып калган, имеш.

Болгарлар үз корылмаларын Алтын Урда, Урта Азия, Кавказ, Кырым, Төркия, гарәп илләре монументаль архитектурасы йогынтысында күтәргәннәр. Болгарның саф үз торагы—бер яктан түбәсе текә итеп ябылган агач йорттан гыйбарәт. Хәрби корылмалар да агачтан ясалган. Куыш... күчмә җинел тире өйләр...»

...Төн табигатьнең ин сак, ин саф чагы. Уй-хыяллар өчен бигрәк тә кулай. Чөнки бернәрсә дә комачауламый. Киресенчә, нindидер сәер кыштырдыклардан алып, өстәл лампасы, куллагы каләмнән ак кәгазьгә төшкән шәүләләргә кадәр шуна этәрә.

Кәшшафка илһам да хисләр белән катнаш килә. Ул язган язмалары аша шул чор вакыйгаларын, кешеләрен аерымачык күрә башлый. Алар белән гәп кора, бәхәсләшә, фикер уртаклаша.

Бу көннәрдә анын болай да жаны бушанган чак. Чөнки ничә айлар буе гәүдәсенә тураерга ирек бирми басып торган бинаһая зур таш, ниһаять, үзеннән-үзе тәгәрәп төште. Заһидә анын өчен галәти хатын-кызга әверелеп калды. Башка да китермәслек хәл. Ә ул аны күнеленнән Бату ханның Йолдызына охшата иде. Бу, әлбәттә, чагыштырырга мөмкин булмаган чагыштыру. Ни урыны, ни вакыты дигәндәй, уртаклык, мөгаен, чибәрлектер.

Йолдыз сылуның язмышын төрлечә гөманлый иде Кәшшаф. Гөманлаган саен яна кыйсса туа иде. Бүген дә туды.

...Бату хан кузгалуының жиденче көнендә гаскәрләренә ял бирде. Анарчы хәтта төннәрен дә ат, дөя өсләреннән төшмәделәр. Көннәр аяз иде. Кояш туктаусыз кыздырды, кешеләр янып-пешеп беттеләр. Батуның хатыннары, жарияләренен генә нәфис йөзләренә кара төшмәде. Алар көннәрен асылма чатыр эчендә үткәрделәр. Хан нәзакәтле, сылу кызларны ярата иде. Шуна күрә һәрберсе матур күренергә тырышты. Беренче булып кем чатырының япмасын ачар Бату хан? Барысы да шуны түземсезлек белән көтте.

Походның башлангыч өлеше нindидер бер бинаһая олы жыенны хәтерләтә иде. Күнел ачу, уен-көлке. Ашау-эчү муллан. Бияләр дә үзләренә төшкән бурычны намус белән үтиләр, кымыз елга булып ага. Жарияләрнен дә чәчәк вакыты. Дошман белән күзгә-күз очрашкач, сөнгеләр, кылычлар ялтырый башлагач, барысы да бергә укмашачак. Үлем, кан, яратышу. Йөзләр кырыслана, хәрәкәтләр тупаслана, жан кыю галәти хәлгә әверелә. Кеше күнелендәге ярату хисе нәфрәт булып кабына.

Әлегә боларның барысы да алда. Кем бар, кем юк дигәндәй, ләззәтләнеп калу хәерле.

Кагыйдә буларак, Бату хан мәхәббәт уеннарын затлы нәселдән килгән бер-бер никахлы хатынынннан башлый иде. Бу юлы кагыйдәне бозды. Йолдызга хәбәр салды. Көнләштеләр дә сон аксөяк хатыннар, кара көйделәр. Хәлләреннән килсә, Йолдызның йөзен-битен тырмап ташларлар иде. Куллары кыска. Киресенчә, алар аны хан катына кертү өчен хәзерләшергә тиешләр. Монысы да зур мәртәбә санала. Бу эш Батуның өлкән хатыны Фубу житәкчелегендә башкарыла.

Ин әүвәл Йолдызны зур ләканга утыртып жылы су белән юдылар. Аннан сон тәненә төрледән-төрле үлән төнәтмәләреннән ясалган боламык сылап чыктылар да, кибәр-кипмәс бик ныклап, тәне йомшаганчы ышкыдылар. Чатыр эченә нindидер татлы ис таралды. Йолдызның ат тизәгенә, дөя сидегенә күнгән күнеле берара болганып та алды.

—Өстенә жәймә каплагыз!—дип әмер бирде Фубу.

Фубу бик һавалы хатын, үзен барысыннан да эрерәк тота. Чөнки Батуга өч ул табып биргән. Бу зур мактанычі!

—Ә син жебеп төшмә,—дип Йолдызга да күзләрен акайтты Фубу.—Синен чатырдан хан чыбыркысын шартлатып түгел, айкыл-мыйкыл басып, әсәрләнеп чыгарга тиеш.

Йолдызның ир-егетләр белән йоклаганы юк әле. Ул бик курка, шуңа күрә үз кайгысы кайгы. Анысын да белеште Фубу.

—Канынны күрсәтә алсаң, бүләк алырсың,—диде. Тик ул нинди кан, аны ничек күрсәтәләр, тәфсилләп тормады. Ә Йолдызга һәр киңәш алтын бәясе.

Аш-суны күрше чатырда әзерләделәр. Йолдызны ул эшләрдә катнаштырмадылар. Аның вазифасы ханны сыйлау, калжаларнын ин майлысын сайлап, аның кулына биреп тору. Ә үзенә хан тәкъдим итсә генә ит кабарга рөхсәт ителә. Аның ярдәмчеләре дә булачак. Өстәвенә, ханның жан сакчылары да шунда басып торачак, имеш. Мир алдында зөфаф киче була димени?

Бату чатырга ау этедәй атылып килеп керде. Камыт аяклы, ныкча гәүдәле, йомры сөякле. Кулында камчы. Йолдыз алдан өйрәтеп куелганча, хужасының аяк астына ауды. Бату ханның йөзе йомшарып китте, күзләре тегәрҗеп кенә сыярлык булып кысылды. Әмма камчысын кулыннан төшермәде.

—Кымыз!

Йолдыз кол тоттырган касәне ханга сузды. Бату сусаган иде, ахры, кымызны кабалана-кабалана, ирен читләренә агыза-агыза эчте.

Хан камчысын барыбер салды. Бу жарияне ошату билгесе иде. Әлеге хәл инде утыргач, тамагыннан ике-өч кисәк калжа уздыргач булды. Озакламый Бату колларны куып чыгарды. Сакчыларына гына тимәде, тик тораташ шикелле катып, басып тордылар. Бер арада хан Йолдызны үзенә таба йолкып алды. Аннан борынны кытыклап, ит исе, кымыз, сөт исе бөркелеп тора иде. Бату Йолдызнын кулын бил турысыннан чалбарның эченә тартып кертте...

—У-у-у!

Бату үгез шикелле мөгрәде. Шунда кемнәрдер Йолдызны күтәреп алдылар да чишендереп ятакка салдылар. Батуга да киемнәрен чатыр эченә чәчәргә булыштылар...

...Кәшшаф сәгать суккан тавышка сискәнеп китте. Бер... ике... өч... Таң атар вакыт килеп житә икән инде. Ә анын күзеннән йокы качкан. Ул төнне керфекне керфеккә какмыйча да үткәрә ала. Бүген исә үзен аеруча жинел хис итә иде. Әйтерсең лә, зәм-зәм суына чумдырып алганнар. Башы саф, тәне пакь, күңеле тыныч. Иярле фикер-хыяллары артыннан житешмәле түгел. Берәүләр тарихны искелек, чүп-чар, хәрәбаләр кебек кабул итә, аның тормыштагы әһәмиятен күрми һәм күрергә дә теләми. Ә Кәшшаф өчен тарих, барыннан да элек, жанлы вакыйгалар. Ул аларны яхшыга да, начарга да аермый. Үткәнгә дәгъва белдерүдән файда юк. Тарих сөйгән яр түгел, ярату кәтми. Ул фәкать өйрәнүгә генә мохтаж. Тик кеше дигәнең һәрвакыт шәхси, жәмгыяви мәнфәгатьләрен өстен куя. Әйтик, шул Бату ханны берәүләр батырлык мөнбәренә күтәрә, икенчеләр вәхшигә саный, басып алучы, ди; өченчеләр өчен ул мәһшүр Алтын Урдага нигез салучы. Кәшшаф та аны беренче чиратта Алтын Урда атлы татар дәүләтенең атасы булган өчен ихтирам итә. Остазы профессор Ашказарский аны объектив булырга, фәнгә тугрылылык күрсәтергә өйрәтте. "Теге яки бу эшкә алынгансың икән, унга-сулга тайпылмыйча, аны ахырынача житкер»,—дип әйтә иде. Аның «Кире чабата» дигән кушаматы бар иде. Дөрестән дә, үз сүзле, сәер кеше иде Ашказарский. Чынмы-ялганмы, имеш, профессор Мөштәри белән тимер юл вокзалында очрашканнар ди болар. Галимнәрнен Идел буендагы ял йортына барулары икән.

—Әйдә, Ашказар, арткы вагонга гына утырыйк, гәпләшеп барырбыз, юл кыскарыр,—дигән Мөштәри.

Тегесе туктап та тормыйча, башын борып кына әйтеп салган:

—Юк, Мөштәри, кыстама, миңа тизрәк барып житәргә кирәк,—дип алга таба узган.

Тәфкилевләр Ашказарскийның Мәскәү ягына баш боруын татар халкының килеп чыгышына карата уртак карашлары булганлыктан дип расларга тырышалар. Янәсе, рус шовинистлары да, Ашказарский да Чыңгызхан явы белән килгән татарларны хәзерге татарларның турыдан-туры варисы итеп карыйлар, болгарны санга сукмыйлар.

Бу дөрес түгел иде. Ашказарский бервакытта да татардагы болгар канын инкарь итмәде. Шул ук вакытта татар дигән зур халыкны Идел буе болгарлары калыбына кертеп карауга да каршы иде.

Сүз дә юк, Бату хан гаскәре Идел буе халыкларын, шул исәптән, болгарларны да басып алган, үзенә буйсындырган. Кан коелган. Сугышлар ана кадәр дә, аннан соң да булып торган. Кемдер жиңгән, кемдер жиңелгән. Вакыт тора-бара аларның барысын да үз урынына утырткан.

Дәүләте дингез булган, үзе Чыңгыз булган, ди халык мәкале. Ни генә булса да, дәүләт оешып калган. Алтын Урда дәүләте. Иң мөһиме шушы.

Ашказарскийны да Мәскәү аркасыннан гына сыйпап тормады. Билгеле булганча, рус миссионерлары «Татардан—татар» теориясен алга сөргәннәр, болгарны бөтенләй исәпкә алмаганнар. Совет чорында исә, киресенчә, рәсми сәясәт болгар чорын өйрәнүне мәгъкуль күрде. Алтын Урда идеологик яктан зарарлы юнәлеш дип саналды. Ашказарский исә бервакытта да морзалыгына хилафлык китермәде, зыялы, тәкәббер, үз сүзле кеше булып кала белде. Бер француз басмасында дөнья күргән мәкаләсендә ул түбәндәге фикерен ассызыклап күрсәткән иде: «Кытай монгол агрессиясе аркасында бер держава булып укмашкан, ә Русь Алтын Урда күләгәсендә Европа дәүләтенә әверелде».

Мәскәү әлеге билгеләмәне кире какты. Аның әле Алтын Урда дәүләтенең жимерелү-таркалу сәбәпләрен бөтенләй башкача аңлаткан гипотезасы да бар иде. Ашказарский фикеренчә, Алтын Урданы таркатуга Аксак Тимер фетнәсе дә, нугайларның битарафлыгы да, Миңлегәрәй хан явы да үз өлешләрен керткәннәр, билгеле. Әмма жимергеч һөҗүмне Алтын Урдага чума чире ясаган. Утыз ел эчендә ун мәртәбә кырган ул аны (1345—1346, 1349, 1352—1353, 1360, 1364—1366, 1374 еллар).

Мәскәүнең бәхетенә, чума рус дәүләтен читләтеп узган.

Кәшшаф бу гипотезаны да жентекләп өйрәнергә кирәк дип саный.

Ашказарский тормышта да унайсыз кеше иде. Хатыны үлгәч, озак кына ялгызы яшәде. Авырый башлагач та кызының ярдәмен кабул итәргә теләмәде. Кәшшаф килгәндә дә: «Минем хәлем яхшы, бушка вакыт уздырып йөрмәгез»,—дип әйтә иде. Ә үзе төнлә ут чыгып фажигале төстә янып үлде.

* * *

...Бату хан төнен Йолдыз чатырында үткәрде. Кыз каз мамыгы шикелле йомшак иде. Мөлаем, оялчан, тыйнак. Хан аны ошатты, калҗасын бүлеште.

Ләкин бу аларның беренче һәм соңгы очрашуы булды. Йолдыз чатырыннан чыкканын сагалап торып Батуга һөҗүм иттеләр.

Очып килгән сөңгене беренче булып Батуның жан сакчысы кыпчак егете Харис абайлап өлгерде. Яшен тизлеге белән хужасын атыннан жиргә бәреп төшерде. Сөңге аның үзенең кулбашын умырып алды.

—Ханны саклагыз!—дип кычкырды ул бар булган көченә.

Батуны сөңгеләр чәкешкән урыннан читкәрәк алып киттеләр, һөҗүм итүчеләр күп иде. Шулай да эшләре барып чыкмаганны бик тиз төшенеп алдылар, күрәсең, таю ягын карадылар.

Харис ике атнадан соң гына хәлгә керде.

—Мин сиңа үземнең чатырымнан бер Чибәркәй бүләк итәм,—диде

Бату хан.—Кыпчак кызы. Өйләнергә теләсәң, өйлән, жария итәсең килсә, жария ит. Үз иркеңдә. Ә минә орышта кулыңа төшкән мал-мөлкәтнең яртысы үзеңә булыр. Монысы минем ихтыярда.

Харис Йолдызны хатыны итте.

Батуга һөҗүмне Гуйук хан оештырган диделәр. Батуның гаскәр башлыгы булуын бигрәк тә ул күтәрә алмады. Чөнки таяныр кешесе бар. Атасы Үгәдәй бөек каган.

Әлеге вакыйгадан соң Бату хан шаһзадәләрне аерым сак астына алды. Сүбәдәй баһадур шулай киңәш итте. Ә Бату остазының сүзеннән чыкмый. Ул гомумән ике генә кеше алдында баш ия. Беренчесе—бабасы Чыңгыз хан, икенчесе—Сүбәдәй баһадур. Хәтта әтисе Жужи хан да аның өчен үрнәк булып тормый.

Чыңгыз ханның суда батмый, утта янмый торган Сәтәр исемле мәшһүр ак аты булган. Сәтәр хуҗасын күп мәртәбәләр үлемнән коткарган. Орыш кырында тезгенен дә тарттырмыйча шушы мизгелдә гаскәр башлыгының ярдәменә мохтаж урынга ерып кергән, хуҗасының кылыч жаена торып, дошман өеренә ыргылган.

Батуның да «Яшен» исемле шундый аты бар. Бик җинел сөякле. Житез. Сәтәр кебек үк җиңү тантанасыннан, кан исеннән үзен-үзе белешмичә әсәрләнә белә. «Яшен»нән тыш походларда аны сыртына ияр тимәгән сөттәй ак икенче бер ат та озатып йөри. Монысы сугыш алласы Сүлдә өчен. Сүлдә Чыңгыз ханга һаман җиңүләр генә китергән. Бату да шуңа өметләнә, Сүлдәгә атап һәр көнне корбан чалдыра. Чаптарын да, әнә, ике шаман тәрбияли.

Сүбәдәй шәкертенә алтын алкалы, көмеш чылбырлы ак әтәч бүләк итте. Баһадур әтәч ярата. Хәер, ул үзе белән барс, арыслан, еланнар да йөртә. Аларны үзе ашата, шуннан тәм таба. Арыслан үзеннән ике мәртәбә зуррак хайваннарны бер сугуда бәреп ега. Сугышчы да шундый ук көчкә ия булырга тиеш, дип саный Сүбәдәй.

Сыгнак белән Итил арасын кәрван кырык көндә үтә. Гаскәр исә ике-өч тапкыр артыграк вакыт сарыф итәчәк. Кулыннан килсә, Бату бу араны кош шикелле очып кына узар иде.

* * *

Очкыч мәйданга кунганчы Кара диңгез белән Мәрмәр диңгезе өстеннән олы гына бер әйләнеш ясап алды. Шушы бер әйләнештә ул Босфор бугазы аша Аурупа белән Азияне бергә тоташтырды. Биектән караганда бу күз күреме житмәс кинлек канатларын җәйгән зур зәңгәр кошны хәтерләтә иде.

Кәшшафның беренче мәртәбә чит илгә чыгуы. Шуңа күрә барысы да мавыктыргыч булып күренә. Юк кына нәрсәдән дә әллә нинди кызык таба, хәтта очкычның кыйшаеп диңгез уравыннан да ул ниндидер бер мәгънә эзләде. Эченнән генә: «Яши беләләр, каһәр»,—дип уйлап куйды.

Аны карсак гәүдәле кара мыеклы бер яшь кенә ир-егет каршы алды. Кешеләрне ера-ера туп-туры каршысына килеп басты. Күрәсең, Кәшшафның килеш-килбәтен бик тәфсилләп аңлатканнар иде үзенә.

—Исәнмесез, Кәшшаф әфәнде, хуш киләсез Төркиягә,—дип, ул кызларныкы шикелле нәфис кулын сузды. Сүзләре татарча, сөйләме төрекчә иде. Шуңа күрә күнегелгәнче аңлавы авыррак булды. Исеме Исмәгыйль икән.—Мин «Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы» вәкиле буламын,—дип тә өстәде.—Сез безнең вакыфның шәрәфле кунагы.

Кәшшафка мәгълүм иде инде, әлеге фондны Татарстандагы Әтнә районы Мәңгәр авылында туып-үскән әтисе, күренекле эшмәкәр Әхмәтвәли бай истәлегенә кызы Сафия Имре ханым оештырган. Максаты—татар мәдәниятына дөньяга чыгарга булышу. Төркиядә яшәгән татар әдипләренең хезмәтләрен туган-үскән илләренә ирештерү.

Кәшшаф Франциядәге Дисней шәһәрчегенә барып эләккән бала

шикелле юл буе машина тәрәзәсеннән чит-ят жирне күзәтеп, күргәннәренә хәйран булып барды. Истанбулның урамнары кин, алар зиннәтле машиналар белән шыгрым тулы. Икешәр катлы автобуслар да күп күренә. Кая карама—реклама. Адым саен базар. Әйтерсең лә, дөнья алыш-бирештән генә тора. Ул тагын бер ачыш ясады: Төркия хатын-кызлары ит бүкәне кебек юан икән. Аның дөньяда иң юан хатын-кызлар Литвадагы Каунас шәһәрендә яши, дип укыганы бар иде. Ул үзе әрмән ханымнарына беренчелекне бирә иде. Баксаң, төрекләрнең дә алга чыгарга мөмкинлекләре бар икән.

Кәшшаф Жансай Хаммат үзе каршы алыр дип көткән иде. Күрәсең, жае чыкмагандыр.

—Жансай әфәнде Америкада, иртәгә кайтып житәчәк,—диде Исмәгыйль аның уйларын укыгандай.—Кич мәжлес буласы. Иртәнге якта Гаяз Исхакый зиратына сәфәр кылырбыз.

Кәшшафның күңеле тагын да күтәрелеп китте. Көткәннәр, әнә, ничек барысын да алдан хәстәрләп куйганнар. Аның үз Ватанында бервакытта да мондый игътибар, кадер-хөрмәтне күргәне булмады, һаман этелеп-төртелеп яшәде.

Исмәгыйль аны кунакханәгә урнаштырып, ашау-эчү якларын жайлап, бераз акча тоттырды да китеп барды. Мона Кәшшаф бик разый-бәхил иде. Чөнки ул үз өстендә торганны яратмый. Төркияне ана үзе өчен үзе ачасы килә иде.

Кунакханәне зур димәс иде. Бик дәрәжәләләрдән дә түгелдер, ахры. Әмма мона кадәр Кәшшаф кунгалап чыккан Русия кунакханәләреннән өстенрәк. Русия кунакханәләрендә, мәсәлән, сак өстенә сак, дежур өстенә дежур: кая барасын, кайчан кайтасын, кемне алып киләсен—тикшереп-күзәтеп кенә торалар. Монда чын цивилизация. Синс кеше түгел, «телевизион күз» үз карамагына ала. Ләкин ул арттан иярсп йөрми, кырыс караш ташламый. Капкында булсаң да, үзеңне иреклс хис итәсен.

Төрекләр каһвә ярата икән. Кая карама, кулларына уймак калдәрле генә чәшке тоткан кешеләргә тап буласың. Өстәл янына утырып ашыйлар гына, күрәсең, кофены сакаллы тәмәкече шикелле аерым бер ләззәт белән үзләре теләгән урында чөмерәләр.

Кәшшаф та кызыгып китеп, кофе сатып алды. Касәсен учына куеп карады, анда тагын—ике-өч касәлек урын кала иде. Кофесы кече теленә дә йокмады. Татарның сөтле чәенә житәме соң?

Ходай кушып, чәй дә эчәргә туры килле. Сыйладылар. Якынтирәдә бераз йөрештереп алыйм әле дип урамга чыккан иде. Көн әйбәт. Кызуы өттерми дә, пешерми дә. Кояш нурлары йомшак кына иркәли. Күрәсең, дингез һавасы шулай тәэсир итә торгандыр.

Троллейбус тукталышына житәрәк Кәшшаф бер кешене туктатты да русча-татарча-төрекчә сөйләүлегеннән: "Sehir merkezine nasil gidebilirim?»—дигән жөмләне укыды (Шәһәр үзәгенә ничек барырга?)

Төрекнең кара калын мыегы жәелеп китте.

—Merhaba, kiymetli dost! (Исәнмесез, кадерле дус.)

Төрек йонлы кулларын болгый-болгый озын-озак итеп нидер такылдады. Кәшшаф һични аңламады, янә бер жөмлә укыды.

—Lütfen yavaş konuşunuz (Акрынрак сөйләгезче, зинһар). Төрек кычкырып көлеп жибәрде. Инде ул Кәшшафны аңламады булса кирәк.

Алар янына әйләндереп куелган борыч кузагына охшаган тар жилкәле, туч гәүдәле бер кеше килеп туктады. Йөзе пешкән чөгендер кебек кып-кызыл.

Башында чуклы фәс. Килә-килешкә ерык авызны тиргәп ташлады. Сүзләрен аңлап житкермәсә дә күзләрендәге очкын шуны аңлата иде.

—Вы из России?—дип мөрәжәгать итте ана Фәс саф рус телендә.

—Я из Казани,—диде Кәшшаф.

—О-о, Казань! Ведь у меня снохa из Казани! Пойдем, земляк, ты мой самый дорогой гость.

Кәшшафның ай-ваена карамастан, яңа танышы аны култыгыннан эләктереп алды да, өстерәп диярлек каядыр алып китте. Кибет хуҗасы икән. Аяк киемнәре сата. Бусагадан атлап кергәнче үк: «Чәй китерегез!»— дип әмер бирде. Күп тә үтми, хезмәтче малай тәбәнәк өстәлгә ике чынаяк чәй, бер савыт печенье чыгарып утыртты.

—Рәхим итегез,—диде хуҗа.—Бик яхшы вакытта килгәнсез, кояшның бәрхеткә төренгән чагы. Диңгездә су май кебек.

Ул Кәшшафка сүз кыстырырга да ирек бирмәде, үзе такылдады. Шул арада сүзен кисәк кенә өзеп, күмер шикелле кара күзле теге малайга кычкырырга да өлгерде:

—Надир, җәт бул, товарларны китер!

Малай табынны җыештырып, өстәл өстенә бер-бер артлы ялтыр-йолтыр килеп торган шома туфлилар тезәргә тотынды. Хуҗа аларны бәрхет чүпрәк белән сөрткәли-сөрткәли Кәшшафка күрсәтә башлады.

—Сафьян күн, унган күмәч шикелле учка сыеп бетә. Табаны фил тоягыннан. Киеп карагыз әле. Нәкъ сезнең үлчәм.

—Рәхмәт, мин ни...

—Бик дөрес әйтәсез,—диде хуҗа.—Ә мин, чүбек баш, һаман үземнекен тукып утырам. Бер дә борчылмагыз, башкасын табарбыз. Сезнең ише дәрәҗәле әфәндегә нәрсә тәкъдим итәргә беләбез анысы, гомерегез буе рәхмәт укырсыз. Менә бу кәҗүл туфли үзегезгә атап тегелгән кебек. Җылы аягыгызда тузар, Аллаһы боерса...

—Юк, юк, миңа туфли кирәкми. Рәхмәт.

—Надир, мин яшереп куйган туфлиларны кунак әфәнденең аякларына кигез әле. Әйдә, миннән булсын яхшылык!

Малай атылып килеп, Кәшшафның аяк астына ауды. «Ә» дигәнче иске аяк киемен салдырып, яңаларын кигертеп тә куйды.

—Вай-вай, ничек килешә,—дип сайрарга тотынды хуҗа. Салып та тормагыз. Надир, әфәнденең иске туфлиларын юып-чистартып капка салып бәйлә!

Надир күз ачып йомганчы монысын да башкарып куйды.

—Әфәнде, мин сездән күп сорамыйм, шулай да сәүдә хакы өчен бераз әҗерен түләгез,—диде хуҗа. Кәшшафның башы чатнап китте. Ник дисәң, ул бу туфлиларны хуҗа ана бүләк итәргә тели дип уйлаган иде. Шуңа күрә теше-тырнагы белән каршы торган иде. Баксаң, алыш-биреш уены гына корган икән бу адәм. Һай, хәйләкәр!

Бәй әфәнде Исмәгыйль калдырган акчаны кырып-себереп алып калды. Акча эшләү беркайда да җиңел түгел икән шул. Күр, бер пар туфли сатып җибәрү өчен күпме тир сыкты. Чын сәүдәгәр икән.

*Ахыры киләсе санда*



## Фәнис Яруллин

### ЮЛЫМ ИЛТӘ ҺАМАН ТИРӘНГӘ

### Яшим икән әле

Тузаннары гына уйнап калды
Үткән юлларымның.
Сандугачлар ерак алып китте
Моңын җырларымның.

Карурманга кереп туктап калдым,
Эзләп бирәр сукмак.
Сандугачлар каршылады мине
Җырларымны җырлап.

Күзләремә яшьләр бәреп чыкты,
Күңелем китте тулып.
Бер сандугач күз яшемне эчте—
Керфегемә кунып.

Тамырларым аша ниндидер көч
Бәреп керде әчкә.
Сузылып яттым да мин, күккә карап,
Чумдым татлы хискә.

Болыт арасыннан кояш чыгып,
Сорап китте хәлне.
...Яшим икән бит әле мин җирдә,
Яшим икән әле!

Фәнис ЯРУЛЛИН *(1938) —шагыйрь, прозаик, драматург; күпсанлы китаплар авторы. Уз— Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Күңел аланында ак чәчәкләр
Сирәгәя бара көннән-көн.
Кемнәр өзә икән гөлләремнең
Сайлап кына иң-иң кыйммәтен?

Кара төндә кара атка менеп,
Караклармы йөри котырып?
Кала җирдә ап-ак чәчәкләрнең
Сабаклары гына утырып.

Тояк изгән чәчәк таҗларының
Керфекләре канга буяла:
Сак куйсаң да, әкияттәге кебек,
Һәрбер төндә бер гөл югала.

Нинди генә уяу булсаң да син,
Таң алдыннан йоклап кителә.
Нәкъ шулвакыт гөлнең иң матуры
Кырау салкынында өтелә.

Еллар үткән саен сирәгәя
Гомер аланында гөлләрем.
Ак чәчәкләр булып, чиксезлеккә
Кереп югалалар көннәрем.

## Юлым илтә һаман тирәнгә

Аскы агым булып агып ятам,
Шауламыйча гына, тын гына.
Аккан саен суым чистарына
Юыла-юыла елга комына.
Ярсый-ярсый аккан вакытларда
Сагыну юк күңел түрендә.
Энҗе-мәрҗәннәрнең иң сафлары
Саклана бит суның төбендә.
Юып үтәм шушы энҗеләрне,
Күрсен димен, күрсен—күзләләр.
Юкса күпләр энҗе-мәрҗәннәрне
Суга керми генә эзлиләр.
Тирәнлектә яткан матурлыкны
Күрсәтәсе килә дөньяга.

Бар байлыгын төпкә яшергәнгә,
Үпкәләп тә куям елгага.
Килә кайчак ярсу елгаларның
Астын өскә әйләндерәсе.
Энҗеләрен учлап-учлап сибеп,
Менә алар, менә, диясе.
Юк, ярамый, һәркем үз кирәген
Үзе эзләү тәмен кичерсен.
Табалмаса—әрнеп бер еласын,
Тапса—шатлыгыннан исерсен...
Ә мин агам аскы агым булып,
Юлым илтә һаман тирәнгә.
Өсләремдә ак күбеккә батып,
Буш дулкыннар ярсып тирбәлә.

## Ай да күрмичә калды

Сулды гөлләр, узды көннәр,
Сукмакта эзләр янды;
Кара чәчле шук малайны
Ай күрде, Кояш алды.

Шаулап-гөрләп килде яшьлек,
Хисләрдән учак янды;
Кочакларлардагы ярларны
Ай күрде, Кояш алды.

Вакыт-рәссам маңгайларга,
Йөзләргә сырлар салды;

Кояш та алмады аны,
Ай да күрмичә калды.

Елата да, елмайта да
Әй дөньясы, дөньясы!
Күктә микән, җирдә микән
Шатлык, бәхет оясы?

Шул ояның эчләрендә
Әй бер яшәп карасы!
...Юк, кирәкмәс, бәхет кадерен
Белмәс адәм баласы.

—Мәңге сине онытмам!—дип,
Ант итмә һич.
Мәхәббәттә яну-көю
Тик татлы төш.

Татлы төшләр безгә әзме
Кереп тора?!
...Һәр яңа төш элеккесен
Оныттыра.

Яхшылыклар эшлимен дә суга салам,
Халык күрми, балык дәшми, балык телсез.
Күңел күзе сукырлар бит дөнья тулы,
Күрми алар чыра яндырсаң да көндез.

Ә шулай да бер игелек кыла алсам
Дустымамы, йә булмаса җиде ятка.
Күңелемә якты нурлар бәреп керә
Һәм яшәүнең мәгънәсе дә йөз кат арта.

## Күк диңгезе

Берсе өстә, берсе түбәндәрәк,
Болытлар да акмый тигез генә.
Өем-өем булып кереп чума
Бар болытлар күкнең диңгезенә.

Болытларның агын, караларын
Берәм-берәм йота күк диңгезе.
Йотып кына, эчкә йотып кына
Чистарта ул шулай үзен-үзе.

## Үксез дөнья

Тәхетендә төннәр буе тирбәлә Ай,
Зөһрә кыз да сулар ташып арган бугай.
Чиләкләре чайкала да суы түгелә,
Тамчылары йолдыз булып күккә сибелә.

Көянтәңне алыр идем иңнәреңнән,
Баскычлар юк яннарыңа менәремә.
Айга алып ялгыз иткән сине язмыш,
Теләсәң дә язмыштан юк кире кайтыш.

Әзме җирдә синең төсле язмышлылар,
Ялгызлыктан күзе тулы сагышлылар.
Үги бала, үги ана, үги дөнья—
Үгиләрнең һәрвакытта күзе юлда.

Зөһрә кыз да җиргә карап үкси Айда,
Йә кем белә, үгиләрнең бәхете кайда?
Ул бәхетне әллә кемдер урлаганмы,
Әллә соң ул бөтенләй дә булмаганмы?

...Миллион язмыш елый җирдә сулык-сулык,
Бөтенебез калмабызмы үги булып?!

*

Әй язгы җил! Сиңа каршы чабам,
Назлап сыйпа әле йөзләремнән.
Керфек аша яз яктысы тулып
Яшь чыгарсын әле күзләремнән.

Сөенечтән күптән елаган юк,
Тупасландымы соң әллә йөрәк?
Хәер, тукта, күзләремне йомам,
Күз карама яз кермәсен үрләп.

Аккан суны куып тотып булмый
Һәм туктатып булмый искән җилне.
Җиңелмәскә күпме тырышсам да
Җайлап кына тотып картлык җиңде.

Хәзер инде минем чәбәләнү
Җәтмәдәге балыкныкы кебек.
Бәлки сикереп чыгалырмын диеп,
Бәргәләнеп ята соңгы өмет.

## Тузганак

Бөдрә чәчле тузганакларның
Чәчен җилләр кырып алганнар.
(Мандатларын алган депутаттай
Мескенләнеп алар калганнар...)

Башлары да борчак кадәр генә,
Тик чәч торган икән зурайтып.
Кояшка да карый алмый алар
Кәкре сабакларын турайтып.

Җилләр кинәт исеп куйса гына
Куба тузганаклар бураны.
Сөенәләр бары бер минутка
Калкып куйсалар да югары.

«Без язларның тәүге чәчәге»,—дип
Эчкә сеңеп калган мин-минлек—
Үлә алмый җәфаланып ята...
Пәрәвезләр җебенә эленеп.

*

Кереп життем дигән чакта гына
Күк капусы куйды ябылып.
Ишегенең ап-ак тоткасына
Сыңар кулым калды кагылып.

Күп сынаулар аша үткән йөрәк
Бу сынауга никтер түзмәде.
Йөрәк урынында калды бары
Кара янган учак эзләре.

Ул урында инде гөлләр үсмәс,
Анда булыр мәңге каралык.
Җил китергән көзге яфрак кына
Ятса ятыр анда таралып.

Бу урында ялга туктамаслар
Эзләүчеләр җирдә матурлык.
Андыйларны бүтән матур җирләр,
Матур гөлләр торыр чакырып.

Беркем белмәс әлеге фаҗигане,
Дөнья өчен ни ул бер йөрәк!
...Рәнҗетелгән мәхәббәтнең генә
Күзкәйләре куяр мөлдерәп.

*

Мәхәббәт—артык мәшәкать,
Мин куркам мәшәкатьтән.
Кем соң файда күргән әле
Сөюдән, мәхәббәттән?!

Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә,
Алар янган, ни калган?
Берни дә калмаган икән,
Димәк, барсы да—ялган.

Юк, юк, мәхәббәт турында
Сүз кузгатмагыз бүтән.
Әйтерләр: бу да—бичара!—
Безнең күк юләр икән.

*

Йодрык кадәр генә калдым инде,
Бу тормыштан һаман нидер көтәм.
Йөрәгенә алып салса берсе,
Бөтенләем белән сыеп бетәм.

*2002*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Барлас Камалов**

## СОҢГЫ КӨННӘРДӘ

хикәя

### I

Стенадагы күкеле сәгать көн уртасы җиткәнен хәбәр итте. Димәк, тиздән әтисе кайтып җитәчәк. Ул колхоз умарталыгында. Яше җитмешенче чакрым баганасын үтсә дә эшли әле. Яратып, бик белеп һәм булсын дип тырышып йөри.

Ун-унбиш минут чамасы вакыт үткәч, Хәбирә, ятактан башын күтәреп, тагын сәгатькә текәлгән иде, ни күрсен, сәгать туктап калган. Шушы күренеш анын йөрәгенә кара шом салды. Каты сырхау болай да шикләнергә, пошынырга-хафаланырга гына тора бит ул. Башы әллә ниткән хәерсез юраулар белән тулган була. Мәгәр миен коточкыч уй бораулап өлгергән иде инде: «Фәрештәләрнең гомерем бетүгә хәбәр салулары галәмәте бу!»

Ул күзләрен чытырдатып йомды, каны качып, юкарып калган иренен тешләде. Сау-сәламәт чагында да еллар буе тынгы бирмәгән уй бу юлы тыелгысыз бер көч белән анын зәгыйфьләнгән җанын айкады.

«Тәвәккәллим. Бик кыен, үтә авыр, чиксез оят булса да, әткәйдән гөзерлим. Барсын, күрсен, чакыруымны ирештерсен. Ул минем җан авазыма колак салмый калмас...»

Хәбирә шундый катгый карарга килде.

### II

Авыл карты икәне беренче карашка ук күренеп тора, шуна күрә анын иртәнге сигез тулыр-тулмаста профсоюз газетасы редакциясенә килеп керүе Тәбриз өчен бер дә сәер түгел иде. Ул һәр көнне килә

---

Барлас КАМАЛОВ *(1930)—прозаик; «Яшь имәннәр», «Канатлы кырмыска», «Ярсөяр әрәмәсе» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

торган авыл апаларының һәм агайларының берсе. Поездлан, автобустан яки теплоходтан төшәләр дә туп-туры шушы йортка киләләр. Хезмәт Сараена. Йомышлары мен төрле була аларның. Бигрәк тә бу болгавыр, ил белән идарә итүнең чамасыз тугарылган чорында. Ата—улны, ана—кызны белмичә дигәндәй, берни белән дә хисаплашмыйча, бирәүләр—череп баеган, икенчеләр хәерчелеккә дучар ителгән елларда. Угрылык канун төсен алганда. Бөтен мәмләкәтендә мөмкинлекләрне эшкә жигүнең рәтле-юньле ысулы табылмаганда...

Галәттә, озын буйлы кешеләрнең аркаларында, олыгая башлауга, бөкре сыман нәрсә кала. Бу агай да шундый, алга сөрлегебрәк тора. Тәбриз ин әүвәле шуна игътибар итте. Аннары гына картның кояшта, жилдә какланып, жиз төскә кергән жыерчыклы йөзенә карады.

—Мина Саматов дигән иптәш кирәк иде.

—Мин булам.

Шулай дигәч, карт төсе унган зәңгәр күзләрен чекрәйтеп ана карап торды, гүя аның Тәбриз Саматов булуына шиге бар иде. Аннары кушучлап күрешергә үрелде.

—Йомышым сина минем алайса...

—Тыңлап карыйк...

Тәбриз әйләнмәле урындыгында кымшанып, ун терсәген өстәлгә терәп, ияге белән учына таянды.

Карт тамак кыргалады, кул сыртын ышкыгалады, сүз башлавы кыен иде бугай ана.

—Син кем, энем...

—Тәбриз.

—Ие, ие, Тәбриз энем. Тау ягындагы Алмыш авылын беләсеңме?

—Беләм.—Тәбриз терсәген өстәлдән алды, гәүдәсе белән картка таба авышкандай булды. Аның кысынкы конгырт күзләрендә очкыннар елтыраша башлады.

—Хәбирә дигән кызны да белә иденме? Колхоз кәнсәләрендә учетчик чагын, ие...

—Белә идем!—Тәбриз бу сүзләрне әллә нинди ялган күтәренкелек белән әйтте.—Тик бу күптән бит инде, абзый.

—Хак әйттен, утыз биш ел, кем, энем. Ул чагында мин дә кырыкка гына атланырга тора идем әле.

—Сез—Низаметдин абзыймы?

—Өстенә генә бастын, нәкъ үзе.

—Гафу итегез, йомышыгыздан алдан ук сорыйм әле, Хәбирә ни хәлдә? Яшьлегендә коточкыч фажига кичергән дип ишеткән идем.

Низаметдин абзый көмешләнгән кечкенә түгәрәк сакалын сыпырып куйды, тирән, бик тирән итеп тын алды.

—Шулай булды шул. Хак Тәгаләнен әмерләр, шулай булды. Башка сыймый торды ул хәлләр. Мөселман сабырлыгы белән генә чыдадык...—Агай әледән-әле тәкерек йота, һава житмәгәндәй, еш-еш сулый иде.—Алтмышынчы елның язында кияүгә чыкты ул. Чыгасы иде... Юкса аның үз итеп өзелгән кешесе барын белә идек. Егетнең монда, Казанда эшләгән чагы иде. Гидраструй диләр идеме сон?.. Казанны су басмасын дигән кантур.

—Әйе, «Гидроспецстрой» дигән трест.

—Э-э, шул. Кыскаватырда иде кияү буласы кеше. Баракта бер почмак бирәсе булганнар фатир итеп... Ну язганнан уза алмыйсың икән. Кремльле урамдагы ЗАГСта язылышып чыкканнар болар. Яннарында иптәшләреннән ике-өч кеше дә булган. Ул елларда бит әле язылышып кайтканда машиналар үкертеп йөрү әллә ни күп юк. Микрасов урамына кайтырга чыгалар болар. Без шунда никах укытырга дип көтеп торабыз... Күрәләр: алыптай бер азгын бичара картны дөмбәсләп ята. Кияү буласы авылдаш егет түзмәгән, картны яклап, араларына кергән. Теге исерек

моның йөрәгенә пычак белән бер генә кереп чыккан. Бар иде кияү—юк булды кияү!.. Авылга кайтарып җирләдек. Кыз, ир күрмичә, тол калды. Бүтәнгә чыгуны уйлап та карамады. Телсез-өнсез гомер итте. Кантурга барды—эшләде, өйгә кайтты—эшләде. Моннан җиде ел элек әнкәсе дөнья куйгач, өйдәге бар шөгыле мине тәрбия кылуга әйләнде... Тәмугка күнгән шайтан кебек, күнгән идек инде аның тол яшәвенә. Бик миһербанлы бала ул безнең, көчсезгә, икмәксезгә булышырга гына тора, олыларны—олы, кечеләрне кече итеп назлый белә... Ходаның хикмәте, янә бәла килде. Хәбирәнең үпкәсендә яман шеш таптылар. Сулды, саргайды...—Низаметдин тынып калды. Кыяфәтенә карап, уйлары бик еракта[дыр] дип чамаларга мөмкин иде. Ул үзе дә ни үле, ни тере иде бу минутта.

Күпмедер сүзсез торганнан соң карт, өстенә салкын су сипкәндәй, кинәт сискәнеп китте һәм, югалып калуы өчен кичерү сораган төсле, янә сүз башлады.

—Минем йомыш дигәнем шул җәһәттән... Кызымның миннән бөртек тә сере юк. Анасы гүр иясе булгач, икебез бер җан кебек яши идек... Хәле хуҗега бара, күңелен боз тотканын сизәм. Үзе барысын да белеп, аңлап тора. Әле өченче көнне генә гозерләде. «Әткәй, Тәбризне табып әйтсәнә, минем аны чирек сәгать кенә булса да күрәсем килә. Бу дөньядан киткәнче әйтер сүзем бар. Сүзенне гүргә алып китүне гөнаһ, диләр. Хатыны белән парлашып җәһәт кенә килеп китсеннәр әле, зинһар. Бик читен булса да мине битәрләми генә ялваруымны тыңлый күр»,—диде. Битәрлимме соң?! Аңлыйм бит, безнең сүзне тыңлап кына чыгасы кияве дә гаип булгач, сине уйлап кына яшәгән икән. Кузгалдым юлга, аманәтен тапшырдым. Өстемнән тау төште. Хак Тәгалә хозурында йөзем ак. Калганы—синең иркеңдә...

Карт күз яшьсез генә елый иде. Тәбризнең җаны дөрләде...

## III

Заманында тирә-юньдә дан тоткан тимерче, гомерлек умартачы Низаметдин картның ак өе түрендә бер-берсен утыз биш ел күрмәгән ике зат сөйләшә. Аларның әңгәмәсенә киң тәрәз төбенә сулы банкага утыртылган чәчәк бәйләме—тажгөлләр генә шаһит. Хәлне аңлатып, юлга чыкканда, ул чәчәк бәйләмен Тәбризнең хатыны сатып алып бирде.

—Үзең генә бар, картым,—диде хәләле.—Мондый чакта өченче кеше тел богаулаучы булыр. Бар, күр, әйтерен тыңла. Мин аның көндәше түгел. Ул, бичара, яшьлек хатирәләре белән генә яшидер. Иң яхшы бүләк—чәчәкләр булыр...

Хәбирәгә авылның шәфкать туташы әле генә укол ясап киткән икән. Ул мендәрен диван артына терәп утырган. Иңнәрендә мамык шәл. Тышта чәчәкле июнь—саратан чилләсе. Өйдә дә һич суык түгел. Ә Хәбирәгә салкынчадыр, күрәсең.

Аның тавышы тыныч, йомшак. Әүвәлдәгечә матур итеп көлүе генә югалган. Елмаюы да бик кыска. Йөзендәге балкышны каһәрле чир урлаган. Күзләре генә элеккегечә. Зәңгәр күлләр! Куе керфекләре—адаштыргыч. Һәм борынының уң яфрагы читендәге мине элеккегечә. Аның сөйкемлелек ноктасы шушы миңдә иде булса кирәк...

Тәбриз, урындык алып, авыруның каршысына утырды. Күз карашын һич аермас иде дә бу сырхау заттан, яхшысынмый. Алай дисән, Хәбирә үзе дә аңа томырылып карап туймый бугай...

Сүзләре төрле тарафка тәгәрәшкән терекөмеш тамчыларына әверелде гүя, җыеп ала торган түгел. Әле бер нәрсәне искә төшерәләр, әле бөтенләй бүтәнне сөйләп китәләр. Мәгәр үткәндәге бер хатирәгә ике кат кайтып тәрәлделәр инде.

Университет студентлары белән Алмыш авылына концерт куярга килгәч, җыр остасы Тәбризнең Хәбирәне бик нык ошатуын кызның әтисе Низаметдин агайга сиздергәннәр.

«Кәжә—мал түгел, артист—кеше түгел»,—дигән тимер остасы.— Тирәсендә жыен шалапут бөтерелсен дип үстергән кызым юк минем!»

Тагын ике елдан, читтән торып укырга кучкәч, Тәбриз үзенең ниятен житкергәч, жавап тагын шул чама булган иде.

«Китап кортларының настаяший ир булганын күргәнем юк. Өметен сузып йөрмәсен штубы! Йодрыгым кувалдадан ким түгел!»

Шуннан юллар аерылды инде...

Бер сәгать күптән үтеп китте. Вакытны йөгәнләр хәл юк. Ничек кенә булса да бүген мәңгегә хушлашачаклар алар. Шуны бик ачык тоепмы, Хәбирә яшьлек хатирәләреннән бүгенге халәткә әйләнеп кайтты.

—Минем сәгатьләрем чикләнгән, Тәбриз. Сине бер күрим дип кенә яшәдем. Яшьлектәге саф мәхәббәт исталеге, өмет күпмедер яшәтә икән. Тик аның да чиге бар. Соңгы чиге житкәч, әткәй тикле әткәйдән сине чакыруны гозерләдем. Оят дигән нәрсәне дә онытып... Бер хакыйкатьне төшендем мин: әткәй теге вакыттагы басымчаклыгы өчен үкенә. Гозеремне әйткәч, берсүзсез риза булды. «Теге еллардагы таш бәгырьлелегем китергән гөнаһтан аз булса да арынмаммы?»—ди. Инде хуш, бәхил бул!

Хәбирә елап жибәрде. Тәбриз аның күз яшьләренең таш эретерлек кайнар, бәгырь кисәрлек ачы икәнлеген аңлый иде. Юатырга сүз таба алмады. Ярый әле Хәбирә үзе тиз тыйлыкты. Каян көч ала диген?!

Ул диванның аргы башындагы ап-ак тышлы мендәр астыннан бер калын дәфтәр алып Тәбризгә сузды.

—Юлда укырсың. Хуш! Бәхилләшик!

Тәбриз дәфтәр тышындагы «1960—1995» дигән саннарны шәйләп өлгерде.

## IV

Станциягә чак килеп өлгерде Тәбриз. Поезд кузгалырга тора иде инде.

Вагонга кереп бераз тынычлангач, сумкасыннан теге дәфтәрне алды. Ни өчендер, ул аны соңгы битеннән укып китте.

«... Авыл башындагы кушкаен әле дә булса син киткән юлга карый. Каен түгел—мин ул. Кушкаен кайсыбызныдыр гаепли. Бәлки икебезне дәдер. Сине—әрсезлеген житмәүдә, мине—кыюсызга. Атам-анам каргышыннан курку көчле иде шул!

Ак каен гаепли дә, жәлли дә ул безне. Жәлләмәсә, һәр көзне сары яфракларын күз яше итеп коймас иде. Ул яфрак койганда, көзге сагыш бар дөньямны каплап, яшәвемнең соңгы сәгатьләрен күз алдыма китереп кисәтә. Мин монарчы да синең барлыгыңны тоеп яшәдем бит, рухиятем таяныч булды мина. Йә, мәңгегә хуш, чыңга аша алмаган өметем, татлы хыялым!»



# Вазыйх Фатыйхов

## ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

⁂

Чикерткә белән серләшәм,
Аңлашабыз серләрне:
Һәркемнең үз баскычы бар—
Һәркемнең үз мөнбәре!

⁂

Агачлар егыла ярларда,
Тамырлар сузылып өзелә.
Мәхәббәт яшь калыр иде лә,
Арага әллә соң көз керә?..

⁂

Елмаюыңны күрсәм—сөенәм,
Елаганыңны сизсәм—көенәм.
Һәрбер мизгелең—минем сулышым:
Сине күзәтәм сөю күгеннән!

⁂

Яшәү өчен көрәш бара табигатьтә,
Кигәвенгә ачу тотып ялгышма!

---

*Вазыйх* ФАТЫЙХОВ *(1958) —шагыйрь; «Тормыш арбасы», «Тормыш—ормыш» исемле китаплар авторы. Балык Бистәсендә яши.*

Ачуланма хәтта тешләк язмышка—
Көлеп күз кысканда кояш батыштан.

⁂

Урамнардан берәү атлый—
Ул синең яп-яшь чагың...
Йөрәкләрне тагын ничек
Теләп алырсың, җаным?!

⁂

Авыл иртәсенең татлы мизгеле бу,—
Ялан-тәпи атлап, чык кагу.
Кояш нурларында уйнап аргач,
Офыкларга төшеп ял алу.

⁂

Кирелегең кире тартып ала,
Җибәрмәстер инде, ышанам.
Бер әләккәч ычкынуы кыен
Сөю дигән серле тышаудан.

⁂

Без бүген коймадә, бер ләззәт—
Хисләрнең куышып уйнавы,
Дулкында, коймәгә сыланып,
Пар йөрәк типкәнен тыңлавы!

⁂

Тәүге кыңгырау чыңлады
Сөю күгендә.
Йөрәк кояшка үрләде—
Ялкын түренә.

⁂

Питрау узды. Тургай җырлый.
Җәй китмәскә килгәнме?
...Әле тоташ җәй булып күк
Табигатьтә бер мәлне!

⁂

Уңга да каердым, сулга да,
Тормышым, язмышым минем шул:
Бер юлың булмаса—җырга тиң!—
Ялгышмый барулар кыен шул!

⁂

Күп гомер үтелгән, чамасыз...
Бүгенге бер мизгел—бер гомер!
Күпме сүз әйтелгән, онытылган...
Синеке—җан көткән әмердер...

Нигә соң, нигә соң, нигә соң...
Яңгырый кабаттан бер үк сүз?
Табалмыйм иясен... Бәлки, бу—
Карурман авазы:—Түз син, түз!

Яшәү дәрте шундый көчле ахры—
Читәннәрдә казык яшәрде!
...Тал сыгылса яшәрәдер,—ә соң
Кем сындырып сыный яшьләрне?!

Читән казыгында ыштан ертып,
Егылып төшеп борын канаттык.
Әмма исән күңел киңлегебез:
Туган-үскән җирдән шан таптык.

Фәлсәфәң күп дисез, тәнкыйтьлисез,
Тормыш үзе шуңа этәрә.
Хисләремне бер иярли калсам,
Туар башка шагыйрь иртәгә...

Көтәсең: үзгәрер...
Туалмыйм янәдән:
Ходайдан әмер юк,
Нишлим соң, мин адәм?!

Көткәнемне сизәсеңме,
Беркатлы син, дисеңме?
Җаныма дип җыенсаң—шул
Битлегеңне киярсеңме?

Үкенәм, үкенмим—
Язмышым кулымда!
Серләрен бер сабак
Итәрмен улыма!

Нигә соң юлыктың юлыма?
Әйтергә кыюлык җитмәде:
«Мәңге» дип бирелгән вәгъдәләр
Мине ник бәхетле итмәде?!

## *Аяз Гыйләҗевнең тууына 75 ел*

# ЮКСЫНУ

Кайчан да булса Аяз Гыйләҗев турында язарга туры килер дип башыма да китереп караганым юк иде. Аяз Гыйләҗев безнен өчен—зур әдәбиятка чагыштырмача соңрак килгән буын өчен—кул житмәс биеклек, әдәбият Олимпында борынгы грек аллаларыныкы шикелле үз урыны, үз сүзе булган изге бер зат тоела иде. Әйе, ул елларда әле үзе исән чагында ук әдәбиятыбызнын алтын баганаларына—классикларга әверелгән әдипләребез, сәнгатькәрләребез байтак иде. Без аларнын фидаилегенә, филакарьлегенә, гыйлем вә тормыш дәрьясында кин колачлыкларына, хәтер сандыкларынын байлык-муллыгына сокланып, эшчәнлекләренең күпкырлылыгына шаккатып карый идек. Соңгы ун-унбиш ел эчендә Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Бакый Урманче, Гариф Ахунов кебек бөекләребез фани дөньяны калдырып бакыйга күчкәч, әдәбият-сәнгатьнең тәхет залы бушап калды. Укучыларын бик еш таң калдырырга, көтмәгәндә уйламаганда яңа әсәре белән шаккатырырга яраткан Аяз Гыйләҗев әнә шул мөбарәк тәсбихнең соңгы мәрҗәне булды бугай. Бүгенге көндә алар биләгән затлы кәнәфи-көрсиләргә утырыр затларны мин әлегә күрмим. Хәер, утырырга ымсынучылары да, юкны бар итәргә теләп ыгы-зыгы тудырырга теләүчеләре дә табылыр. Изге урын буш тормас ди. Әмма алар дәрәҗәсендәге бөеклекләргә ирешү өчен әдәбият түрәсе булу да, хакимият кәнәфиләрендә утыру да житми. Менә ирешү өчен аларча филакарьлек, каһарманлыкка тиң әдәби батырлык һәм еллар буе энә белән кое казып тупланган тәжрибә вә гыйлемлек тә кирәк шул. Еллар үтәр, әмма егерменче гасыр дәвамында әдәбиятыбызнын төп йөген жигелеп тарткан, анын егәр-куәтен билгеләгән олуг әдипләребезнең бай мирасы тоныкланмас, асыл кыйммәте вә бәясе арзанаймас.

Ни кызганыч тоелмасын, азрак яшәде Аяз абый. 2003 елнын гыйнвар аенда ана әле нибары 75 яшь тулган булыр иде. Сиксәнне куып барганда, ансә туксанга килеп житкәндә дә ныклы кул белән, тыгыз фикергә, жете сурәтләүләргә һәм мәгънәле тасвирга бай әсәрләр язып әдәбият яратучыларны сөендереп яшәгән аксакал әдипләребезне искә төшерсәң азрак тоела икән шул. Аяз абыйнын язасы әсәрләре, газиз халкына әйтеп калдырасы байтак фикерләре, шиксез булгандыр. Шушылай дип язып куйдым да уйга калдым: язучынын гомер озынлыгы, бәлки, яшәгән елларының күплеге-саны белән билгеләнми дә торгандыр әле. Бәлки, әдипнен тынгысыз ижатта янып үткән бер елы да үзенен рухи тыгызлыгы, яшәү мәгънәсенен тирәнлеге белән кайбер кемсәләрнең дистә елларына торадыр. Тукайны мин, мәсәлән, бүген аксакаллы карт итеп, акыл иясе итеп күз алдына китерәм. Якты дөньядан нибары егерме жиденче яшендә китеп барган шагыйрь калдырган бай ижат әле тагын әллә ничә гасырлар буена миллиятебезгә рухи байлык бирергә житәрлек.

Затлы прозаик, ялкынлы публицист һәм нечкә драматург Аяз Гыйләҗев калдырган рухи мирас та үзенең колачы, фәлсәфи һәм психологик тирәнлеге белән күпләрне таң калдырырлык. Йөзләрчә хикәяләр, дисталәрчә повесть-романнар, утыз дистәгә якын драма әсәре, санап бетергесез тәнкыйть мәкаләләре, ялкынлы публицистика... Ә инде әдипнең көндәлек язмаларын, хатларын да искә алсак, әдәбият тарихын өйрәнүчеләргә байтак елларга житәр әле ул. Ләкин хикмәт аларнын күплегендә генә түгел. Монда сүз—бөек тел остасы, олы художник, адәм баласынын катлаулы психологиясен тирән аңлаган философ, чын мәгънәсендә әдип булып өлгергән кешенен мирасы турында бара. Аларны жентекләп өйрәнү, матбугатта бастырып чыгару өчен дә шактый еллар үтү кирәк булырдыр әле. Чөнки Аяз абый

бер генә гаделсезлекне дә көнел күзеннән җинел үткәреп җибәрми, теле белән әйтмәсә, аларны кайда да булса теркәп калдыру җаен карый иде. Үзе өчен генә яисә варислары өчен генә язган ул көндәлекләрдә һәм хатларда нинәр генә булмас, "очсыз-кырыйсыз күк бит ул" дигәндәй, илле елдан артык тупланган хатирә-мирас, чарасызлыктан гаҗиз булып, тешләреңне кысып, кулларыңны йодрыклап йөрәгең бәргәләнеп язган хис-тойгылар концентрациясе бит ул! Чоры шундый иде!

Әйе, чоры шундый иде... Ләкин яшьлек чорында Аяз атлы егетебезнең дә түзә алмаган чаклары булган, күңелендә бикләнеп калырга тиешле сүзләре үз ихтыярыннан башка ташып чыккан, күрәсең. 1986 елда басылган "Совет Татарстаны язучылары" дигән калын зур хезмәтне—биобиблиографик белешмәне карап утырам. "Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстан АССРның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Балачагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз классын һәм Сарман урта мәктәбенең ун классын тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын ВЛКСМның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була. 1948–1950 елларда ул—В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенты, *ә 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казакъстанда яшь һәм төзелештә ташучы, бетон коючы, бригадир һәм десятник профессияләрен үзләштерә.* Аннары, янадан Казанга кайтып, университетта укуын дәвам иттерә".

Чоры шундый иде.

Курсив белән аерып җыелган юлларга кабаттан күз төшерик әле, кадерле укучым! Нинди гади, битараф садә юллар. Әйтерсең хыялый студент егет, яшьлек романтикасына бирелеп, университетта баш катырып мәшәкатьләнмәскә карар иткән дә чемоданын тотып Казакъстан далаларына чыгып киткән. Барысы да бик җиңел һәм рәхәт икән! Әмма эзләнүчән, зиһенле һәм зирәк укучы ул чорларда юл арасында яшерелгән мәгънәне дә бик тиз тотып ала белә, юл арасында калганнарны укырга аеруча маһирланып беткән иде инде. Белешмәлекне төзүчеләр әнә шул маһирлыкны истә тотып, цензорларны үзләренчә бик оста "алдаганнар" да инде. Менә шушы бер җөмләгә егерме ике яшьлек студент егетнең тоталитаризм чорындагы "Җинаятьләр



*1998 елгы редколлегия утырышы. Алгы рәттә (сулдан уңга): Ф. Латыйфи, Аяз Гыйләҗев. Икенче рәттә: Р. Гаташ, Р. Низами, Х. Миңнегулов, Ә. Баян, Ә. Еники, Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Ә. Рәшит. Арткы рәттә: Х. Әюпов, Р. Зәйдулла, Ш. Галиев, М. Госманов, З. Хөснияр, Т. Галиуллин, Р. Мөхәммәдиев.*

кодексы"ның дәһшәтле 58 нче маддәсе буенча хөкем ителүе дә, алты елга диярлек сузылган каһәрле каторга газаплары да, җәһәннәмнең җиде катын узута тин кара көннәр дә сыйган.

Аяз ага серле кеше иле. Еш кына бер сәбәпсез сүзсез калып, уйларына чумып онытылыр иде. Әйтерсең, янында иптәшләре дә, аның бер калимә мәгънәле сүзен көтеп колакларын шомрайткан яшь-җилкенчәкләр дә юк. Әйтерсең, ул далада япа-ялгызы калган. Менә бераздан ул башын чайкап куяр һәм бераз гына кыштайган, мактанган сыманрак иттереп, "Мин каторжан бит, парин!" дип куяр. Әмма бу тышкы кыяфәт, "егетләнергә тырышу" артында ни-нәрсәләр ятканын күпләр аңлап та житкермәгәндер. Каян белеп бетермәк кирәк! Аны без әле соңгы елларда гына бераз төшенә башладык та бугай. Хәер, андый чакларда Аяз абыйның һәрнәрсәгә сынап, җентекләп карый торган уйчан күзләрен монсулык, әйтеп аңлатып булмый торган, аны башкалардан аерып куючы ниндидер элпә каплагандай була торган иде. Еллар үтеп, "Ягез, бер дога" романын уку бәхетенә ирешкәч кенә, ул "егетлек"нең асыл бәясен чынлап аңладык та шикелле.

Шөкер, татар әдәбияты олпат шәхесләргә, телебезнең нечкәлекләрен үтә сизгер тоемлаучы, һәр калимәнә, асыл мәгънәсен белеп, алтын кысага утыртылган бриллиант кимәленә житкерә белүче сүз осталарына бай булды. Һәм аларның берсе дип, мин, һич икеләнүсез, Аяз ага Гыйләҗевны күрсәтер идем. Редакциядә шактый озак эшләгән кеше буларак әйтәм: бер биткә сыеп бетмәгәнлектән, еш кына әсәрләрне кыскартырга, бер яки берничә сүзне алып ташларга кирәк була. Корректор яисә техник мөхәррир хәл итә торган гап-гади мәсьәлә бу. Кайбер авторлардан хәтта тулы абзацларны, тулаем-тулаем битләрне алып атсаң да әсәрнең эчтәлегенә зыян килми. Киресенчә, җыйнакланып кына кала әле. Ә менә син тиеп кара Әмирхан Еникигә! Тиеп кара Гомәр Бәшировка! Кая ул бер бит яки абзац! Аларда бер сүзне кыскарта алмыйсың. Чөнки һәр сүз нәкъ үз урынында, һәр сүз янәшәсендәге иптәше белән мәгънәви яктан шулкадәр тыгыз тоташкан, бәйләнгән ки, аны алсаң, яисә кыскарак язылышлы башка берәрсе белән алыштырсаң, бөтен җөмләнең, хәтта кайчагында бөтен әсәрнең ямен, бизәген җимерәсең. Менә ул сүз тәмен тою! Менә ул сүзләрнең чын һәм асыл бәһасен белеп куллану! Бу инде гадәти язу түгел, бу—сүзләр дөньясында яшәү, сулау. Аяз Гыйләҗев тә әнә шундый осталардан иде. Техник кыскартулар кирәк булганда корректорларыбыз аз "чиләнмәде" Аяз абый әсәрләре белән. Әмма ул рәхәт "чиләнү", сүз чишмәсенең челтерәп аккан саф агымын тоюдан татлы ләззәт кичерүгә тиң иде.

Дөресен әйтим, мин үземне Аяз ага белән күп аралашкан, иҗат юртларында бергәләп сәйран кичергән, фикердәш, әңгәмәдәш вә табындаш булган кешеләрдән дип әйтә алмыйм. Әмма 1986 елдан бирле "Казан утлары" журналында эшләү дәверендә редколлегия утырышларында, тегә яки бу әсәр хакында фикер алышканда шактый еш очраша идек. Хәтта бер-ике тапкыр өендә дә булырга туры килде әле. Хәтергә шунысы уелып калган: тикшерелгән һәр мәсьәләгә, һәр әсәргә карата аның анык һәм өешып житкән үз фикере була. Булсын әдәбият мәйданын тетрәтеп торучы каләм иясе, булсын журналда әле беренче әсәре белән баш тартүче яшь егет—Аяз абый "авторитет"ларга, дәрәҗәләргә карап тормыйча турысын ярып салыр иде.

Соңгы очрашуыбыз, ялгышмасам, 2002 елның февраль ахырларында булды. Журналның баш редакторы Равил Фәйзуллин белән аның өенә барган идек без. Аяз абыйның инде байтактан урын өстендә икәнен беләбез, хәлен белеп чыкмакчы идек. Ләкин без килеп кергәч тә ул, әйтерсең, эшләп арыган һәм бераз хәл алырга гына яткан кеше шикелле, торып утырды, егетләрчә күрешергә кулларын сузды. Ябыккан, нык бетәшкән иде. Әмма керфекләре арасында авыру кеше күзләре түгел, ә бар нәрсәне белергә, аңларга, күрергә омтылучы акыллы күзләр елтырый иде. Үзе хакында ләм-мим. Сорашканы-белешкәне—редакция хәлләре, язучыларның нинди әсәрләр китерүе, кемнең ниндирәк әйбер язып ятуы, әдәбият язмышы, Татарстанның суверенлыгы, халыкның киләчәге.

Монсу һәм хәзер күңел төбендә аерым мәгънәгә ия була барган бу соңгы очрашу мизгелләрен тәфсилләп сурәтләп Аяз абыйның бердәнбере һәм гомер буе тугры юлдашы булган Нәкыя апаның, балаларының күңелен кузгатасым килми. Ләкин шуны аерып әйтәсем килә: гомеренең соңгы сулышына кадәр Аяз абый әдәбият дип, халык дип яшәде. Бер генә көне дә әдәбияттан аерым булмады.

"Казан утлары" журналының 2001 елгы декабрь санында аның "Өметләр уята торган әсәр" дип исемләнгән соңгы мәкаләсе басылып чыкты. Язмыштыр инде, ул без фәкыйрегезнең "Бәйсез этләрне атарга" дигән роман-нәсере хакында иде. Үләренә берничә ай калганда да аның язганнарында "өмет" сүзенең сүрелмәве үзе генә дә бик күп нәрсә турында сөйли сыман тоела миңа.

Кыска гына мәкаләдә Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, олы һәм катлаулы язмыш иясе, талантлы әдип Аяз ага турында барысын да язып та, иҗатына анализ ясап та булмый. Хәер, минем максатым да ул түгел. Бу язмалар үткен сүзле гаярь әдипнең тууына 75 ел тулыр көннәр алдыннан аны искә алып юксыну, ялгыз калып уйлану гынадыр. Ләкин мин бер нәрсәне анык тоемлыйм: сагынабыз Сине Аяз абый, тирән фәлсәфи әсәрләреңне сагынабыз, редакциягә килеп йөргән көннәреңне юксынабыз. Әдәбиятка һәм безгә Син кирәк, бик-бик тә нык кирәк идең шул!..

**Флүс ЛАТЫЙФИ.**

# Аяз Гыйләҗев

## ҮГИ АНА ЯФРАКЛАРЫ

хикәя

Бер-берсенә сырышып утырган тәбәнәк агач келәтләр арасыннан ургылып чыккан дуамал җил такырда коенты бодайларны чүпләп йөргән эре, ак казларның канатларын каера, аларга тыныч кына ашарга ирек бирми, йолыккалый, туктаусыз бимазалап тора. Келәтләр авылдан шактый еракта, атау сыман калкулыкта, нәкъ җил күзендә тезелешкәннәр. Казлар очып китәргә җыенгандай берара җилгә буйсынып ияреп баралар да кинәт туктыйлар, ка-ка дип кычкырып, ялгыз түгеллекләренә өерелеп куаналар да сүз берләшеп тагын келәт алдындагы бодайлы машинага таба тартылалар.

Каравылчы Мифтахетдин, тол дүдәк булганга, төнлә генә түгел, көндез дә келәтләр янында урала. Ул озын кулларын җәеп казларны куа башлый, учларын бер-берсенә сугып шапылдата, яргаланган юка тиреле кызгылт иреннәрен бөрештереп сызгыра:

—Кө-өш! Көш дим, каһәрләр! Фью-фью!

Мифтахетдиннең буйлы-буйлы көрән чалбарының утыра торган җиренә тегәрҗеп белән эре-эре атлатып дәү кызыл ямау салганнар, ул стоп-сигнал кебек янып әллә кайдан келпеп тора. Ямауны күреп шофер Галимҗан жыр-жыр көлә.

Казлар бер тамчы да курыкмыйлар, алар кемне кемнән аералар, бүрекле ата каз егетләрчә гаярь басып Мифтахетдингә каршы ук китә һәм озын, юан чыбыркы муенын сузып яман ысылдый. Озак еллар каравылда торып мылтык асып йөрергә өйрәнгән Мифтахетдин коралсыз калганда тач куркакка әйләнә, ул вак-вак адымнар белән йөгереп кабина кырына килеп ышыклана, анда да шүрләп икенче якка ук чыга. Галимҗан көлүен оста яшереп авызын учы белән каплый: өйләнмәгән егеткә тол төнге каравылчы белән ызгышмау яхшырак...

Тезенә төшеп торган озын әлинур күлмәгенең итәгенә вак-вак шадралар чуарлаган кин битен сөртә-сөртә келәт ишегеннән йөкче Хәнәфи килеп чыкты. Амбарчы белән берне көйрәтеп ул кинәнеп кенә тәмәке тарта башлады. Мифтахетдин дә аларга барып кушылды, сүз китте. Ул арада Галимжан түземсезләнеп машинасын кычкыртты. Кычкыртуы булды, Хәнәфи тәмәке төпчеген жиргә бәреп тиз-тиз кабинага кереп утырды:

—Дөрес итәсең, бүген ашыгырга кирәк. Үрләт әйдә!—диде.

Мифтахетдин чалышайган үкчәле туфлие белән Хәнәфинең тәтенле төпчегенә баса-баса кычкырып жибәрде:

—Штраф түләтермен! Бу жиллә...

Машина куанып гөрли башлауга, казлар жыйнаулашып алгарак чыктылар. Әллә көчле жил, әллә күзгә туклык шаукымы аларның оныты лып беткән кыргый, ирекле чакларын искә төшерде, ин элек шәбәеп ата каз аваз салды, ана каз куштанланып аның тирәсендә әйләнгәләде, бәбкә икәнлекләрен аермаслык бала казлар, яна, шук тавышлар белән кангылдашып, әткә-әнкәләренә кушылдылар. Кузгалып чаба башлаган машина кинәт тукталды, авыр, жәһәт эштән сон изрәп барган Хәнәфинең мангае чак түбәгә бәрелмәде.

—Яп-яланаяк,—дип сүгенде ул галәтенчә яратып.—Нәрсә бар тагын, Галимжан?

—Әнә, казлар...

Хәнәфи берәр юньсез бәбкә тапталгандыр дип исәпләп чыраен сытты һәм, кабина тәрәзәсеннән башын тыгып:

—Кырып бетерәсе затлар!—дип кычкырды.—Берәрсе чәнчелдеме?

—Юк,—диде егет юаш кына.

—Ни булды соң?

—Очалар,—диде Галимжан, казлардан жемелдәгән күзен ала алмыйча.

Казлар чыннан да дәү, ак канатларын жилпеп-жилпеп жил унаена йөгереп бардылар да келәтләр тезелешкән атаудан аерылып үзән өстенә һавага күтәрелделәр: һава чуп-чуар булды!

—Моторынны ник сүндердең?

—Тавышларын тынлыйм. Ишетәсеңме, очканда гына шулай кангылдашалар бит алар! Кыр казлары дип белерсең!

Хәнәфи йон баскан кыска муенын кашып алды:

—Бодай тыгынганнар да очалар! Ул Мифтахетдиннең муенын борасы бар! Себереп ал дим, иренә!.. Казлар симергән, шаярасылары килә.

—Симезлектән очмый алар, Хәнәфи абый,—диде егет, сокланып.—Ерак-ерак бабаларының кыр казлары, ирекле кошлар икәнен оныта алмыйлар! Каннарында бәйсезлекне, күк биеклеген тою уяна! Жилләр белән көч сынашалар алар!

Хәнәфи оеп утырган жылы урыныннан ялт кына калкынды, житү сакал-мыекларын кул аркасы белән ышкып алды.

—Нәрсә, нәрсә диден әле син?

Галимжан йөкчесенен ни әйтергә теләвен бик яхшы анлады, дөнья, табигать, яшәү кануннары хакында сүз чыкканда алар еш кына әләгешәләр иде, шуна күрә Хәнәфинең соравын уенга алды:

—Әйттем дә оныттым, Хәнәфи абый!

Бүген Хәнәфи белән тәмсезләнәсе килми иде аның... теләсә ни уйласын!

Казлар үзән өсләп очып үттеләр дә арьякка, әрәмә кырына ук барып кундылар. Галимжан жинел сулап куйды: шактый ара үтте казлар! Кузгалдылар. Такырны артта калдырып үзәннән бара башлагач, машина тагын шып туктады. Рәхәт ойый башлаган Хәнәфи йокы тиз эленгән күзләрен көч-хәл белән әйләндереп тагын сүгенде:

—Яп-яланаяк, нишлисең син? Ятьрәк ташып бетерик тә якты күздә өйгә ычкыныйк әле бүген.

Шофер ияге белән унга ымлады. Тегермән ягыннан килгән тар сукмакта кабалана-кабалана берәү бу якка таба атлый иде.

—Рәисме?—дип сорады нигәдер пышылдап Хәнәфи.

—Үзе.

Хуҗалар белән очрашудан һәрчак ниндидер хәвеф көткән йөкче ипи калагы төсле эре, саргылт тешләрен күрсәтеп ачуланырга тотынды:

—Ни шайтаныма кирәкте әле ул сиңа? Шыпан-шыпан гына ташып бетерик тә сызыйк инде. Үз юлыбыз, үз эшебез.

—Туктарга кушып кул изәде.

Колхоз былтыр гына «Москвич» машинасы сатып алган иде. Гадәттә бер дә машинасыннан төшми торган председатель Шәйхулла, урак өсте җиткәч, әллә нишләде. «Москвич»ын калдырып җәяү генә чыгып китә дә юл уңаенда туры килгән машиналардан файдалануны артыграк күрә иде. Эреләнми, атка да утырып китә! Шәйхулланың бу гадәтен белеп өлгергән Хәнәфи, малай-шалай сыман тузанлы әрҗәдә аунап барырга туры киләсен уйлап, Галимҗанны әрләргә тотынды.

—Күрмәмешкә салышып ычкынасы да бит, үз акылыңны биреп булмый. Тинтәк!

—Галимҗан,—диде Шәйхулла, исәнлек-саулык алышканнан соң,—сезнең янга ашыга идем. Семенаны кичкә ташып бетерәсезме?

Егет тын гына һаман казларны күзәтә иде, аерылмады, борылмыйча гына баш какты.

—Бик әйбәт,—диде шуны гына көтеп торган Шәйхулла.—Алайса, миңа шул, бодай төяп төнгә Зәйгә чыгасыз. Удар бишкөнлек игълан иттеләр!

—Ярар,—дип Галимҗан шунда ук ризалыгын бирде.

—Эшне тизрәк очлыйк дисәң, миңа Хәнәфи абыйны да ияртерсең.

Галимҗан сүзне беткәнгә санап кулын тормозга сузганда, Хәнәфи аның уң беләгеннән эләктереп алды:

—Бәләкәй генә сабыр ит, энем... Миңа да барырга кушуың булдымы, Шәйхулла? Удар бишкөнлек игълан итүләре калхуз өчен үтә дә шәп анысы! Бодайны алып барырга кирәк, анысы хак. Хәтта ки, бик кирәкле эш! Тик үз хәлемне әйтәм: Зәйгә чыгып китә алмыйм!

Рәиснең йөзе кырысланды:

—Нигә?

—Соң, Шәйхулла, уракка чыкканнан бирле гел машинада! Басу белән келәт арасыннан кайтып кергән юк! Бүген симәнәләрне салып бетергәч, әзрәк әл-хәл алып, мунча чабынып, кырынып, бераз адәм сурәтенә керерменме әллә дигән идем. Ипидер миңа, катын янына ятырга оят!

Шәйхулла Галимҗанның кардай ак күлмәгенә төртеп күрсәтте:

—Күзең бар ич, күр! Синең белән бергә йөри! Әле иртәрәк тора, соңрак кайта. Машина арасында урала! Ә үзе күкәйдән бүген ярылып чыккан чеби кебек чеп-чиста!

Хәнәфинең ансат кына бирешергә исәбе юк иде:

—Егет кеше лә ул! Ак күлмәгенең дә бер-бер хикмәте бардыр, Зәйгә барам дип кимәгәндер. Атлыгып торалар ди бераүләр... Бишкөнлекләр әнә-әү күпме булды инде безнең гомердә! Аннары, Галимҗанга аңа нәрсә? Мокыт бит ул, җиде камыт кидерсәләр дә тарта торган нәмәрсәкәй! Җене өзелсә дә, теле аркылы килсә дә дәшмәс ул, тартыр!

Галимҗанның сабыры бетте, ул шап иттереп машина ишеген япты, газ бирде. Кузгалдылар.

—Кая шул хәтле куасың?

—Үзең тизрәк бул дидең ич, Хәнәфи абый.

—Бая әйткән идем шул... Хәзер кусаң ни дә кумасаң ни! Ике чабата бер кием!.. Калхуздан, колхоз рәисеннән игелек көтсәң, икенче көнне үк тәпи сузарсың.

Хәнәфи тәмәке кабызып, таракан кырырлык зәһәр төтенен йота-йота үзе белән үзе сөйләшеп бара иде. Ул шоферга чынлап торып ачуланган иде, тик кайсы яктан чеметергә икән дип җай эзли иде.

—Казлар нигә оча дидең әле син?

—Ирекне сөеп, бәйсезлекне тоеп дигән идем.

—Шул шул миңа! Казлар булып алар да ирекне яраталар, ара-тирә булса да күккә менәләр, телсез мәхлуклар! Ә синең кебек сары бәбкәләр

авыз ачарга да куркып утыралар! Шәйхулла күренүгә тормозларыгыз бушый, тотмый башлый! Егетлек юк синдә, энекәш!

Галимжан бүген Хәнәфи белән ачуланышмаска, сүзгә кермәскә тырыша иде, бу юлы да мөмкин кадәр сабыр булырга тырышып җавап бирде:

—Син өндәгән нәрсә, Хәнәфи абый, егетлек түгел. Кирелек аның чын исеме. Дөрес әйтәсең, анысы миндә юк. Мәгънәсезгә тәртәгә тибүне җенем сөйми!

—Син бер булса да тибеп күрсәт! Нигә без һаман-һаман үшән ат сыман тәртә арасында йөрергә тиеш? Үз хакыңны хаклап сүз әйтерлек чама юкмыни синдә?!

—Ә егетлеккә килгәндә,—дип дәвам итте Галимжан,—аны тыр-пыр итеп күрсәтеп йөреп булмый.

—Ә син аны күрсәт, күрсәт!—дип бәйләнде Хәнәфи.

—Кешеләр дә кайвакытта казлар сыман биеккә күтәрелә, Хәнәфи абый.

—Күрсәт син аны миңа, күрсәт!.. Шалишь, калхузчының канат әллә кайчаннан киселгән. Эх, йомран баласы! Курай чыжтырдаса да өненә кереп сеңә торган нәрсә!

Егетнең сабырлыгы Хәнәфинең ачуын һаман дөрләтә иде. Ул алай итеп тә, болай итеп тә рәт чыкмагач, гади генә әйтеп куйды:

—Сон, апаң мунча ягып көтеп тора. Бәлеш салган булырга тиеш. Алган яртым мич артында балкып утыра булыр...

—Күптән шулай диләр аны!—Егет яңгыратып көлеп җибәрде.—Мунчаңа да барырсың, Хәнәфи абый, өлгерерсең! Зәйгә үзем генә чыгып китәрмен.

—Ә яртыны кем белән эчәрмен?

—Үзең генә!

—Бер башым аракы чөмереп утырырга син миңе, теге кем, саран Гаптери дип белдеңме әллә? Мин бит шешәне синең белән икәү бөкләргә дип аларынып алган идем.

—Нигә минем белән?—Егет шулай дип сорады да оялды һәм кызарынып өстәп куйды.—Эчәсем килми.

—Кайчан исә бер башларга кирәк ич!

—Исәп башламаска.

—Тел сөйли ул! Безнең тормыш—...кырмыш, үзеннән-үзе эчертә! Әле яшьлек тилелеге белән сайрыйсың! Барыбыз да бер төсле, бер калыпта сугылган.

—Бер төсле түгел!

—Әй!..

Йөкче сүгенеп йонлач кулын селкеде.

Юка тузан өертеп олы юлдан бардылар-бардылар да борылып басу өстенә керделәр. Тигез кыркылган бодай камылларын сытып аркылы-торкылы машина, комбайн эзләре сузылышып яткан. Ике-өч җир буе киткәч, Галимжан унга каерылып яңа эз салып бара башлады. Бераздан алар чәчелмичә калган буш җир кырына барып туктадылар.

Өй урыны кадәр генә өчпочмаклы кишәрлектә котырынып чүп үлән үскән. Сары, ак ромашкалар, ипи чәчәкләре, шартлавыклар, билчән-шепкәннәр бергә-бергә җилдә рәхәт чайкалышып утыралар. Бодай арасында җәй буе интегеп утырган чүп үләннәр иркенгә чыкканнар!

—Нәрсәгә алып килдең син монда?—диде Хәнәфи ярсып, калкынып.

—Күрәсеңме, Хәнәфи абый?

Бодайны Хәнәфи үзе чәчтергән иде. Галимжан шуны онытмыйча, төпченеп, казынып йөриме әллә?..

Һәм Хәнәфи күкерт шикелле кабынды:

—Син, энем, бармагыңны минем күзгә төртмә! Белдеңме? Кеше эшеннән гаеп-кыек кына эзләргә торалар. Сәхра кадәр басуда песи учы хәтле җир чәчелмичә калган икән, синеке кимедеме әллә?

—Мин аны әйтмим, Хәнәфи абый... Күр әле, дим, нинди матур чәчәкләр!

Хәнәфи иренеп кенә карап тора иде, башын чайкады, авыр сулап әйтеп куйды:

—Чүп-чар диген, әкәмәт! Нинди чәчәк булсын ди.

—Чүп-чар түгел!—диде кызып егет.—Һәммәсенең дә исе, төсе, исеме бар аларның. Тик без белеп кенә бетермибез. Менә бу кырыйдагылары күзлут дип атала.

Йөкче мәзәк кенә пырхылдады:

—Урыны бәләкәйрәк, чабып алганда, ярыйсы булыр иде. Күзлутмы, чузлутмы, сыерга аңа барыбер, бөтерә дә тыга! Шәйхулладан курмыны барыбер бик каера алмассың.

—Ә менә шушы чәчәкне беренче тапкыр күзлут дип атаган кешегә барыбер булмаган ул, Хәнәфи абый!.. Ә син кешеләрне бер калыпка сугалар, дисең! Алай түгел бит... Бик күпләр чүп дип йөрткәннәр, йөзләр, меңнәр уйлап-нитеп тормаган, шуны кабатлаган, ә берәү тоткан да «күзлут!» дип исем биргән. Безнең борынгы бабайлар үләнне «ут» дип йөрткәннәр. Шуннан утар, утлык, утау сүзләре калган. Атлар утлап йөри дибез икән, бу инде бахбайлар үлән ашыйлар дигән сүз була. Күзлут—күз кебек үлән. Чыннан да, зәңгәр күзгә охшаган бит чәчәкләре?

Хәнәфинең тирән чокырларда утырган күзләре туктаусыз елтыраштылар, ул борын яфракларын киереп һава сөзде:

—Чәчәген белмим, әмма ачы бал исе килә! Берәр җамаякны түңкәйтеп җибәрергә диген син! Мунчадан соң, ә? Менә булыр иде эш!

Машина тагын җәлт кенә кузгалды. Киттеләр. Тәгәрмәчләр сары камылларны чыштырдатып күңелле генә тәгәриләр. Унда, Кырынды тавы өстендә, тракторлар борчак җирен сөреп бетереп киләләр. Җил. Коры тузан уйнап тора.

—Ә син боларны каян беләсең?—дип сорады Хәнәфи бераз баргач.

—Укыдым.

—Шундый гыйлемлегең булгач, нигә колхозда изаланасың?

—Изаланмыйм, эшлим.

—Таптың эш! Теләсә кем теләсә кая куа. Сәгате-минуты язылмаган, их, синең урында булсаммы мин!.. Төкерер идем авылга. Тормышмыни бу, яшәүмени? Шәйхулла типкесендә йөр инде. Сәнәктән көрәк булган нәмәстәкәй!..

Галимҗан баягы сөйләшү кузгаласын ачык тоеп сүзгә катышмады.

—Яши белмисең... «Саный белсәң, саесканның коерыгы—уналты», дип әйтә иде минем әткәй мәрхүм...

—Нигә санамадың соң, Хәнәфи абый?

—Җүләр булганга! Менә синең күк чакта акыл бирүче булмаган. Тотып ярган булсалар, аңлаган булыр идем, мөгаен! Хәзер инде соң. Гомер үтте. Күләгә булып, шәүлә булып, сүзсез-өнсез сарыктай яшәлде...

Хәнәфинең үзалдына сөйләшә торган гадәте барын белә иде Галимҗан. Ул аны тыңламыйча акрын гына үз уйларын уйлый иде. Аның уйлары да шактый күңелсез, очсыз-кырыйсыз иде бүген.

Чәчәкле кишәрлекне төнәген үк күреп киткән һәм сокланып үткән иде Галимҗан. Төнәген үк аның башында бер план да төзелгән иде. Семенаны ташып бетергәч, эштән соң, туп-туры шушында килергә һәм бер кочак кыр чәчәкләре җыеп алырга иде аның исәбе... Бик кирәк иде аңа бу чәчәкләр. Бик кирәк! Ак күлмәкне дә юкка гына кимәгән иде ул. Соңгы рейстан өенә дә кереп тормаска иде аның исәбе. Тик менә соңгы рейс булмаячак. Аның урынына бодай төяп Зәйгә чыгарга кирәк.

Бәлки Галимҗан чыннан да куркактыр? Мокыттыр? Киреләнсә, карулашса, йә булмаса чиргә-сырхауга сабышса, мондый көнне (бүген алар семенаны ташып бетерәләр бит!) Шәйхулла артык кысмас та иде. Дәүләткә дигән ашлык та ташылып бетеп килә. Бер машинадан ни була?

Иртәгә кадәр бу чәчәкләр торырмы-юкмы? Хәзер печән бик кадерле, берәрсе чабып култык астына кыстырып китсә? Иртәгә тагын берәр мәшәкать килеп чыкса? Чыннан да Галимҗанның көннәре, гомере, Хәнәфи абыйсы әйткәнчә, нәкъ башкаларныкы сыман ук төссез, чырайсыз үтеп китәрмени? Эш, тагын эш, тагын эш...

Хәнәфи һаман үзенекен сукалый:

—Әйтик, менә бүген, нигә ризалаштың инде?

Чыннан да, нигә ризалашты әле ул?.. Тик бу сорау да аның күңелен тулаем биләп тора алмады, егет һич тә көтмәгәндә Хәнәфигә борылып сәер генә сорау бирде:

—Ә синең, Хәнәфи абый, айлы төннәрдә, апрель азакларында кыр казларының каңгылдашып килүләрен ишеткәнең бармы? Алар биектә-биектә авыл өстеннән үтеп китәләр!..

Йокче эндәшмәде, кабина тәрәзәсе аркылы лач итеп төкереп куйды. Ул аптырашта иде. Ни булган бу малайга? Сүгәсең, ачуланасың, тик утыра. Элек келәт, иген тирәсендә кош-корт күрсә, «колхоз икмәген әрәм итәләр» дип пошына иде. Чүп үләннәр үскән бу ызаннар очрый калса, «бу җәфалар күпме орлыкларын биреп калдыралар инде!» дип зарлана иде. Бүген әнә әллә нишләгән...

Башка вакытта ындыр табагына барып җиткәнче рәхәт кенә черем итә торган Хәнәфи бу юлы пошыргаланып, борчылып утырды. Беләсе дә бик килә иде, сорарга да унайсызланды. Нәрсә булды икән?

Моннан ары алар телгә алырлык сүз сөйләшмәделәр. Егет таркау һәм уйчан, Хәнәфи турсайган һәм хәтере калган иде.

Семенаны кечкә кырын соң гына ташып бетерделәр.

Районга кузгалганчы, ин элек өйгә кагылып чыгарга кирәк иде. Йөк белән өйгә кайтырга яратмаса да, Галимҗан бүген кереп чыгасы итте.

Хәнәфиләр турысына җитеп аны төшереп калдыргач, Галимҗан җиңеләеп киткәндәй булды, машина тыелып торган арала сиздермичә генә, әмма ниндидер яшерен өмет белән йөкчесенең өй тәрәзәләренә карады. Җил булганга, тәрәзәләр нык ябылган иде, өйдә хәрәкәт сизелмәде. Болдырга чыгып килүчесе Хәнәфинең озын, матур хатыны иде, ахрысы. Өй ягыннан бәлеш исе дә килгәндәй булды, егет көлемсерәп Хәнәфигә кул болгады һәм машинасын урам буйлап алга куды.

Өйгә кайтып аяк өсте генә капкалады, баздан сөт алып чыгып, ишкелетүрле мыраулап йөргән песигә салды. Салкын, дымлы чүлмәкне күтәреп үзе дә сөт эчте. Өзелеп карыны ачкан икән, рәхәт булып китте.

Эш бетте. Ул аскы иренен тешләп урам коймасы янына килде һәм түбән очка, яна гына үзе кайткан урамга карап тора башлады. Әнкәсе кайтырга иртәрәк шул әле... Кинәт ул үзенең бөтенләй әнкәсен көтмәвен, өйгә кайтуының максаты да аны күрү түгеллеген, хәтта аның турында уйлап та карамавын, күңелен бөтенләй башка кеше, үзгә уйлар тетрәтеп торуын аңлады.

Ни аяныч! Вакыт үткәреп өйгә кайтып йөрүнең һич кирәге калмаган иде бүген, тамагын элеватор буфетында да ялгый ала иде, ул тәкатьсез көтеп алган кичтә өметләр акланачак түгел, сабырсызланып, гасабиланып көткән кешесе күзгә-башка күренмәячәк иде! Ничек күрешсеннәр ди, ул да кеше кешесе, үз ихтыярында түгел, хәзерге минутларда җәйләүдә сыерлар савып, эшен бетереп йөридер. Галимҗан авылдадыр дип күңеленә дә китерми торгандыр! Аның эше бетүгә, егет машинасы белән җәйләүгә барып җитәргә тиеш иде! Кабинасында бер кочак хуш исле кыр чәчкәләре булырга тиеш иде аның: ромашкалар, ипи чәчәкләре, күк күзләр, күзлүтләр. Кыз чәчкәләрне күреп гаҗәпләнергә, кабина ишегеннән ачуга: «И-и, монда мина урын да калмаган икән!» дип кычкырып җибәрергә тиеш иде...

Егет авырттырып тешләрен кысты, әйе, алар бүген таш яуса да очрашырга тиешләр иде! Очрашырга һәм аңлашырга!

Дөрес, монарчы да алар күрешми тормадылар. Бер авылда яшәп, бер урам-тыкрыклардан йөргәч, очрашмый каласыңмы соң? Аңлашырга җайлы вакытлары да булмады түгел, тик Галимҗан аның белән аңлашуны ниндидер олы, тиңдәшсез зур, мөһим эш итеп күз алдына китерә һәм ул минутларны гомергә онытылмаслык итәргә омтыла иде. Юк, Хәнәфи абый, кешеләр ахыр чиктә бер калыпка сугылмаганнар! Һичьюгында бер тармакта булса да кеше үз казанында кайнап пешә! Кеше дигәнең инкубатор чебеше түгел, башка күп җәһәттән алар бер-берсенә охшасалар да, күңел ягына килгәндә адәм уллары үзгәлеккә омтылырга тиешләр!.. Кешенең хет күңеле буйсынмыйча

ирекле калсын! Хет бер ягы белән бүтәннәрдән аерылып торсын! Галимҗан шулай уйлый иде. Шуңа күрә егетнең кызга мөнәсәбәте тирән сер иде, күңеле серенә ул үзе, бер башы гына хуҗа иде. Ул башка бик күпләр кебек уртага яртыны куеп кызлар турында шалтырарга яратмады. Аның күңел капкасы бүтәннәр өчен ябык, бикле иде. Бүген ул шул капканы киң итеп ачарга һәм аны күңел түренә чакырып кертергә тели иде. Егет күңеле мөлдерәмә тулган һәм бүген чайпалырга тиеш иде...

Ә Зәйгә бармаса? Таңнан, карангыдан чыгып китә ала ич ул!.. Ана бер сүз дә әйтүче булмаячак. Айлар, еллар буе сүз тыңлап, бер карышусыз эшләп йөргән егеткә кем базып сүз әйтә алыр?!

Бару-бармау мәсьәләсен хәл итүдә ул ирекле диярлек иде. Әнә шул ирекне тою аны юлга ныграк этәрә, тик күңеленең кайсы чирегендәдер туган икеләнү божрасын тиз-тиз өзеп ташлый алмау гына аны сәерсендерә иде. Хәнәфи абыйсының усал хөкеме борчыдымы аны? Яп-яшь Галимҗан Шәйхуллага башын биреп аның ишегенә әйләндеме? Кем белсен!

Егет Шәйхулланы ярты сүзеннән аңлады. Менә бу иртәдән бирле котырынган җил тикмәгә түгел, аның артыннан ияреп яңгырлар килә. Ә яңгырлар бер башланса, районның иң кырыена урнашкан авылдан Зәйгә үтеп йөрүләр, ай-һай! Юллар бик начар шул әле, бик начар! Юлларның рәтләнер исәбе дә күренми!.. Һәм Галимҗанның күңеленә ят бер уй кагылып үтте: кайсысыннан ныграк курка Шәйхулла—яңгырданмы әллә район игълан иткән бишкөнлектәнме?.. Район башлыкларыннан ныграк шүрлидер рәис, менә аны кеше кешесе дисәң дә ярый!..

Ни генә булса да, яңгырлар тоташтан шәбәергә керешкәнче, иген үз урынында, коры амбарда булырга тиеш. Галимҗан шуны белә, шушы кагыйдәгә башын бирә...

Ә мәхәббәт? Ә якты хыяллар? Ичмасам мәхәббәттә булса да үз-үзенне табарга тырышулар?.. Галимҗанга да башкалар кебек ашык-пошык кына, йә эш арасында, әйтик, клубтан кайтканда, капка баганасын саклап кына аңлашырга туры килерме? Алай икән, апрель азакларында кыр казларын нигә тетрәнеп озаткан ул, кыр чәчкәләренең матурлыгы алдында нигә телсез калган? Күңелендәге иң якты теләкләр, иң сихерле сүзләр шул аңлашу вакытында телгә килерлек булмагач, нигә ул егет исемен күтәреп йөри?..

Мотор теләр-теләмәс кенә кабынды. Урам буп-буш иде. Тик ниндидер мәгънәле серләр яшергән кебек буш иде. Җил тузан уйната, түгәрәк өермә ясап ындырларга, бәрәңге бакчаларына кереп китә. Тузан машинага кара коерык булып тагылып уйнаклап бара. Кабинага керә, егетнең ап-ак якасына куна, күлмәген каралта. Каралсын, инде хәзер барыбер. Алда юл, алда мәшәкатьле төн, алда Зәй, алда ялыктыргыч ялгызлык...

Кемдер аның исемен яңгыратып кычкырган кебек булды. Ул колагы белән ишетүдән бигрәк күңеле белән сизенеп як-ягына каранды һәм Галәмәйләр тыкрыгыннан чыгып килүче аны күрде. Ул ап-ак күлмәк кигән иде. Йөгергән, ахры, йөзе, колаклары бурлаттай яна.

—Галимҗан абый! Уф...

Егет үз күзләренә үзе ышанмыйча машинасы белән бергә дерелди, калтырый иде.

—Мине дә Зәйгә утыртып бар әле, Галимҗан абый.

Зәйгә? Каян белгән ул аның Зәйгә барасын? Монда ничек килеп чыккан? Нигә мондый ап-ак өр-яңа күлмәк әле аның өстендә?..

Һаман телгә килә алмады егет, сүзсез генә кабина ишеген ачты, утыргычны учы белән кат-кат сыпырды. Кыз утырып киң итеп сулыш алды, җәһәт кенә чәчләрен рәтләде. Кузгалдылар.

—Галимҗан абый, син безнең турдан үтмә инде, яме,—диде кыз оялып кына.

Егет шунда ук борылып тыкрыкка керде һәм ындыр артлатып олы юлга чыкты.

«Олы юлга!» дип уйлады да Галимҗан әсәренеп китте.

Аның белән!

Янында ул утыра!

Кыз ярым көлемсерәп егеткә күз ташлап ала һәм, аның уйларын аңлаган кебек, бер сүз дә эндәшми. Икесе дә күрешү кинәтлегеннән исәңгерәп шактый вакыт сүзсез бардылар. Тик гел-гел болай барып булмый ич инде, нидер сөйләшергә дә кирәк! Икесе дә моны аңлыйлар, йөрәксенеп сүз башларга гына базмыйлар иде.

Эштән кайтучылар, юлаучылар аларга борылып-борылып карап калалар иде. Ап-ак күлмәкләр киеп, әрҗәгә бодай төяп кая баралар болар? Ул Хисами Галимҗаныннан әллә ни көтәргә була, юаштан юан чыгар, диләр булыр, аны күрүгә күзләрен тасырайталар. Бәлки әнә шул ят күз карашлары аларны ятсындырып, телләрен бәйдә тотадыр? Юк, анысына да артык исләре китми иде аларның, ахрысы...

Кечке монсу төтеннәре, куанычлы ыгы-зыгылары белән авыл артта калды, өянкеләр мул бизәгән Сай чокырны да үттеләр һәм икесе дә сүз берләшкәндәй җинел сулап куйдылар.

Сүз үзеннән-үзе килеп чыкты, ялганды.

—Син бик арыгансыңдыр инде, Галимҗан абый,—диде кыз, ана җылы карап.

Егет баранкасын кысыбрак тотты:

—Ә үзен, Сөмәя?

—Мин бүген армадым! Юк, кая ди ару!—диде кыз, кабаланып.—Армадым!

Егет өчен бу сүзләр кадерле иде. Кыз бүген диле бит! Ул аның таңнан торып кичкә хәтле ниләр эшләгәнен күз алдыннан үткәрде: мәшәкатьле авыр хезмәт ул сыер саву! Ә ул, әнә, армаган! Аны көткән!

Кызның ничек итеп үзен көткәнне генә белә алмый иде Галимҗан! Чөнки кыз әбәд вакытында ук егетнең килә алмавына, икмәк төяп Зәйгә чыгасын ишеткән иде инде. Шуның өчен иптәшләре аның кичке савымын бүлешеп алдылар, ул беренче туры килгән машина белән авылга кайтып җитте. Алар бүген һичшиксез очрашырга тиешләр иде!

—Юл әйбәт,—диде кыз.

Егет бу сүзләрдә үзенә теләктәшлек, якынлык, җылылык сизде. Шофер өчен юл—ярты гомер дигән сүз...

Аннары бүген сүзләр авыздан чыгуга ук яңачарак мәгънә алалар иде. Сүзләр генә түгел, юл да, күнегелгән тирә-як та икенчерәк, катлаулырак һәм серлерәк иде бүген. Авылдан шактый ерагайгач, бәләкәй, юаш тауочыкта сураеп утырган җил тегермәне турына килеп җиттеләр. Күз ияләнгәнгә, кайчагында күрмичә дә үтеп китә торган иде аны ул. Ә бүген тегермәннең япа-ялгыз икәнлеген дә, сукмагын үлән басуын да, канатларының җилләнгырда калшаеп, сәлперәеп салынуын да ап-ачык күрде. Гаҗәп: кыз да тегермәнгә текәлеп бара икән!

—Нинди дәү һәм мескен безнең җил тегермәне!—диде ул уйчан гына.

—Картайган инде.

—Урын алып кына тора. Ник сүтмиләр икән үзен?—дип сорады кыз. Әмма, тавышында шушы тегермән хәрәбәсен кызгану аһәннәре яңгырады.

—Кемнең кулы барсын? Беркемнең дә сүтәсе килми. Сугышка киләр әллә кайчан җиткергәннәр аны. Салучы осталар да, тегермәнче дә әйләнеп кайтмаган. Истәлек! Авылдан җитмеш биш кеше үлеп калган. Безнең авылда аларга бүтәнчә һәйкәл юк та диярлек... Алар салган өйләр тузган, яңаларын, ара-тирә, уллары, оныклары җиткерә. Ә тегермән, карт бөркет кебек, һаман барыр, кайтыр юлларны саклый...

—Безнең әткәй: «күпме утын череп ята!» ди. Ватып ташларга кыҗрап йөри,—диде кыз, нигәдер әрнеп.

—Юк, Хәнәфи абыйның да кулы бармас! Теле белән әллә ни әйтер, эш сүтүгә барып җитсә, уйлар...

—Биектә утыра...

—Биектә!

—Кызганыч, еллар аямас, үзеннән-үзе череп таралыр инде. Һәйкәл дисен бит, Галимҗан абый.

—Анынчы кешеләр бирәр нәрсә уйлап табар! Житмеш бишәү ятып калган бит!

Тегермән боегып артта калды. Бормаланып-бормаланып аккан тар инешне кичтеләр. Күпер култыксалары да кыйгаеп, җимерелеп беткән иде. Юл тузанлы, тигез диярлек иде. Иренеп кенә караңгы төште. Аның көндәгедән иртәрәк инүен икесе дә сизделәр.

—Менә килеп тә җиткәннәр,—диде егет, күккә ымлап.

—Яңгыр ишә башласа?—диде кыз куркып кына.

—Зыян юк. Брезент йөк өстендә. Хәзер каплыйбыз аны.

—Ә юл?—диде кыз, көлемсерәп.

—Юлны брезент белән каплап булмый.

Кыз тыелып кына көлеп җибәрде:

—Җитмәсме?

—Ана бетон, асфальт кирәк,—дип аңлатты егет.

—Шәһәрдәге кебекме?

—Юньле хуҗалар бар җирдәге кебек. Машиналарны сирәк-сорак кайтаралар, анысы бәлки худка китәр. Асфальтны бирмиләр.

—Кайчан исә бер булыр әле, Галимҗан абый.

—Булыр булуын...

Егет күз кырые белән кызга күз салгалый иде. Сөмәянең житди, олы булып үзен тыңлап баруы ана ошый да, берникадәр сәер дә иде. Алар, чыннан да, икәү баралармы? Янәшә? Зәйгә?! Валлаһи, икәү бит! Алайса нигә көндәгечә эш, тормыш мәшәкатьләре хакында сөйләшә башладылар әле алар? Сүзләр бүтән кирәк иде бит, башка уйлар, башка фикерләр... Каян, ничек табарга шул яшерен, серле сүзләрне?

—Аклы күлмәгенне кигәнсең, Сөмәя.

—Үзең дә, Галимҗан абый.

—Каралды инде. Машина акны сөйми.

—Ак кулны да, Галимҗан абый.

Ничек мине эзләп киләсе иттең, дип сорарга теләде егет. Базмады, бу сорау артык гади иде, кызның дәрәҗәсен, очрашуның бәясен төшерә кебек тоелды ана. Бүген алар очрашырга тиешләр иде бит! Сөйләшеп куйганнар иде!

Машина уты үзенә юл таләп итеп һаман алны ялый, алда җил. Җил тузанны кабинага бөркеп кертә, битләргә, колакларга сибә.

—Җил!

—Җил, Галимҗан абый. Бүген урман көне буе гөжләп торды. Чыгам да тыңлап карыйм: гөж-гөж итә. Туктаусыз гөжли. Машина тавышы дип әллә ничә кат алдандым. Күккә карыйм, кояш әле әнә кайда-а!

—Җил!—диде куанып егет.

—Яңгыр китерер микән?

Кызның соравына җавап биргәндәй, кабина тәрәзәсенә беренче эре тамчы килеп сыланды.

Егет шундук машинасын туктатты, җәлт кенә кабинадан чыкты да әрҗәгә сикереп менде. Кабалана-кабалана брезентны җәя башлады.

Сөмәя башын ишеккә тыгып ана карап тора иде.

—Чыкма, чыкма, чыланасың!

—Ява бит, Галимҗан абый!

—Ява!—дип, нигәдер шатланып кычкырды егет өстән.

—Ничек шыбырдый,—диде кыз, учын яңгырга куеп.

—Ужымнарга дым кирәк иде,—диде егет, кабинага кереп утыргач. Аның чәчләре чыланып маңгаена сыланган, үзе яшәреп, малайланып калган иде.

—Кырынды өсте иртәгә күпереп үсеп чыга инде.

—Тормыш шундый. Яшәрергә, орлык бирергә тиеш.

—Тоташ яңгырга әйләнеп китмәсме?—дип сорады кыз.

—Әле иртәрәк!

Егетнең тавышында шундый тирән ышаныч, ныклык бар иде, кыз кинәт тынычланды һәм алдан да, яннан да коеп яуган яңгырга сокланып

бара башлады. Яңгыр астында юлда рәхәт! Әле ул пычранып өлгермәгән, тузан басылган, тәрәзәдән дым исе, юеш кыр исе, нарат исе кереп тулды.

—Кашка тау турысына килеп життекме әллә?

—Таулар,—диде егет уң якка ишарәләп.

—Син күрәсенме аларны, Галимжан абый?

—Күрәм.

Кыз да караңгыга текәлеп карады. Яңгыр тоташ стена булып коя иде. Тик шулай да караңгылык арасыннан ул нарат агачларының томанлы очларын күргән сыман булды. Үзе исә:

—Ә мин күрмим... Берни дә күрмим,—дип борчылып кабатлады.

Егет үз ягындагы тәрәзәне яба башлады.

—Тимә, Галимжан абый.

—Үтәли жил йөри. Сина салкындыр.

Кызга чыннан да салкынча иде, тик аның кабина эчендә бернәрсәне дә үзгәртәсе килми иде. Ничек булган, шулай булсын! Менә шулай, менә шулай...

—Үтәли жилдән курыкмыйм мин. Салкыннан да.

—Ява!—диде егет, кульяулыгы белән битен сөртеп.

—Яусын!—диде кыз тантана белән.—Ныграк яусын!

Яңгыр тавышыннан бөтен тирә-як жанлангандай булды, караңгылык хәрәкәткә килде, бу үзгәреш, жанланыш шушы кара төндә икәү генә калган юлчыларга ниндидер сөенеч, шатлык өсти иде. Алар шулай эчтән генә куанышып, төнге яңгыр шавы астында, бер-берсенә сыенып шактый озак бардылар.

Тирә-як кинәт тынычланып, гадиләнеп калды. Алар сәерсенеп мотор тавышын ишетә башладылар. Ни булды? Жил көчәйгән иде шикелле, ә тавышлар тынды. Егет елмаеп кызга карады:

—Теләгең кабул булмады, Сөмәя, яңгыр туктады.

—Мина житәрлек булды, Галимжан абый.

—Чыландыңмы?

—Бераз бар!

—Тунарсың инде?

—Тунмыйм, тунаммы соң! Жылы ич бүген!.. Ә һавасы нинди?.. Борынына төреп тыгарлык ди безнең әткәй.

—Ул шулай дип әйтә беләме?

—Сирәк-мирәк!—Кыз яңгыратып көлеп куйды.—Тауларны үттекме әле, Галимжан абый?

—Тауларнымы? Тауларны үтеп булыр иде, алда Тирән чокыр бар әле. Караңгыда дәшми-тынмый гына астан килеп чыга ул! Сагалап тора! Менә аны үтәсе бар!

Кыз егет тавышындагы хафаны аермачык ишетте.

—Шулай бит әле. Истән чыккан. Зәйгә бармаганга да байтак шул. Тирән чокыр ярты юл буламы?

—Ярты юл.

—Шулай рәхәт булып китте, иеме, Галимжан абый?

—Язгы яңгырлар күнеллерәк. Анда ичмасам тамган бер тамчының үлән, иген тамырына сеңүен аңлыйсың. Һәрбер нәни тамчыда көч, тормыш яшерелгән. Ә көзге яңгырлар моңсу, әллә ниләр уйлата...

Яңгыр монда шәбрәк яуган ахрысы. Борылмадан үтүгә, зур-зур жәенке күлләвекләр очрый башлады. Димәк, урта юлга житеп киләләр. Тирән чокырга... Тирәнлеге Сай чокырдан әлләни артык булмаса да, атналар буе кипми торган авыр үзле балчыгы өчен ана шундый исем такканнар. Шоферларның тенкәсенә тия торган әшәке бер урын иде бу. Ел саен нәзек бүрәнәләр тәгәрәтеп яна күпер сугалар, ел саен яз башында тракторлар, авыр машиналар үтеп-сүтеп ул бүрәнәләрне сындырып, чәрдәкләп бетерәләр. Аннары шоферлар жәй буе күпер төбендәге зирек, тал әрәмәсен аяусыз ботарлыйлар.

Машинаның хәле китте, тәгәрмәчләр, машина авырлыгын тигез тота алмыйча, таеп-таеп китәләр иде.

—Чана кебек салулый!
—Үтә алырсыңмы, Галимҗан абый.
—Үтәргә кирәк иде, Сөмәя.
Күпер башына язын бульдозерлар өйгән балчык дымда җебеп аккан, монда аерата уяу булырга кирәк. Галимҗан кайда нәрсә ятканын ап-ачык хәтерли иде. Күпергә хәтле зыянсыз гына килеп җиттеләр, машина киреләнеп янтаеп-янтаеп алгалады, андый мизгелләрдә кыз күзләрен чытырдатып йома һәм егетнең таза беләгенә ябыша иде.
Ниһаять, машина иләмсез янтайды, әче улап тукталды. Көчәнеп алга ыргылып карады, кузгала алмады, тәгәрмәчләр сыек балчыкта сыпкы боламыгы болгатып зыр-зыр әйләнделәр.
—Утырдык,—диде егет, кызга карап. Аның күзләре көлә иде.
—Ныкмы, Галимҗан абый?
—Утырсак нык инде,—диде егет.—Казынтылы, хәтәр урын.
Ул кабина ишеген ачып янтаеп артка карады.
—Күлнең күзенә генә басканбыз. Төшмә, төшмә, Сөмәя.
Егет, чалбар балакларын өскә кайтаргач, чупырдап аска төште. Кыз каерылып аңа карап утырды да, туфля, оекларын салып аның артыннан иярде. Су салкын, җил вак дулкыннар куалап кисеп-кисеп исә иде. Галимҗан кабина артына беркетелгән тимер көрәген алып баткан арткы тәгәрмәчләр янына килде.
—Казырга туры килә,—диде ул, учын төкерекләп. Кыз болганчык судан башка берни күрә алмыйча иелгәләп каранды да, егетнең максатын аңлады, Галимҗан канау казып чокырга җыелган суны агызырга тели икән.
—Көрәгенне алай текә тотма, Галимҗан абый,—диде ул йомшак кына. Күпердән ерак та түгел куаклар караеп утыра иде.
—Балтаң бармы? Ә, Галимҗан абый?
—Шунда, кабинада,—диде егет, еш-еш сулу алып.
Бераздан шатыр-шотыр агач сынганы ишетелә башлады. Егет сокланып карангыга карады:
—Сөмәя, өстеңдә ак күлмәк ич!
—Һей, Галимҗан абый!
Егет казыган тар канаудан су түбәнгә, дамба астына ага башлады, кыз кочак-кочак ботак-сатак китереп торды. Шактый озак азапландылар. Тез тинентен су шәрә балтырларны өшетә, тирләгән аркаларны суык җил үчегеп кыйный иде.
Су күзгә күренеп кимеде, Сөмәя байтак ботакларны тәгәрмәч асларына җәйде.
—Хәзер кузгатып карыйбыз,—диде егет.
—Галимҗан абый, бу юлларны берәр заман рәткә салырлар микән?
—Салырга кирәк иде дә... Тик әлегә мин белә-белгәннән бирле юл төзүче оешмада начальниклар гына алышына! Ә юллар һаман шул килеш!
Агач-магач түшәлгән баткактан машина тиз генә чыгарга ашыкмады. Тәгәрмәчләр ботакларны туздырып, атып-бәргәләп бер урында әйләнделәр. Кыз яланаяклары белән тая-тая ине белән әрҗәне алга этте. Менә тәгәрмәчләр аны сыек сыпкы белән коендырып кузгалдылар, ул бар көченә:
—Китте, китте! Бара, Галимҗан абый!—дип кычкырды.
Машина үксеп-уфтанып кузгалды, күпер өстенә керде һәм үрне менеп җитеп тукталды. Егет кабинадан сикереп төшеп кызны чакырды:
—Монда кил, Сөмәя.
—Бармыйм.
—Нигә?
—Мин сыпкыга, лайга батып беттем, Галимҗан абый.
Егет, эре-эре адымнар белән сикергәләп кыз янына төште, үргә алар җитәкләшеп менделәр. Ут яктысына чыккач, бер-берсенә карашып озак кына көлештеләр.
—Мина ачуланасыңмы, Сөмәя?
—Ник ачуланыйм ди, Галимҗан абый! Шундый күңелле булды, шундый кызык!..

—Монда ерак түгел чишмә бар,—диде егет кыюсызланып.—Юынып алабызмы әллә?

—Кайда чишмә, кайда елга барын син беләсең инде, Галимҗан абый. Хәтереңдәме, мин бәләкәй чакта син бездәй ыбыр-чыбырны җыеп Тугай суына көпшәгә алып барган идең?

—Онытмадыңмыни әле шуны?

—Карыным ачып, кайтыйк инде, дип җылаганым да исемдә... Әйдә, юынып киләбез, Галимҗан абый!

Кыр өстеннән, дөм караңгыда җитәкләшеп бару нинди рәхәт! Төн салкынча, күк аязган, яңгыр юган күкнең кара шәленнән йолдызлар тамарга тора. Аяк астындагы юеш үләннәрне кабартырга тырышып җил йөгерә.

—Чишмәгә еракмы әле?

Кызның зур ачылган күзләреннән якты нур ага.

—Менә монда, чокырда.

Алар җитәкләшеп төшә башладылар, егет таеп шуа башлаган иде, яланаяклы Сөмәяның кулларына тотынып калды. Эре-эре яфраклар белән капланган чокыр төбендә тонык кына кара су елтырый иде.

—Менә ул!

—Бу бит Хәйри кизләве!

—Әллә килгәнең бар?

Кыз сүзсез генә ым какты.

—Шушы чишмә янына агач утыртырмын дип йөрим, һаман өлгерә алмыйм.

—Алайса бергәләп киләбез! Мине дә алып килерсеңме, Галимҗан абый?

—Минем бу ярларга өрәңге, имәннәр утыртасым килә. Нык агачлар. Озак үсә алар, ләкин мәңге утыралар. Юын, Сөмәя.

Кыз су өстенә иелде дә озак итеп тавышсыз карап торды:

—Галимҗан абый, кара әле, йолдызлар!

Су өстендә кызның дерелдәп торган тонык күләгәсе белән янәшә сансыз-исәпсез йолдызлар тирбәлә иде. Ул куш учлап су чумырып алып шаяра-көлә юына башлады. Егет аннан күзен аера алмыйча текәлеп карап тора иде. «Менә хәзер, менә хәзер!» дип типте аның йөрәге. Ул юынып кына бетерсен дә... Менә хәзер... Үзендә ниндидер аргынлык сизеп, егет сөзәк ярга утырды. Кыз, чишмәгә иелгән килеш, ана борылып карады.

—Нинди салкын, юеш яфраклар.

—Ә син аларның исемнәрен беләсеңме?

—Белмим.

—Үги ана яфраклары дип атыйлар аларны.

—Нигә икән, Галимҗан абый?

Егет, кулында үги ана яфракларын бөтереп, сөйләп бирде:

—Ул исемне тапкан кеше шагыйрь булган... Гомумән, безнең бабайлар шагыйрь булганнар алар! Күккә караганнар да Киек каз юлы дигәннәр. Тимер казык йолдызын белгәннәр. Җиргә караганнар да менә шушы ин төссез,салкын чокыр яфракларына Үги ана исемен биргәннәр.

—Сәер исем...

—Бу үләннең чәчәге яз башында, кар китүгә үк чыга. Кайбер авылларда аны умырзая дип тә йөртәләр. Бездә кимәшә башы дип атыйлар. Кимәшәсе нидер тагын, яздыр, мөгаен.

—Күргәнем бар! Чәчәге сап-сары була, яр буенда сибелеп утыра.

—Чәчәгең ата, ә яфрагы һаман юк. Яфрак белән чәчәк бервакытта да очрашмыйлар. Яфрак үсеп чыкканда, чәчәге беткән була инде.

—Бер дә, бер дә очрашмыйлармы? Кызганыч...

Егет тә, кыз да ниндидер серле мәгънә алган салкын яфракларны җыя башладылар. Яфраклардан ниндидер төче саз исе, ләм исе аңкый иде. Галимҗан үз кулындагы яфракларны кызга сонды.

—Менә!

Алар икесе дә тавышсыз гына көлеп җибәрделәр. Бик, бик рәхәт, күңелле иде. Кайдадыр еракта машина гөжләгән тавыш ишетелеп китте.

—Сәгать ничә икән, Галимҗан абый?

—Белмим, Сөмәя.

Ул көннең озынлыгын уйламас өчен сәгатен өйдә калдырган иде.

—Ишетәсеңме, Галимҗан абый?

—Ишетәм, Сөмәя. Зәй ягыннан берсе кайта.

Беравык тын алырга да базмыйча тынланып тордылар.

—Йөгердекме, Галимҗан абый?

Җир өсләп кенә юлга йөгерделәр.

—Сиңа салкын тимәсме?

—Бүген юк!..

Юлда аларның машинасы юаш кына кәтеп тора иде. Зәй ягыннан килүче машина һаман якыная, гөжләве ачыграк ишетелә.

—Галимҗан абый!

—Әү, Сөмәя.

—Нинди машина булыр бу?

—Ибраһим булырга тиеш.

—Мин аның белән кайтып китәм.

Егет үз колакларына үзе ышанмады:

—Син миңа үпкәләдеңме?

Кыз егеткә сыенырак, аңа иркәләп эндәште:

—Мин бүген бик бәхетле, бик... Тик соң инде! Син әйләнеп кайтканчы әле... Миңа иртәнге савымга өлгерергә кирәк... Аннары көн яктысында бу өс-баш белән кайтып керү дә уңайсыз булыр.

Кызның сүзләре хак, мәгънәле иде. Егет карышырлык дәлилләр тапмады, тик аңа нигәдер бик күңелсез булып калды. Тагын шулай гына, сүзсез-аңлашусыз аерылырлармы алар? Ул нииндидер тирән мәгънәле сүзләр эзләп азапланды. Шул арада теге машина килеп тә җитте.

—Син нәрсә, ватылып ятасыңмы әллә?—диде Ибраһим күрешкәч.

—Юк. Сине көтәм. Менә Сөмәяне утыртып кайт инде син.

—Ә ул каян кайта?

—Киек каз юлыннан!—дип көлде кыз һәм Галимҗанның зур, кытыршы учын үзенең нәни, кайнар кулына кысты.

—Рәхмәт сиңа, Галимҗан абый!

—Хәерле юл, Сөмәя!..

Кабинага кереп утыргач кына, Ибраһим кызның өс-башы шактый юеш, пычрак икәнлеген абайлады һәм, кулындагы яшел яфракларга күрсәтеп:

—Шушы себеркене җыярга килдеңме әллә? Әйт әле, нинди ырымы бар аның? Үзебезнең Чүке буенда да күп ич алар,—дип тезеп китте.

Кыз эндәшмәде, яфракларны күкрәгенә кысты.

* * *

Сөмәя дөрес әйткән икән, яңа көн тугач кына әйләнеп кайтты Галимҗан. Хәнәфиләр турысына җиткәндә, ул ирексездән машинасын акрынайтты. Йорт янындагы бакчада алмагачлар арасына тартылган кер бавында очып китәргә җыенган дәү аккош кебек ак күлмәк җилферди, бакча як тәрәзә төбендә зәп-зәңгәр вазада яшькелт үги ана яфраклары балкып утыра иде. Егет туктап тормады, урамдагы бозауларны, казларны өркетә-өркетә, урам буйлап Югары очка менеп китте.

*Июль, 1961 ел, Ялта.*
*Март, 1964 ел. Казан.*



## Илдус Гыйләҗев

### ТАТАРНЫҢ НӘКЪ ҮЗЕ КЕБЕК...

### Исәнме, Казан!

Алтын Урданың «бер кыйшылчыгы»!—
Синең бер тарих—йөзгә торырлык...
Исәнме, Казан—мең яшьлек бабай,
Синең саулыгың—безнең горурлык.
Акыл утыртыйк, булган хаталар
Калсыннар бары үткән елларда.
Исәнме, Казан—мең яшьлек абый,
Безнең бәйсезлек—синең кулларда.
Күрергә иде синең кочакка
Барлык татарлар килеп тулганын...
Исәнме, Казан—мең яшьлек сабый,
Бар өметебез—синдә, туганым!..

### Сатлыклар эшедер

Безнең халык әле бүгенгәчә
Айный алмый ерак суештан:
Казан ауган чакта күп татарлар
Мәскәү яклы булып сугышкан...
Торыннары монда калгандыр бит,
Яшиләрдер безнең арада.

---

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ *(1946) —шагыйрь; «Җир китабы», «Өмет ае», «Хак сүз» һ. б. китаплар авторы. Азнакай районында яши.*

Йөриләрдер җае чыккан саен
Таяк тыгып безнең арбага.
Кан аркылы күчә бөтен гадәт...
Каплап тора болыт күгемне.
...Мөстәкыйльлек безгә авыр кирә,
Шул сатлыклар эше түгелме?..

## Казан метросы

Ничә әйттек: анда казымагыз!
Тыңламыйсыз безнең ишене.
Үзегез үк хәзер интегәсез,
Метрогыз убыла, ишелә.
Урап үтеп китеп булмыймы соң
Җимерелгән кирмән тирәсен?
... Күпме татар башын салган җир ул,
Кертмәс өчен Мәскәү «тәресен».
Каргыш төшәр, тимик ул тирәгә,
Җанны кыйный гөнаһ зурлыгы.
Үлгәннәрнең анда—горурлыгы,
Саткан-качканнарның хурлыгы.
Ком белән су ишә икән, имеш!
Ялгандыр ул, чынлап карасаң.
... Илсез калган милләт килеп чыгар,
Казан тавын әгәр актарсаң...

## Галәм тулы маймылмы?

Ерак йолдызлардан килеп безне
Өйрәнәләр «озын колаклар».
Арабызда, хәтта, йөри ди бит
Кеше кыяфәтле «кунаклар».
Шулай булгач, ачык аңлашыла
Чыгышыбыз охшаш икәне.
Без маймылдан, диләр... Вәт, хәерсез,
Галәм тулы маймыл микәнни?..

## Буш йөриләр

Кемнәрнедер «алып китәләр» дә,
Кайтаралар, йолдыз күрсәтеп.
Ник соң, кайткач, берни сөйләмиләр,
Куялармы ныклап кисәтеп?
Эх, үземне алып менсәләрме...
Җай табармын, илһам качмаса—
Берәр кызларына гашыйк булып,
Шигырь язар идем ичмаса...

## Күреп белдек

Торгызырга—кирәк бик күп еллар,
Миллионлап корбан өстәсе.
... Илне җимерергә җитә кайчак
Бер исерек, бер тел бистәсе...

## Чатыртау

Гел түбәтәй төсле инде:
Мәртәбәле, ыспай, җыйнак.
Татарның нәкъ үзе кебек—
Үзе биек, үзе тыйнак...

## Яшьләргә бер сорау

Укымышлы була, имеш, яшьләр безнең
Чит бер телне ныклап өйрәнгәчтен.
...Укый башларсызмы әллә туган телдә—
Ят бер телгә ул да әйләнгәчтен?..

## Мәгълүм нәрсә

Җитәкчеләр угры булган илдә
Урлашудан халык туктамас.
Тәртип каян килсен, казый-йодрык
Һәр кадакка тигез сукмагач...

## Язмыш кына гаеплеме?

Торасыз да, язмыш дисез,
Эшләр барып чыкмаса.
Кайчагында оттырсак та,
Гадел булыйк ичмаса.
Бик җиңел ул, ялгышыңда
Чит берәүне гаепләү—
Шулай хасил булмый микән
Әле—рухи гариплэр?
Мин кылган эш—мин кылган эш!
Үзем тотам җавапны.
Суксын... язмыш хөкемен
Куеп торам яңакны.
Минем катнаш белән булгач,
Туры килә түзәргә.
...Кирәктер бит ара-тирә
Үзеңне дә сүгәргә...

## Тутыкмый затлы тимер

Гашыйк ирләр—утта кызган тимер кебек:
Бөген була, сузып, бөгәрләп,
Шундый хәлгә төштем әле мин дә менә
Килгән чакта гомер тәгәрләп.
Сандал белән чүкеч табып ал да, ханым,
Төй туйганчы, тукма, курыкма.
Белеп чүке: төрле хәлгә керсә керер,
Затлы тимер мәгәр тутыкмас...

## Барыбер үтәрмен

Гафу сорыйм синсез үткән елларымнан,
Янәшәмдә син бармаган юлларымнан.
Хәзергәчә йөрим һаман кыенсынып
Син исәпкә алынмаган уйларымнан.
Эзләнүдән бик тә иртә туктаганмын,
Кирәкмәгән ят сукмаклар таптаганмын.
Хак Тәгалә нигә насыйп итмәгәндер,
Яшьлегемдә сине эзләп тапмаганмын.
Соң икәнен белә торып, газапланам:
Җил капкаңны ачарга дип азапланам.
Җиңел булмас: аркылыга суккан такта
Йозле кадак белән ахры кадакланган...

## Мин—боҗрада

Синнән башлана да, сиңа кайта
Минем уйлар.
—Ераккарак китегез, дим,—
Тыңламыйлар.
Синнән башлана да, сиңа кайта
Минем юллар.
—Читтәнрәк урагыз,—дим,—
Тайпылмыйлар.
Синдә башланам да, синдә бетәм,
Божра сыман.
... Бөгелергә Ходай үзе миңа
Боера сыман...

## Гадиләштермә мәхәббәтне

Гадиләштермә син мәхәббәтне,
Авыр аны сөйләп аңлату.
Синең янда булып китү генә
Түгел әле чынлап ярату.
Ялгыз калгач, сагыш эчәсе бар,
Сагынасы—кибеп, тилереп.
Чырагачка калып ябыгасы,
Көнләшүдән шикләр кимереп.
Күзләремнән йокы качасы бар,
Йолдызлардан киңәш сорасы.
Кача-поса барып күрер өчен,
Туксан тугыз хәйлә корасы.
Чәчәкләрне эзләп табасы бар,
Күзләреңә тәңгәл килерлек.
Баштанаяк моңга чумасылар,
Йөриселәр җырлап, тилереп.
Шулай булмаганда, нигә кирәк
Килеп-китеп йөрү, сөйрәлеп.
...Мәхәббәтне зурлап яшәдек без,
Шашып яратырга өйрәнеп...

# Publisistika
# Публицистика

## Әхәт Мушинский

# ҖАН АВАЗЫ

*Язучыларның Македониядә үткәрелгән 68 нче Бөтендөнья конгрессыннан соң туган тәэссоратлар*

—НИ ӨЧЕН Македониядә?!

Македониянең Охрида шәһәрендә 17-24 сентябрь көннәрендә булып узган Язучыларның (ягъни халыкара ПЕН-клубның) 68 нче Бөтендөнья конгрессыннан әйләнеп кайткач, күп кенә дус-ишләр, күрше-күлән дигәндәй, миңа шундыйрак сораулар белән мөрәҗәгать иттеләр. Чынлап та, нишләп соң әле Македониядә?! Ә җавап бик гади: язучыларның—тынычлык илчеләренең!—мондый югары абруйлы форумын (анда бөтен дөньядан 280 делегат катнашты) эре башкалаларда һәм курорт-саулыкханә шәһәрләрендә генә түгел, кем әйтмешли, кайнар нокталарда да үткәрү зарур. Чөнки дөньяның барлык почмакларыннан җыелган алдынгы карашлы язучылар оешмасы вәкилләренең тавышын—нәкъ менә хәрби конфликтлар барган ноктадан торып әйтелгән сискәндерерлек Сүзен киң катлау җәмәгатьчелеге, парламентлар, хөкүмәтләр ишетергә тиеш. Ә конгрессның Охридада үткәрелүе мәсьәләсенә килсәк, ул биредә узган ел ук җыелырга тиеш иде, әмма хәрби-сәяси вакыйгаларның катлауланып китүе сәбәпле язучылар Балкан җиренә быел көз көне генә аяк баса алдылар.

Менә без Македония кунаклары... Республиканың башкаласы Скопле очкыч аланында ук хәрби техниканың күплеге күзгә ташлана—күз күреме җир «кабыргаларына» Америка Кушма Штатлары, Германиянең танып белү билгеләре сугылган самолетлар, вертолетлар, бронетраспортерлар белән тулган. Ирексездән: «Әйе, Балкан җире гомер-гомергә дөньяның болгавыр урыны булган, XXI гасырда да шулай булыр, ахрысы»,—дип уйлап куясың.

Республика башкаласыннан Охридага кадәр, Албания чиге буйлап, ике сәгать ярым эчендә барып җитәргә мөмкин икән, ләкин адым саен блок-постлар куелуга да карамастан, бу юлдан йөрүе бик тә куркыныч һәм хәвеф-хәтәрле дип аңлаттылар безгә һәм таулар, үзәнлекләр аша

---

Әхәт МУШИНСКИЙ *(1951)—прозаик; «Шейх и звездочет», «Записки горбатого человека», «Адаш малай», «Бер тибүдә гол» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

бөтен илне гиздереп башка юлдан алып киттеләр. Шулай итеп, без биш сәгатьлек сәфәр кичәргә мәҗбүр булдык.

Әйтергә кирәк, без моңа бер дә үкенмәдек—юллар күзгә кебек ялтырап тора биредә: җитмәсә, алар әле тауларга үрмәлиләр, әле упкынга төшеп китәләр яки тоннельләргә кереп югалалар. Кыскасы, әкияти гүзәл манзара каршы алды һәм озата барды безне. Ләкин юл өстендә агач-урманнар, хәтфәдәй болынлыклар юк диярлек, кая карама—таулар да таулар... Яссу калкулыклар итәгендә исә, кадер-хөрмәт белән үстерелгән йөзем бакчалары җәйрәп ята. Менә без кечерәк кенә шәһәрләр вә карьялар аша үтәбез. Бер-берсенә охшаш итеп төзелгән йортларның күбесе җимерек хәлдә. Чиркәүләрнең бихисап булуы гаҗәпләндерә, анда-санда мәчетләр дә очраштыра. Төнлә белән биек тау түбәсендә урнашкан галәмәт зур хач-тәре бер мәл барыбызны да телсез-өнсез калдыргандай булды—утлар белән бизәлгәнгә күрә ул ерак-еpактан ук күренеп тора иде. Әйе, Македониядә, нигездә, православие дине өстенлек итә. Бу бөтен дөнья христианнарының табыну урынына әверелгән, Европада иң борынгылардан саналучы Охрида күле тирәсендә аеруча күзгә ташлана. Бу тирәләрдә борынгы чиркәүләр һәм монастырьлар—Византия культурасының гүзәл үрнәкләре сакланган. Без килеп төшкән Охрида шәһәре элеккерәк заманнарда Балкан Иерусалимы дип аталып йөртелгән, биредә Охрида шәһәре кешесе Климент тарафыннан Европада беренче Славян университеты ачылган. Охрида сыенып утырган тау түбәсендә борынгы туплары һәм чүкеп ясалган тимер капкалары белән Самуил кальгасы кукраеп утыра. Аннан бераз астарак биш мең тамашачыны сыйдырырлык ачык һавада амфитеатр урнашкан. Шушы югарылыктан шәһәр һәм күл тарафларына биниһая гүзәл манзара ачыла. Ул күлдәге суның чисталыгына, ул сулаган һаваның сафлыгына исең китмәле. Бүгенге көнгә кадәр Европа уртасында шушындый «кеше кулы» тимәгән табигать почмагының саклануына хәтта ышанасы да килми.

886 елда биредә славян мәгърифәтчеләре—Кирилл һәм Мефодийның шәкертләре Климент белән Наум, бик күп җәфалар чиккәннән соң (җитмәсә, фикердәш-арадаш Горазд та һәлак була), алман чиркәү руханилары эзәрлекләвенә түзә алмыйча килеп урнашалар. Аларның теләге—славян язуын һәм мәдәниятен үстерү була һәм нәтиҗәдә шушында ачылган беренче Славян университетында өч мең ярым студент белем ала башлый. Ахыр чиктә Климент мәшһүр әдәбият мәктәбен тудыручыларның берсе була.

Менә шушы борынгы вә бай тарихлы җиргә, гүзәл Охрида күле буена дөньяның төрле почмакларыннан җыелган язучылар, шул исәптән Кирилл белән Мефодийның һәм аларның Охрида мәктәбе шәкертләренең өйрәтмәләренә хөерхаһ кылучы провославие динендәгеләре дә, Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы тарафыннан Россиядә яшәүче барлык халыкларга кириллицаны көчләп тагу сәясәтенә каршы чыгыш ясадылар һәм татарлар үзләренә кулай алфавит сайларга вәкаләтле һәм тулы хокуклы дип, безне бертавыштан яклап чыктылар.

Сүз уңаенда искәртеп үтү зарур дип уйлыйм: минем уйлавымча, Дәүләт Думасы безгә—татар халкына чын кириллицаны түгел, ә бәлки кириллицага нигезләнгән рус алфавитын кулланырга тәкъдим итә. Шушы уңайдан бер тәкъдимем дә бар: кызык өчен генә теләсә нинди җитди, әтрафлы энциклопедиянең «Кириллица» һәм «Рус алфавиты» дигән битләрен ачып карагыз һәм сез утырып уйлар уйлар өчен бик күп гыйбрәтле мәгълүматлар табарсыз.

* * *

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ үз язуын үзгәртеп корырга омтылуы шулай ук зәһәр ниятле иҗтимагый-сәяси буза куптарыр дип кем уйлаган! Үзенең уйларын ак кәгазьгә төшергәндә нинди алфавиттан файдалану һәр халыкның шәхси эше дә бит, югыйсә. Бихисап күп газаплар кичергән авыр язмышлы татар халкы милли язуын гасырлар дәвамында һәм

гарәп, һәм латин, һәм... кириллицага нигезләнгән рус хәрефләрен кулланып башкара килгән. Кыскасы, безнең халыкның алфавитны сайлау мөмкинлеге бар иде. Һәм ул сайлады да...

Ни гаҗәп, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы латин графикасына күчү турында кабул иткән хокукый карары Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы тарафыннан яклау тапмады; алай гына да түгел, һичбер сәбәпсез кире кагылды. Мондый башбаштаклылык кына канәгатьләндермәде, ахрысы, Дәүләт Думасы татар язуын үзгәртеп коруны Россиянең милли куркынычсызлыгына һәм территориаль бөтенлегенә куркыныч янаучы сәяси акт дип игълан итте. Шул рәвешле, 2002 елның май аенда Думада Россиянең барлык халыклары да рус алфавитына нигезләнеп язарга тиешлеге тәгаенләнгән закон проекты беренче утырышта ук (әйтерсең лә, янып килә!) кабул ителде. Ноябрь аенда исә, икенче, шуннан соң ук өченче укылыш үткәрелеп, ул гомумән гамәлгә кертелде.

Димәк, Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның, шул исептән татар халкының да, табигый хокукларын чикләү закон белән ныгытып куелды. Дәүләт Думасының мондый да кыргый кыланышлары бернинди демократия кысаларына да сыймый, әлбәттә. Язучыларның Охридада үткәрелгән Бөтендөнья конгрессы һич икеләнүсез моның шулай икәнлеген раслады да. Конгрессның Татарстанга кагылышлы резолюциясендә Россиядә яшәүче барлык халыкларның да дәүләт телләрен бердәйләштерү буенча Дума кабул иткән закон проекты милли мәдәниятләрнең үзенчәлекләрен кысуга, лингвистик төссезләндерүгә юнәлтелгән дип ассызыклап билгеләп үтелде. Язучыларның олуг форумы Россия хакимиятен татар халкының латин алфавитына күчәргә омтылуына каршы төшмәскә чакырды. Менә шулай, татар язуы тирәсендә барган ыгы-зыгы Россия Федерациясе чикләреннән үтеп чыкты һәм алдынгы карашлы бөтендөнья әдәби җәмәгатьчелегенең, нинди сәяси мохиттә яшәүләренә карамастан, кызыксыну өлкәсенә әверелде.

Халыкара ПЕН-клубның лингвистика комитеты, аннан соңрак конгрессның делегатлар ассамблеясы тулаем Россия Федерациясендә, аерым алганда, Татарстанда телләрнең гомуми торышы турында һәрьяклап нигезләнгән фикер алышулар үткәрде. Бирегә Рус ПЕН-үзәге вәкиле Александр



*Татар ПЕН-клубы утырышларының берсе. Уңнан сулга: Индус Таһиров, Равил Фәйзуллин, Нәбирә Гыйматдинова, Тәлгат Бариев, Газинур Морат, Туфан Миңнуллин, Әхәт Мушинский, Разил Вәлиев, Рафаэль Мостафин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Ркаил Зәйдулла, Марсель Галиев.*

Ткаченко, Беларусьтан Анна Герасимова, Финляндиядән Юкка Маллинен татар ПЕН-үзәге тәкъдим иткән резолюция проектын яклап дәлилле чыгыш ясадылар. Фикер алышуларда шулай ук инглизләр, американнар, итальяннар, болгарлар, серблар, македоннар катнашып, безнең белән теләктәш булуларын белдерделәр.

Татар ПЕН-үзәге делегатлары, ягъни юрист Борис Пантелеев һәм мин фәкыйрегез, Конгресс делегатлары белән ПЕН-клуб мохитендә—ирек сөючәнлек һәм халыкара хокук телендә аңлаштык. Кызганычка каршы, Россиядә без мондый аңлау тапмадык. Мәскәүдә чыга торган кайбер басмаларда хәтта: «Татарстанда яшәүче руслар да латинча укырмы?»—кебегрәк сафсаталарны да очратырга туры килә. Кем әйтмешли, хикмәтнең кибәктә икәнлеген аңлатып тору кирәк түгел бирегә.

Әле күптән түгел генә миңа Дәүләт Думасыннан Ляшенко дигән бер ханым шалтыратты. Мәсьәлә болайрак тора иде: Язучыларның Бөтендөнья конгрессы кабул иткән Татарстан турындагы резолюциясен—дөресрәге, Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миңнуллин белән мин фәкыйрегез кул куйган русча нөсхәсен танышу өчен алдан ук Думага юллаган идек. Ляшенко ханым беренче сүзеннән үк миңа сорау артыннан сорау яудыра башлады һәм мине тыңлап та тормастан, аңа үзе ук җавап та биреп барды. Дөресрәге, ике арада булырга тиешле әңгәмә аның озын-озакка сузылган монологына кайтып калды һәм ахырдан шунсы да мәгълүм булды: татарларга латин имлясына күчү зарарлы икән, ул халыкларны дошманлаштыруга гына китерәчәк икән. Аңлашылса кирәк, Дәүләт Думасы спикеры хозурына безнең юллама барып ирешкән һәм аның исеменнән безгә шундый җавап алынды: ярамый! Ә бу рәсми җавап иде...

* * *

ГЛОБАЛИСТЛАР һәм антиглобалистлар бәйгесендә милли телләр, әдәбият һәм мәдәниятләр сагында торучылар соңгылары ягында булырга тиеш иде кебек. Сүз дә юк, без барлык халыклар өчен дә уртак мәдәният «тудырылуга», бер телнең икенчесе өстеннән хакимлек итүенә каршы, әлбәттә. Ләкин шул ук вакытта танырга мәҗбүрбез, глобализм үзенең табигате белән бер тоташ бертөрлелек дигән сүз түгел. Ә инде ахыргача гадел булырга теләсәк, моның уңай яклары да бар. Ә глобализмның кире яклары турында сүз алып барганда, мин трансконтиненталь корпорацияләрнең кечкенә һәм хәлсезләнгән финас-икътисади берләшмәләрне «йотуын» түгел, ә бәлки тел-ләгать өлкәсендә алып барылган карагруһчылыкны күз алдында тотам һәм, халыкара тәҗрибәдән чыгып, глобализмның ике төрдә булуын—«макси» һәм «мини» төрләрен аерып күрсәтәсем килә.

Миниглобализм төренә мин Россия хакимиятенең Россиядә яшәүче халыкларның алфавитын руслаштырырга омтылуын кертер идем. Башта бер дәүләт теле, аннары фән, мәдәният һәм көнкүреш өлкәсендә дә барлык халыклар өчен бер тел тудыру ул, башка берни дә түгел, бөтен ил күләмендә ныклы вә какшамас вертикаль хакимият урнаштыруның ачык мисалы. Шушындый хәвефле шартларда татар телен һәм саклап калу, һәм үстерү максатыннан максиглобализм, ягъни латин графикасында язуга күчү—дөнья цивилизациясенә кушылу!—отышлырак та, безгә кулайрак та. Латин имлясында язу үтә дә явыз руслаштыру глобализмын җиңәргә мөмкинлек бирәчәк; дөресрәге, моңа ышаныч тудырачак.

* * *

ШУШЫ УҢАЙДАН кайберәүләр дистәләгән еллар буена рус алфавиты нигезендә иҗат ителгән татар әдәбияты әсәрләре чорлар тузаны астында күмелеп калмасын дип хафаланалар. Ышанам әйтергә мөмкин: калмас! Чөнки рус теле—дәүләт теле; шулай булгач, рус алфавиты юкка чыгар дип курку урынсыз. Шуңа бәрабәр рәвештә, хәрефе югалмагач, рус алфавиты нигезендә язылган әдәбият та югалмый һәм азмы-күпме татар теленнән хәбәрдар булган кеше өчен ул чит-ят тоелмас.

Тагын бер мөһим шарт бар: латин имлясына күчү акрынлап, баскычлап-баскычлап үткәреләчәк. Хәзерге сәяси шартларда шулай булмый мөмкин дә түгел. Ләкин шул ук вакытта йоклап ятарга да ярамас һәм Мәскәү тарафыннан уңай җилләр искәнен көтеп торсак, соңга калуыбыз да мөмкин. Сәяси законнар табигать законнарыннан шунысы белән аерыла—алар бүген бар, иртәгә юк.

Тормышка аша калса, күчеш бәла-казасыз барыр кебек, чөнки латинны олысы да (алар яңалифтә укыган, язган), кечесе дә (алар чит телләрне өйрәнәләр) таныл белә. Ә көнбатыш телләре, белгәнебезчә, латин графикасына нигезләнгән.

Латин графикасы халыкара аралашуны җиңеләйтергә ярдәм итәр; хәер, ул хәзер үк ярдәм итә башлады инде—Интернет челтәре нәкъ менә латинга корылган, лабаса. Бүген язу аша халыкара мәйданга чыгу өчен (хәтта мобиль телефоннар ярдәмендә шәһәрара бәйләнешләр өчен дә) рус теле үзе дә латин графикасына таянуга мохтаҗ. Рус теле язуын латин графикасына күчерү турында Мәскәүнең күп кенә җитди басмалары да күтәреп чыкты. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, әйтик, кириллица белән язучы славян иле Македония дә, ә бүген Россия Федерациясенең хакимиятне вертикальләштерү тарафдары Мәскәү үзе дә шәһәрдәге күп кенә күрсәткеч язуларны латин графикасында кабатларга мәҗбүр булдылар. Бу—бүгенге көннең чигенеп булмас зарурияты. Хәтта туган телләренә карата аеруча сакчыл японнар, кытайлар, кореялылар да язу мәсьәләсендә заман таләпләренә буйсынырга кирәклеген аңладылар һәм үзгәреш юлына аяк бастылар.

* * *

ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ Македониядә уздырылган Бөтендөнья форумы эшчәнлеген кабат хәтердә яңартам да, шундый нәтиҗәгә килә м—татар язуы язмышы турында безнең делегация керткән резолюция бик тә вакытлы һәм урынлы булган, ул юкка гына зур яңгыраш алмаган икән. Конгрессның төп шигарьләреннән берсе «Телләрнең киләчәге—киләчәк теле» дип аталуы да бер дә юкка түгел, ләбаса. Безгә, Татар ПЕН-үзәге делегатларына, сорау артыннан сорау яудырып кына тордылар: телнең статусы ничек хәл ителгән, тел республикада гына түгел, чит төбәкләрдә гамәлдә ничек кулланыла, судлар кайсы телдә алып барыла, ике дәүләт теленең мөнәсәбәтләре ничек урнаштырылган—язучыларны барысы да, барысы да кызыксындырды. Кыскасы, Конгресс делегатлары татар язуына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе, ягъни латин графикасына күчәргә омтылу лингвистик яссcылыктан сәяси яссылыкка кайтарылуын аңлап вә төшенеп, татар халкына теләктәшлек иттеләр.

Дөрес, Россия Федерациясенең бүгенге хакимияте гражданлык мөнәсәбәтләренә корылган демократик җәмгыять төзибез, Россия Европа һәм халыкара кануннарга таянып яшәргә тиеш дип чат саен лаф ора. Тел һәм язу турында сүз бара икән, ул кануннар чынлап та дөньякүләм әһәмияткә ия. Мисаллар кирәкме? Рәхим итегез, хаким әфәнделәр—Язучыларның Бөтендөнья конгрессы кабул иткән 19 нчы резолюция тулаем һәм махсус рәвештә татар алфавиты язмышы мәсьәләләренә багышланды һәм анда акка кара белән, һәркемгә аңлаешлы һәм үтемле итеп һәрбер халык, һәрбер телләр берлеге үзе теләгән язу үрнәген сайлап алырга вәкаләтле дип язып куелды. Ә 1996 елда Испаниянең Барселона шәһәрендә уздырылган Конгресста Лингвистик хокук турында Бөтендөнья декларациясендә болай диелгән иде: «Барлык тел бердәмлекләре үз телләре системасын кодекслаштыру, стандартлаштыру, саклау һәм үстерү хокукына ия».

Дөрес, без үз өебездә—Татарстанда туган телебезнең язуына нииндирәк үзгәрешләр кертү мәсьәләсендә бәхәсләшеп тә алырбыз һәм, ахыр чиктә, кайсыбер уртак фикергә дә килербез, әмма халыкара демократик кануннар нигезендә яшәргә телибез икән, безнең хәләл максатларыбызга читләрнең тыкшынуы, күрсәтмә бирүе, үз мәнфәгатьләрен көчләп тагарга омтылуы катгый рәвештә тыелырга тиеш.

* * *

КАЙЧАК миңа Россия Айда яки Марста яшидер сыман тоела, үзәк хакимиятнең күршеләре дә юктыр, алар газета-журналлар да укымыйлардыр, радио да тыңламыйлардыр, телевизор да карамыйлардыр кебек һәм, әйтерсең лә, һәрбер халыкның—аз санлымы, күп санлымы, җир яки кабилә-ыру халыкларымы ул—туган телендә сөйләшергә, язарга хокуклы булуы хакында Европа Советының, БМО Генераль Ассамблеясының, бөтен дөньяга танылган абруйлы халыкара иҗтимагый оешмаларның резолюцияләреннән, декларацияләреннән, конвенцияләреннән бөтенләй дә хәбәрдар түгелләр. Югыйсә, бит ул документларда кызыл җеп булып үткән, соңыннан Халыкара укытучылар федерациясенең Генераль ассамблеясы (Венгрия, 1996) кабул иткән декларациясендә беркетеп куелган, тәмам тәгаенләштерелгән бер фикер үткәрелә: кеше хокукының төп нигезе булып, аның туган теленә булган хокукы саналырга тиеш!

Шушы уңайдан лингвистик хокук хакында Бөтендөнья декларациясеннән тагын бер өзек китереп үтәсем килә: «Үзенең юридик буйсынуында бер тарихи халыктан артык булган хакимиятләр, башка халыклар аны аңлыймы-юкмы, барлык законнарны һәм гадәти кулланыштагы хокук кәгазьләрен һәрбер телдә бастырырга тиешләр».

Россия халыклары өчен бу, әлбәттә,—фантастика...

* * *

АЛГА киткән хокукый илләрдә иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтүгә зур игътибар бирелә. Еш кына дәүләт карамагында булмаган оешмалар да дәүләт тарафыннан финанслана. Әйтик, Европа Советы менә берничә ел инде АТТАС дип аталган (АТТАК дип укыла)[1] антиглобалистлар хәрәкәтенә акча күчереп килә. Чөнки антиглобалистлар да бер генә төсле түгел, кайберләренең программалары кайсыбер илләрнең, халыкларның, халыкара бердәмлекләрнең омтылышларына һәм карашларына туры килә. Ул бездә, Россиядә генә антиглобалистларны экстремистлар дип атап йөртәләр. Югыйсә, хакыйкатьнең күзенә туры карап әйтсәк, бу, яшь буынны үзе артыннан ияртеп бара алырлык чын мәгънәсендәге интеллектуаль хәрәкәт; бу, ахыр чиктә, үрнәк алырлык, җәмгыятьнең гомуми торышын билгеләүче барометр буларак гражданлык башлангычы.

Нигә дип болар хакында сөйлим соң әле мин? Юк, шуңа авыз суын корытам, татар милли мәдәнияте вәкилләре, аның идеологлары барлык милли байлыкларыбызны, үзебезнең татарлыгыбызны саклап калу максатыннан чыгып, глобаль иҗтимагый-сәяси хәрәкәттә сак һәм тирәнтен уйланып катнашырга кирәклеген ачык күзалларга тиешләр. Әйе, без мәдәният өлкәсендәге глобализмга каршы. Ләкин язуыбызны җайга салу мәсьәләсендә глобализм «безнең яклы», ул бөекдержавачыл рус шовинизмына каршы торырга ярдәм итәчәк. Төптәнрәк уйлап карасаң, ПЕН-клуб та үзенең табигате белән дөньякүләм глобаль язучылар оешмасы, лабаса. Өстәп әйтәм: демократик эчтәлекле, дөньякүләм интеллектуаль гражданлык оешмасы, әмма дәүләти оешма түгел.

Кызганыч ки, Россиядә әлегә кадәр гражданлык җәмгыяте төзелмәгән. Моңарчы яшәп килгән барлык иҗтимагый оешмалар да ялганга корылган иде, алар дәүләтнең имгәтелгән бер дәвамы була килде. Шуңа күрә дә алар исәптә булсалар да, санда юк иде. Хәзер дә шулай, гәрчә чын-чынлап дәүләти булмаган гражданлык оешмалары барлыкка килсәләр дә.

---

[1]Бу аббревиатура: «Гражданнарның Тобин налогын яклау хәрәкәте» дип шәрехләнә. Тобин—америка икътисадчысы, Нобель премиясе лауреаты, ул спекулятив финанс килешүләренә 0,01% күләмендә налог салырга кирәк дигән тәкъдим белән чыга. Аның исәпләүләренчә, шушы ысул белән җыелган акча бөтен дөнья ачларын туендырырга, акушерлык-гинекология мәсьәләсен хәл итәргә һәм башлангыч белем бирүне җайга салырга җитәргә тиеш.

Без үзебезнең көч буларак пәйда булганыбызны тоябыз, ә менә Россиянең хакимият органнары—юк: белмиләр дә, белергә дә теләмиләр. Декларацияләр, резолюцияләр турында сүз чыктымы, Дәүләт Думасында, мәсәлән, беренче чиратта бу документларның нинди вәкаләткә ия булулары белән кызыксыналар. Нишлисең, алар җәмәгатьчелек көченә генә ия шул. Шушы хакта ишетү белән хакимият чиновниклары: «Ә-ә, алай булгач, гафу итәсез инде...» дигәндәй, тәртәләрен кире боралар.

Шуңа күрә дә Россиядә телләрне кысу уңае белән Бөтендөнья язучыларының (хәтта язучыларның да!) куәтле тавышы закон чыгаручы хакимият тарафыннан ишетелүенә шикләнеп карыйм. Ләкин Россия Федерациясенең хакимияте татар халкының Туган теле, Ана теле язуын үзе теләгәнчә җайга салу юнәлешендәге хыялларын томалап, антидемократик карашта торуын, гомумкешелек кануннары буенча яшәячәкбез дип лаф оруларының ялган икәнлеген тагын бер кабат расладылар.

* * *

КОНГРЕССТА Россия Федерациясе буенча, безнекеннән тыш, тагын өч резолюция кабул ителде. Аларның берсе Россия Федерациясендә сүз иреген тәэмин итү һәм язучы В. Сорокин, НТВ телевидениесе журналисты А. Титов һәм А. Иванов, Б. Ширянов кебек авторларга карата кулланылган эзәрлекләү чараларын туктату турында иде. Икенче резолюциядә кулга алынган журналист Г. Паськоны кичекмәстән азат итү таләп ителде.

Өченче резолюциядә исә, Чечня Республикасына каршы алып барылган сугышны туктату мәсьәләсе күтәрелде, анда ачыктан-ачык чечен халкын кыру-үтерү барганлыгы, ягъни тулы бер халыкка карата геноцид кулланылганы катгый тәнкыйтьләнде. Язучыларның Бөтендөнья конгрессы бу нәүбәттән, хәрби конфликтны тыныч юл белән хәл итү өчен Россия Федерациясе президенты В. Путинны һәм хөкүмәтне А. Масхадов җитәкчелегендә халык тарафыннан сайлап куелган кануни Чечен Республикасы хакимияте белән сөйләшүләр башларга чакырды.

Чечня буенча кабул ителгән резолюциядә шулай ук «Новая газета» корреспонденты Анна Политковскаяның Россия кораллы көчләренең Чечен Республикасында алып барган хәрби хәрәкәтләрен—сугыш алып баруын тәнкыйтьләп язган мәкаләләре өчен көч куллану структуралары тарафыннан эзәрлекләнүенә тирәнтен борчылу белдерде. Бу журналист ханым тормышына куркыныч янаганлыктан, Мәскәүне ташлап, хәтта чит илдә яшәргә мәҗбүр булган икән.

Анна Политковская Македониядә үткәрелгән Конгресс эшендә үзе дә катнашты. Ул Татар ПЕН-үзәге делегаты Борис Пантелеев белән күптәннән таныш булып чыкты һәм без аның белән Россия Федерациясендәге милли мәсьәләләрнең торышы хакында күп тапкырлар сөйләшеп утырдык. Әйтергә кирәк, Анна Политковская бик тә кызыклы һәм ачык күңелле әңгәмәдәш булып чыкты. Аның милли мәсьәләдә нык торуын, аның фикерле булуын күреп сөендек, ә шәхси батырлыгы хакында сөйләп тә тормыйм—болай да аңлашыладыр дип уйлыйм. Конгресста ул Чечнядагы хәлләр турында доклад белән чыгыш ясады һәм чираттагы бер әңгәмә вакытында әлеге вакыйгаларның, зурдан кубып әйткәндә, бик сирәк кешеләрне генә борчуын искәртеп үтте. Әйе, бу сугыш бүген берәүне дә чын-чынлап кызыксындырмый диярлек шул.

...Боларның барысы хакында да сүз сентябрь аенда уздырылган Бөтендөнья язучылары форумында, Мәскәүнең шарикли подшипниклар житештерү заводының культура йортында булачак вакыйгалар алдыннан алып барылды.

*2002 ел, октябрь.*

# ТЕАТРГА ГАШЫЙК БУЛЫГЫЗ!

## ДРАМАТУРГЛАРЫБЫЗНЫҢ СОҢГЫ ЕЛЛАР ИҖАТЫ

Драматургия—ул әдәбиятның үзенчәлекле тармагы. Автор тарафыннан иҗат ителгән пьеса спектакль буларак өлгергәнче шактый катлаулы юл үтә, үзенең башлангычында бер канаты белән әдәбиятка таянса, икенче канаты аның театрга талпына. Менә шушылар драматургка «ике хуҗаның хезмәтчесе» итеп карарга җирлек тудыра да.

Ләкин язылып һәм басылып та, пьеса сәхнәдә яңгырамаса, ул әле тулы хокуклы әдәбият, сәнгать әсәре буларак танылмый, кабул ителми кала. Мисалга ерак барырга кирәк түгел, мәшһүр драматургыбыз Нәкый Исәнбәтнең «Җирән чичән һәм Карачәч сылу» пьесасын искә төшерик. 1944 елда язылып, ул сәхнә күреп өлгерсә дә, мәгълүм сәбәпләр аркасында репертуардан төшерелә һәм бары тик 1999 елда гына аны режиссер Фәрит Бикчәнтәев казып чыгара, яңадан сәхнәгә кайтара. Бу спектакльнең төрки халыклар театрларының «Нәүрүз» фестивалендә иң әйбәт, күркәм спектакльләрнең берсе булып яңгыравы—беренче урын алуы—чын әдәбият һәм сәнгать җәүһәренең «тутыкмавы», шундый әсәрләрне күрә, тоя, аңлый, бәяли белә торган режиссерларның кирәклеге турында да сөйли.

Әйе, драматург режиссер белән уртак тел тапканда гына үз максатына ирешә ала. Ләкин теләкләре булганда режиссерлар драматургия төренә карамаган әдәби чыганакларны да—проза, хәтта шигърият әсәрләрен дә сәхнәләштерә ала. Чаллы драма театры 1999 елның октябрь аенда уңышлы күрсәткән «Йосыф» премьерасы шул турында сөйләмимени? Библиядә дә, Евангелиедә дә, Ветхий заветта да урын алган бу риваятьнең мөселман диненә кучкән сюжетын спектакльнең режиссеры Ренат Әюпов сәхнә теленә яраклаштырган һәм шул кыйсса театрда менә дигән куелыш табып, җәмәгатьчелектә киң яңгыраш алды.

Әйе, сәхнәнең үз законнары бар. Пьеса авторы иң әүвәл менә шул сәхнә таләпләрен күзалласа гына язылган әсәрен театрда күрү бәхетенә ирешә ала. Театр һәм язучы арасында менә шушы тыгыз бәйләнеш, үзара аңлашу булмаса, авторның әсәре үз максатына ирешә алмый калачак. Мөгаен, шул сәбәпледер, драматургия мәсьәләләрен өйрәнүгә күп елларын багышлаган хөрмәтле галимебез Азат Әхмәдуллин үзенең бер мәкаләсендә сүз уңаеннан гына: «драматургия буенча билгеле бер чорга нәтиҗәләр ясау, үсеш тенденцияләрен ачыклау шактый авыр эш. Хикмәт бу әдәбият төренә икенче сортлы нәрсә дип караудан гына тормый»,—дип шәрехләп уза. Әйе, хикмәт драматургиянең әнә шул театрга нык бәйле, хәтта аңа буйсынган булуындадыр.

...Гадәттә әдәбиятка яшьләр агым-агым булып килеп керәләр. Кайсы еллар безне бер төркем шагыйрьләре белән куандыра, ә кайчак яшь прозаиклар

белән шатландыра. Драматургларыбыз да алардан нык аерылып тормый. Соңгы тапкыр алар шундый көчле төркем булып 60 еллар башында дәррәү килеп керделәр дә, нәкъ менә шулай булырга тиеш, шулай кирәк сыман—хаклы рәвештә—театр сәхнәләренең түрен биләделәр. Тарихи күзлектән караганда бу чорны галимнәр «яңару чоры» дип атыйлар, мөгаен, бу күренеш шул чорның шифалы сулышы нәтиҗәсе булгандыр. Ул елларда күренә башлаган драматургларның исемнәрен генә атау да күп нәрсә турында сөйли: Хәй Вахит, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Юныс Әминов, Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллин... Соңрак бу агымга Диас Вәлиев, Әхәт Гаффар, Рабит Батулла, Ризван Хәмид, Рөстәм Мингалимов, Фоат Садриев, Юныс Сафиуллин, Фәнис Яруллин кебек танылган исемнәр кушылды. Аларның күбесе, Аллага шөкер, бүген дә исән-имин, иҗатларын уңышлы дәвам итә. Менә соңгы елларда Г. Камал театрында сәхнә күргән дүрт яңа әсәргә күз салыйк: Т. Миңнуллинның «Эзләдем, бәгърем, сине», З. Хәкимнең «Чапты атым Казанга», М. Гыйләҗевнең «Баскетболчы» һәм Р. Зәйдулланың «Саташкан сандугач» пьесалары. Бу авторларның берсе—Т. Миңнуллин быелгы төрки халыклар театрларының «Нәүрүз» фестивалендә иң яхшы драма әсәре номинациясендә җиңүче булды. Әлеге күңелле вакыйга безнең татар драматургиясенең башка халыклар белән бәйгедә нинди югары урынны биләве турында сөйли торган бер факт буларак игътибарга лаек һәм ул күп нәрсәне аңлата да.

Т. Миңнуллинның киң колачлы драматургиясе әллә ничә төрле теманы, идеяне, мәгънәне, моң-сагышны, уен-көлкене, гореф-гадәтне үз эченә ала. Ул кагылмаган нинди генә өлкә калды икән—әйтүе кыен. Бу юлы Туфан мәхәббәт турында драма язган һәм ул яшьләргә адресланган. Ләкин бу пьеса авторының кем икәнен алдан белмичә укысаң да күзне йомып әйтәсең: бу—Туфан әсәре! Монда аңа гына хас кайнарлык, аһәңлелек, хәзерге көн өчен актуаль иҗтимагый әһәмияткә ия уй-фикерләр ачык чагыла. Язмыш кушуы белән имгәнгән, аяксыз калган ике яшь йөрәк телефон аша, очраклы рәвештә генә таныша. Ялгызлыктан котылу ниятеннән генә чыгып шылтыратылган телефон тавышы тора-бара мәхәббәт авазы булып яңгырый башлый. Пьесада әллә ни зур вакыйга да, хәрәкәт тә юк—ике кеше телефон аша гына сөйләшә. Конфликт та кычкырып тормый (миңа калса, бу пьеса бик әйбәт радиопостановканы хәтерләтә), ләкин шул ук вакытта ул тамашачының нечкә күңел кылларын тибрәтә, аның йөрәге аша уза. Драматург монда да үзенә тугры булып кала—ул һәрвакыттагыча кем беләндер ярсып бәхәскә керә. Аның пьесалары эчке рухлары белән гел дә диспутны хәтерләтә. Соңгы вакытта Г. Камал театрында куелган «Илгизәр плюс Вера», «Хушыгыз!», «Сәяркә», «Шәҗәрә» һәм К. Тинчурин театрында сәхнәгә менгән «Саташу» әсәрләрендә дә хакыйкатьне эзләү, яшәү мәгънәсен, кайда ак, кайда кара икәнлеген аңларга теләү, аларны ачык итеп күрсәтергә омтылу ярылып ята. Әмма бу пьесалар темалары, сюжетлары, образлар системасы белән бер-берсен кабатламый, шул ук вакытта композиция төзелешенең конструктив корылуы, геройларының кыланышларына тирән мәгънә салынган булуы белән Т. Миңнуллин үзенә тугры кала.

Шулай ук актив язучы һәм театрларның иң яраткан авторларыннан берсе—Зөлфәт Хәким. Ул үзенең иҗади табигате буенча—шагыйрь кеше. Шигырьләрендә, җырларында, гомумән, үзе катнашкан концертларда аның бард-башкаручыларга хас авазы, гражданлык хисләренең кайнарлыгы, публицистик аһәңе бик ачык чагылыш таба. Соңгы 10 ел эчендә Г. Камал театрында гына аның 6 әсәре дөнья күргән, шуның өстәвенә але кайберләре Әлмәт, Минзәлә, Чаллы театрларында кабатлап та куелган. З. Хәким пьесалары режиссерларны мавыктыра, илһамландыра. Моның сере нидә икән, дигән сорау үзеннән-үзе туа. Миңа калса, Зөлфәт Хәкимнең пьесаларында шагыйрьләргә хас идея энергетикасы нык тәэсир итүчән, шул идеяне ул актив көчкә әвереллдерә белә, аны бик тәвәккәл рәвештә куллана. Нигездә, күп очракларда аның төп герое шул идеянең җанлы яшәешенә әверелә. «Чапты атым Казанга» комедиясендәге авыл клубы мөдире Салихны гына алыйк. Әсәр гади бер авыл кешесенең җыр-моңга сусавы, матур хыяллар белән януы, баян сатып алам дип, атын җигеп, Казанга юл тотуы турында сөйли. Ихлас

күңелле бу зат безнең заманның Дон-Кихоты кебегрәк кабул ителә. Мондый кызык, фанатик кешеләрне халык һәр чак үз итә. Әсәр дә шуңа ирешә. Көтелмәгән-уйламаган сукмакларда әсәрнең башка персонажлары белән очрашабыз, әмма алар очраклы кешеләр генә булып кала, бу персонажлар характер һәм язмыш иясе, образ буларак автор өчен кызык түгел. Образлар системасына шундый ук мөнәсәбәт аның Камал театрында куелган «Мин төш күрдем» әсәрендә дә (Әлмәттә ул «Көзге романс» исеме белән куелды) бик ачык чагыла. Монда да төп герой бүгенге шагыйрь язмышын гәүдәләндерә, аның хатыны исә иҗат вәкилләренең хатыннары кичергән авырлыкларны үз җилкәсендә татыган, тормыш мәшәкатьләрендә йөзә, иренең мәнфәгатьләре белән генә яшә торган гади бер бухгалтер хатын. Ләкин биредә сүз алар арасында туган каршылык турында бармый. Ә бәлки үзеңә-үзең хыянәт итү хакында бара. Автор геройны төрле ситуациягә куя һәм аны сыный. Биредә дә авторның хыял көче төп геройга сарыф ителә, башка образлар ярдәмчел рольне генә үтиләр. Шул сәбәпледер бу рольләр бик үк «үтемле товар» дип кабул ителми.

Бер идеяне сәхнә әсәренең нигезе дип кабул итүчеләр арасына драматург Мансур Гыйләҗевне дә кертер идем. Ул чынбарлыкның һәм образларның реальлек иллюзиясенә таянып, ул шул чынбарлыкка бик тә якын торган, әмма аның белән адекват булмаган, ни дәрәҗәдәдер үз автономиясенә ия булган яңа бер дөнья тудыра. Монда аның иҗади хыял көче, фантазиясе ярдәмгә килә. Пьеса тормыш күренешләренең эчке бәйләнешләренә тирәнрәк үтеп керергә һәм аларны төгәлрәк ачарга тырыша. Аның 1998 елда Әлмәт театрында куелган «Сафиулла»сы да шул турыда сөйли. Бу әсәр дә чорыбызның иң актуаль темасын күтәрә. Автор дөньяви хәлләрнең агышын тирән аңлап сайлый алган, фәлсәфи эчтәлек белән баеткан. Сюжет җебен дә махсус рәвештә чуалчык итеп корган, тик аңардан әсәрнең драматик эчтәлегенә зыян килмәгән. Гомер буена Сафиулланың күңелендә ике кеше яши, алар бер-берсе белән килешә алмыйлар һәм шуның нәтиҗәсендә ул корган йортның нигезе черек була, бу йорт аңа иминлек алып килми. Әсәрнең структурасы катлаулы, төрле боҗралы комбинацияләргә бай, шул сәбәпле аны сәхнәләштерү режиссер өчен (Ф. Ибраһимов) үтә катлаулы эш булса да, иҗади канәгатьләнү хисе алып килгәндер дип беләм.

Ә менә 2001—2002 еллар сезонын шаулаткан, мәшһүр режиссерыбыз М. Сәлимҗановның васыяте буларак кабул ителгән «Баскетболчы» спектакле хыялга нигезләнгән. Хыял көче монда вакыйга үзәгендә тора. Баскетбол уенында дөньякүләм беренче урынны алу турында хыяллану—үзе үк абсурд! Ләкин автор әсәргә эчке мәгънә сала алган. Татар халкы ни өчен әле дөньяви көрәш уеннарында мөстәкыйль рәвештә чыгыш ясамаска тиеш, икән дип уйлыйсың. Шул хыял-ният әсәргә якты романтик төс бирә дә инде.

Г. Камал театры афишаларында тагын бер яңа драматург исеме пәйда булды. Ул—Ркаил Зәйдулла. Аның «Саташкан сандугач» драмасы минем үземә психологик планда кеше җанына анализ ясау белән ошады. Р. Зәйдулла бүгенге көнебез турында язуы, әле кичә генә какшамас булып тоелган совет системасында тәрбияләнгән яшь кешеләрнең идеалны югалтуын бәрелү-сугылуларын тирәннән тасвирлый алуы белән игътибарны үзенә җәлеп итте. Әле бу кискен социаль борылыш чорында театрларның үзләренең дә илдә бара торган үзгәрешләргә үз мөнәсәбәтләрен ачыклап җиткерә алганнары юк иде. Драматург җәмгыятьтә бара торган шушы процессның кеше күңелен ни дәрәҗәдә гарипләвен, аның рухын сындыруын ачынып һәм үткен тасвирлый. Әсәрдәге вакыйгалар гади генә бара сыман: символиканың, шартлылыкның, риториканың эзе дә юк. Тик шулай булуга карамастан, заманыбызның караңгылыгы, ак белән караның буталуы үзләренең эчке бер табигый агышында сурәтләнә һәм шуның белән бу әсәр ота, безгә кадерле.

Кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне күрсәтә алучы драматург Ризван Хәмид әсәрләре Г. Камал исемендәге һәм Әлмәт, Минзәлә театрлары сәхнәләрендә куелды. Рухи тамырларыбызны, кешеләрдәге эчке матурлыкны алгы планга чыгара алган бу драматургның пьесалары артистлардан да, тамашачыдан да тирән фикер йөртүне таләп итә һәм психологик анализ

осталыгын чагылдыруда үзенә күрә «чикләвек төше» булып тора. Кайвакытта театрларның аның әсәрләренә бик үк тешләре үтми: миңа калса 2001—2002 ел сезонында Чаллы драма театрында куелган «Тигезәкләр» спектакле моның ачык мисалы.

Бу әсәр илебездә бара торган бүгенге процессларга кагыла. Анда бүгенге вакыйгаларны тарих күзлеге аша үткәрү, гаять тә катлаулы иҗтимагый бер чорны гади бер гаилә тормышы—Бадакшановларның яшәү рәвеше аша күзаллау, алар аша чор фаҗигасен ачу максат итеп куелган. Советлар хакимлек иткән чорда бар кешене тигезләү, «бер үтүк» белән бастыру процессы көчле булды. Аның нәтиҗәсен халык бүген дә үз җилкәсендә татый. Әсәрнең төп конфликты кешеләр арасындагы каршылыкларны гына күрсәтеп калмыйча, еллар буена җыелып килгән рухи канәгатьсезлек фаҗигасен ачуга корылган. Кызганыч ки, Чаллы театры артистларының уен манерасы, сәхнәдә яшәү ысулы, драматургның әйтергә теләгән фикеренә, язу ысулына тәңгәл килмәде, шунлыктан аның иҗтимагый идеясе бер читтә калды. Бу очракта тәнкыйть укларын театрга юнәлтәсе килә.

Соңгы елларда иң актив эшләүчеләрнең берсе итеп инде чын драматург булып җитлеккән Данил Салиховны атыйсы килә. Аның хәзер үзенең язу ысулы, күңеленә хуш килгән, бары тик анык гына булган, ул тудырган образлары бар. Миңа калса, бу персонажлар аның якын танышлары кебек һәм автор алар белән көн дә аралаша сыман. Алардагы характер бөтенлеге һәм җанлылыгы өлкән әдипләребезнең иҗат алымнарын хәтерләтә. Бу драматургның геройлары авыл кешеләре һәм гаҗәеп халыкчаннар, шул ук вакытта аларны ниндидер тар кысаларга кертеп булмый. Аның пьесаларында оригиналь ситуацияләр, фантастика алымнары да шактый күп кулланыла. Аяз Гыйләҗев тә аның хакында: «Данил Салиховның драматургиягә кулы ята, сатира алымнарына сыйган әсәрләре аерата тапкыр, үтемле чыгалар»— дип язган иде.

Дөрестән дә, нигездә ул комедия жанрында иҗат итә, шунда йөзә. Ләкин образлары комик-сатирик планда чишелсәләр дә, без күнеккән, «таныш калыпка» төрелгән, әсәрдән-әсәргә күчеп йөрүче тискәре образлар гына түгелләр. Алар—үзләренчә хикмәт ияләре. Соңгы өч ел эчендә сәхнә күргән «Капчыктагы Мәгъфия», (К. Тинчурин исемендәге театры), «Мөгезле Мәүлихан» (Чаллы театры), «Кетмәгәндә, уйламаганда» (Әлмәт театры) дигән әсәрләрен күрсәтеп китү генә дә җитә. Данил—бәхетле драматург, аның язган бер әйбере сәхнә күреп кенә калмый, ташка да басып калдырыла: «Яшьлек хатам—йөрәк ярам» дигән китабында 6 пьесасы басылган, ә «Узып барышлый» дип аталган икенче китабында тагы шуның кадәр үк пьесасы дөнья күрергә әзерләнә. Димәк, Данил—12 пьеса авторы.

Д. Салиховның язу ысулындагы тормышчанлык һәм шартлылык төрле аспектта кулланыла, яңалык булып, сәнгатьчә яңгыраш ала. Бу алымнар театр сәхнәсен баетырга, артистлар уенын төрләндерергә дә мөмкинлек бирә. Пьеса геройлары милли хисләргә һәм хикмәтле сүзләргә байлар, автор үзе яза торган мөхитне яхшы белә, нечкә аңлый. Аның «Пуля»сындагы ситуацияне генә алыйк. Череп баеган «яңа татар» үз күләгәсеннән үзе куркып яши. Автор аны нинди генә мәзәк һәм көтелмәгән хәлләргә дучар итми, ничек кенә тыпырчындырмый, тик, ни хикмәт: куркыныч, хәтта кеше ышанмаслык мондый хәлләргә тамашачы ышана, рәхәтләнеп көлә, аларны чынбарлыкның бер сатирик чагылышы буларак кабул итә. Сүз уңаеннан гына әйтим: Д. Салихов урыс драматургы Александр Вампилов куллана торган «капма-каршы кылаңыш» алымын да оста файдалана.

Алда исемнәре аталган драматургларыбыз театр сәхнәләрендә үз урыннарын белгән, үз йөзләрен тапкан, тормыш һәм иҗат позицияләрен ачыклаган, язу стильләрен аныклаган, заманыбызның рухи проблемаларын үткер сиземләүче шәхесләр. Алар бүген мәйдан тоталар. Бу исемнәр арасында бу юлы Юныс Сафиуллин белән Гафур Каюмов исемнәре аталмады. Алар соңгы елларда «тайм-аут» алдылар булса кирәк. Дөрес, Гафур Әлмәт театрына барып үзенең элек язган «Мирас» драмасын «Ахырзаман» исеме астында режиссер буларак үзе куеп кайтты. Уңышлымы, уңышсызмы—анысы икенче

мәсьәлә. Монда бит мин соңгы елларда язылган әсәрләр турында фикер йөртәм. Сүз уңаеннан тагын шуны әйтә алам: 1998 елдагы драматурглар бәйгесендә Г. Каюмов «Ыру» драмасы белән II урынны яулап алды. Ләкин, кызганычка каршы, бу әсәргә әлегә театрларның мөрәҗәгать иткәне юк. Чөнки ул тарихи-философик аспектта язылган бик җитди әсәр. Гомумән, Г. Каюмов соңгы елларда журналистлык эше, режиссерлык шөгыле белән мавыгып китте, пьесалар язмый башлады. Бик кызганыч, дияр идем. Г. Каюмов—драмалар остасы бит. Бу җәһәттән ул үз кадерен үзе белеп бетерми ахыры.

Р. Сәгъдинең «Яз галәмәте» дип аталган моңсу комедиясе К. Тинчурин театрында куелды. Комедия—гадәттә җәмгыять тормышындагы бер дисгармонияне чагылдыра торган жанр. Димәк, игътибар үзәгендә шул, «тормышны боза торган» берәр вакыйга ятарга тиеш. Монда исә вакыйга тулай торакта озак еллар бергә гомер кичергән гаиләләрнең гадәти тормышын бозып, бер чибәр ир заты пәйда булудан башлана. Ул—тулай торак коменданты Мәдинә Абрековнаның 20 ел элек яраткан яры икән. Зур чәчәк букеты тотып килеп кергән бу чибәр ир үз ирләреннән гомер буена якты чырай күрмәгән хатын-кызларның «соры» дөньяларын кинәт ямьләндереп җибәрә. Әлеге вакыйга мондагы хатын-кызларга үзләренең яшәешләренә читтән торып карау, бәя бирү өчен бер сәбәп тә була. Автор хатын-кызның ялгызлык темасын әнә шулай моңсу хисләр аша чагылдыра. Шулай итеп тормыш прозасы сәхнәдә поэзия белән кушыла, гадәти тормыш агымына югары идеаллар килеп керә. Тик бу әсәрдә хатын-кыз образлары бик нәфис, тирән яшеренгән хисләр яссылыгында хәл ителсәләр дә, ирләр исә—бертөрлерәк һәм төссезрәкләр. Өч ир-ат—өчесе дә исерекбаш. Өчесенең дә характерына җанлылык җитми. Гомумән алганда, Р. Сәгъдинең әсәрләрен лирик мотивлар, сафлык, пакълек, шаянлык-наянлык бизи. Бу авторның яшьләр театрында куелган «Аппаксылу» әкият-пьесасы да шундый ук ачык, матур төсләргә бай. Халык иҗатында яшәп килгән Аппаксылу, Таңбатыр, Шүрәле, Пәри, Җен, Дию кебек образларны Р. Сәгъди бүгенге көнгә күчерә, гади генә бер сюжет төзеп, вакыйгаларга тарих күзлеге һәм юмор күзлеге аша карый—чорыбызның рухи халәтен сурәтли. Бу пьесада әхлакый, тәрбия мәсьәләләре күтәрелә, балаларга әйбәт акыл бирелә.

Фәнәвил Галиевнең күптән түгел сәхнә күргән «Узма яшьлек заяга» дигән әсәре проблемасының җитдилеге, актуальлеге белән кызыклы. Җаннарын кая куярга белмәгән яшь егетләр-кызлар наркомания коткысына бирелгәннәрен сизми дә калалар—аларның юл таба алмый бәргәләнүләре әсәрдә җан ачысы белән сурәтләнә. Тик бу әсәрдә театр өчен бер четерекле урын бар. Спектакль итеп куйганда җыр-бию белән артык мавыгу бик мөмкин. Яшьләр театры куелышында әнә шулай килеп чыкты да.

Аманулла исеме дә безгә таныш. Аның пьесалары шактый күренде. Күңелгә иң хуш килгәне—Г. Камал театрының яшьләр труппасы куйган «Әле кичә генә яз иде» дигән лирик драмасы. Ул чыгарылыш сыйныфы укучыларының тормышына багышланган һәм күтәрелгән проблемасы белән гаять актуаль.

Яшьрәк буын драматурглар арасында инде 15 әсәрен театр сәхнәләрендә күреп өлгергән Хәбир Ибраһимов исеме дә бар. Минзәлә театрында уңышлы куелган «Газиз ярым» драмасы кичерешләргә, нечкә хисләргә бай булуы белән күңелгә хуш килде. Бу әсәрне артистлар бик яратып уйныйлар һәм ул тамашачыларда зур уңыш казанды.

Яр Чаллы театрының артисты Булат Сәләхов «Яр» исемле әсәр язган иде. Ул аны 2001 елның җәй көне драматурглар семинарында укыды һәм пьеса тыңлаучылар тарафыннан бер тавыштан яратып кабул ителде. Ә инде 2002 елда без бу әсәр нигезендә куелган берьюлы ике спектакль белән таныштык. Бер үк пьеса, тик безнең алда ике төрле спектакль! Сәхнә вариантларында Чаллыныкын—«Намус хөкеме», ә Минзәләнекен «Ак хәтер» дип атарга булыр иде. Нинди дә булса әсәрне сәхнәләштерү ул, беренче чиратта, сюжет линиясе белән түгел, ә бәлки идеянең сәнгатьчә чагылышы белән бәяләнергә тиеш. Бу пьеса исә үзенең үтә шартлылыгы, поэтик яңгырашы белән чын мәгънәсендә яңалык алып килгән әсәрләрнең берсе булды.

Йомгаклап әйткәндә, күрәбез: драматурглар соңгы елларда бик тырышып эшләгәннәр, язганнар, аларны сәхнәгә еш күтәргәннәр. Менә мондый бер кызыклы фактка игътибар итәсе килә: 1998 елны Татарстан мәдәнияти министрлыгы тарафыннан игълан ителгән һәм «Татар пьесасы» дип аталган конкурста барлыгы 66 пьеса катнашкан иде. Ябык бәйге булгач, аларның авторлары чит исем астына яшеренгән иделәр. Димәк, иң кимендә, 30лап язучы катнашкан булырга тиеш. Бу сан аз түгел. Димәк бездә драматургия белән кызыксыну сүнмәгән, сүрелмәгән. Әмма, жюри әгъзасы буларак әйтә алам: әсәрләрнең яртысыннан күбесе игезәкләрдәй бер-берсенә охшаш һәм художество эшләнешләре ягыннан тәнкыйтьтән түбән тора иде! Тик, ничек кенә булмасын, көчләрне барлау ягыннан бу конкурс бик кирәкле чара иде.

Мәдәният министрлыгы театр әһелләре берлеге белән 2001 елда ике тапкыр драматурглар семинары да уздырды. Гаҗәеп кызык, кирәкле сөйләшү булды ул.

Бөек артистыбыз Габдулла Шамуковның 1968 елда басылган «Әйдәгез, уйлашыйк» дигән бер мәкаләсе искә төшә. Анда ул: «Заман таләпләренә җавап бирә торган гүзәл сәхнә әсәрләре иҗат итү—язучылар коллективының төп бурычларыннан берсе,—дип белдерә.—Әдипләр театрлар белән тыгыз бәйләнештә булырга тиешләр. Ә аларны соңгы 15-20 ел эчендә театрда бик сирәк очратырга мөмкин. Хәтта драматургия өлкәсендә эшләүчеләр дә театрга үз әсәрләре куелганда гына киләләр. Ә бит бездә шундый заман булган: Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гафур Колахметов, Хәсән Ямашев, Габдрахман Кәрим, Сәгыйть Рәмиев һәм башкалар театрның үз кешеләре булып саналганнар, театрда ниләр эшләнгәнен белеп торганнар. Бу уңай традиция әле егерменче-утызынчы елларда да бар иде. Гадел Кутуй, Һади Такташ, Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт һәм башка язучылар аны уңышлы дәвам иттерделәр»—ди. Габдулла абыйның сүзен дәвам иттереп, бүген дә мондый традицияләр онытылмаса ничек әйбәт булыр, дигән фикерне куәтлисе килә.

Шулай ук бу уңайдан Туфан Миңнуллинның бер чыгышы истә. Ул болай дигән иде: «Минем шаяртып та һәм чынлап та әйтә торган бер сүзем бар. Әгәр дә драматург буласың килсә, син һәр театрның иң кимендә ике артисткасына гашыйк булырга тиешсең. Әлмәт театрында минем шундый ике артисткам бар иде. Дамира Кузаева һәм Луиза Солтанова. Хәер, нигә әле «иде»? Алар бүген дә минем күңелемдә. Гашыйк булганда гына рәтле-юньле пьеса яза алам».

Менә мин дә драматург Туфаннан үрнәк алып, драма театры артистларына һәм артисткаларына гашыйк булырга чакырам. Аларга атап әйбәт рольләр язылса, алар сезне, әсәрегезне күтәрерләр, күккә чөярләр! Ә режиссерлар исә—сезнең әсәрләрегезгә иң мохтаҗ кешеләр, алар сезгә иң хәерхак теләктә калучылар.

**Дания ГЫЙМРАНОВА**

## Рифат Сверигин

# АНЫ БЕЛӘБЕЗМЕ?

ФӘНИС ЯРУЛЛИНГА 65 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН

Фәнис Яруллин... Бу исемне телгә алуга күз алдына явыз язмыш ихтыярына бирешмичә яшәргә, көрәшергә, иҗат итәргә көч тапкан мәгърур шәхес килеп баса. Кайберәүләр аны татарның Николай Островские дип атыйлар. Әмма кайчандыр «Корыч ничек чыныкты» белән «Җилкәннәр җилдә сынала» әсәрләре һәм аларның авторлар арасында охшашлык табарга теләгән иптәшләр бүген башка бер хакыйкатьне дә сиземләргә тиешләр: Н. Островский әсәре заманалар үткән саен тоныклана, төссезләнә һәм элеккеге әһәмиятен югалта барса, милләттәш әдибебез исә үз иҗатының тәүге басмасы булган әлеге әсәреннән соң янадан-яңа иҗат биеклекләренә күтәрелгәннән күтәрелә генә бара!

Әмма бу борылышны—әдипнең олы иҗат юлына чыгып, ныклы адымнар белән атлап китүен—җәмәгатьчелегебез шәйләп тә, аңлап та җиткерә алмады сыман әле. Әгәр дә шулай булмаса, ни өчен соң һаман да бик күпләребезгә Фәнис Яруллин үзенең шәхси бәхетсезлеген җиңә алган, шактый авыр физик шартларда иҗат итәргә сәләтле зат рәвешендә генә аңлашыла?

Ә бит янәшәбездә, затлы һәм бәхетле, адашканнарыбызга юл күрсәтердәй, җәмгыятьнең, заманның сулыш-тойгыларын йөрәге, күңеле белән тоючы, милләтебезнең чиста, саф вә раушан көзгесенә тиң бөек кеше яши! Нәкъ менә шушындый Фәнис Яруллинны күреп, белеп һәм аңлап җиткермичә калсак, бу бик аяныч һәм гафу ителмәслек бер хәл булыр иде. Дөрес, соңгы елларда әдип тирәсендәге битарафлык, илтифатсызлык бозы чатный, җимерелә башлады кебек. Күптән түгел ул Татарстанның халык шагыйре исеменә лаек булды. Президент имзасы белән бик хаклы рәвештә тиешле югарылыгында бәяләнгән бу шәхеснең иҗаты каләмдәшләре, тәнкыйть әһелләре тарафыннан хуплап яктыртылырга, энәсеннән җебенә кадәр өйрәнелеп чыгылырга тиешле кебек иде дә бит...Әмма әлегә каләмдәш дигәннәребез һәркайсы үз эше белән мәшгуль, ә тәнкыйтьчеләребез «әйе, тәнкыйть—кирәкле шәйдер» дип, бөек Тукайның бүгенгедәй ваемсызлыкка чыдап тора алмаган минутларында әйтелгән мәгълүм сүзләрен кабатлаудан ары уза алмыйлар...

Узган 10-15 ел дәвамында Фәнис Яруллинның дистәләгән китаплары үз укучысына барып иреште. Без бу урында беренче нәүбәттә аның «Чәчәкләр моңы», «Гамьле дөнья», «Йөз аклыгы», «һәр күнелдә сер ята», «Яралы язмышлар», «Урман кызы», «Серле дөнья», «Көн сулышы», «Яз гөлләре», «Көзге моң», «Пьесалар» исемле китапларын истә тотабыз. Әле шушы көннәрдә генә «Мәктәп китапханәсе» исемле яңа басма да Фәнис Яруллин томы белән ачылып китте. Проза, драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть, балалар әдәбияты дип аталган тармакларның һәркайсысында да әдип олы, игелекле эшләр башкара. Бу әсәрләрдән нинди дер аһәнлелек, шигърият, моң агыла. Чын шагыйрь кайда да Шагыйрь булып кала! Бәлки барын да поэзия теле белән генә әйтеп, сөйләп бетерел булмый да торгандыр? Әллә шуңа күрә ташып торган хис-уйларынны башка жанр калыпларына куеп аңлатырга кирәк буламы икән?.. Бөек Тукай да саф шигърият кысаларына гына сыя алмаган—чәчмә әсәрләрне күп иҗат иткән, әмма ни өчендер аны «прозаик Тукай» дип әйтергә һич тә телебез әйләнми, чөнки Тукай кайда да үзен шагыйрь итеп тойган, «шагыйрь» дигән исемнең олы һәм җаваплы дәрәҗә икәнлеген белгән. Менә калса, шушы янәшәлек, шушы мәгънә бүгенге шартларда Фәнис Яруллинга бик якын сыман.

Шигърият офыкларының киңлеге, сурәтләү чараларының чикләнмәгән

байлыгы әйтергә теләгән образлы уй-фикерене шунда ук укучыга житкерергә мөмкинлек бирә. Шул исәптән, менә мондый «ялгышучыларга» да җавап табыла:

Минем хакта берәү болай диде...
(Мөһим түгел аның исеме):
«Жәлләп кенә аны күтәраләр,
Әллә аны шагыйрь дисенме...

...Кура да бит сынгач көй чыгара
Төзек чакта—кура монсыз ул.

Язмышына рәхмәт әйтсен инде,
Яза алмас иде шунсыз ул».

Жавап биреп тормыйм бу кешегә,
Әрнетсә дә йөрәк ярасын.
Бирә алам бары сынык кура,
Бүлдыралса уйнап карасын...

(«Берәүгә»)

Фәнис Яруллинның шигъри дөньясы һәртөрле абстракт, буш, төссез, җимсез сурәтләрдән азат. Аның өчен кешенең хәле-халәте, яшәү рәвеше, аның шартлары әһәмиятле.

Каты чирдән бераз хәл алгачтын,
Тәрәзәмне эретеп тын белән,
Озак итеп тышка карап тордым
Әллә нинди сагыш, моң белән.

...Жир өстенә хисләр түшәлгәннәр,
Агачларга моңнар эленгән.
Дөнья үзе җырлый тып-тын гына—
дөнья сүзсез җырга күмелгән.

(«Авырудан соң»)

Әдип үз тормышының мизгелләреннән әнә шул олы дөньяга, яшәү мәгънәсе турында уйлатырлык хакыйкатьләргә килеп чыга.

Шагыйрь бөтен гомере буена кешеләргә ышанып яшәде, үз замандашын гел матур һәм олы итеп күрергә теләде:

Ә мин менә, мәҗүсидәй,
Табынып яшим һаман утка.
Нинди көчле давылда да,
Коеп яуган явымда да
Сүнми торган сихри утка—
Кешеләрнең күңелендәге
Нур сибүче яктылыкка.

(«Табыну»)

Яктылык, сафлык, намуслылык тарафдары буларак, шагыйрь үз-үзенә дә таләпләрнең иң зурысын куя:

Керсездән керсез нәрсә?—
Керсездән керсез—кояш.
И вөҗдан, керләнмә бер дә,
Халкың белән син һәр җирдә
Сафлык теләндә сөйләш.

(«Яктыдан якты нәрсә?»)

Тора-бара, әдипнең карашлары киңәя төшкәч, әйләнә-тирәдәге «дуслар»ы арасында тыштан гына ялтырап йөргәннәре дә беленә башлый:

Тигәнәктәй ябыша башлый безгә
Ялган, хәйлә, мәкер, хөсетлек,
Ялагайлык—тагын әллә ниләр—
Саный китсәң, җыела йөз этлек.

Онытабыз хәтта елмаюны,
Авыр түгел юкса бу һич тә.

Тыпырчынып яткан яхшылыкны
Үтерәбез буып без эчтә.

һәрберебез зур бәхеткә лаек,
һәрберебез кеше ләбаса.
Яшәү шундый җиңел булыр иде
һәркем әгәр башка берәүнең дә
Кеше икәнлеген аңласа.

(«Яшәү шундый җиңел булыр иде»)

Әшәкелек-бозыклыклар, ямьсезлек-гаделсезлекләр күбәйгәннән-күбәя барган заманда Фәнис Яруллин каләменнән инде элеккечә гел бал гына тамып тормый, һәртөрле алдакчылар, ришвәтчеләр, байлык, мөлкәт дип башкаларны таптап үтүчеләр хакында язганда шагыйрь кырысрак тонга күчә:

Ялганнар, ялганнар, ялганнар—
Дөньяны уратып алганнар.
Давыллар аударган агачтай
Ялганнан батырлар ауганнар.
*(«Ялганнар»)*

Яңа буын килә аренага,
Хәтерсез һәм әрсез надан буын.
Телләрендә бары катлы-катлы
Сүгенү сүзе генә калган буын.

Милләтсез һәм динсез кавем бит ул,
Беркем белми—кемнең балалары.
Алар өчен изге бернәрсә юк,
Байлык кына табыну аллалары.

...Хәвеф көтә безне урамнарның
Һәр чатында, һәрбер почмагында.
Безнең жаннар йөри шул буынның
Кесә төбендәге пычагында.
*(«Безнең жаннар»)*

Мондый юлларда—аянычлы гаҗәпләнү дә, каушап, аптырап калу да, шушы халәткә карата килешмәүчән мөнәсәбәт тә чагыла. Илебезнең, милләтебезнең шушы дәрәҗәгә төшүенә һәркайсыбыз гаепле һәм җаваплы икәнлегенә дә басым ясала монда.

Түбәнлекнең көче нәрсәдә дип
Уйлыймын да—табам җавабын.
Аның көче—безнең көчсезлектә,
Көчлеләргә сихере юк аның.
*(«Түбәнлекнең анатомиясе»)*

Ә без артык кыюсызлар булдык.
Кагылырга куркып тарихка,
Хакыйкатьне гел тиргәп уздык,
Риза булдык рухи тарлыкка.

...Куркаклыкның бер әсире булып
Күпне күрми генә яшәдек.
Гаделсезлек күрсәк, күзне йомдык,
Безгә тимәсәләр—дәшмәдек.
*(«Актарыла тарих катламнары»)*

Сәясәтнең төрле хикмәтләренә, борылышлары-зигзагларына бигүк битараф түгеллеген яшермәсә дә, Фәнис Яруллин нигездә җирнең гади кешесе, ә шигърияттә рациональлек белән лириканы бик табигый рәвештә бергә үрә белүчеләрнең бер вәкиле булып санала ала. Сәясәткә бәйләнешле төп нәтиҗәне дә ул һәр татарга аңлаешлы итеп, бераз гына ирониясен дә кушып, ярып сала:

Үткән белән, ялгыш белән
Көрәшәбез, алышабыз:
Башны тартып алабыз да
Койрык белән ябышабыз.

Барысына да без чыдарбыз,
Бу хәлләрдән бер чыгарбыз.
Әгәр инде чыгалмасак,
Лаек, димәк, гел шунар без.
*(«Өйрәттеләр»)*

Чыннан да, Фәнис Яруллин иҗатының төп чыганакларын явызлыкны каһәрләүдән бигрәк, яхшылыкка табыну тирәсеннәнрәк эзләргә кирәктер. Ул

һәрнәрсәдән ямь табып яши белә, һәр күренеш ана шигъри тема, шигърият чыганагы була ала.

Шигырь кайда?—Бөтен төштә:
Зур диңгездә һәм инештә,
Күктә, җирдә, урманнарда,
Рәшәләрдә, буран нарда.
Яшеннәрдә, күкрәүләрдә,
Мәхәббәттән тетрәүләрдә...
Ал битендә алмаларның,
Шат йөзендә балаларның,
Кояш туган тамчыларда,
Елгаларда, ташуларда,
Чәчәкләрнең тажларында,
Урманнарның ташларында,
Дәртле кошлар сайравында...
*(«Шагыйрь булу гына кирәк»)*

Әйе, тормышның һәр күренеше олы илһам чыганагы була ала. Аларны сайлап алу әлләни кыен эш түгел. Әмма Фәнис Яруллин шигърияте иң беренче нәүбәттә шагыйрьнең югары гражданлык позицияләренә һәм гуманистик карашларына нигезләнә. Нәрсә турында язса да, ул гаҗәеп самими һәм ихлас күңелле, үзе шикелле гади укучының дусты һәм теләктәше булып кала. Фәнис Яруллинның шигъриятгәге феномены гадилекнең бөеклеге рәвешендә аңлашыла. Әмма бу бөеклек бар бөтенлеге һәм тулылыгы белән саф һәм пакь күңелле кешеләргә генә барып җитә ала. Шагыйрь карашы әнә шундый—аны аңларлык катламнарга төбәлгән.

Шул ук вакытта бу автор беркайчан да укучының күңелен аяп, «тукта, моны шигъри дулкыннарымда тибрәтеп, юатыйм әле» дигән исәп белән эш итми. Гүя бу шигъри юллар аша һәркайсыбызга намуслылыгыбызны, кешелек дәрәҗәбезнең чамасын, микъдарын үлчәп карарга форсат ачыла. Галәттә, үз-үзен белү юнәлешендә объективлыгын һәм кыюлыгын югалтмаган укучы шкаласындагы дерелдәп торган укның үзе фараз иткән нормальлектән байтак авышканлыгын яисә шул урынга килеп җитмәгәнлеген күреп ала. Үз-үзеннән оялып та куясың. Тик боларга бер мин генә гаепле сон, дисең. Әнә бит аларның кайберләрен шагыйрь үз өстенә дә ала:

Кычкырасы килә кайчак:
«Коткарыгыз, батабыз!»—
Алда—сазлык, артта—упкын,
Торабыз бер чатта без.

...Кычкырасы килә әрнеп:
«Коткарыгыз, батабыз!»
...Кем коткарсын?—
Упкыннарга
Бер-беребезне тартабыз,
Бергаләшеп батабыз.
*(«Кычкырасы килә»)*

Сәрхүшлек, байлыкка, акчага, нәфескә табыну, ялган һәм шәфкатьсезлек—мондый бик киң таралган, әйләнә-тирәбезне инләп алган афәтләргә шагыйрь һич тә битараф кала алмый. Боларга каршы юнәлтелгән көчле публицистик пафос бик күп шигырьләрне сугара, бер урында ул ананың газиз баласына әйткән киңәшләре булып та яңгырап китә:

Өч нәрсәдән саклан, балам,
Киңәшемне ташлама:
Беренчесе—бер кабым да
Харам ризык ашама.

Икенчесе—күңеләнә
Оялмасын ялган.
Ялган бар җирдә хаклык юк,
Шуны онытма, балам.

Өченчесе—иң мөһиме—
Шәфкатьсез була күрмә:
Шәфкатьсез кеше—Тиран ул,
Шәфкать юк илләр—Төрмә.
*(«Коткарыгыз»)*

Шагыйрь иң яраткан шигъри сурәтләрнең берсе—күк киңлекләрендә, биеклекләрендә, иркенлектә, хозурлыкта гизүче кош образы. Әдипнең үзе турында «мин бары тик очышта гына яши алам, минем матурлыгым очышта» дигәннәре

канатлы гыйбарә булса да—аның рухи халәтенә искиткеч туры килә.

Кошлар юлы биек-биек,
Китә болытларга тиеп.
Кошлар юлын күзәтәмен
Башларымны күккә чөеп.

Әй соклангыч очышлары,
Үз-үзләрен тотышлары.
Яшеннәрне кисеп үтә
Үткен канат-кылычлары.

...Ярый канатлы кошлар бар,
Ярый кошлар юлы биек.
Карыйсың бер күтәрелеп,
Йөргән чакта башны иеп.

*(«Кошлар юлы»)*

Бу кош ерак күкләрне генә гизеп калмый, түбәнгә, кешеләр янына да төшә, күңелләребезне иркәли, үз-үзебезнең хәл-халәтләребезгә дә ишарә ясый:

Әллә инде артык сукырлар без,
Күп нәрсәне күрә белмибез.
Матурлыкны кешеләрдән түгел,
Йолдызлардан, күктән эзлибез.

Ә бит шундый матур күңелләр бар—
Эче тулы байлык, хәзинә.
Ул хәзинә ургып килеп чыгар
Кагыл гына аңа әз генә.

...Бик гади дип йөргән кешенең дә
Тамырлары буйлап моң ага.
Ләкин күпләр күңелендәге кошын
Очыра алмый кала дөньяга.

*(«Аккош булып оча һавада»)*

Фәнис Яруллинның шигъри җаны бер халәт, бер кыяфәттә генә калырга теләми. Бер караганда ул укучыны үзендәгедәй шаянлык, җор күңеллелеккә чакыра, үз кимчелекләребезне үзебезгә күрсәтеп, көлдерә һәм уйландыра («Алдану», «Иң матур кеше», «Дачада», «Бер үк бишмәт», «Гомер юлын барлаганда, «Аңладым», «Әй, замана, замана»). Кайчагында шәхси күңелсезлекләре турында сөйләп, азрак кызгандырып та ала («Сары чәчәк—сагыш диләр», «Керми киттем каен урманына»). Тик бу урында бер искәрмә дә бирергә тиешбез: аның «яралы язмалар» дип аталырлык шигъри учмалары башлангыч чор иҗатында ешрак очрый иде, хәзер алар елдан-елга кими барып, юк дәрәҗәсендә генә калды. Аларында да минутлык күңел төшү мизгелләре бик тиз юмор һәм шаян сүз уйнату бизәкләре белән алмашына, алардагы оптимизм нурлары безнең күңелләребезне дә кузгатып, үсендереп җибәрә.

Әдипнең юмор өлкәсендәге осталыгын өйрәнергә махсус хезмәт багышларга кирәк. Юмор пафосы шигырь чикләрен бик җиңел үтеп чыгып, башка жанрларга да тарала. Сәхнә әсәрләрендә бу сәләт аерымачык күренә: «Әнә килә автомобиль», «Бай әти», «Бер көрешү—үзе бер гомер», «Кызларның кызганнары», «Шүрәлеләр каргышы», «Сөембикә егет сайлый», «Койрыксыз сандугач», «Мәхәббәт янгыры» кебек комедияләре авторның бу өлкәдәге гаять зур мөмкинлекләре һәм перспективалары хакында сөйли. Ул тормыш ыгы-зыгыларының һәр мизгелендә, һәр борылышында комедиячел ситуацияләр таба белә һәм шулар ярдәмендә укучыга, тамашачыга кызыклы фикерләрен җиткерә.

Драма әсәрләрендә Фәнис Яруллинның шагыйрьлеге сизелеп тора. Алар арасында шигъри драма рәвешендә иҗат ителгәннәре дә бар. Башкаларын куйганда да сәхнәдә җыр һәм музыка янгырап тора. Драма-комедияләрендәге шаянлык, шаяру аша әйтелгән җитди уй-борчылулар да, фикерләрнең фәлсәфә катыш лиризмга байлыгы да барысы да әдипнең шагыйрьлегеннән килә диярргә нигез бар. Автор моны үзе дә яшерергә теләми: «Шигърият—минем беренче һәм мәңгелек мәхәббәтем. Башка жанрларга мин чит болынга кызыгып кергән тай кебек кереп-кереп кенә чыгам. Ул «чит болында» озаграк тоткарлансам, күңелемә нидер җитми башлый. Җанны юксыну, каядыр ашкыну хисләре биләп ала. Бу халәттән мин бары тик шигырь язып кына котылам. Шигырь бары тик җан өчен генә языла»,—ди ул.

Чынлан да, төп хикмәт иҗатчының нинди жанрда эшләвендә генә түгел ахрысы. Хикмәт кешенен, авторның үзендә. Күңелендә һәрчак янгырап торган моң, кешеләргә мәдхия җыры әллә ничек җинел генә аның каләме тигән башка жанрларга да күчә, һәм ул иҗат иткән хикәяләр, повестьлар, драмалар, комедияләр—барысы да диярлек, сыйфатлары, эшләнешләре, тәэсир һәвәсләре ягыннан шигърияттә ирешелгән биеклекләр дәрәҗәсенә күтәреләләр. Бу очракта да без шәхеснең бөтенлегенә, иҗатының һәм яшәешенең һич тә бүленмәс, таркалмас монолит ныклыгына юлыгабыз. Ә язучы үзе сәхналәргә комедияләренең тизрәк менүен тели. Монысын да үз шәхесенә һәм язмышына бәйләп аңлата:

«Гомер буе мин җор күңелле кешеләрне яраттым. Нинди генә шартларда да тормыш куйган сынауларга, хәтта үзенә дә юмор аша карый белгән кешеләр мине сокландырды. Бәлки тормышым артык фаҗигале булганга күрә, иҗатта булса да башкача яшисе килү теләге туадыр, шунар комедияләрне якынрак итәмдер». (Ф. Яруллинның шагыйрь Илдар Юзеев белән әңгәмәсеннән.)

Фәнис Яруллинның иҗатында, бигрәк тә лирикасында, аләм тормышының мәгънәсе, кыйммәте, яшәешнең катлаулы, каршылыклы яклары турында уйланулар, образлы фикерләр еш очрый. Катлаулы фәнни терминология яратучы белгеч-галимнәр әлеге сыйфатны бәлки үз телләрендә бүтәнчәрәк әйтер иде, әмма бу хезмәтебездә без гадирәк, ихлас күңелле һәм кешечә сөйләшә-аңлаша белә торган укучы белән гәп корабыз. Шуна күрә исе-төсе, тәме-тозы булмаган андый терминнарны ул галимнәрнең үзләренә калдырып, андый нәрсәләрдән читтәрәк йөрергә тырышабыз.

Әйе, дөнья һәм тормыш күренешләрен фәлсәфи яссылыкка куеп аңлатырга омтылу—Фәнис Яруллин иҗатына, бигрәк тә аның лирикасына хас күренеш. Бик күп очракларда ул үтә дә сакчыл, һәр сүзнең урынын, кадерен белеп эш итә, һәм гаҗәеп афоризмнар уйлап таба:

Акыллыларга алтын кирәкми,
Алтынлыларга акыл кирәкми.

Батырлык сынала мәйданда,
Кешелек сынала һәркайда.

Тиз барып җитәрмен димә,
Бик якын диеп ара.
Йөрәк шундый якында да,
Ә юлын табып кара.

Дөньядагы рәнҗетелгәннәрне, яклаучысыз калганнарны, мәхрүммескеннәрне күрә, кызгана, шундыйларга күпләрнең игътибарын юнәлдерә белгән бөек шәхесләрдән Виктор Гюго, Кнут Гамсун, Ф. М. Достоевский, Н. В. Гоголь, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукайларның эшчәнлеге тирән ихтирамга лаек. Алар тормышта гаделсезлекнең, мәрхәмәтсезлекнең гадәти бер халгә әйләнеп баруына тирән ачуларын, килешмәүчәнлекләрен белдерделәр һәм моның белән җәмгыятьнең вакытлыча томаланган күзләрен ачарга ярдәм иттеләр. Шуна күрә дә бу кыю, талантлы, зирәк һәм кеше кайгысына аеруча сизгер әдипләргә, аларның игелекле эшчәнлегенә карата һәркемнең күңелендә иң изге хисләр җанлана.

Бүгенге җәмгыятебез дә шушы мәсьәләдә үзенең уятучысына мохтаҗ икәнлеген дә төшенмичә, йокымсыраган хәлендә яши бирә. Әдипләребез башлап чаң кагарга тиеш кебек иде дә бит... Тик аларның күбесе әлегә үзләренең тар рухи тартма-читлекләреннән чыгарга һәм әйләнә тирәдәге хәлләргә карарга бик ашыкмыйлар...

Ниһаять, битарафлык томанын ярып, таратып, тоташтан шәфкатьлелек идеяләре белән сугарылган «Яралы язмышлар» әсәре дөньяга килде. Хәзер, аны кат-кат укып чыкканнан соң, бер хакыйкать ачыграк аңлашыла башлый: әйе, язмыш һәм тормыш гаделсезлекләре тарафыннан кыерсытылганнарны яклап, иң олы сүзне теләсә кем түгел, ә үз намусларына кер дә кунмаган затлар гына әйтергә хаклы! Һәм шушы вазыйфаны нәкъ менә Фәнис Яруллин җилкәләре күтәрүе—үтә дә табигый бер күренеш. Бу урында Федор Михайлович Достоевскийның: «дөньядагы нәрсәләрнең барысы бергә бер сабый күз яшьләренә тормавы» хакындагы мәгълүм фәлсәфәсе янадан искә төшә.

«Яралы язмышлар» әсәре чын педагог, олы хәрефләрдән башланган Укытучы һәм Тәрбияче тарафыннан иҗат ителгән. Бу изге эшкә гомерләрен багышлаган һәр кешенең өендә, киштәсендә, бигрәк тә өстәлендә шушы китап ятсын иде. Педагогика фәне махсус өйрәнелә, укытыла торган йортларда да... Монда житкәч, азрак уйланып та калдым. Ә чыннан да шулаймы соң? Хәзер бездә педагогика фәне артык коры, җаны-сүле калмаган теоретик догмалар җыелмасына гына әйләнә башламадымы? Совет чорында аны күренекле педагоглар Макаренко һәм Сухомлинский үз тәҗрибәләре һәм әсәрләре белән җанландырырга тырышкан булсалар, бүген бу юнәлештә «Яралы язмышлар» кебек китапларга һәм Минсылу (Миңлегөл) кебек образларга мөрәҗәгать итү урынлы булыр иде.

Без киләчәктәге картлык көнебездә барыбызның да балалар кулына калачагын искә алмыйча: балалар бәхетен, киләчәген тиешенчә һәм житәрлек дәрәҗәдә кайгыртмыйча, ваемсыз гына яши бирәбез. Акча һәм шәхси байлык туплау турында гына баш ватучы җәмгыять әгъзалары алдында киләчәк тормышның хуҗалары булырга әзерләнүчеләрнең бүгенге халәтләре һәм алдагы тормышлары-язмышлары кирәксез, мәшәкатьсез һәм абстракт төшенчә булып тоела. Мондый җәмгыятьнең, шул юлыннан борылмаган тәкъдирдә, рухи упкынга убырылып төшәчәген аңлый алмавы һәм моны аңларга да теләмәве аерата кызганыч.

Боларын да безгә Фәнис Яруллиннар төшендерергә тиешмени? Алар төшендергәч акча, байлык артыннан куудан башканы белмәгән җәмгыять борылыш ясармы? Тик шулай да Фәнис Яруллинның бар өмете—яшьләрдә, балаларда, сабыйларда. Ул үзе дә—гомере буена сабый булып кала белгән бәхетле кеше.

Ф. Яруллинның балаларга багышланган китаплары белән танышканда («Яз гөлләре», «Серле дөнья» һ. б.) авторның төрле рольләргә керә белүе гаҗәпләндерә. Бала күзләре белән дөньяга гаҗәпләнеп карап торганда да, ул нәни укучысына кирәкле сүзләрне әйтергә өлгерә:

Че078 килгән безнең күлгә,
Белмим, нинди челәндер.
Нинди булса да, мөгаен,
Безне сагынып килгәндер.

Сынар тәпиенә басып,
Кузгалмый ул көнозын.
Балыкчы кебек сабыр ул,
Сунарчы кебек түзем.

...Явыз малайлар да аңар
Таш атмыйлар нигәдер.
Күрәсең, матурлык шулай
Явызлыкны җиңәдер.

*(«Челән»)*

Фәнис Яруллин үз укучысы белән әкиятләр телендә дә сөйләшергә ярата. Аларның «Ак яфрак», «Шүрәлеләр каргышы» кебек олы сәхнәләрдә уйналырлыклары да, төрле кичәләрдә башкарылырлык «Исемсез кыз», «Әмәк белән Шәмәк», «Каракның бүреге яна», «Ай турында әкият», «Өч кыз һәм унөч алма», «Суыкборын һәм Суыкколак» сыманнары да бар.

Шулай да әкиятләрнең күпчелеге (аларның саны алты дистәдән артып китә!) традицион фольклор калыбында иҗат ителгәннәр. Әмма аларның барысы да—әдипнең үз фантазиясе белән уйлап чыгарылган әсәрләр—заман әкиятләре дип исемләп тә булыр иде. Мәгълүм ки, бу типтагы әсәрләр арасында бөтендөнья классик әдәбиятын бизәп торганнары да очрый. Шуларның иң гүзәлләреннән мәшһүр Антуан де Сент-Экзюперинең «Кечкенә принц»ын генә искә төшерик. Никадәр гүзәллекне, яхшылыкны үзенә җыйган әсәр ул! Абдулла Алиш, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзиләр дә заманында бик матур әкиятләр иҗат иткәннәр иде. Һәм менә бүген шушы юнәлешнең бер тарафдары буларак—Фәнис Яруллин!

«Йолдыз тапкан кыз», «Яз кайда кышлый», «Тылсымлы ачкыч», «Йокыбай», «Кайнар чишмә» кебек әкиятләрендәге мавыктыргыч сюжет, заманыбыз сурәтләре аша укучыга бик күп файдалы мәгълүмат җиткерелә, үгет-нәсихәтсез генә тәрбия бара. Мәсәлән, «Йолдыз тапкан кыз» әкиятендә «байлык артыннан куа торгач, кешелек абруеңны югалтканыңны сизми дә калырсың» дигән фикер гаять мавыктыргыч, үтемле-тәэсирле вакыйгалар тезмәсенә салып бирелә. Зирәк әбисенең сүзен тыңлаган Таңсылу урманнан якты йолдыз ташы табып кайта, шуның белән чирле, зәгыйфьләрне дәвалап, күп рәхмәтләр ишетә. Әмма бераздан моның үзенә акча чире йога һәм кыз бүгенге экстрасенслар сыман акча җыя башлый—буш кул белән килгәннәрне авыр сүз әйтеп, рәнжеткәләп тә чыгаргалый. Шунда хикмәтле

ташның сихәтле нурлары сүнә. Әбисе дә үлеп китә. Клиентлар да юк, бай кияүләр дә ишек шакымый... Зиннәтле келәмнәрне тузан баса, татлы ризыклар да күптән ашалып беткән... Һәм, кыз үзе әле күптән түгел генә куып чыгарган хәерче кыяфәтендә, ил буйлап хәер сорашырга чыгып киткән, ди.

«Урман әкияте» дә кулга тоту белән яшь укучыны җәлеп итә. Бу юлы җәнлекләр урманда агач ботагына эленгән телевизор табалар. Һәм аны урман хуҗасына—аюга тапшыралар. Эчендә нинди тәмле әйбер бар икән? дип бераз баш ваткач, тартманың төп вазыйфасын белеп алалар һәм телетамашачыларга әвереләләр, хәтта бер мәлгә авыл тирәсеннән кош-кортны да урламый башлыйлар.

Менә шундый заман әкиятләре белән генә чикләнмичә, Фәнис Яруллин халкыбызның традицион әкиятләре кысаларыннан бигүк читләшмәгән әкиятләр дә иҗат итә. Алар арасыннан ин беренче нәүбәттә «Яз кайда кышлый?» һәм «Тылсымлы ачкыч» дип исемләнгәннәренә күзем төште. Беренчесендә ягымлы Язбикә, кыю Җилбатыр, нәни Тамчыкай образлары аша салкын кышлар үтеп, җир өстенә язлар килүе баланың үз телендә искиткеч матур сөйләп бирелгән. Икенчесендә, төрле халыкларның әкиятләрендәгечә зирәклекне, тапкырлыкны мактау өстенлек итә.

«Кечкенә чакта Ибрайның бишеген җилләр тирбәткән, көйсезләнсә, кошлар сайрап юаткан, авырып китсә—урман чәчәкләре үзләренең шифалы суларын эчереп терелткәннәр. Малайның теле бик иртә ачылган. Бишектә чакта ук сандугачларга кушылып җырлаган, урман шавын тынлап моңайган, сихри күккә карап уйланган».

Әкиятче шагыйрьнең Камыр батыр янсә Иләтәйләр балачагын хәтерләткән герое әнә шулай табигать матурлыгы аша хозурландырып бирелә.

Әйе, әдипнең алтын сарайлары бер генә түгел. Тик бу юлы без аларның икесенә генә: шигырь сөючеләргә һәм нәни укучылар өчен дип салынганнарына гына күз йөгертеп алырга өлгердек. Драма, проза, публицистика дигәннәренә исә атлап керә алганнар юк әле. Кыскасы, Фәнис Яруллин иҗаты, тулаем алсак, белгечләрнең кулы тимәгән, өйрәнелмәгән кыйтга булып кала бирә.

Әдипнең яшьләребезгә—бүгенге катлаулы тормышта үз урыннарын табарга теләүчеләргә—әйтер сүзләре бик күп. Алар белән ул җитди проза телендә дә сөйләшә. «Кайту», «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», «Язмышлар язылганда», «Портрет» кебек повестьларда, күп санлы хикәяләрендә, заманның бик әһәмиятле, өлгергән, әмма хәл ителми килгән мәсьәләләре куела. Күбесе җәмгыять, армия, яшьләр, балалар тәрбияләү өлкәсендәге ялгышларга, җитешсезлекләргә, гаделсезлекләргә килеп тоташа.

Безнең фикеребезчә, сәнгати көче, иҗади пафосы белән, Фәнис Яруллин иҗаты казанышлары дөнья әдәбияты казанышлары белән янәшә торырлык. Гомумән, без, ни өчендер, татар әдипләренең иҗатлары татарның үзе өчен генә ярый, безне үзебезнекеләр укыса, шул бик җиткән, дигән үтә тыйнак, мескен, канатсыз, перспективасыз халәттә торабыз. Без шул халәтнең сөреме астында көн итәргә үз-үзебезне күнектергәнбез, гадәтләнгәнбез. Дөнья шедеврларына торырлык әсәрләр тудырган Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Рафаил Төхфәтуллин, Әхсән Баянов, Мөхәммәт Мәһдиев, Миргазиян Юныс, Мәгъсум Хуҗин, Айдар Халим кебекләрне ник күтәрмәдек һәм ник күтәрмибез? Үсеп килүче, үз фикерле, үз стильле яна талантларга да түшәм такталарын «безгә шуннан артык ярамый» дип бүген түбәннән суззып куярбызмы?

Соңгы елларда Х. Миннегулов, А. Әхмәдуллин, Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, А. Саяпова Р. Харрасова, Д. Заһидуллина кебек галимнәрнең хезмәтләрендә татар әдәбиятының классик һәм бүгенге кайбер казанышларын дөнья әдәбияты үлчәмнәренә куеп карау омтылышы беркадәр сизелә башлады. Бу эш сөрелмәсен иде. Бәлки Фәнис Яруллинның иҗат байлыгына бу унайдан мөнәсәбәт әйбәт якка таба үзгәреп тә китәр. Өметләр белән яшик.

Шушы мәкаләмне язганда сокландыргыч бер күренешкә юлыктым: Фәнис Яруллинның иҗат дәрьясында һәр туган көнгә сөенеп, әйләнә-тирәгә оптимистик караш сирпеп, башкаларның күңелләрен канатландырып, шатландырып яшәүче, олы җанлы шәхес иң алгы планга килеп чыга! Бу шәхесне, бу иҗатны тулаем белер, аңлар өчен дә безгә чын биеклекләргә—Вөҗдан, Намус, Кешелеклелек биеклекләренә күтәрелергә кирәк. Аның әсәрләре гел шуңа чакырып тора.

Галимҗан Гыйльманов

# ТАКТАШКА КАЙТУ

Такташ минем күңелемә, тормышыма, язмышыма 1975 елның җәендә өермәдәй бөтерелеп, ташкындай ургылып килеп керде. Бу җәйдә без— Казан университетының татар бүлегендә укучы бер төркем егетләр, кызлар—Мордва республикасы буйлап чәчелгән татар авылларына фольклор җыярга чыктык.

Буыннары ныгып, күңелләре утырып та җитмәгән, фикерләре оешып кына килгән беренче курс студентларын ул вакытта, халык иҗаты мирасыннан бигрәк, юл романтикасы һәм шау-шулы кичке концертлар күбрәк җәлеп иткәндер. Шулай да, экспедиция җитәкчебез Марсель абый Бакиров безне иҗади һәм эшлекле хәлдә тота алды, һәм без бу сәяхәтебездән искиткеч бай, хәтта, уникаль язмалар, басмалар алып кайттык.

Мукшы иленең (мордвалар үзләре «мордва» атамасын яратмыйлар) Такташ ватаны булуын беләидек, әлбәттә. Әмма бу хис, бу тойгы җәйге йомшак томан кебек, күңелне һәрвакыт иркәләп, сөеп торса да, без бунтар һәм трибун шагыйрьдән бик ерак идек әле. Шуңа күрә Такташ Сыркыдысына килеп керүгә без шок кичергән кеше хәлендә калдык.

Сыркыдыда Такташны белмиләр иде...

Күренекле шагыйрь, бөек тарихлы бөек халыкның бөек улы, ниһаять, үз якларының горурлыгы булырдай шәхес дәрәҗәсендә белмиләр иде аны...

Ә бит Сыркыдыга кадәр без олы хис белән йөрдек. Бу яклардагы һәр мишәр авылында мәчет эшли, укымышлы имамнары, кичке мәдрәсәләре безне тарихыбызның иманлы чорларына дәшеп, җаныбызны сафландырып торды. Әби-бабайлар кулында йөргән борынгы кулъязмаларның исәбе-хисабы юк, һәр әби-чәби—җырчы, һәр карт-коры—әкиятче... Пешләдәге Ш. Камал музее, язучы торган йорт та безне сөендерде. Акшарга буялган, абзар-сарайны хәтерләткән бу кечкенә өй безгә халык хәтерендә калыккан мәһабәт сарай булып күренгән иде.

Һәм... менә сиңа мә! Иманын онытмаган халык Такташны онытып бетерә язган! Пародокс шунда: ярты авыл Такташев фамилиясен йөртә, ярты авыл Такташ нәселеннән! Ярты авыл халкы шундый ук зәп-зәңгәр күзле, җирәнрәк чәчле, җор телле, бунтарь рухлы...

Ул вакытта безне кечкенә бер малай озатып йөрде. Исемен хәтерләмим, әмма фамилиясе Такташ иде. Телгә беткән, ачык күңелле, саф җанлы бу малай минем хәтеремдә мәңге саклаunion. Чөнки ул безгә: «Мин дә шагыйрь булачакмын!» диде. «Кем соң ул шагыйрь?»—дип, юри сүзне көлкегә бормакчы булдык. Ә ул бик җитди чырай белән, мишәрчәләп: «Шагирларны бөтен кеше белә!» дип чатнатып җавап кайтарды. Бу темага башка шаярмадык.

Такташ нигезенә баруыбыз хакында озак итеп, борчылып, әрнеп, күз яшьләренә төелеп сөйләргә булыр иде. Бу хактагы хатирәләрем шигъри юлларга да төшеп калган, шул шигъри кичерешләрем белән чикләнәм.

Озак йөрдем шагыйрь йортын эзләп,
Тик... кайда соң, кайда?—Табалмыйм.
Сабый Такташ кереп-чыгып йөргән
Җил капканы ачып ябалмыйм.

Җан өшеткеч тынлык бары—ни бу?
Мин көтмәгән бушлык, буш нигез.
Карт өянке... Әллә андамы сез?
Һади абый! Мин бу—төшегез!..

Карт өянке—Такташ тәрбиясе,—
Ялгыз калган, ятим, караусыз.
Җыерчыклар баскан, бөкре чыккан,
Салынып төшкән чәче тараусыз.

Салынып төшкән ботакларын карт тал
Йомшак кына күлгә терәгән.
Һади тәнен юган карт күлнең ул
Тыңлый кебек чирле йөрәген.

Алар шулай ике ятим кебек,
Бер-берсенә сыенып яшиләр.
Такташ истәлеге—бу картларны
Нигә рәнҗетәсез, кешеләр?!

Күл саеккан, карт тал бөкерәйгән,
Алабута баскан як-ягын.
Әрем исе аңкый...
Кайда, шагыйрь,
Торган җирең синең, мактаган?

Табалмадым! Юк ул! Югалтканнар!
Бетергәннәр синең нигезне.
Кайда Такташ—дөнья яңгыраткан,
Һади Такташ кайда—нигезле?!

1975 елның 17 июлендә язылган бу шигыремне нык тетрәнеп язганмын, күрәсең. Нәкъ шул тетрәнү минем күңелемне кузгатып җибәргән һәм Такташлы иткән, ахры.

Аяк язып бер ял итәр өчен
Тирә-юньнән түмгәк күзлимен.
Дөнья яңгыраткан Такташ эзен
Әрем арасыннан эзлимен!

Чыннан да шулай: мин гомерем буе Такташны эзләдем, Такташка килдем, Такташка кайттым бугай. Сыркыды юлы—бу олы сәфәремнең башы гына булган. Соңрак бу эзләнүләремдә миңа бик күп атаклы шәхесләр юлдаш һәм теләктәш булды.

Алар арасында Шәехзадә Бабич аерым урын тота. Мин бик күп татар шагыйрьләрен Бабич шәхесе, Бабич иҗаты аша аңладым. Шул исәптән Такташны да. «Бабич һәм Такташ» темасы—өйрәнелмәгән тема. Әмма татар әдәбияты тарихында принципиаль тема. Әдәбият дәреслекләрендә, гыйльми монографияләрдә бу янәшәлеккә, бәйләнешкә бөтенләй дә игътибар ителми, ә бит аңа күптән, бик күптән инде бөек Туфаныбыз төртеп күрсәткән иде. Ул 1928 елда ук: «Тукайга Бабич аркылы гына кайтып була. Тукайдан бүгенгегә дә Бабичны үтмичә килеп булмый. Үктәбер шагыйрьләре (Һ. Такташ һ. б.) Бабич ауган җирдән яңа юл салып киттеләр. Бабич Тукай эпигоны гына булып калмаган кебек, болар да Бабич эпигоны гына булмадылар»,—дип язган. Икенче бер язмасында Туфан, шул ук Һ. Такташны күз уңаенда тотып, мондый фикер әйткән: «Безнең сизгер шагыйрьләребез, әлегә кадәр тел эчендә яшеренеп яткан орлыкларны Үктәбер туфрагына күчерәләр. Алар формадагы үсүне Тукай, Бабич туктаган җирдән алып киттеләр. Ирекле бетемнең төрләрен үстерәләр».

Бабич—Такташ традицияләлегендә күзгә бәрелеп торган янәшәлекләр дә байтак. Бабичның «Язгы җыр» (1918) шигырендәге искиткеч мөлаем юлларны кем генә белми икән:

Утырдым мин тауның күкрәгенә;
Җырлар язам, җилкәй, исми тор!
Чишмәкәй! Тын! Әкрен!.. Чү! Шаулама!
Үткән гомерем, искә төшми тор!

Такташның «Урман кызы»нда (1922) шушы таныш образларны очратып, тагын бер мәртәбә рәхәт хисләр кичерәбез:

Күл янында утырып җырлар язам,
Әй, таң җиле, тукта, исмәче!
Йоклап яткан таллар, тирәкләрнең
Яфракларын уйнап ишмәче!

Ике шагыйрь иҗатында мондый янәшәлекләр күп. Әмма күзгә бәрелеп торган уртак образлар, мотивлар, аһәңнәр—традициялелекнең өске катламы гына. Мондый күренешләр, гадәттә, шагыйрьләрнең башлангыч һәм өйрәнчек чорларында күзәтелә. Өлгергән, инде шәхеслеккә дәгъва итүче шагыйрь үз остазларының казанышларын механик күчерү белән генә шөгыльләнмичә, поэтик мотивизация, фәлсәфи һәм психологик анализ, вәзен һәм өслүб, интонация-аһәң тирәнлегендә кабул итәргә һәм үстерергә омтыла. Такташ та Бабичтан күп нәрсә ала. Дөресрәге, ул үзенең шигъриятен Бабич салып калдырган нигезгә кора. Бу хакта Туфан искәрткән иде инде.

Бабич—Такташ күчемлелеге нигездә ике яссылыкта бара. Беренчесе—мифологик яссылык, ягъни образлар яссылыгы. Шагыйрьнең беренче иҗади гомере, «Такташ үлде» (1923) шигыренә кадәрге әсәрләре тулысынча Бабич иҗатыннан үсеп чыккан. Минем үземә Такташның шушы чор иҗаты якынрак, кадерлерәк. Чөнки нәкъ шушы этаптан соң Такташ декларативлыкка һәм риторикага таба юл ала. Әмма, образлылыктан, тирән фәлсәфәдән һәм психологизмнан ераклашса да, ул үз талантын лирик, ироник һәм идеологик тирәнлекләргә көйли, җиргә, тормышка, кешегә якынайта бара. Чын талантта шулай гына булырга мөмкин. Такташның югалтулары да матур, чөнки алар—чор сәясәте таләпләренең гыйбрәтле нәтиҗәсе генә. Шагыйрь үзенең мифологик иҗатын соңыннан да гел сагынып яши, урлап, яшереп кенә булса да, таныш, газиз образларны куллана, качып кына егерменче еллар чатына барып кайта...

Бабичтан ук килүче бу «мифологик поэзия»нең («мәктәп» дияргә кыюлыгым җитми) мәгънәсе шунда—мифологик сюжетка корылган әсәрләр нигезендә реаль тормыш мәгънәләре, образлары, күренешләре, вакыйгалары ята. Һәм бу мәгънәләр, образлар гаять дәрәҗәдә тирән яшерелгән була, аларны гади күз белән генә күреп тә, гади күңел белән генә тоеп та булмый. Хәзергә кадәр Бабичның «Газазил»ен, «Кандала»сын «сүтә» алганыбыз, һәм хәзергә кадәр Такташның «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Таң кызы», «Күләгәләр», «Янар таулар», ниһаять, «Җир уллары трагедиясе»н ахырга кадәр аңлап җитә алганыбыз юк. Аларны егерменче елларда Такташка «әдәби суд» оештырып йөргән ЧК иярченнәре дә, утызынчы-кырыгынчы еллардагы культ идеологлары да, «алтмышынчылар», «җитмешенчеләр» дә, бүгенге әдәбият белгечләре дә аңламады. Моның нәтиҗәсе аянычлы—әнә бүген дә Такташка кизәнүче галимнәр табылып тора. Бөтен бер Фәннәр Академиясендә Такташ иҗатын өйрәнүче галим юк. Аспирантлар арасында да андый яшьләр күренми.

Шагыйрьнең башка әсәрләрен укучы игътибарына калдырам. «Җир уллары» хакында гына берничә сүз. Бу трагедияне мин кешелек тарихының, кеше психологиясенең энциклопедиясе дияр идем. Бабичның «Газазил»ен кабул иткән кебек, һәр чор укучысы бу әсәрне үзенчә аңлый. Әмма төп принцип үзгәрмичә кала: идея (иман)—беренчел, хәлиткеч һәм мәңгелек. Ахыр килеп, Такташ соңгы чор иҗатын да шул ук концепциягә кора. Әмма бу юлы инде ул, телиме-теләмиме, әлеге идеяне большевизм һәм коммунлык эчтәлеге белән алыштыра («Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар» h. б.) Ләкин әхлакый нигезне барыбер үзгәртми.

Идеологик шаукымнан азатрак әсәрләрендә, бигрәк тә «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә һәм «Алсу» әсәрендә бу әхлакый момент аеруча ачык төсмерләнә.

Бабичтан килүче икенче традиция ритмда, рифмада, интонациядә һәм аһәңдә күренә. Ирекле, хәтта бунтарь рухлы өслүб, аһәң, интонация татар шигырендә Кандалыйдан ук килә. Ул С. Рәмиев, Ш. Бабич иҗатларында көчәйтелеп, Такташ иҗатында югары дәрәҗәсенә ирешә. Бу хактагы тикшеренүләрне галимнәргә калдырып, бер нәрсәне генә искәртәсем килә: егерменче елларда образлар кризисы кичергән Такташ үзенең рухи потенциалын интонациядә ача башлый...

Бабич белән Такташ очрашканнармы? Мин бу хакта күп эзләндем, күп

уйландым һәм «очрашканнар» дигән фикергә килдем. Юк, алар күзгә-күз очрашмаганнар. Әмма Такташ Бабичның эзенә басып йөргән. 1918 елда Урта Азиядән Сыркыдыга кайткач, Такташ укытучы булып эшли. Әмма әдәби иҗатка, белемгә омтылу Такташны 1919 елның көзендә Оренбургка алып килә. Ул анда «Юксыллар сүзе» газитендә җаваплы секретарь булып эшкә урнаша, Афзал Таһиров кебек күренекле әдипләр белән таныша, мәдәни чараларда актив катнаша, политик курсларда укый. Оренбург әле шагыйрь Бабичны әйбәт хәтерли, аның ялкынлы һәм бунтарь иҗатының серле гипнозында яшәвен дәвам итә. Бабичны «Юксыллар сүзе» газитендә яхшы беләләр, бу яклап та Такташ аның үкчәсенә басып бара. Ш. Бабичның «Язгы җыр» әсәренә аваздаш «Урман кызы» әсәрен язу идеясе дә Такташта Оренбургта туа. Нәкъ шушы чорда ул чын Бабич рухында фикер йөртә башлый:

Үтте еллар... Эзләдем мин, эзләдем бер тугры дин,
Тапмадым, әмма югалттым бар иман,
«Алла»мны мин...

Әйе, минемчә, Такташ Такташ буларак нәкъ менә Оренбург чорында, Бабичның бу шәһәрдә калган гипнозы тәэсирендә формалаша. Һәм Ташкентка, Казанга киткәнче үк:

Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны
Егълатырга. Әйе, миндә көчле Байроннар җаны,—

дип әйтерлек шәхескә әверелә.

Мине Такташ белән очраштырган тагын бер шәхес—Зәбих Искужин. Аның хакында татар укучысы бик аз белә. Ә бит бу кеше татар әдәбияты өчен бәһа биргесез эшләр эшләп калдырган.

З. Искужинның гомер юлы да Бабич, Такташ юлына тәңгәл бара. Уфа губернасының Зилаир төбәгендә туган Зәбих Оренбургта укый, Такташны да шунда күрә. Аның Зилаирда яшәүче әтисе исә 1919 елның язында шовинистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән Бабич һәлакәтенең шаһите була. Шул вакытта ук Зәбих шәкерт Бабич иҗатын өйрәнергә сүз бирә. Оренбургта чакта Бабич янына Такташ өстәлә. Шушы максатлары аны утызынчы еллар башында Казанга алып килә. Монда ул педагогия институтында укытучы Галимҗан Нигъмәти җитәкчелегендә аспирантурада укый башлый. Такташ һәм Бабич иҗатларына багышланган хезмәтләр өстендә ул берьюлы эшли. Әмма Такташ хакындагы монографиясен алдарак тәмамлый.

Шул чордагы бер көндәлегенә З. Искужин түбәндәге юлларны язып куйган: «Такташта стиль, тематика мәсьәләсе (20 басма табак), 2 нче февраль, 1935 ел».

Һәм тагын: «Көндезге сәг. 2:05 минут. 15 нче февраль, 1935 ел: Такташ турында төп фикерем әйтелеп бетте бугай. Фикерләр кабатлана башлады. Ярый, караламаны акка күчерәсе, аннан соң...

Җитәр. Ялыктым...
Инде Бабичка, Бабичка!»
Шунда ук шигырь:

Һади, синең көчле елларымның
Менә дигәннәрен бирдем мин.
Чөнки синдә йөрәк хисләремә
Азык мул икәнен күрдем мин.

Уйлама син тагы, мин биредә
Сине генә «сүгеп» үтә дип.

Сиңа ыргытылган ачы сүзләр
Үзәмә дә тиеп китә бит.

Мине Оренбурның тынлыгыннан
Синең уйлар тартты Казанга.
Шуңа менә, ихлас дәртем салып,
Синең хакта китап язам да.

*15.02. 35 ел, Дәүләт университеты китапханәсе».*

Яшь галимнең биш еллык гомерен алган бу хезмәт Татгизда чират көтеп еллар буе ята. Әмма ул һаман басылмый. Нindидер бер көч аны тоткарлый, басмага юл бирми. З. Искужин үзенең кайбер хатларында бу хакта күңел әрнүе белән яза.

Менә Г. Галигә язган бер хат кисәге:

*«Гомәр ага!*

*Сезгә бик зур утенеч белән кергән идем. Мин әнә шул кулыгыздагы китапка сездән бер фикер аласым килә иде. Ип. Н. һаман соңлатырга, әкренәйтергә чамалый. Ә беләсез, миңа инде алда Бабичны эшләү өчен бер стимул кирәк. Бу, шиксез, шул Такташны бастырып чыгару-чыгармау белән бәйләнгән. Татгиз җәй чыгарырга уйлый. Сез, карап чыгып, бер фикер әйтә күрегез инде! 1.07.35. Искужин».*

Кызганычка каршы, З. Искужинның Такташ иҗатына багышланган монографиясе дә, Бабич хакындагы китабы да (диссертациясе) дөнья күрә алмый, 1935-1937 елларда серле рәвештә эзсез югала. Махсус эзләп карадым: дәүләт архивында да, нәшрият архивында да бу хезмәтләр сакланмаган, бары тик З. Искужинның шактый туздырылган шәхси архивында (аны ИЯЛИ архивына Мөхәммәт Гайнуллин тапшырган) гына бу китапларның кайбер караламалары сакланып калган.

З. Искужинның язмышы да аянычлы. Г. Нигъмәти белән алар арасында нәрсә булгандыр, хәзер әйтүе кыен. Әмма З. Искужинның гыйльми карьерасы өзелә, ул пединституттан чыгарыла, башка җиргә эшкә урнаша алмыйча шактый интегеп йөри, баш очында кара болытлар да куера башлый... Әмма ул кулга алынырга өлгерми, ачлыктан һәм авырулардан вафат була.

Менә шундый тарих. Безнең тарих. 20 басма табаклык гыйльми хезмәтнең югалу тарихы. Такташ вафатыннан соң биш ел дигәндә, безнең кулда шундый күләмле хезмәт булган! Кайда ул? Нәрсә хакында ул? Иң аянычлысы бу да түгел әле. Мин үзем Зәбих Искужинның шәхси архивын сиксәненче еллар башында ук тәртипкә салып, битен биткә теркәп, тасвирлап куйдым. Ел ярым эшләнгән эшем белән мин хәзер дә горурланып яшим. Дистәләгән папкалардан торган бу фонд хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр Академиясенең гыйльми архивында саклана. Такташ хакындагы язмалар тасвирламасы да бар анда. Ни гаҗәп, кызыксынучы кеше генә юк! Югыйсә, З. Искужинның Такташка багышланган хезмәтен күпме бар шул күләмдә булса да дөньяга чыгарырга вакыт инде!

Мине «Такташ орбитасы» на алып кергән тагын бер кеше—өлкән дустым һәм остазым Хатип ага Госман. Бу бөек кеше мине, әдәби әсәрне генә түгел, әдәби әсәр аша аның авторының шәхесен дә тоярга өйрәтте. Бабич белән дә, Такташ белән дә, башкалар белән дә шулай булды. Әдәбияттагы психологик башлангыч әлегә бик аз өйрәнелгән. Ә бит теләсә кайсы әдәби әсәрдә автор җаныннан өзелеп калган күзәнәк яши. Шигырьне яисә повестьне аңлар өчен әнә шул җан күзәнәген кузгатырга, уятырга һәм яшәтә башларга кирәк. Профессор Х. Госман шулай өйрәтә иде.

Әйе, әсәрне укыганда аның авторы белән серле бер магик бәйләнешкә керү мөһим. Әсәр сиңа «җанын ачарга» тиеш. Такташ әсәрләрен шунсыз аңлап та, күңелгә кабул итеп тә булмый. Бигрәк тә Такташ әсәрләрен! Ни өчен Такташ әсәрләрен тәрҗемә итеп булмый? Чөнки җанны (моңны, гамьне) тәрҗемә итеп булмый!

Укучыларга мәгълүмдер: Хатип Госман Такташның тормышына һәм иҗатына махсус хезмәт багышлады. Әлбәттә, аңа кадәр дә, аннан соң да Такташ хакында монографияләр күренгәләде. З. Искужиннан соң Такташка М. Мамин, Х. Хәйри һәм Г. Халит мөрәҗәгать иттеләр, әмма Х. Госман хезмәте үзенчә бер тирәнлек һәм җылылык белән аерылып тора. Без бу хезмәтне бик тиз һәм хаксызга оныттык, дип уйлыйм. Чөнки Такташның «җан диалектикасын», аның иҗатының логик барышын профессор Х. Госманнан да тирәнрәк анализлаган галим юк. Дөрес, бу хезмәттә сәяси өскормага шактый урын бирелә. Әмма үзәктә бу түгел. Үзәктә—Такташның поэтик осталыгы һәм новаторлыгы, тагын... аның әдәбияттагы каһарманлыгы!

1924 елның 27 апрелендә Коммунистик клуб йортында (хәзерге авиация техникумы бинасы) сулфчылар тарафыннан Һ. Такташ иҗатына каршы оештырылган әдәби суд хакында да беренче булып Хатип агадан ишеттем. Әйе, егерменче елларда шундый судлар практикага кергән була. Мондый җыелышларда Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш кебек әдипләребезнең җанын нык җәфалыйлар.

Башкаларныкыннан «Такташ суды» шактый аерылып тора. Чөнки ул үзен үзе яклап чыга. Гаяз Ризванов дигән төп докладчыга да, башкаларга да ул төпле, нигезле итеп отпор бирә. «Аларда (сулфчыларда.—Г. Г.) психологическая искренность юк. Алар техниканы, машина-заводларны җырлап, аларны кем эшләп чыгарганын әйтмиләр, ышеләләр. Ә Такташ, революциягә ныклап катнашканлыктан, тормышның эченә керә,—ди ул. Аннары өсти:—Такташ революциягә киләме, юкмы, дип көтәсе юк, ул хәзер килгән инде!»

«Кызыл Татарстан» газетенең 1924 ел 13 май санында бу суд-диспут хакында хәбәр басыла. «Шагыйрьне кат-кат алкышлагач, резолюциясез-нисез генә диспут ябылды»,—дип тәмамлана ул.

Хатип ага Такташны фанатикларча ярата иде. Күп шигырьләрен, хәтта поэмаларын яттан белә иде. Кычкырып сөйләргә ярата иде. «Такташ менә шулай укыган»,—дип, җилкенә-җилкенә сөйли иде. Миңа калса, аны күбрәк Такташтагы бунтарьлык җәлеп итте. Бунтарь, гыйсъянчы Такташ—аның күңелендә яшәгән иң матур образларның берсе булгандыр.

Шундый вакыйга истә калган. Хатип ага картайган көнендә дача йорты салып йөрде. «Йорт өмәсе»нә мин дә элэктем. Иске йортны сүтеп аттык та яңа бура өчен урын әмәлли башладык. Менә бәла: яңа бура иске йорттан зуррак булып чыкты. Аны якында гына үсеп утырган каенны кисмичә урнаштырып булмаячак. Кемдер пычкы алып килде, зифа, күркәм каенны кисәргә җыена башлады.

Моны Хатип ага күреп алган. Ул өермә кебек пыр тузып килде дә теге кешедән пычкыны тартып алды. «Бу бит Такташ каены, нишлисез сез!»—дип кычкырганын сизми дә калды. Осталар: «Бурага урын тар калган, кисмичә булмый»,—дигәннәр иде, ул соңгы хөкемен әйтте: «Сыймаса, әнә бураны кыскартыгыз, тик бу каенга кагыласы булмагыз!»—диде.

Соңыннан сорашып белдем. Ул Такташ хакындагы хезмәтен шушы каенга карап язган икән. Хатип аганың язу өстәлендә дә Такташның сурәте тора иде. «Аның белән сөйләшеп җанны тынычландырам»,—ди иде ул.

Хатип ага Һ. Такташның улы Рафаэль Такташ белән хат алышып яшәде. Рафаэль абыйның бу хатларын миңа да укыды. Бервакыт ул миңа Р. Такташның бер озын хатын тоттырды да: «Укып фикереңне әйт әле»,—диде. Шулай туры килгән инде, мин берничә барып та остазымны туры китерә алмагач, бу хатны ераккарак куйганмын һәм... аның хакында онытканмын. Хәзер ул хат миндә. Ул хат чынлап та серле һәм принципиаль хат иде. Анда язылганнарны мин әле дә акка төшерә алмыйм. Әмма бу хат миңа нык тәэсир итте һәм Такташның шәхесен тагын да ныграк аңларга булышты. Рәхмәт сиңа, Рафаэль абый! Рәхмәт сиңа, Хатип ага!

Мине Такташ белән күп мәртәбәләр очраштырган тагын бер шәхес бар—Хәсән Туфан. Ул да Такташ хакында тыныч кына сөйли алмый иде. Ниндидер бер эчке тетрәнү һәм ярсыну белән, гәүдәсе белән калкына-калкына сөйли иде. Гүя бу вакытта аның иңенә канатлар үсеп чыга да, талгын гына кагынып, аны күккә, галәм киңлекләренә алып китәргә тели...

Туфан—Такташ дуслыгының тарихы 1924 елдан башлана. Бу хакта Туфан үзе язып калдырган: «Бөек Тукайдан соң поэзиядәге күренекле бер вакыйга буларак Бабич килеп китте, аңардан соң шундый ук вакыйга булып Такташ килеп чыкты. Көмеш кыңгырау дигән төшенчә бар. Такташның шигъри авазы көмеш кыңгырау гына түгел, алтын кыңгырау булып тоелды. Эшләрне, укытуларны ташлап, Такташлы Казанга килдем».

Казанда бу ике шагыйрьнең тормышы, иҗаты гел үрелеп барган. Бу хакта бик күп хатирәләр сакланган. Тагын Туфанны тыңлыйбыз: «Такташның ялгыз чагы, беренче Гөлчирәсеннән аерылган еллары иде. Төннәрдә, кайдан булса кайтып килешли, мин аңа кунарга керә идем. Төн урталары булса да, чәй янында сөйләшеп утыргач, идәнгә урын салып, серләшә-серләшә йоклап китә идек. Мин уянганда, Такташ күптән торган була иде инде... Такташның «Туфан йоклый» дип башлаган шигыре 1930 елның көзендә, «Киләчәккә хатлар»га керешер алдыннан язылган булса кирәк...»

Х. Туфанның Такташка мөнәсәбәте бик үзенчәлекле иде. Үз хатирәләрендә ул аны халкы өчен үзен корбан иткән фидакарь бер җан итеп

тасвирлый иде. Мин соңыннан Хәсән аганың бу фикерен «Җырланган җырлар турында» исемле язмасында танып сөендем. Менә шуннан бер өзек.

«Халык телендә бер легенда бар. Диңгездә давыл күтәрелгәндә, җилкәнле көймәләрне һәлакәттән коткарып калу өчен (гаҗәп зур балык рәвешенә кергән диңгез анасына корбан буларак) берәр фидакарь суга ташланырга тиеш булган. Тукай моны 1905 ел революциясеннән соңгы реакция чорында иҗтимагый җирлеккә күчереп:

Көймә бата... йота торган балык өчен
Үзен фида итә алган бер җан кирәк!—

дип, ил өчен фида булырга әзер икәнен әйтә.

Икенче бер классигыбыз да:

Кайсы юллар, нинди упкын
Тарта безне җан сорап...—

дип, шул ук фикерне куәтли. Такташ та шуны ук, ләкин Такташча югары накал белән, кан тамырлары шартлап китәрлек киеренкелек белән әйтә:

Төн уртасы, әнкәй, мин дар ясыйм.
Өмер булган мине асарга.
Мин дар ясыйм яшь бер пәйгамбәргә,
Дарга басып күккә ашарга...

Шагыйрьләр тумыштан ук фидакарь җанлылар алар».

Такташка «пәйгамбәрлек» статусы бирә Туфан. «Пәйгамбәр» сүзенең синонимы—«Шигырь»? «Шагыйрь! Кем ул?—дип сорый Туфан. Үзе үк җавап та бирә.—Шагыйрь шигырь язучы гына түгел, шагыйрь—үзе шигырь ул. Шигырь дигән сүзне әйтү белән күңел күзе алдына Тукайлар, Есениннар килеп баса. Такташ шундыйларның берсе иде. Такташ—шигырь иде ул».

Тагын бер язма: «Шундый шигырьләрне иҗат итә алган шагыйрь җирдән, анадан туып түгел, легендалар, эпослар, халык әкиятләре дөньясы эченнән килеп чыккандыр кебек булып тоелды. Гадәти гади кеше генә түгел бу, чын талантның, иҗади кодрәтнең көче булып гәүдәләнешедер бу, дигән фикер тудырды. Такташның үзен күреп белгәч тә, аның белән иң якын дусларча бергә яшәгән елларда да бу тойгы үзгәрмәде».

Хәсән ага Такташның үлеме хакында тыныч кына сөйли алмый иде. Трибун шагыйрьнең сәер үлеме әлегә кадәр җәмәгатьчелеккә сер булып кала. бу хакта Хәсән ага кат-кат әйтә иде.

«Байтак иптәшләр бездән: «Нишләп Такташны авырудан аралый алмадыгыз? Ул нишләп шулай тиз үлде?»—дип сорыйлар. Такташның нигә терелмәве хәзер дә ачык түгел. Мин барганда Такташ янында врач юк иде. Гөлчәһрә (Такташның икенче хатыны—Г. Г.) миңа: «Такташны дәвалап йөрүче докторны Һади, аңына килгәндә, куды, аны яңадан китермәскә кушты»,—дип сөйләде. Бу көннәрдә Такташны дәвалау икенче күренекле врачка тапшырылган иде. Соңыннан, Такташ үлгәч, кайсы оешмадандыр килеп, беренче докторның рецептларын, тикшерү өчен, алып киткәннәр. Тифның шулай Такташны алып китәрлек дәрәҗәгә килүе безгә әле һаман гаҗәп хәл булып тоела».

Әлбәттә, Такташ сизенгән. Ул, хәтта, нидер белгән. Төгәл белгән. Әмма бу хакта әйтеп җиткерә генә алмаган. Тагын Туфан сөйли: «Такташ, үләр алдыннан, бөтенләй аңына килде. Ул безгә һаман сөйләде, соңгы сүзләрен әйтте. Ләкин ул шулкадәр хәлсез иде ки, бары иреннәре генә хәрәкәтләнә, ә тавышы юк иде. Никадәр тырышсак та, бер генә сүзен дә ачык ишетә алмадык...»

Икенче бер урында Хәсән ага Такташның үз үлемен сизүе, тоюы хакында тетрәнеп яза: «Такташ... күркәм, таза, нык кеше иде. Көтмәгәндә, һичбер көтмәгәндә, очраклы тифтан гына башланган нәрсәнең кинәт менингитка әйләнеп китүе аның могҗиза кебек гаҗәп гомерен чикләде. Әйтерсең лә шулай буласын җаны алдан ук сизгән. «Нәни шаярулар»ы арасындагы:

Ашкынып җырланган теләкләрнең
Чәчәкләрен килә күрәсе...
Аһ, үләсе килми, үләсе...

Яки: «Әйтче, кайсын шунда җырлап бетереп була безгә тигән кыска гомернең»,—дип куйгалавы, шигырьләренең дөньяга чыкмаган бер вариантында: «Әйтергә дә оят. 30 яшькә җитми арылган...» рәвешендәге сүзләре сагайта, уйландыра иде...»

Ниһаять, Хәсән ага яшьлек дусты, мәхәббәт җырчысы Такташның шундый бер шигырен искә ала:

Мәхәббәт—ул үлем юлы түгел.
Аны тудыра яшәү ялкыны.
Киләчәккә безнең каныбыздан
Тормыш үтә аның аркылы.
Аһ, син, үлем,
Ничек үләргә соң?
Сагыныр кешеләр синдә булганда?

Бу мәкаләмне дә Хәсән ага Туфанның 1975 елда әйтелгән сүзләренә ялгап бетерәсем килә. Ничек кенә тырышсам да, аннан да әйбәтрәк әйтә алмам кебек.

«Ул—мөлаем, күркәм, олы җанлы, көләч күңелле, матур, атлет төзелешле, нык, исән-сау егет иде. Һич тә көтмәгәндә, кинәт авырып, атна-ун көн эчендә, гүя янды ул,—Такташсыз калдык. Такташсыз калуыбызга 44 ел үтте инде. Кара чәчләр агарды. Тагын бер гомергә җитәрлек еллар узып китте. Ә мин һаман аның истәлеге алдында хәйран калып басып торам».

*2001 ел, ноябрь.*

---

## КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ:

Журналның быелгы өченче саны шигърият һәм чәчмә әсәрләргә аеруча бай. Шигырь сөючеләр, мәсәлән, Татарстанның халык шагыйре **Равил Фәйзуллинның** яңа әсәрләре белән бергә **Рашат Низами, Фирая Зыятдинова** һәм **Фирүзә Җамалетдинова** шигырьләре белән таныша алыр. Казанда яшәүче урыс шагыйрәсе **Ольга Левадная** әсәрләре татарчага шагыйрь Зөлфәт тәрҗемәсендә тәкъдим ителә.

Чәчмә әсәрләрдән **Марат Әмирхановның** "Тояк эзе" романының азагы дөнья күрәчәк. Байтак еллар ТУ-124 һава лайнерында беренче пилот булып эшләгән язучы **Рәшит Ибраһимовның** "Очучы язмалары" да журнал укучыларга үзенең тематик яңалыгы белән кызыклы булыр. Болардан тыш яшь язучылар **Нурзилә** хикәяләре һәм **Айгөл Нуретдинованың** балаларга атап язылган әкиятләре дә басылып чыгачак.

Журнал дөнья әдәбияты үрнәкләре белән таныштыруны дәвам иттерә. Бу санда атаклы детектив остасы, инглиз язучысы **Агата Кристиның** "Гаепләүче шаһит" дип исемләнгән хикәясе урын алыр. Аны татарчага әдәбиятыбызга илле еллап хезмәтен багышлаган тәрҗемә остасы **Саимә апа Ибраһимова** тәкъдим итә.

Журналда шулай ук галим һәм яшь язучы **Нурулла Гарифның** урта гасырларда Алтын Урда шәһәрләре гөрләп торган Әстерхан якларына сәяхәт турындагы күләмле юлъязмасы, шагыйрә **Нәҗибә Сафинаның** тәнкыйтьче, әдәбият галиме Сәгыйдулла Хафизовка ачык хат рәвешендә язылган һәм Башкортстандагы милли сәясәтнең күздән яшерелгән кайбер якларын ачарга омтылган мәкаләсе урнаштырылачак.

*Казанның 1000 еллыгына*

# ХАНЛЫК ЧОРЫНДА БОЛАК АРЪЯГЫ КАЗАНЫ

Казан турында аз язылмаган. Меңъеллык шәһәребезнең үткәне турында елъязмалар, тарихи документлар һәм археологик истәлекләр сөйли, матбугат битләрендә көн күргән күп санлы мәкаләләр һәм монографияләр, әдәби һәм публицистик әсәрләр аның шөһрәтле сәхифәләрен яктырта. XV—XVI гасырларда Көнчыгыш Европада иң гүзәл калаларның берсе булган Казанның тарихи үзәге—кремле, анда булган урамнар, капкалар һәм биналар турында тарихи әдәбиятта байтак материал бар, ханлык башкаласының сәяси һәм икътисади тормышы да халкыбызга ярыйсы ук житкерелгән. Әмма ул чорда шәһәр яны булып, бүгенге көндә аның территориясенә кергән авыл һәм бистәләрнең барлыкка килү, тормыш-көнкүреш һәм этимология мәсьәләләрен өйрәнмичә, аларның кала белән мөнәсәбәтләрен белмичә мәркәзебезнең тарихын тулы итеп күз алдына китереп булмас иде. Әйтергә кирәк, бу жирләрнең күпчелеге (мәсәлән, Болак арты һәм Кабан арты), археологлар күрсәткәнчә, Казанның тарихи үзәгеннән, шул исәптән кремльдән дә, кешеләр тарафыннан алданрак үзләштерелгән *(Казань в памятниках истории и культуры.—Казань, 1982; Археологическое изучение булгарских городов: сборник/ редкол: Ф. Ш. Хузин и др.,—Казань, 1998).* Бу мәкаләдә без Болак аръягы авыл-бистәләренең (кызганычка каршы, аларның тарихы гафу ителмәслек дәрәжәдә аз өйрәнелгән) үткәнен чагылдыруны максат итеп куймыйча, Болак төбәгенең урыслар яулап алганчыга кадәр татар Казанындагы ролен чагылдыру һәм аның урта гасыр шәһәре өчен хужалык һәм фортификация ягыннан әһәмиятен күрсәтеп китү белән чикләнергә булдык.

Археологик тикшеренүләр Болак буенда борынгыдан кешеләр яшәгәнлеген күрсәтә. Монда неолит, бронза, Казан алды һәм болгар чорына караган торак урыннар булган. Ләкин бу жирләрне актив үзләштерү XIV—XVI гасырларда, Казан шәһәре болгар-татарның төньяк жирләренең сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәгенә әверелү чорында башлана. Болак буенда, аның аръягында авыллар һәм бистәләр үсә, зурая, яналары барлыкка килә. Болар—Көрәеш бистәсе, Бишбалта авылы һәм 1552 елгы фажигадән соң татар исемнәрен югалтып, урыс торак пунктлары булып киткән татар авыллары һәм бистәләре—Архангельская, Архиепископская, Преображенская, Ямская, Мокрая h. б.

Болак төбәген үзләштерү урынның рельефын ясалма үзгәртү юлы белән алып барыла. Сазлыклы урыннар күмелә, киптерү каналлары казыла, Болакның агымы үзгәртелә. Болакның, елга булудан битәр, озынча күл булуы ихтимал. Андый күлләр Казанда аз булмаган. Хәзерге Тукай мәйданы урынында булган Гүзи күле, Ак Мунча һәм Черек күлләр дә озынча булганнар. Казанлыларның зур хезмәт куюлары—каналлар казу, су юлын үзгәртү h. б. нәтижәсендә Болак күл ага торган, хәтта суднолар йөзә алган елгага әйләнә. Урыны белән «бигрәк тә ләмле һәм үтеп чыга алмаслык» *(Курбский А. История князя великого Московского.—СПб.,—1902.—С. 16)* елга Түбән Кабан күлен һәм Казансуны тоташтырган, озынлыгы 2,25 чакрымга житкән. Елга суны Кабаннан, жир асты һәм яр буе чишмәләреннән алган (мәсәлән, урыслар «Тайницкий ключ» дип йөрткән чишмәдән); яңгыр һәм язгы кар сулары күп санлы чокыр-ерганаклар буенча килеп, Болакны мул сулы иткән. Тукай мәйданы янындагы ерганак суы елга өчен аеруча әһәмиятле булган. Бу жирләр (Түбән Кабан, Болакның көньяк

очы һәм Гүзи күле районы) сазлыклы түбәнлектә булып, монда кешеләр яши алмаган. Казансуга койган урында, төньякта, Болак икегә бүленгән: кала янындагысын Черек Болак дип, көнбатыштагы агымын Зур Болак дип йөрткәннәр. «Казан тарихы»нда, безнен уйлавыбызча, Черек Болак турында әйтелә: «Болак елгасы Казан елгасына шәһәр астыннан агып чыга, суы пычрак һәм ләмле, бик тирән дә түгел» (*Казанская история.—М.—Л.—1954.—С. 127*). Бу урында елганын ләмле халәте ясалма рәвештә аны буып, шәһәрне дошманнардан саклау өчен эшләнгән булуы ихтимал. XVI гасырда Болакнын урта агымы хәзергегә караганда киңрәк һәм тирәнрәк булып, 2 метр чамасы су торган, балык йөзгән (*Н. М. Мингазова. Ю. С. Котов. Казанские озера (исторический обзор).—Изд-во Казан. ун-та.—Казан—1989.—С. 48*). Язгы ташу вакытында елга агымы үзгәргән. Идел һәм Казансу елгаларынын мул су ташкыннары Болак буйлап Түбән Кабанга менгәннәр, ә жәй башында барлыкка килгән кире агым күл һәм елганы сафландырып торган. Әйтергә кирәк, Болак Казан өчен елга порты ролен үтәгән: Идел буйлап шәһәргә килгән зур сәүдә судонолары Казансу елгасы тамагында туктарга мәжбүр булганнар, товар мондагы пристаньнарда Бишбалтада, Бакаллада, Елантауда) күп санлы кечкенә судноларга бушатылып, Казансудан Болакка менгән, шуннан каланын сәүдә нокталарына житкерелгән. Казанга уңайлы коры жир юллары аз булганлыктан, Идел—Казансу—Болак су юлы шәһәрнең төп сәүдә артериясе саналган.

Казанлылар елганын хәлен даими күзәтеп торганнар: анын үзәнен күп тапкырлар турайтканнар һәм тигезләгәннәр, яр буйларын чистартканнар һәм ныгытканнар. 1505 елда, Мөхәммәтәмин хан чорында, Болакнын төбе һәм ярлары имән бүрәнәләргә төренә, ә мона кадәр анын төбенә таш жәелгән булган. Шул нисбәттән «Казан хәбәрләре» газетасы 1929 елда «Болак кушылдыгы борынгы заманнардан ук яшәп килгән ясалма канал», дигән нәтижә ясый.



*XX гасыр башында Болак*

Болак артынын байтак өлеше язгы ташуларда су астында калганлыктан, монда жәй чилләсендә дә кипмәс сазлыклы жирләр өстенлек итә. Кешеләр елганын урта агымында урнашкан ике калкулыкта гына яши алганнар: беренчесе—хәзерге Колхоз базары тирәсендә Көрәеш бистәсе булып, икенчесе—аннан төньяктарак, археологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, XIII—XIV гасырларда барлыкка килгән болгар-татар авылы. XVI гасырнын икенче яртысында шушы авыл нигезендә урыс торак пункты—Ямчылар бистәсе формалаша. Шушы бистә тирәсендә халык телендә Патша күле (Царево озеро) дип йөртелгән күл булган. XIX гасырнын 70 нче елларында бу күлнең яшәве билгеле (*Заринский П. Очерки древней Казани, преимущественно XVI века.—Казан.—1877—С. 212*) Болакнын түбәнге, Казансуга якын агымында, жәйге Ташаяк ярминкәсе гөрләгән (хәзерге цирк һәм Бауман урамы башланган урын арасы). Халык монда даими яши алмаса да судноляр өчен причаллар, пристань тоткан, базар өчен корылмалар төзегән, дөньянын күп илләреннән килгән кунакларны—сәүдәгәрләрне каршы алган, аларга сату-алу һәм яшәү өчен шартлар тудырган. Корылмалардан бары тик таштан эшләнгән Таһир мунчасы гына безгә билгеле: 1552 елнын 25 августына каршы төндә Казанны штурмлаганда урыс укчылары «Болакнын икенче, шәһәргә якын ягында чокырлар казыдылар һәм татарларга шәһәрдән чыгарга мөмкинлек бирмәделәр. Һәм анда, шәһәр дивары астында, Даир дип йөртелгән таш мунча бар, шушы мунчада воевода кушуы буенча урнаштылар» дип хәбәр итә елъязмачы (*Древняя Казань глазами историков и современников (составители и авторы комментариев Ф. Ш. Хузин, А. Г. Ситдиков).—Казань.—Изд-во «Фест».—1996.—С. 38*). Бу мунча (монда тагын берничә мунча

салынганлыгы билгеле) кремль калкулыгының инеш-чишмәләргә бай төньяк-көнбатыш итәгендә, Болакның Казансуга койган урыныннан ерак булмаган җирдә урнашкан булган.

Казанлылар Болак артын XV—XVI гасырлар чигендә интенсив үзләштерүгә керешәләр. Елга аркылы күперләр салына, төрле үләннәргә бай көтүлекләр, тезелеп киткән бакчалар, хуш исле печән болыннары барлыкка килә, балыклы дистәләгән күлләр һәм елгалар кешегә хезмәт итә башлый. Көрәеш бистәсеннән көнбатышта Эчке Казан (Ичка) дип йөртелгән елга агып яткан, ул Түбәнге Кабан һәм Болак арасында урнашкан күп санлы кечкенә күлләр, инеш-чишмәләрдән туенган. Бу елга Зур Болактан 200 метр көнбатышта башланып, көньяк һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә агып, Казансу тамагыннан көнчыгыш якта 3 км. ераклыкта Иделгә койган (тамагы Иске дамба дип аталган урында булган). Эчке Казан XVII гасыр һәм аннан соңгы Казан шәһәренең планнарында озынча һәм боргаланып яткан күлләр һәм кушылдыкларның чолганып беткән чылбыр булып күренә. Казанлылар бу елгадан XV—XVI гасырларда интенсив файдаланганнар, чөнки моннан су юлы, Елантауны әйләнеп үткән Туры Казанга караганда, кыскарак булган *(Калинин Н. Ф. История Казани с древнейших времен до XVII века// Рукопись докт. дисс.—Архив ИЯЛИ АНТ.—Ф. 8, Оп. 1, Ед. хр. 202).* Шушы шактый ук мул сулы елга белән Түбәнге Кабан күле арасында куе кара урман башланган, ул күлнең көнчыгыш яры буйлап дәвам итеп, Арча урманы белән кушылган. Болактан алып Тирән Үзәк дип аталган үзәнгә кадәр елъязмаларда телгә алынган Падишаһ болыны (Царев луг) җәелеп яткан, һәр җәйдә шунда сабантуй, ат чабышлары, хәрби өйрәнүләр үткәрелгән, шәһәр халкы йөзләгән чатырлар корып, елның иң матур мизгелен саф һавада, кәеф-сафа корып уздырган. Бу болын турында А. Курбский: «зур, киң һәм бик матур болыннар... шәһәргә кадәр арада бер мильдән артыграк булыр... җәелгән», дип сурәтли *(Курбский А. История князя великого Московского.—СПб.—1902.—С. 20).* «Казан елъязмачысы»: «Болактан алып Иделгә кадәр җиде чакрымга гүзәл һәм дәү Падишаһ болыны җәелгән, ул күп төрле үләннәргә һәм чәчәкләргә бизәнеп төренгән», ди. *(Казанская история (подготовка текста, вступительная статья и примечания Г. Н. Моисеевой).—М.—Л.,—1954. С. 128).* Шушы болыннар аркылы Кабан артына таба—Кырым юлы, Иделгә юнәлеп Мәскәү юлы үткән. Иделдә данлыклы Сәүдә (Гостиный остров) утравы булып, һәр елны 24 июньдә халыкара ярминкә башланган, анда «бөтен Рус җиреннән бай сәүдәгәрләр һәм ерак илләрдән килүчеләр... кыйммәтле бихисап күп товарлары белән сәүдә иткәннәр» *(ПСРЛ, т. XIV.—С. 23).* Ярминкәнең каладан 5-6 чакрымда булуы транзит сәүдәсе өчен өстенлек тудырган. Казансуның Иделгә кушылган өлеше—тамагы Тирән Үзәк дип аталган, халык монда даими яшәмәсә дә, пристаньнар тоткан. Гомумән, Идел елгасының Казансу тамагы, сәүдә максатыннан тыш, татар башкаласының көнбатыш, төп капкасы ролен дә үтәгән. Шушында килгән кунакларны каршы алганнар, каладан читкә китүчеләр монда туктап, ял иткәннәр. Казанны яуларга килүче урыс гаскәрләре Тирән Үзәктә туктый торган булганнар, әсирләр алмашу да бу үзәндә башкарылган. 1551 елның 14 августында Казан ханлыгы өчен үтә дә әһәмиятле мәсьәлә—Тау ягының язмышын хәл иткән корылтай да монда чакырылган.

Билгеле булганча, урысларның Казанга һөҗүме, күпчелек очракта, гаскәрнең Казансу тамагына—Тирән Үзәккә килеп төшүе белән башланган. 6-7 чакрымга сузылган елга-инеш һәм күлләргә бай сазлыклы болынны үтеп, гаскәрләр Болак аркылы күперләр салып, Түбән Кабан күленең урманлы яры буйлап Арча кырына җиткәннәр, шуннан торып шәһәрне штурмлаганнар. 1530 елда Казанга урыслар тарафыннан янә куркыныч янагач, дошманны шәһәр оборонасының йомшак җиренә—Арча кырына үткәрмәү максатында Сафагәрәй хан шәһәрнең көнбатыш ягын, беренче чиратта, Болак аръягын ныгыту эшенә керешә. «Барлык олысларына казан кенәзләрен һәм морзаларын җибәреп, аларга Казанга җыелырга һәм Болак тирәсенә урнашырга һәм Казанга якын-тирәдә яшәүче чирмешләрне куып китереп аларга посад янында һәм Арча кырында острог *(ныгытма—Р. С.)* ясарга боерды, һәм Болактан алып Казан елгасына кадәр ныгытма тирәли чокыр казырга, шунда килгән кешеләр белән чирмешләрне урнаштырырга, шәһәргә ярдәм булсын өчен» *(Древняя Казань...—С. 234).* Кыска гына вакыт эчендә Казанның көньяк

һәм көньяк-көнбатыш юнәлешләрендә (шул исәптән Болак артында да) алгы саклангыч ныгытмалар корыла. Бу турыда П. Г. Заринский болай дип яза: «Казаннын XVI гасырда руслар тарафыннан яулап алынганчы ук Болак аръягына таралганына һич шик юк, анда крепость киртәсе яки алгы ныгытмалар төзергә омтылу булган» *(Очерки древней Казани...—С. 181).* Әмма шул ук елны мондагы ныгытмалар урыс гаскәрләре тарафыннан алыналар. Шушы позициядән торып, туплардан шәһәрне утка тотып, урыслар казанлыларны солых сорарга мәҗбүр итәләр. 1530 елгы уңышсыз сугыш хәрәкәтләреннән соң, казанлылар Болак артындагы ныгытмаларыннан баш тартып, 1552 елгы хәлиткеч сугыш алдыннан аларны юк итүләре ихтимал.

XVI гасырда Болак артында яшәп яткан, иң зур һәм Кремльгә иң якын урнашкан торак урын булып легендар һәм серле Көрәеш бистәсе санала. Ул Болакның югары агымын биләгән, бу урын хәзерге Киров, Г. Камал, Париж Коммунасы урамнары урнашкан районга туры килә. Бистәнең барлыкка килүе һәм этимологиясе көрәешләргә (дөньяга Мөхәммәт пәйгамбәрне биргән ыруг) бәйле булырга мөмкин, дип фаразлыйлар кайсыбер галимнәр *(Калинин Н. Ф. Казань XVI—XVII веков по писцовой книге 1566—1568 гг.—Архив АНТ: Ф. 8, Оп. 1, Ед.хр. 322; Айдарова-Волкова Г. Н. Татарские слободы Казани: архитектурно-градостроительное развитие и методологические аспекты реконструкции. /Уч. пособие.—Казань, 1999.—С. 10).* Исламны таратучы бу халыкның Урта Иделгә дә килеп чыгу ихтималы юк түгел. Сәетләр дә бары тик шушы халыктан гына булганнар. Казанның соңгы сәете Кол Шәриф шәҗәрәсе дә Мөхәммәт пәйгамбәргә килеп тоташа *(Худяков М. Г. Очерки по истории Казанского ханства.—Репринтное воспроизведение издания 1923 г.—Казань, 1990.—С. 195).* Көрәеш авылларының мөселманнарда хөрмәтле саналган зиратлар янында барлыкка килгәне дә билгеле. Хәзерге Колхоз базары җирендә олы бер мөселман зираты булган, көрәешләрнең шушы борынгы изге урынны саклаучылар булу ихтималы булып, Казан үсү процессында монда бистә барлыкка килә. Әйтергә кирәк, тарихчылар арасында бистәнең аталышын Олуг Мөхәммәт ханга күрсәткән хезмәтләре өчен бу авыл биләмә итеп бирелгән Көрәеш бәк исеме белән бәйләүчеләр дә бар. Ханлык чорында Көрәеш исемле авыл Тау ягында да булган *(Чернышов Е. И. Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья.—Казань, 1971. Выпуск 1.—С. 272—292).* Көрәеш бистәсенең ярыйсы гына зур булып, Болак артында әһәмиятле роль уйнавын ханлыкның атаклы морзасы Чапкынның әтисе Үтәш (бу кешенең ханлыкта зур роль уйнавын аның урыс елъязмаларында еш телгә алынуы сөйли) салдырган мәчет күрсәтә. Мәчет таштан эшләнгән булырга тиеш, 1565—1568 елгы язу-теркәү кенәгәләрендә (ягъни Казан яулап алынганнан соң 13-16 ел үткәннән соң да исән булган, ә агачтан эшләнгән барлык мәчетләр дә юк ителгәннәр) ул телгә алына *(Список с писцовой книги г. Казани с уездом.—Казань, 1877—С. 50).* Шәһәрдән бу бистәгә юл Кырым капкасыннан башланып, Болак аркылы салынган күпердән үткән. 1552 елның казанлылар өчен фаҗигале җәендә шушы бистә урнашкан Кырым юлында, Үтәш мәчете янында урыс патшасы Иван IV нең шәхси полкы лагерь булып урнаша. Ханлык яулап алынганнан соң Көрәеш бистәсе яшәүдән туктый, бу җирләр Казанның беренче архиепископы Гурийга биләмә итеп бирелә (билгеле, татарлар моннан куыла, урыс крестьяннары күчертеп утыртыла), Көрәеш атамасы онытылып, архиепископская слобода булып китә.

Тирән үзәктән еракта түгел, Туры Казан буйлап Елантауга менгәндә, XV гасырда барлыкка килгән, күп санлы сәүдә һәм хәрби корабларны сыйдырырлык уңайлы дәү бухтасы булган Бишбалта исемле тагын бер татар бистәсе—урман кисүчеләр, балта осталары һәм кораб төзүчеләр бистәсе гөрләп яшәп яткан...

**Ринат СОЛТАНОВ,**
*Татарстан Фәннәр Академиясенең*
*Тарих институты аспиранты*

✤

*Гаяз Исхакыйның туувына 125 ел*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ СӘЯСИ КАРАШЛАРЫ

* * *

Татар халкында XX йөз башы вакыйгалары эчендә милли сәясәтне тудыручы һәм аны әйдәп баручылардан берсе Гаяз Исхакыйның тууына 2003 елның февраль аенда 125 ел тула. Соңгы 12-13 ел арасында татар гуманитар фәне аның иҗатын һәр яктан өйрәнде, төрле аспекттан чыгып яктыртты. Әдәби әсәрләре бүгенге көн таләбенә җавап бирерлек итеп интерпретацияләнде. Аеруча әдипнең Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗаты күз уңында булды. Эмиграция чорында язылган әдәби әсәрләре «Өйгә таба» (1922, Берлин), «Көн» (1923, Берлин), «Локман Хәким» (1923, Берлин), «Җан Баевич» комедиясе (1933, Берлин), «Олугъ Мөхәммәд» тарихи драмасы (1947–1948, Истанбул) «Мирас», «Казан утлары», «Идел» журналлары һәм газета битләрендә бастырылды. Шулай ук гаҗизлектән чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булган татар милләтен бер йодрыкка берләштерүдә әһәмиятле роль уйнаган «Яңа милли юл» (1928 елның декабре–1939) журналыннан аерым мәкаләләр атап үткән журналларда урын алды. Бу чыганаклар Г. Исхакыйның эмиграция чорындагы әдәби һәм публицистик иҗатына азмы-күпме бәһа бирергә ярдәм итә шикелле. Әмма әдипнең чит илләрдәге әдәби эшчәнлеге татар укучысына барып ирешсә дә, әлегә аның публицистик язмалары өлешчә генә нәшер ителде. Шунысын искәртеп куюны кирәк санйым: Г. Исхакый Парижда, Берлинда яисә Варшавада, Ерак Шәрекъта, Төркиядә яшәмәсен, барыннан да элек, ул сәясәтче һәм публицист буларак чыгыш ясый. Әдипкә 100 ел тулуга багышлап аркадашлары тарафыннан төзелгән җыентыкта «Яңа милли юл» журналы һәм «Милли байрак» газетасында үзе исеменнән һәм тәхәллүсләре белән 178 мәкаләсе барлыгы хакында мәгълүмат бирелә

Г. Исхакыйның иҗаты туган иленә әйләнеп кайту белән эмиграциядәге чор публицистикасына да игътибар көчәйде. Аеруча аның «Яңа милли юл» журналында алып барган эшчәнлеге күренекле әдәбият галимнәре Х. Миңнегулов, Ф. Мусин, филология фәннәре кандидаты А. Кәримова, Л. Гайнанова язмаларында киң яктыртылып, журналның тематикасы, характеры, авторлары хакында, публицистик, тәнкыйди, тарихи мәкаләләренә аңлатмалар бирелеп, укучыларга билгеле бер дәрәҗәдә барып ирешә. Кызганыч ки, чит илләрдә яшәргә дучар ителгән милләттәшләребез тормышында мәгълүм урын алган «Яңа милли юл» журналы белән (барлыгы 136 сан) бүген дә тулысынча танышу мөмкинчелеге юк. Беренчедән, моңа журналның Берлинда нәшер ителеп, нигездә эмиграциядә яшәүчеләр арасында гына таралуы сәбәп булса, икенчедән, журналның туган иленә кайткан очракта да, төрле кешеләрнең кулларында калуы да хәлне авырлаштыра. Шулай да безгә килеп җиткән саннарда Г. Исхакый XX гасырның 30 нчы елларында дөнья тарихында мөһим роль уйнаган сәяси вакыйгалар, СССРда большевизм исеме астында алып барылган «уеннар» һәм башкалар белән якыннан таныштыра. Минем уемча, аның 30 нчы еллар сәяси вакыйгаларына төпле анализ биргән, үзенең киң эрудициясе белән тирән логик фикерләве нәтиҗәсендә дөнья сәясәтенең нигезен ачкан һәм II Бөтендөнья сугышын якынлаштырган күп төрле сәбәпләрне күрсәткән мәкаләләре аеруча әһәмиятле. Алар гаять тә күпкырлы, фактик яктан бәһаләп бетермәслек дәлилле.

Мәкаләләреннән күренгәнчә, дөнья күгендә сугыш куркынычы янарган бер чорда, әдип вакыйгаларга битараф кала алмый. 1937–1939 елларда ул «Дөнья әхвалләре» исеме астында басылган мәкаләләрендә төрле кайнар нокталарда барган үзгәрешләргә үз бәяләмәсен бирел кила. Күпчелек вакытта бу бәһаләр объектив булса

да, кайбер очракларда аерым вакыйгаларга, шәхесләргә, бигрәк тә большевизмга, коммунизмга каршы мөнәсәбәт белдергән мәкаләләрендә субъектив фикер дә салына.

Мәгълүм ки, XX йөзнең 30 еллары тарихта II Бөтендөнья сугышына әзерлек чоры буларак кереп калды. Сугышка алып килгән сәбәпләр тирәндә ятса да, аны башлауга китергән сылтаулар да җитәрлек иде. Сәбәпләрнең беренчесе, Гитлер армиясе генералы Курт фон Типпельскирх язганча, аның чыганаклары I Бөтендөнья сугышы алды вакыйгаларына барып тоташа. Ягъни, гасыр башында ук Европаның көчле дәүләтләре–Англия, Германия, Франция, Италия, Россия дөньяны бүлүдә үз максатларын алга куялар. Икенче зур сәбәп: 1917 елгы инкыйлабтан соң дөнья сәясәтендә кайбер мотивлар үзгәрүдә: инде хәзер Европа дәүләтләре кешелек өстенә кара болыт булып күтәрелгән большевизм, коммунизм идеологиясеннән саклану өчен бер-берсе белән берләшү ягын карыйлар. Россия исә Г. Исхакый язганча, «милләтсезлек, динсезлек» өчен «дөнья революциясе» пропагандасын җәелдерү юлына баса; бу күп акчалар сарыф итү бәрабәренә тормышка ашырыла башлый. Мәсәлән, 1918–1919 елларда бик аз вакытта гына Германиядә социалистик революция булып ала, Россия анда да «дөньякүләм инкыйлаб утын» кабызырга теләп шактый күп акча түгә. Г. Исхакый «Большевиклык–русчалык» мәкаләсендә (1939, N4) бу хакта менә ничек яза: «Алманиядә коммунист инкыйлабы ясарга сарыф иткән миллионнар, икенче елны Кытайга күчте, аннан Якын Шәрекъка килде. Аннан тагын Аурупага кайтып, Испаниягә җирләште, Франса, Ингилтерәнең колонияләренә юнәлдерелде». Россиянең мондый сәясәтенә карата канәгатьсезлек белдергән алдынгы карашлы дәүләтләр, әдип билгеләп үткәнчә, Аурупаның бөтен ноктасында большевизмга каршы хәрәкәт «кави милләтчелек» нигезендә гәүдәләнергә башлады [...], һәрбер җирдә большевиклык, коммунистлык, динсезлек, әхлаксызлыкны куарга кереште. Большевизм, коммунизмның иң каты һөҗүменә ураган *(очраган)* Италия, Алманиядә милләтчелек фикеренең бу гәүдәләнеше мәмләкәт, дәүләтне саклау төсен алып тизрәк тәмам булды. Вә бу җәбһәнең *(якның)* дөнья большевизмасы берлә тартышы да элегрәк башланды». Димәк, II Бөтендөнья сугышына китергән сәбәпләр, чынлыкта, большевизм белән тартышуга бәйле карала. Боларны асылда сылтау итеп тә карарга мөмкин. Әмма иҗтимагый-тарихи үсеш хәрәкәтен күздән кичерсәң, аның сәбәпләре Курт фон Типпельскирх һәм Г. Исхакый күрсәткәннәре белән генә чикләнми, ә бәлки җәмгыятьнең сәяси һәм икътисади закончалыкларына да бәйле булуы аңлашыла. Шулай да Г. Исхакый фикере белән килешмичә булмый: әлеге сәбәпләр II Бөтендөнья сугышы башлануга сылтау гына булып калмады, ә бәлки 30 нчы елларда дөнья сәясәтендә зур болганышларга алып килгән афәтләрнең иң коточкычы да иде.

Утызынчы елларда бөтендөнья сәясәтен коруда Гитлер һәм Сталинның роле зур булды. Бу ике шәхес алып барган эчке һәм тышкы сәясәт бер-берсенә бик нык охшаганнар, хәтта «дөнья бүлү» өлкәсендә дә аерымлыклар сизелми диярлек. Мәсәлән, Гитлер 1933 елда хакимияткә килеп, милитаристик сәясәтен тормышка ашырып кына калмый, немец халкын шовинистик рухта тәрбияләүгә һәм алман җирендә яшәүче яһүд халкын күпләп юк итүгә дә ирешә. Сталин да шундый ук сәясәт алып бара. Сталин хакимият иткән өч дистәгә якын ел эчендә СССР биләмәсендә кеше акылына барып ирешмәслек вәхшилекләр кылыну, миллионлаган сәяси корбаннар бирелү, үз-үзенне саклап калу өчен корылган интригалар системасының тәмам камилләшеп җитүе, рус шовинизмының тагын да ныграк көчәюе (әйтергә кирәк, Г. Исхакый мәкаләләрендә бу мәсьәлә киң яктыртыла), милли изүнең патша Россиясе алып барган сәясәткә караганда да куркынычрак төсләргә буялуы Россия тарихына гына түгел, дөнья тарихына да куркыныч бер афәт булып кереп калды. 30 нчы еллар башында Испаниядә булып узган вакыйгалар 1936–1939 елларда кабынып киткән илдәшләр сугышы башлануга китерде. Испаниядә бер яктан, Германия һәм Италия фашистик сәясәт алып барса, икенче яктан, СССР Испаниядә аз гына вакытка хакимияткә килгән коммунистларга булышлык күрсәтә. Шундый ук хәл Кытайда да кабатлана. Барлык бу күренешләр «Яңа милли юл» журналында Г. Исхакый тарафыннан язылып, «Дөнья әхвалләре» баш астында бастырылган мәкаләләрдә (1937, №12; 1939, №2; 1939, №4; 1939, №5; 1939, №7) чагылыш таба. Дөрес, аларда башка әһәмиятле сәяси вакыйгалар да яктыртыла.

Европада 1937–1938 елларда фашизм һәм коммунизм афәте якынлашу нәтиҗәсендә сәяси хәл шактый катлаулана. 1938 елның сентябрендә Мюнхен

киңәшмәсе буенча, Чехословакиянең немецлар күпләп яшәгән Судет өлкәсе Германиягә кушылу да моңа этәргеч бирә. Озак та тормый, Чехословакия коралсыз гына Германиягә буйсындырыла. Шулай итеп, дөнья ике фронтка бүленә: Германия, Италия, Япония үзләренең милитаристик сәясәтен алып барса, Англия һәм Франция теләмичә генә СССР белән бәйләнешкә кереп, фашизмга каршы көрәшү юлына басалар. 1939 елда Италиянең Албанияне басып алуы сугышның якынлашуын тагын да тизләтә. Польша сугышчан әзерлеккә баса. Венгрия, Румыния, Болгария дә саклык чараларын күрә башлыйлар. Шул рәвешле, II Бөтендөнья сугышы башланыр өчен бөтен алшартлар да туа. Бу нәүбәттән, сәяси мохитне тулырак күзаллау максатыннан, Г. Исхакыйның «Яңа милли юл»да басылган (1939, №5) «Дөнья әхвалләре» исемле мәкаләсеннән бер өзек китереп үтү дә җитәр кебек: «Албания истикъляль *(бәйсезлеге)* бетерелүе Аурупаны тагы зур тәшвишкә *(шиккә)* төшерде. Кечкенә мәмләкәтләрнең башкаларының башына да шундый бәла килә дигән курку тугды. Һолландия, Исвиргә *(Швейцария)* кеби мәмләкәтләр үзләренең алтын хәзинәләрен Америкага озаттылар. Ләһстан кыйсмән *(өлешчә)* гаскәрне сугыш хәленә китерде. Аурупа харитәсенең *(картасының)* тагын үзгәртеп Аурупа мөвазәнәсен *(тигезлеген)* югалтачак дип уйлап, Ингилтерә Ләһстанның сәламәте мөлкиясен *(дәүләт милкен)* бар көче берлә саклаячагын игълан итте, вә бирничә көннән соң Румыниягә дә шундый ук тәэминат бирде, куркынычсызлык вәгъдә итте. Аның артыннан Франсә дә гайни *(әһәмиятле)* вәзгыятьне алды. Франсә, Ингилтерә матбугаты Совет Русиясен дә шундый тәэминат бирергә өндәргә керește. Совет дипломатларына Аурупаның эчендә интрига уйнатырга киң зәмин *(җирлек)* хазирләде [...]. 28 нче апрельдә Гитлер җәнапләре рейхстагны туплап, шуның ачылуында озын бер сәяси нотык сөйләп, Алманиянең карашын аңлатты, вә шул нотыктан берничә генә сәгать элек Ләһстан хөкүмәтенә меморандум җибәреп, 1934 елда мәрхүм маршал Пилсудский берлә хөкүмәт башы Гитлер җәнапләре арасында имзаланган гадәме тәҗавез могаһәдәсенең *(һөҗүм итешмәү турындагы килешү)* хакиме *(өстенлеге)* калмавын белдерде. Һәм дә Ингилтерәгә дә диңгез көчләрен чикләү хакындагы 1935 елда ясалган могаһәдәнең хакиме беткән итеп саналуын игълан итте».

1939 елның июнь-июль айларында Европада хәл тагын да кискенләшә. Курт фон Типпельскирх күрсәтүенчә, II Бөтендөнья сугышы 1939 елның 1 сентябрендә башланачагы май аенда ук билгеле була. Гитлер гаскәрләрне Польша чигенә урнаштыру турында яшерен карар бирә. Шул ук вакытта сугыш афәтеннән качу өчен төрле очрашулар, киңәшмәләр уздырыла, килешүләр төзелә. Болар барысы да «Яңа милли юл» журналының 1939 ел 7 санында бәян ителә. Мәкаләдән күренгәнчә, әле шул вакытта да сугышның башланачагы хакында төпле мәгълүматлар юклыгы ачыклана. Ягъни, Г. Исхакый түбәндәгечә язганча: «Дөньяның төрле почмакларында булып яткан төрле-төрле шул вакыйгалар *(мәкаләдә тасвирланган вакыйгалар турында сүз бара—З. М.)* бөтен дөньяда «сугыш иртәгә башлана, өченче көнгә башлана!» дигән гасабилыкны дәвам иттереп киләдер вә тынычлыкның никадәр дәвам итә беләчәген сөаль галәмәте астына куядыр».

Европада башланып киткән мондый ыгы-зыгылар күп кенә колонияләрдә милли азатлык хәрәкәте башланып китүгә сәбәп була. Бу бигрәк тә Төньяк Африка, Якын Көнчыгыш, аеруча Фәләстыйна, Сирия, Сөгуд Гарәбстаны һ. б. дәүләтләргә карый. Мәсәлән, Г. Исхакый «Фәләстыйна эшендә гарәп берлеге» *(1939, № 3)* мәкаләсендә 30 елларда Англиянең Фәләстыйнага күпләп яһүдиләрне утыртуын һәм анда яһүдиләр дәүләте төзүгә каршы баш күтәргән гарәп халкының көрәшен тәфсилләп тасвирлый. Ләкин Европаның биләп алган сугыш болыты Англия алып барган гарәпләр өчен куркыныч сәясәтне бер якка куеп торырга мәҗбүр итә. Шулай да II Бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң вакыйга кабат өскә калкып чыга һәм 1948 елда Фәләстыйна җирендә Израиль дәүләте төзү белән тәгаллана.

Күренә ки, тирән фикер, нечкә тоемлау белән язылган мәкаләләрендә әдип, нинди генә темага алынмасын, ул аны тарихи чыганаклар белән ныгыта, чор, заман вакыйгаларына мөмкин кадәр объектив бәя бирергә омтыла. Укучыга тәкъдим ителәчәк мәкаләләрдә Г. Исхакый публицистикасының көче һәм аның тирән фәлсәфи фикерләү дәрәҗәсе никадәр югары торуы раслана.

**Зөфәр МӨХӘММӘТШИН**,
*филология фәннәре кандидаты.*

## Гаяз Исхакый

### Дөнья әхвале

Испаниядә илдәш сугышлары әле беткәне юк. Генерал Франко хөкүмәте соңгы җиңүләреннән соң Мадридка катгый һөҗүм итәчәк дип язса, сөйләсә дә, бүгенгә кадәр бу җәбһәдә *(фронтта)* әле каты сугышлар башланганы юк. Инде тиздән кыш вакыты, ягъмурлы айлар башланачак булганга, бәлки язга кадәр җәбһәләрдә зур үзгәреш тә булмас. Лондарадагы (Лондондагы) «Испания эшенә катышмау комиссиясе» дә рәсмән ябылмаса да, һичбер катгый тәдбирләр *(катгый таләпләр)* ала алмаенча, Испанның ике тарафыннан күпме чит халык гаскәре сугышканны белер өчен комиссионнар күндерергә булып истирахәткә ял итәргә таралды.

Испаниянең җөмһүрият хөкүмәте үзенең җирләшкән шәһәре Валенсиянең *(Валенсиянең)* Франконың һөҗүменә очраудан куркып Барселонга күчте. Большевикларның генерал Франконы сугышучы көч итеп тану мәсьәләсе, французларның каршы килүләре берлә эшкә аша алмаса да, Ингилтерә *(Англия)* хөкүмәте генерал Франко берлә мөзакәрәгә керешеп *(киңәшләшеп)*, үзенең ярты рәсми илчеләрен генерал Франко хөкүмәте уңына күндерде вә бу мөнәсәбәт берлә ике арада шактый күп мәсьәләләр дә, аңлашулар да булды кеби хис ителәдер. Шул мәсьәлә хәл ителер итмәс, Италия күңеллеләренең *(иреклеләренең)* бер өлеше Испаниядән илләренә кайтарылачагы игълан ителде. Ингилтерә берлә генерал Франконың бу аңлашмасы, Франко хөкүмәтенең якында рәсмән танылуы берлә тәмам булачак диләр.

* * *

Ерак Шәрекътагы сугышлар көннән-көн тирәнәя барадыр. Япон гаскәрләре Шанхай шәһәренең Кытай кулында булган өлешен забыт итте *(басып алды)* вә Кытай гаскәрен—Нанкинга таба куарга башлады. Бу җәбһәдәге сугышларда Кытай гаскәре үзеннән көтелмәгән рәвештә каршылык күрсәтә алды. Японнар үзләре дә бу җәбһәгә зур куәт куймаенча, бу сугышларга Кытайның гаскәрен биләп тотар өчен маневралар дип кенә карап килгәнгә, сугышлар бу җәбһәдә озайды. Ләкин шимали Кытайда япон гаскәре зур мөвәффәкыятьләр *(зур җиңүләр)* кулда итте. Русия берлә Кытай арасындагы юлны тәмамән кисте. Монгол җирләрен тәмамән диярлек дәрәҗәдә алып бетерде. Шуннан файдаланып, монголлар 20 нче октябрьдә Пекин шәһәрендә бер киңәш мәҗлесе ясадылар вә мәҗлес эчке Монголстанның әхвален тикшерер өчен 28 нче октябрьдә монгол корылтае ясарга карар иттеләр вә һәрбер монгол кабиләләренә чакырулар тараттылар. 28 нче октябрьдә (монгол хисабы бирелә Чыңгыз хан туудан 732 нче елда) Суийан *(дөресе: Суйнан)* шәһәрендә тупланган монгол корылтае, эчке Монголстанның истикълялын *(бәйсезлеген)* игълан итте. Вә монгол хөкүмәтен сайлады. Бу хөкүмәт хазирге көндә өч миллион ярым монгол халкы вә анда җирләшкән ярты миллион кадәр чин халкына таянып эш итәдер. Монгол дәүләте корылып бетеп, башкүз алгач та, хазир үк Совет Русиясендә калган тышкы Монголстанны да кайтарырга керешәчәкме? Әллә Монгол илләрен берләштерүне киләчәк форсатта калдырачакмы? Моны киләчәк вакыйгалар күрсәтәчәктер. Мөстәкыйль Монголстанның тууы Ерак Шәрекъ өчен генә түгел, үз халыкларын истикъляллырына кавыштырыр өчен тырыша торган бөтен җәберләнгән милләтләр өчен зур сөенечле бер эштер. Тарихыбызның парлак дәвере *(күренекле дәвере)* якты көннәре безнең монголлар берлә бергә хәрәкәт иттегебез вакытларда булганга, бу вакыйга Идел-Урал, Себер төрек татарлары өчен безнең кортылышыбызның да якынлашуына зур бер фалдыр, хәерле өмидле эштер. Без Ерак Шәрекътагы монгол кардәшләребезнең бу уңышларын тәбрик итеп, тиздән бөтен монгол илләрен коткарып, Чыңгыз байрагы астында берләштерергә насыйп булсын дип, дога кылабыз.

Японнарның шимали Кытайдагы уңышлары, Аурупа дәүләтләрен

куркыткан кеби шимали Америка җөмһүриятен дә өркетте. Нәтиҗәдә, Җәмгыяте әкъвамда *(Милләт лигасында)* Кытай вәкиленең японнар өстеннән шикаяте каралганда, 1922 елда Вашингтон шәһәрендә японнарның Ерак Шәрекътагы хокукларын чикләр өчен Кытайның сәламәте мөлкиясен *(дәүләт милкен)* саклар өчен җыелган конференцаны туплаган тугыз дәүләтнең җыелышын яңадан җыярга карар итте вә ноябрь башына шул тупланыш Боруксел *(Брюссель)* шәһәренә тәгъйин ителде *(билгеләнде)*. Ләкин тупланышка Япония хөкүмәте вәкил күндермәгәнгә вә мәҗлескә катышкан дәүләтләр, Японийгә каршы катгый тәдбир алудан гаҗиз булганга, конференца һичбер эш эшли аламады. Ике мәртәбә Японийгә чакыру берлә эш бетте. Әлегә бу тупланыш рәсмән ябылмаган булса да, үле туган бер бәйнәлмиләл *(халыкара)* баладан хәерле бер эш өмид иткән кеше юктыр. Кайбер газитәләрнең язуына күрә, бу тупланыштан файдаланып инглизләр берлә французлар Американы дөнья эшләрендә озакта калмаенча, Аурупа эшләренә катышырга дәгъвәт итәләр имеш вә бу өч демократ дәүләтнең бөтен дөнья мәсьәләләрендә бергә эш алып бара беләчәк хат-әл-хәрәкәсен (төп юнәлешен) мөзакәрә *(киңәш)* итәләр имеш. Ләкин бу имешләрне тасдыйк итә торган да *(раслый торган)*, тәкбиз итә торган да *(ялганга чыгара торган да)* бер вакыйга да әле булганы юктыр.

* * *

Борукселдә тугыз дәүләтнең киңәшмәсе булып ятканда (Алмания иштирәк итүдән *(катнашудан)* баш тарткан иде). Алмания хөкүмәтенең, Япония императорлыгының вәкилләре берлә Италия хөкүмәтенең хариҗия назыйре *(тышкы эшләр министры)* арасында Рома шәһәрендә 7 нче ноябрьдә Италиянең «антикоммунизм иттифакы» на керү могаһәдәсе *(килешү)* имзаланды. Бу могаһәдәгә имза куючы дәүләтләрнең вәкилләре матбугаты, бу могаһәдә фәкать дөнья мәдәниятын коммунизмның җимерүче, ватучы һөҗүменнән саклар өчен эшләнгән инсани бер эш кенә дип сөйләсәләр, язсалар да дөнья матбугаты бу вакыйгага бик күп «диде», «куды» — кушты. Аурупа, Америка матбугаты бу мәгънәви могаһәдәнең астында гизли серләр *(яшерен серләр)* вә гаскәри аңлашмалар бар дип күп нәрсәләр яздылар. Хосусан үзләренә алман дошманлыгын бер мәсләк итеп алган яһүди матбугаты, яһүди даирәләре бу эшне бик кабарттылар. Большевиклык, коммунизмга каршы булган бу хәрәкәтне гүя Ингилтерә каршы кеби күрсәтергә маташтылар. Франсә матбугатында да бу мөгаһәдә Франсә галәйһенә *(каршы)* имеш кеби итеп бик күп яздылар.

Могаһәдә әле яңа гына имза ителгәнгә, моның Аурупа, Америка, Ерак Шәрекъ гамәли рәвештә тәэсире никадәр булачактыр, хөкүм бирергә вакыт иртәрәк; ләкин бу могаһәдә совет илләрендә фәүкылгадә *(гадәттән тыш)* зур курку уятты. Вә аларда башбаштаклык башланды. Соңгы көннәрдә большевик хөкүмәтенең хариҗиясендә ясалган таваккыйф *(кире кагу)* шул куркуның җимешләре дип тәфсир итәләр. Төркиядәге большевик сәфире *(илчесе)*, яһүди Карски Испаниядәге Совет баш илчесе Антонов-Овсеенко хариҗия комиссары могавине *(ярдәмчесе)* Крестинскилар янына советларның Япония сәфире *(илчесе)* булып бу ел гына әле Алманиядәге большевик илчесе, яһүди алыштырган иске рус коммунисты Юреневларның кулга алынулары, һәм дә Ләһстанда мөстәшар (киңәшче) булып торган әрмәни коммунисты Давтян тәукыйфы *(кулга алынуы)* болар берлә бергә бик күп олуг-кечек хариҗия мәэмүрләренең *(чиновникларының)* эштән чыгарылулары шул башбаштаклыкның соңгы җимешләредер. Совет дәүләте эчендәге каршылыклар, чит илләрдәге хөрмәтсезлекләр берлә Совет хөкүмәтенең аягы кулы багълы булганга, бу иттифакларга каршы бер эш эшләүдән гаҗиздер. Аягы багъланып суярга яткырган куян кеби суючының пычагын кайрап өлгерерлек кенә вакыты калганын үзе дә хис итәдер.

* * *

Төркиядә милләт мәҗлесе ачылды. Рәис җөмһүри Мостафа Кәмал паша хәзрәтләре үзенең ачу нотыгында да киләчәк елда эшләүе матлуб эшләрнең өлчесене күрсәтеп үтте. Баш вәкил Җәлал бәкнең милләт мәҗлесенә тәкъдим

иткән эш ляихәдә *(проектта)* шул теләкләрнең тәфсилле рәвешендә иде. Бу елгы, бу ике мөһим нотыкта да күзгә ташланачак мәсьәләнең берсе киләчәк елның икътисади ислахларга *(реформаларга)* хазир ителүе, икенчесе дә, кирәк рәис җөмһүриятнең нотыгында, кирәк баш вәкилнең нотыгында, Гасыймәт паша заманасында булынган кеби Совет Русиясенә махсус мәдхияләр укымаудадыр. Бу эшләрнең икесе дә, кирәк эчке эшләрендә, кирәк тышкы сәясәтендә Төркиянең саглам юлга *(ышанычлы юлга)* керүен күрсәтә торган вакыйгалардыр, вә бөтен төрек милләтчеләрен сөендерәчәк әхвәлләрдәндер.

* * *

Җәнүби Американың *(Көньяк Американың)* Бразилия дәүләтендә сайлау мөддәте тиздән чыгачак. Рәис җөмһүри: «Канун әсасыны үзгәрттем»,—дип игълан итеп, милләт мәҗлесене вә әгъяние *(аристократларны)* таратты. Фашизм принципларына якын бер ысулда идарә корачагыны игълан итте. Әүвәлге көннәрдә бу әхвәл фашистлык гаясенең *(теләгенең)* Америка туфрагына һөҗүме төсендә язылып, Аурупаның кайбер дәүләтләрен гаепләүләр булса да, бара-тора, бу инкыйлабка да Җәнүби Американың да һәр җирендә, һәр елын булып үтә торган төрле «инкыйлаб»ларның берсе генә дип карау фикере хаким булды *(өстен булды)*.

* * *

Дөньяның башка кыйсмәндә *(өлешендә)* иң авыр хәлләр Фәләстыйнда дәвам итеп киләдер. Инглизләр гарәпләргә каршы каты тәдбирләрне *(чараларны)* куеп, яһүдләрне яклап киләләр. Гарәпләр дә бу золымга чыдый алмаенча, басмачылык тартышын куәтләндерә баралар. Вә көннән көн кан түгелү көчләнә киләдер. Инглизләр бу хата юлларыннан сапмаячак булса, башка гарәп илләрендә тынычлык озын суза алмаячактыр. Инглизләрнең яһүди дустлыклары үзләренә дә бик бәһалыга мал булу ихтималы җанлы рәвештә күз алдына килеп басадыр.

ГАЯЗ. *Дөнья әхвәле. «Яңа милли юл».—1937, №17, 20—24 б.*

## Дөнья әхвәлләре

Үткән айның иң мөһим сәяси вакыйгасы Арнаутлыкның *(Албаниянең)* ярым мөстәкыйль вәзгыятен югалтып, тәмамән Италиянең мөстәмләкәсе *(колония)* хәленә төшеп калуы булды. Арнаутлык дүрт йөз илле бер буйдан *(1467 елдан алып)* Төркиянең бер мохтар вилаяте кеби идарә ителеп килде. Арнаут халкы сугышчан булганга, гаскәри бер дәүләт булган Төркиядә боларның урыннары һәрвакыт бик хөрмәтле булып барды. Арнаут халкының алга баскан өлеше Төркиянең идарәсендә, гаскәрендә бик зур роль уйнап килде: ләкин Төркия дәүләте зәгыйфьләнүдән соң унтугызынчы гасырның башларында төрле милләтләрнең Төркиядән аерылуы уртага атылып, бу халыкларның төрлесе Төркиянең мирасына күз теккән чит дәүләтләргә таянып, Төркия дәүләтчелеге берлә тартышка керешкәч, Арнаут халкының да бер өлеше Төркиядән аерылу фикеренә бирелде. Арнаутлыкның Төркиядән аерылуы ул вакытның Австрия Венгриясенә, Италиясенә, хәтта Юнанстанда, Русиягә дә файдалы төсле күренгәнчә, бу дәүләтләрнең агентлары Арнаутлыкта бик зур пропаганда өйрәттеләр: төрек дошманлыгы таратыр өчен бик күп акча түктеләр.

Арнаут халкы тормышының бик ибтидаи *(башлангыч)* баскычында яшәвеннән үтмәгән булганга, боларда милләт фикере ул вакытларда һичбер юк иде. Аз-маз халыкка тәэсир итә беләчәк мәгънәви бер көч булса, ул да дин иде. Халыкның бик зур күпчелеге ислам динендә булганга, бу дин берлеге чын Арнаут халкын Төркия берлә бик каты бәгълап килә иде. Шуны күреп, Австрия, Италия, Русия монда бик күп акчалар берлә миссионер кыяфәтендә, бик күп хәфийяләр *(шпионнар)* күндерделәр. Ул вакыттагы капитуляционның

Төркиядә үзләренә биргән уңайлыкларыннан файдаланып, Арнаут халкын дин ягыннан да мөселман Төркиядән аерырга бил багълап керештеләр. Акча берлә католик, протестант, православный мәзһәбләренә мөселман Арнаутларын күчерә башладылар. Бик күп уңайлыклар биреп, шул ук дин әһлемиссионерлар үз диннәрен өйрәнер өчен бушлай мәктәпләр ачтылар. Аңы аз арнаут халкы бер угылыны—киендереп, ашатып-эчертеп укыта торган, үзенә дә бәйрәмләрдә мылтык, ядрә бүләк итә торган рус православие попларының мәктәбенә җирләштерде, бер кызыны—тагы шул ук бушлай тәрбия итүче ата-анасына тәрегә башка акчалата, ашамак-эчмәк, сугыш коралы берлә дә ярдәм итүче католик мәктәбенә урнаштырды. Бер угылына Италия миссионерларыннан ярдәм алып торган бер гаиләнең кызын алды. Бер кызыны төрек җандармына кияүгә бирде.

Шулай итеп, дүрт-биш йөз ел мөселман гаиләсе булып, мөселманлыкның уртак гангәсе *(традициясе)* берлә яшәп килгән арнаут гаиләсе эченнән төрлеләнде, җимерелде. Бу арнаут халкының исламияте куәтле өлешендә тәгассыб—фанатизм уятты. Арнаут халкының баерак сыйныфында Австрия, Италия, Русия акчалар биреп корал таратып, моны да үз тарафына күчерергә тырышты. Нәтиҗәдә, Арнаут сатлык бер хатын хәленә төшеп, Төркияне зәгыйфь итәр өчен күрше мәмләкәтләрнең кулында корал булып килде. Төркиядән төрле икътисади, сәяси имтияз *(рөхсәт кәгазе)* алырга теләгән күрше дәүләтләре, үзләренең тарафдарлары аркылы арнаутлыкда гыйсъян *(фетнә)* ясауны гади бер дипломат уен хәленә куйдылар.

1908 елдагы «иттихад тәрәкъкый инкыйлабы» Төркиягә эчтән ислях ясап, дәүләт буларак ныгырга имкян *(мөмкинлек)* ачты. Иттихад тәрәкъкый хөкүмәте милләтләргә киң хокуклар вәгъдә итеп, исляхат *(реформалар)* эшләргә кереште. Хөррият тартышларына бик күп Арнаутлылар катышкан булганга, хөррият каһарманы мәрхүм Ниязи бәк Арнаутлыктан чыккан булганга, яңа идарә вакытында Арнаутлыкның Төркиягә багъланышы ныгыды. Төркиянең яңа солтаны Бишенче Мәхмүд Арнаутлыкка кадәр сәяхәт итеп, халыкның күңелен алды.

Ләкин «иттихад тәрәкъкый» фиркасы төреклекнең үзеннән чыккан бер агым булмаенча, француз инкыйлабыннан илһам алып, франк масонлыкның бер шагыйбәсе *(төркеме)* төсендә эшкә керешкәнгә, моның исляхат программыда тормыштан алынган түгел иде. Билгакес *(киресенчә)*, Төркиянең төрек хәяте, мөселман дөньясының ул вакытта кичердеге тормыш төсенә тәмамән ят, чит иде. Асыл максат: халыкны киң хокукка ирештереп, мәдәни тормышка кавыштыру булса да, моның юллары һичбер тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән иде.

Арнаутлыкка иттикад тәрәкъкый хөкүмәтенең тәгъйин иткән беренче төрек вәлисе, үзе озын еллар мөһаҗир булып Франсәдә торып, театрны бик сөйгән бер кеше булып чыкты. Юлы юк, мәктәбе юк, шәһәре ватык-сынык, ярым күчәбә *(күчмә)* хәлендә яшәүче Арнаут эчендә беренче кирәкле эш итеп юл салу, мәктәп ачу җиренә ул килер-китмәс Арнаутлыкның зур шәһәре саналган Дуратсуда *(Албаниядәге Дуррес шәһәре)* зур театр салырга карар бирде вә халыкны шул театрга таш ташыттырырга тотынды. Моны Арнаут халкы аңламаса да, Австрия, Италия, Русиянең хәфийяләре, миссионерлары: «Вәли паша театр салдырып, сезнең бөтен кызларыгыз, хатыннарыгызны театрга китерәчәк, анда аларның йөзләрен ачып, аларны ят ирләр берлә биетәчәк, һәрбер мөселман Арнаут кызының-хатынының рәсемен алачак»,—дип ялган пропаганда башладылар. Надан мөтәгассыйб *(фанатик)* халыкны вәлигә каршы гына түгел, Төркия хөкүмәтенә каршы да аяклангдырдылар. «Без театр салмыйбыз, театрга бармыйбыз, хатын-кызларыбызның пәрдәсен ачмыйбыз!»—дип гыйсъян чыгарттылар. Бу гыйсъян Балкан сугышының мөкаддәмәсе *(башы)* булып китеп, сугышка кадәр тынычландырылмады.

Балкан сугышында *(1911—1913)* Төркия җиңелеп, Македониядән, Арнаутлыктан чигенде. Арнаутлык Италия исемендә бер мөстәкыйль мәмләкәт итеп игълан ителде. Ләкин Албания дәүләт төсенә кереп корылып өгермәде, дөнья сугышы башланды. Дөнья сугышыннан соң могаһәдәләр, Албанияне кулына төшерергә тырышкан Италиягә ихтыяр бирмәенчә, Арнаутлыкны мөстәкыйль итеп игълан итте вә анда башланган мөстәкыйль дәүләт корылышы элгәре җөмһүрият төсендә башланып, 1928 елда рәис җөмһүриләре

Әхмәд Зогуны король итеп сайлады. Ул да Италиягә дуст сәясәт йөртеп, һәм дә Италиягә таянып, 10 ел буеннан Албаниянең короле булып яшәп килде.

Италиянең сәясәтенә һәм дә теләкләренә каршы килерлек Албаниянең көче булмаса да, Албания короле Әхмәд Зогу башыннан аягына кадәр башларында Албаниягә ультиматум биреп, таләпләре кабул ителмәгәч христианнарның иң мөкаддәс саналган бәйрәме алдындагы җомга (7 апрель) бик күп очкычлар, танклар берлә Албаниягә һөҗүм итте вә берничә көннән Албаниянең королен, хөкүмәтен илләреннән качырып, мәмләкәтне үзенә баш идерде. Инде Албания Италиянең мөстәмләкәсе *(колониясе)* рәвешендә сугылып, Италия короле Албаниянең дә короле итеп игълан ителде.

Албаниянең бөтен халкы бер миллион да бер йөз мең чамасындадыр. Моның сигез йөз меңе мөселманнар. Ике йөз меңе христиан-православныйдыр, йөз мең кадәресе котоликтыр. Корольләре Әхмәд Зогу мөселмандыр, аның хатыны бер маҗар кызы христиандыр. Хөкүмәт күпчелек булган мөселманнардан ясала торган иде. Италианнар тарафыннан төзелгән яңа хөкүмәттә мөселман исеме очрамыйдыр.

Албания хазирге көндә Аурупада мөселман мәмләкәтләреннән Төркиядән соң икенчесе иде. Аның бетерелүе берлә Аурупада Төркиядән башка мөстәкыйль ислам дәүләте калмады.

* * *

Албаниянең истикъляллы *(бәйсезлеге)* бетерелүе Аурупаны тагы зур тәшәүвишкә *(шиккә)* төшерде. Кечкенә мәмләкәтләрнең башкаларының башына да шундый бәла килә диган курку тугды. Һолландия, Исвигрә *(Швейцария)* кеби мәмләкәтләр үзләренең алтын хәзинәләрен Америкага озаттылар. Ләһстан кыйсмән гаскәрне сугыш хәленә китерде. Аурупа харитасенең тагы үзгәреп, Аурупа мөвазәнәсен *(тигезлеген)* югалтачак дип уйлап, Ингилтерә Ләһстанның сәламәте мөлкиясен *(дәүләт милкен)* бар көче берлә саклаячагын игълан итте вә берничә көннән соң Руманиягә дә шундый ук тәэминат бирде. Аның артыннан Франсә дә гайни *(әһәмиятле)* вәзгыятьне алды. Франсә, Ингилтерә матбугаты совет Русиясен дә шундый тәэминат бирергә өндәргә кереште. Совет дипломатларына Аурупаның эчендә интрига уйнатырга киң зәмин хазирләнде.

Ләһстанның хариҗия назыйре *(тышкы эшләр министры)* Бек Лондонны зиярәт итеп, Ингилтерә хөкүмәте берлә аңлашты (6 апрель). Фәкать советлар катышкан һичбер могаһәдәгә Ләһстанның катышмаячагын, Советлардан һичбер ярдәм теләмәвен ачык сөйләп, аңлашуны кара-каршы ярдәм тәсенә генә сукты. Болар өстендә матбугатның күтәргән шау-шуы дөнья күләмендә тагы сугыш башланырга озак калмады диган шөбһәне уятты.

Шул хәбәрләргә таянып, Америка рәис җөмһүри Рузвельт Алмания дәүләт вә хөкүмәт рәисе Һитлер җәнабләренә шәхси телеграмма берлә мөрәҗәгать итеп, солых саклашырга чакырды. 28 апрельдә Һитлер җәнабләре рейхстагны туплап, шуның ачылуында озын бер сәяси нотык сөйләп, Алманиянең карашын аңлатты вә шул нотыктан берничә генә сәгать элек Ләһстан хөкүмәтенә меморандум җибәреп, 1934 елда мәрхүм маршал Пилсудский берлә хөкүмәт башы Һитлер җәнабләре арасында имзаланган гадәме тәҗавәз могаһәдәсенең *(бер-берсенә һөҗүм итешмәү турындагы килешүнең)* хакиме калмавын белдерде һәм дә Ингилтерәгә дә диңгез көчләрен чикләү хакындагы 1935 елда ясалган могаһәдәнең хакиме беткән итеп саналуын игълан итте.

Бу ике вакыйга тагы шау-шуга сәбәп булса да, Һитлер җәнабләренең нотыгы Аурупага да солыхны саклау рухында булганга, вәзгыять ачыла төште. Аурупаның матбугаты Алмания берлә Ләһстан арасында һәм дә Ингилтерә берлә Алмания арасында яңадан сөйләшүләр башланып, мәсьәлә тәфсир итәләр. Аурупаның шул авыр көннәрендә Советлар дөньяны бутауларында дәвам итәләр. Төркия ике җәбһәнең берсенә дә кермәенчә, битарафлыгын сакларга тырышып ятадыр.

ЧЫҢГЫЗ. *Дөнья әхвалләре. «Яңа милли юл» — 1939, №5, 20-24 б.*

Гәп Фән

# ҖӘҮҺӘРЧЕ

**ХУЖИ МӘХМҮТОВКА 70 ЯШЬ**

*Фольклор әсәрләрен еш кына «халык җәүһәрләре» дип атап йөртәләр. Шушы чагыштыруны кулланганда, Хуҗиәхмәт Мәхмүтовны тулы нигез белән оста җәүһәрче дип атый алабыз. Халкыбызның авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү белән ул инде 40 ел буена диярлек даими һәм нәтиҗәле төстә шөгыльләнеп килә.*



*Туган авылы Түбән Ушмыда җидееллык, Мамадышта урта мәктәпне тәмамлагач, Хуҗиәхмәт ике ел авылда балалар укыта. Аннан Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Бу мәшһүр уку йортын кызыл диплом белән тәмамлый. Берничә ел Буа район газетасында җаваплы сәркатиб, бүлек мөдире вазифаларын башкара.*

*1966 елдан алып бүгенге көнгә кадәр Х. Мәхмүтов Г. Ибраһимов исемендәге институтның халык иҗаты бүлегендә эшли. Биредә ул аспиранттан баш гыйльми хезмәткәргә кадәр үсү юлы үтте, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклады; «Җомак әйтәм», «Кечкенә дә төш кенә», «Ел тәүлеге — 12 ай», «Язылмаган кануннар», «Афористические жанры татарского фольклора», «Канатлы сүз — хикмәтле сүз», «Болгар, Казан төшми телләрдән», «Мәңгелек ядкяр», «Ай колакланса, ни була?» «Әйтем — чәчәк, мәкаль — җиләк» кебек мавыгып укыла торган китаплар язып бастырды.*

*Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнгән 12 томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасының кайсы гына китабын ачып карасак та, анда Х. Мәхмүтов тарафыннан илебезнең татарлар яши торган төрле-төрле өлкәләрдә язып алынган уннарча, йөзләрчә әсәрне табарбыз. Ул әлеге фундаменталь басманың редколлегия әгъзасы, биш томның фәнни мөхәррире булды, ә «Мәзәкләр», «Табышмаклар», «Мәкальләр һәм әйтемнәр» томнарын матбугатка турыдан-туры үзе әзерләде, аларга тирән эчтәлекле кереш мәкаләләр һәм фәнни искәрмәләр язды. Томнарны төзегәндә галим афористик жанрларны төркемләүнең үзе эшләгән яңа принципларын файдаланды. Әгәр элек бездә сүз, нигездә, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар һәм сынамышлар хакында гына алып барылган булса, Х. Мәхмүтов халык афоризмнары эченнән тагын антлар, алкышлар, каргышлар, ышанулар (юраулар), канатлы сүзләр, әзер җаваплар кебек яңа төрләрне аерып чыгарды, аларның һәркайсына билгеләмә бирде, жанрлык үзенчәлекләрен ачыклады. «Мәкальләр һәм әйтемнәр» томында мондый әсәрләр, татар фольклористикасында беренче тапкыр буларак, махсус бүлекчәләрдә бирелделәр.*

*Күптән түгел Х. Мәхмүтовның «Борынгылар әйткән сүзләр» исемле зур күләмле яңа монографиясе басылып чыкты. Анда сүз VIII—XVII йөз төрки-татар ядкярләрендәге афористик жанрлар турында бара. Автор Беренче Төрки каганлык чорыннан калган Орхон ташъязмаларында, борынгы уйгырларның «Юрау китабы», «Турфан текстлары»нда, М. Кашгариның «Диване лөгатәт-төрк сүзлеге»ндә, «Кодекс*

*Куманикус» һ. б. кыпчакча чыганакларда сакланган афористик иҗат үрнәкләрен табып, барлап, бүгенге татар мәкальләре һәм табышмаклары белән чагыштырып өйрәнеп чыккан, безнең бик күп афоризмнарыбызның чишмә башы шул ерак мирас булуын дәлилләгән. Аның мондый ачыш-табышлары бөтен төрки халыклар фольклористикасында да яңалык булып тора. Шуңа күрә мөхтәрәм галимебезнең халыкара Төрки академиягә хакыйкый әгъза итеп сайлануы һич очраклы түгел.*

*Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы халык иҗаты, туган тел хәзинәләрен пропагандалауга күп көч куя. Газета-журналларда аның 600 дән артык мәкаләсе дөнья күрде. Ул 30 елга якын «Тел күрке—сүз» радиотапшыруларын алып баруда катнашып килә. Намуслы, тырыш хезмәтнең төбе хөрмәтле була. Х. Мәхмүтов—Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре. Ул мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле фәнни, мәгърифәтчелек эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.*

---

**Хуҗи Мәхмүтов**

## ХАЛЫК АФОРИЗМНАРЫНДА МАГИЯ ҺӘМ ЯШЕРЕН ТЕЛ ЭЗЛӘРЕ

Афористик жанрларның бик борынгы төрләрендә, аеруча ырымнарда, имтомнарда, юрау-ышануларда, алкышларда, каргышларда, мәкальләр һәм табышмакларда ыруглык җәмгыяте чорына хас булган мәҗүсилек карашлары, анимизм, антропоморфизм, магия күренешләре ачык чагылыш тапкан. Сүз, әлбәттә, бу төр әсәрләрнең иң кадими үрнәкләре хакында бара. Ләкин әле санап үтелгән күренешләрнең аерым эзләрен бүгенге көнгәчә килеп җиткән кайбер афористик әсәрләрдә дә табарга мөмкин.

Күренекле инглиз галиме Джемес Фрэзер магик фикерләүнең төп ике принципка нигезләнгән булуын күрсәтә. Шулардан беренчесе «охшаш охшашны тудыра яисә нәтиҗә сәбәпкә охшый» дип раслый. Ә икенче принцип буенча кайчандыр үзара контактта булган әйберләр соңыннан да—турыдан-туры бәйләнешләре өзелгәч тә—бер-берсенә тәэсир ясауларын дәвам иттерәләр. Беренче төрне Дж. Фрэзер гомеопатик магия (охшашлык законы), икенчесен—контагиоз магия (контакт законы) дип атый *(Фрезер Дж. Золотая ветвь.—М., 1980).*

Дж. Фрэзер тарафыннан китерелгән күпсанлы мисаллардан күренгәнчә, борынгыларның магик эш-хәрәкәтләре (сихерләре) махсус гыйбарәләр, сүз формулалары белән бергә үрелеп барган. Соңгыларына шулай ук гаять җитди игътибар бирелгән, аларның тәэсир көче бик зур саналган. Тора-бара магик хәрәкәтләр акрынлап онытыла башлагач та, сүз формулалары үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар, элекке вазифаларын мөстәкыйль төстә башкаруларын дәвам иткәннәр. Антлар, алкышлар, каргышлар кебек афористик жанрлар әнә шуна мисал булып тора.

Гомеопатик магия принципларын күп кенә татар ырымнарында ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, кыярак шешен имләгәндә, аның шикелле үк каты һәм бик

охшаш янгырашлы кайрак ташыннан файдаланганнар: *«Кайрак каты, кыярак каты, бу кешенең шеше кайрак кебек булган, кыярагы кайракка китсен, берләтә кайтсын, бизеп бетсен».*

Элек татарлар өйдә берәрсе кызамык белән чирләгәндә, тәрәзәләргә кызыл тукыма корганнар, авыруның күзләрен кызыл әтәч каны белән чылатканнар. Ә сары белән авыручыны самавыр каршында озаклап утырта торган булганнар. Дәвалауның мондый ысуллары *«Кызамыкка кызыл кор», «Сарыны сары кайтарыр»* кебек махсус гыйбарәләрдә беркетелгән. Аларны безнең мәкаль җыентыкларында да очратырга мөмкин.

«Охшаш охшашны тудыра» дигән принцип та күп санлы юрау-ышануларга нигез итеп алынган. Шундый кайбер борынгы мисалларны Мәхмүд Кашгари үзенең «Диване лөгат әт-төрк» сүзлегендә дә китерә. Уника еллык хайван календаре турында сөйләгәндә ул: *«Төркиләр Сыер елында сугышлар күп булыр дип юрыйлар, чөнки сыер сөзешергә ярата торган хайван»,*—дип яза. Ә Нек (Крокодил) елында явым-төшемнәр мул булырга тиеш икән. Ни өчен дигәндә, ул—суда яшәүче хайван. Яки менә бүгенге җыентыкларыбызда очраучы кайбер юраулар: *«Куш чикләвек ашасаң, игез бала табасың», «Иләк аша карасаң, киявең шадра була»* һ. б. Контагиоз магиягә дә бер мисал китереп үтик: *«Баш киемен мунчала итеп идән юарга ярамый—башың түбәнлеккә төшә».* Ягъни, кайчандыр кигән (контактта булган) бүрек, искереп ташлангач та, элекке хуҗасына тәэсир көчен саклый. Аны мунчала итеп файдалансаң, хуҗасының да башы түбәнлеккә төшә.

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, кешеләрнең магик эш-хәрәкәтләре һәрвакытта да уңай гына түгел, бәлки тискәре нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин: *«Шадра кияүгә тап була, башы түбәнлеккә төшә»* һ. б. «Кыргый кеше,—дип яза Дж. Фрэзер,—әгәр дә ул ниндидер бер гамәл кылса, ... котылгысыз рәвештә аннан шундый-шундый нәтиҗә килеп чыгачагына тирәнтен ышана. Әгәр берәр эшнең нәтиҗәсе ул теләгәнчә көтелмәсә, аның өчен куркыныч туарлык булса, кыргый аны үз өстенә китермәскә тырыша. Башкача әйтсәк, ул үзенә зарар китерәчәк гамәлләрне кылудан тыелып кала, аларга табу сала.

**Табу** ул гаять күпкырлы күренеш һәм аның зур гына бер өлешен табу сүзләр, ягъни теге яки бу шартларда әйтергә ярамый дип санала торган сүзләр тәшкил итә. Табу башлыча кешеләр, табигатьтәге явыз рухлар, төрле чирләр, хайваннар, кошлар, бөҗәкләр исемнәренә салына. Аңлашыла ки, андыйлар иҗтимагый үсешнең түбәнрәк баскычларында торучы кабиләләр телләрендә аеруча күп очрый. Күренекле этнограф һәм фольклорчы Д. К. Зеленин тыелган сүзләрнең әүвәл аучылык һәм балыкчылык кәсепләре белән бәйләнештә туган булулары турында әйтә. *(Зеленин Д. К. Табу слов у народов Восточной Европы и Северной Азии—4. Т. // Сборник музея антропологии и этнографии.—Т. VIII. 1922).* Борынгылар хайваннарда да кеше сөйләмен аңлау һәм ерактан ишетү сәләте бар дип ышанганнар (бу антропоморфизм күренеше дип атала). Янәсе, җәнлекләр кешеләрнең үзара сөйләшүләреннән аларның уй-ниятләрен белеп алалар да, тиз генә еракка качып китәләр. Нәтиҗәдә, сунар уңышсыз чыга. Менә шушы хәлне булдырмау өчен, аучылар сунар алдыннан киекләрнең һәм кошларның исемнәренә табу салганнар, ягъни аны әйтүне тыйганнар. Инде алар турында сөйләшү ихтыяҗы туганда, хайваннар «аңламый торган», аларга «таныш булмаган» алмаш исемнәр кулланганнар. Тора-бара мондый табу кораллар һәм ау кирәк-яраклары исемнәренә дә көчәерелгән. Шул рәвешчә, акрынлап борынгы аучыларның профессиональ телләре барлыкка килгән. Яшерен телдән файдалану уңышлы кәсеп итүнең мәҗбүри шарты булып исәпләнгән.

Табу салынган сүзләргә алмаш исемнәр ясау төрле-төрле ысуллар ярдәмендә эшләнгән. Д. К. Зеленин бу җәһәттән аларны өч төркемгә бүлә. Беренчеләре—исеме әйтелмәүче әйбернең аерым тышкы сыйфатларын күрсәтәләр: сарык—*тонконогая*; болан—*рогатый, сохатый*; куян—*длинное ухо* һ. б. Икенче төркемдә функциональ билгеләр, ягъни әйбернең нинди вазифа башкаруы әйтелә. Мәсәлән, пычак—*режущее*. Өченче төркемгә керүчеләре исә тыелган әйберне аңа охшаш икенче әйбер исеме белән атыйлар. Башкача әйтсәк, монда метафора кулланыла: куян—*полевая коза*, елан—*червь*.

Д. К. Зеленин бу алмаш исемнәрнең, бигрәк тә өченче төркемнең, халык табышмакларына искиткеч охшаш булуларын әйтеп үтә. Тик моны ул сүз уңаенда гына эшли. Табышмак жанрының килеп чыгышын өйрәнү белән бәйләнештә алмаш

исемнәргә беренче булып И. М. Калесницкая мөрәҗәгать итә. Табу сүзләрнең алмашларын һәм табышмак текстларын үзара чагыштыру нәтиҗәсендә, ул аларда бер үк нәрсәләрнең охшаш чаралар ярдәмендә сурәтләнүләрен ача. Автор яшерен телдәге алмаш исемнәрне табышмакларның орлыгы дип атый, шул алмашларны төрлечә эшкәртү, катлауландыру, ритмлаштыру, рифмалаштыру ярдәмендә акрынлап бүгенге халык табышмаклары формасы барлыкка килгән, табышмак жанр буларак үсеп чыккан дигән нәтиҗә ясый.

Аңлашыла ки, борынгы ыруның һәр әгъзасы табулаштыру принципларын һәм яшерен телне яхшы белергә тиеш булган. Бу—яшь егетләрне өлкән ирләр сафына кабул итүнең мәҗбүри шартларыннан саналган. В. П. Аникин «табышмаклар элекке яшерен телдәге алмаш исемнәрне һәм шартлы билгеләрне үзләштерергә ярдәм иткән булырга тиешләр» дигән фикер әйтә *(Аникин В. П. Русские народные пословицы, поговорки, загадки и детский фольклор.—М., 1957).* Шуның белән бергәттән, табышмаклар кешене сынау, аңа бәя бирү кирәк булганда (мәсәлән балигълык йолаларында) үзенә күрә бер критерий да булып торганнар.

Табу сүзләрнең алмашларына һәм табышмаклардагы сурәтләргә күп кенә очракларда нейтральлек хас, аларның төп бурычы әйбернең, затның, күренешнең исемен атамау белән генә чикләнә. Әмма һәрвакытта да алай түгел. Аерым очракларда кеше, алмаш исемнәрнең һәм табышмакларның тылсым көченнән файдаланырга омтылган. Мәсәлән, борынгы календарь йолаларда күк җисемнәрен, табигать көчләрен «рәхимләндерү», алдагы ел уңышына аларның бәрәкәтле йогынтысын тәэмин итү өчен Кояш, Ай, йолдызларны, җирне, җил, яңгыр һ. б.ларны мактый торган табышмаклар әйтелгәннәр: *«Ул булса—көн була, ул булмаса—кем була?»* (Кояш); *«Йөгерек-йөгерек—ни йөгерек?»* (Агым су); *«Симездән симез—ни симез?»* (Җир) һ. б. Инде табигатьтәге явыз көчләргә, яман рухларга килсәк, халык алмаш исемнәр ярдәмендә аларны зарарсызландырырга, буйсындырырга, яхшы якка үзгәртергә тырышкан. Ул бу мәсьәләгә бик җитди караган, хәтта шушы хакта махсус кагыйдәләр иҗат иткән. Аларда әйберне нигә үз исеме белән атарга ярамавы, ни өчен һәм нинди алмаш исем кулланырга кирәклеге турында сүз бара. Мәсәлән: *«Җылан дисәң, җылышып килә, корт дисәң—корый»* һ. б.

Табу һәм сүзләр магиясенең шушы рәвешчә бергә үрелеп китүе түбәндәге очракларда шактый ачык күзгә ташлана.

**Тотемизм һәм анимизм белән бәйле исемнәрне табулаштыру.** Мондый мәгълүматлар бездә бик аз сакланган. Борынгы төркиләрнең иң популяр тотемы—*ак бүре*. Аның *бозкорт, башкорт, кашкар, ашыт* һ. б. синонимнары барлыгы билгеле. Бер легендада ак бүренең үзенең улавы белән дошман камалышында калган төркиләргә котылу юлын күрсәтүе хакында сөйләнелә. Кыпчакларда иртәгә сугыш буласы дигән төндә, далага чыгып, бүре булып улау йоласы булган. Чөнки бүре улавы яхшы фал саналган. Бу тотемистик ышанудан татар телендә *«бүресе улый»* дигән әйтелмә сакланып калган. Ул «кулга дәүләт, байлык керү һ. б. ш. сәбәптән эшләре алга китү, тормышны яхшыру» мәгънәсен белдерә.

Бараба һәм Омск өлкәсендә яшәүче татарлар аюны *олы ата, олы әкә, бабай, хуҗа, көрән* кебек алмаш исемнәр белән атыйлар. Моннан максат—аюның күңелен табу, аны рәхимләндерү. Чөнки, имештер, ул *«Аю дисәң—ачулана, бабай дисәң—куана»* икән. Ихтимал, монда аюны кайчандыр булган тотемлаштыру эзләре саклангандыр. Фәнни әдәбиятта Казан татарларының куян исемен башка исем белән алыштырулары аны, изге, тотем хайван итеп санаудан килә дип языла. Әлбәттә, моның анимизм белән бәйләнгән булуы да бик мөмкин. Борынгы кеше табигать күренешләренең серләрен аңлый алмаган, алар артында ниндидер тылсымлы, кодрәтле затлар тора дип уйлаган. Аныңча, кырларның, урманнарның, елга күлләрнең, торак урыннарының үз «иясләре» булган. Билгеле, бу затларны кеше үзе өчен куркыныч көч итеп санаган. Чөнки ул аларның «биләмәләрендә» киекләр аулаган, балык тоткан, җиләк-җимеш җыйган. Җитмәсә, бу «ияләр» әле үзара да дошманлашып торганнар. Шушы катлаулы мөнәсәбәтләр эчендә кеше «дипломатик зирәклек» күрсәтергә тырышкан. Әйтик, йорт тирәсендә киек хайваннарның исемен телгә алудан сакланган: йорт иясе, ачуланып, зыян салыр дип курыккан. Шушындый ышану тәэсирендә булса кирәк, татарларда элегрәк сарык бәрәннәре янында куян исемен әйтү катгый тыелган: аны *озын колак, кыр тәкәсе, чал тәкә, пырыйк, кыртый, миран* кебек алмаш исемнәр белән генә атаганнар. Әгәр бу шартны боза калсаң, имеш, бәрәннәр үлеп бетәчәк икән.

Куянның алмаш исемнәреннән кайберләре табышмакларда да файдаланылган. Мәсәлән, *«Чал тәкәдә мөгез юк»* (Куян.).

**Төрле явыз рухларның исемнәренә табу салу.** Ялмавыз, җен-пәри, шайтан ише яман затларны да халык алмаш исемнәр белән атап йөрткән. Мифтагы сынар күзле ялмавызның кушаматы сынар тәрәзә булган. Н. Исәнбәт язганча, андыйлар, «төрле сурәткә кереп, кешеләрнең ни сөйләшкәннәрен ишетеп торалар, әгәр дә сүз үз хакларында бара икәнен белсәләр, безне таныды дип гайрәтләнәләр, шуңа күрә аларны сүреллеру, биздеру өчен, берәр яман исем белән атарга кирәк, шуннан алар, гарьләнеп, кешене калдырып китәләр» имеш. Шушы җирлектә бу явыз рухларны иске чабата дип атау киң таралган булган. Аларны халык бизгәк таратучылар дип санаган һәм бизгәкне «иске чабата чире» дип йөрткән». Бу хакта әле алдарак тагын сүз булыр.

**Кешегә зарарлы хайваннар, кортлар, бөҗәкләр исемнәрен тыю.** Борынгы легендаларда бүре изге тотем, игелекле, ярдәмчел нәсел башы буларак күзаллана да, реаль тормышта ул безнең якта киң таралган явыз ерткычларның берсе. Кешеләр, табигый ки, мал-туарларын аннан сакларга тырышканнар, үзләре дә аның белән очрашырга бик ашкынып тормаганнар. *«Бүрене телгә алсаң, каршыңа чыгар, ди»* кебек ырау-ышанулар бу исемгә табу салынган булуы хакында сөйли.

Бүре кебек үк куркыныч һәм еш очрый торган икенче бер зат—*кара елан*. Аның чагуы кайчакта кешене хәтта үлемгә үк китергән. Шуна күрә дә урман кырларда еланга юлыга калганда, татарлар аны һич тә үз исеме белән атамаганнар, ә *кара таяк, чыбык, майлы каеш, чыбыркы* кебек алмаш исемнәргә мөрәҗәгать иткәннәр. Тышкы яктан еланга охшасалар да, болар барсы да җансыз, хәрәкәтсез әйберләр. Димәк, мондый алмаш исемнәрнең тылсымы астында елан үзе дә хәрәкәтсез калыр дип көтелгән:

Жылан дисән—жылыта,
Камчы дисән—тик ята.
Елан дисән йылып[1] китә,
Каеш дисән—кайышып[2] китә.

Еланның алмаш исемнәре табышмак текстларында да еш очрый. Бер үрнәге әле 1303 елда төзелгән «Кодекс куманикус»та ук теркәлеп калган: «Йазда[3] йаулы[4] кайыш йатыр. Ол йылындыр». Ә менә бүгенге фольклор җыентыкларыннан алынган мисаллар:

Юл өстендә майлы каеш.
Җир астында майлы чыбык.
Җир камчыны тотып булмый.
Ялан аша сапсыз чыбыркы
Сак кына шуып сыпыртты.

Кешеләр сүзнең тылсым көченә паразит бөҗәкләргә каршы да юнәлткәннәр. Беренче чиратта, әлбәттә, кандалага каршы. Аны «кибү» сүзеннән ясалган *кибәк*, «лапаю»дан[5] алынган *лапак* кебек алмаш исемнәр белән атаганнар. Янәсе, ул *«Кандала дисәң—кадала, кибәк дисәң кибә»*, ә *«Лапак дисәң—лапаеп китә»*. Бу бөҗәкне «ярсытмас» өчен аны «ул үзе белми торган» *кыскаяк, кызыл, яссы* кебек алмаш исемнәре белән дә атаганнар. Болары табышмакларда кулланылыш тапкан:

Өй тирәли кызыл бодай чәчтем.
Асты такта, өсте такта,
Кызыл егет карап ята.
Кызыл корсаклы бала
Кеше таларга бара.
Үзе яссы, үзе сасы.
Киштә буйлап кызыл йомгак тәгәри.

---

[1]Й ы л у—шуу, шуышу.
[2]К а й ы ш у—бөгелү, бөгәрләнү.
[3]Й а з (йазы)—дала.
[4]Й а у—май.
[5]Л а п а ю—җәелү, яньчелү.

**Төрле чир исемнәрен, үлем-житемгә бәйле атамаларны тыю.** Ихтимал, бу төркемгә караган табу сүзләр сан ягыннан иң күптер. Бездә байтак чирләрнең исемнәрен телгә алмау инде үзе үк алардан котылып калуның житди чарасы булып саналган. *«Авыруның колагы сак»* дип кисәтә халык ышануы. Имештер, үз исемен ишетсә, чир-авыру шунда ук килеп тә житә икән. *«Атың атама—адашып китсен!»* дигән гыйбарә әнә шундый хәвефтән ничек саклану кирәклеген күрсәтә. Каюм Насыйри язганча, әле XIX йөзнең икенче яртысында да бизәкне һәм томауны атсыз дип кенә йөрткәннәр. *«Атсыз авыруның аты корсын!»* дип тә теләгәннәр. Дөрес, «бизгәк» сүзенә табу салганда халык бу чирне бөтенләй үк исемсез калдырмаган, ана *шом тоту, суык тоту, суык чир, өшеткеч, өшетү сырхавы* һ. б. ш. алмаш исемнәр дә уйлап тапкан.

Бизгәккә каршы көрәшнең житди чараларыннан берсе итеп халык медицинасында бу чирне (дөресрәге аны таратучы явыз рухларны) куркыту ысулы саналган: *«Бизгәк авыруы белән авырган кешене бик каты куркытсаң, бизгәге кача, ди»; «Куркытсаң бизгәк кача, имеш»; «Суык тотса, бәхерниса*[1] күрсәтәләр: курыксын өчен» һ. б. Шушы максатта бизгәк белән авыручы өстеннән аю атлатып чыгарганнар. Яки каты итеп: «Пожар!» дип кычкырганнар...

Бизгәкне, инде әйтеп үткәнебезчә, тагын *иске чабата, ташландык чабата, черек чабата* дип тә йөрткәннәр. Бизгәк эләктерүне белдерергә теләгәндә: *«Миңа иске чабата ирде бит әле»*—ди торган булганнар. Бу очракта, күрәсең, чирнең хурлануыдан, гарьләнүдән качып китүенә өмет тотылгандыр. Сүзләр магиясе еш кына гамәл-хәрәкәтләр белән үрелгән. Бизгәк тотучыны, артына иске чабата тагып, урамга чыгарып жибәргәннәр. Шуның белән өйдән чир дә чыгып китә дип уйлаганнар.

Табу сүзләр урынына чирләргә кушыла торган алмаш исемнәрнең тылсым көченә ышану чуан-сызлавыкка караган мисалларда да бик ачык чагыла. Бу чирнең корыботак, оч, бетчә кебек исемнәре кергән күп кенә афористик ышанулар, юраулар бар:

Чуан дисән—чыгам ди,
Корыботак дисән—корый.

Чуан дисән—юаная,
Корыботак дисән—корый.

Чуан дисән—чыгам дип әйтә, ди,
Оч дисән—очып китә, ди, имеш.

Чуан дисән чыга,
Бетчә дисән—бетә.

Татар теленең аерым сөйләшләрендә зур чуанның ныжы дигән атамасы да саклана. Им-томчылар элек балтырына ныжы чыккан баланы кәжә тәкәсенә атландырганнар. Яки оланны, керәккә бәйләп, өч мәртәбә яңа гына ипие чыгарылган мичкә тыгып алганнар. Бу вакытта: *«—Ни куырасың?—Ныжы кырам»* кебек диалог та алып барылган. Шуңа охшаш им-томны рахит авырулы балаларга карата да үткәргәннәр. Бу хакта халык ышануында хәбәр ителә: *«Ипи шинасы булса, баланы керәккә бәйләп, мичкә тыгып алалар»*.

Магик алмаш исем һәм куркыту күзгә арпа чыгуны туктату өчен дә кулланылган: *«Арпа дисәң—арта ди, бодай дисәң—бетә, ди»; «Күзгә арпа чыга башлагач та пычак күрсәтсәң, куркып чыкмый, имеш»*. Монда, күрәсең, пычакның корал гына түгел, ә металл әйбер булуы да исәпкә алынгандыр.

Кайбер чирләрнең исемнәрен тыю дәвалау максаты белән генә түгел, ә аларны турыдан-туры атау әдәпсез, уңайсыз булу, эвфемизм белән дә бәйләнгән. Мәсәлән, женес әгъзалары чирләрен «начар авыру» яисә «кыргаяк» дип атау бар. Тышкы яктан үк бик авыр һәм шомлы тәэсир калдыра торган бума өянәге (эпилепсия, зыяндаш турында) *«үзчир, үзенеке тоткан, убыр күзе кагылган»* диләр. Ул, имеш, убыр карап киткән кешедә була икән.

Үлем-житем турында халык шулай ук ачыктан-ачык түгел, ә читләтеп, йомшаграк итеп әйтергә тырыша, ягъни эвфемизмга мөрәжәгать итә. Мәсәлән, терелмәслек авыру эләккән, әжәле житкән кешегә «жан талавы тигән» дип әйтәләр.

---

[1] Бәхерниса—бака.

Бу атама *«Жаманга җан талавы тими»* дигән мәкальгә дә кереп калган. Тагын *«Мәңгелек йокыга талу»*, *«Башсыз атка мену»*, *«Җиңсез-якасыз күлмәк кию»* кебек әйтелмәләр киң кулланылышта булган. Каюм Насыйри хәбәр иткәнчә, татарлар каберлекне «төтенсез авыл», «каенсар» кебек эвфемистик исемнәр ярдәмендә белдергәннәр. Болар барсы да безнең табышмакларыбызда да еш чорыйлар:

Төтенсез авыл—ул нәрсә?

Авылы бар, төтене юк,
Әтәч кычкырмый,
Халык тормый[1].

Берәү гомер буена киткән,
Каенлы күлнен каен төбенә житкән.

Башсыз атка менгән,
Жинсез күлмәк кигән,
Ашыга-ашыга ерак сәфәргә китеп бара.

Эвфемизмнар турында сүз чыккач, аларның өстә карап үтелгән башка тематик төркемнәр өчен дә хас булуын әйтеп китү урынлы булыр. Мәсәлән, күсене, үз исеме белән атарга ярамагач, *озын койрык* диләр. Бу гадәти, нейтраль, эчтәлекле алмаш исем. Әмма аны кайчакта *чибәр егет*, тычканны *идән асты кошы* дип, матур итеп тә атыйлар. Монда әлеге корткычларның күңелен табу, аларны юмалау мотивлары сизелә. Соңрак ул, әлбәттә, ироник төсмер дә алган. Пәрине *йорт яме* диюдә дә шул хәл сизелә. Татар халкының зәвыгы «дуңгыз» исемен тискәре кабул итә, ул башлыча хурлау, ачулану сүзе булып йөри. Шуңа күрә телебездә дуңгызны еш кына каты борын дип атыйлар. Ул табышмакка да кереп калган: *«Мыр-мыр мырлысы, бик каты икән борнысы»*.

* * *

Табу һәм яшерен тел лингвистиканың гаять күпкырлы һәм кызыклы күренешләреннән берсе. Бу мәкаләдә без аның кайбер өлкәләренә генә кагылып уздык. Әйтик, кеше исемнәрен табулаштыруның күптөрле мотивларына бөтенләй тукталмадык. Чөнки безнең тикшерү максаты булган афористик жанрларда соңгылары житәрлек чагылыш тапмаган, дөресрәге бу темага караган мәкальләр, табышмаклар һ. б. ш. әсәрләр йә булмаган, йә сакланмаган. Хәзер билгеле текстлар буенча хөкем йөрткәндә, аларда кеше исемнәрен куллану нигездә рифмалаштыру максатларына хезмәт итә.

Этнографик һәм лингфистик табу һәм шулар белән бәйле яшерен тел, алмаш исемнәр аеруча табышмак жанры язмышында житди роль уйнаган, хәтта, белгечләрнең раславынча, аның барлыкка китүенә үк этәргеч биргән. Ә соңрак табышмак инде үзе кешеләрдә яшерен тел күнекмәләре тәрбияләү өчен дә хезмәт иткән. Шулай ук юрау-ышануларда, им-томнарда, алкыш-каргышларда табу һәм сүзләр магиясе эзләре ярылып ята. Алар арасында аерым сүзләрне тыюның һәм алмаш исемнәр кулланунын ни өчен кирәклеген бәян итә торган афористик формадагы махсус кагыйдәләр булуы зур игътибарга лаек.

[1]Тормый—бередә йокыдан тормый, уянмый мәгънәсендә.

# 38—САД (ДАУТ) СҮРӘСЕ

**Сад сүрәсе 88 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Сүрәнең беренче хәрефе Сад. Исеме шуннан килә. Ләкин аны «Даут сүрәсе» дип тә йөртәләр.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Сад. Изге Коръән исеме белән әйтәмен ки: **(2)** имансызлар *(тыштан)* тәкәббер һәм *(эчтән Аллаһка, пәйгамбәренә)* каршы гыйсьяни халәттә булырлар. **(3)** Алардан элек яшәгән ничә халыкларны һәлак иттек. *(Коточкыч газап килгәнен күргәч)* алар ничек итеп кычкыра-кычкыра ялвардылар. Ләкин соң иде инде. Котылу форсаты узган иде. **(4)** Үз араларыннан чыккан кеше, үгетләүче килгәч, алар аптырап калды һәм ул кяферләр әйтте:

—Бу шыр чыккан алдаучы, *(бер күз буучы)* сихерче,—диделәр. **(5)** Тәңреләребезне бетереп, бары тик бер генә Алланы калдырырмы ул? Чыннан да, бу гаҗәп сәер гамәл,—диделәр. **(6)** Аларның юлбашчылары:

—Әйдә, барыгыз! Потларыгыз янына китегез дә, аларга табыныгыз. Сездән башка нәрсә таләп ителми. **(7)** Соңгы динебездә *(христианлыкта)* без бу турыда һич тә ишетмәдек. Бу бары тик уйдырма, ялган. **(8)** Бу Коръән арабызлагылардан бер аңа гына иңдерелгәнме?—дип Мөхәммәд янынннан китеп бардылар.

Хәер, алар Китабыма әллә кайчаннан бирле шикләнеп баглалар иде инде. Чөнки әле алар газабымны татып бакмады. **(9)** Әллә соң газиз вә юмарт һәм кодрәт иясе Раббыңның рәхмәт хәзинәсе алар кулындамы? **(10)** Яки күкләрнең вә Җир арасындагы хөкемдарлык алар кулындамы? Шулай икән, ул чагында алар *(ысуллары булса, бөеклеккә менеп карасыннар)*. **(11)** Алар төрле-төрле төркемнәрдән оешкан аламан гаскәрләр. Алар шунда ук тар-мар ителәчәк.

**12, 13.** Алардан алда да Нух халкы да, Гад халкы да, казыклар остасы Фиргавен дә, Сәмуд, Лут кавемнәре дә, Әйкә халкы да пәйгамбәрләрне ялганчыга чыгарып, мыскыл иттеләр. Менә шулар *(пәйгамбәрләргә каршы)* берләшкән өерләр иде.

*(Али Тургут язуынча, Фиргавен кешеләрне дүрт казыкка бәйләп җәзалый торган булган. Аять шуңа ишарәли. Ләкин М. Али «казык» кәлимәсе «куәтле илнең тоткасы» мәгънәсендә килә, ди.)*

**14.** Аларның һәрберсе күндерелгән пәйгамбәрләрне ялганчыга чыгарды һәм шуның аркасында алар җәза алды. **(15)** Болар да *(Мәккә кяферләре дә)* бер мизгелгә дә кичекми торган куркыныч бер аваз *(гөрелте—Җәбраил фәрештәнең кычкыруын)* көтә. **(16)**

—Раббыбыз! *(Үзебезгә тиешле җәзаны)* өлешебезне Хисап Көненнән алдан бир,—диделәр.

**17.** *(Ий, Мөхәммәд)* аларның кылмышларына сабыр ит, бәндәбез Даутны, куәт иясен хәтерлисеңме? Ул һәрвакыт Аллаһка юнәлә иде. **(18, 19)** Хактыр ки, Без иртә-кич аның белән бергә тәсбих әйтүче тауларны, төркем-төркем кошларны аңа буйсындырдык.

**20.** Аның хөкемдарлыгын куәтләндердек, аңа хикмәт вә итагатьле матур сөйләм бирдек. **(21, 22)** *(Ий, Мөхәммәд)* сиңа ике гаугачы турындагы хәбәр

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

килеп ирештеме? Ничек итеп алар мәчет диварына үрмәләп, Даут янына керделәр. Аларны күреп, Даут бик нык курыкты.

—Курыкма, без ике дәгъвачы. Беребез икенчебезгә зыян салды. Эшебезне гаделлек илә хөкем ит. Зинһар, хөкемеңә хөсетлек кертмә. Безгә дөрес юлны күрсәт,—диделәр.

**23.** *(Аларның берсе)* әйтте:

—Бу—минем кардәшем. Аның туксан тугыз баш сарыгы бар. Минем сарыгым бәрәү генә. Ул: анысын да миңа бир, дип соңгы сарыгымны да тартып алды.

**24.** Даут:

—Синең сарыгыңны үзенең көтүенә кушарга омтылып, ул хаксызлык кылган. Чыннан да, уртак мал белән эш кылучылар бер-берсенә хөсетлек кыла. Иман китереп, игелек кылганнар исә алай эшләми. Ләкин андыйлар аз.

Даут үзен сынап караганыбызны сизенде һәм *(намазын бозганына)* тәүбә итеп, Аллаһтан ярлыкау сорады, сәҗдә итте. **(25)** Сонра аның бу эшен *(намаз бозганын)* без гафу иттек. Яныбызда ана мәртәбәле урын бирдек һәм аның киләчәген бәхетле иттек. **(26)** Әй, Даут, Без сине Җир йөзендә *(үз кавемеңә)* хуҗа иттек. Шулай булгач, инсаннар арасында гаделлек белән хөкем йөрт. Артык хирыс һәм нәфесле булма. Шулай булсаң, соңыннан алар сине Аллаһ юлыннан яздырыр. Хактыр ки, Аллаһ юлыннан язганнарга, Кыямәт Көненә ышанмаганнарга интектергеч газаплар булыр.

**27.** Күкне, Җирне һәм алар арасындагыларны Без тиктомалга *(максатсыз)* юктан бар итмәдек. Бу—инкарьчыларның фикере генә. Инкарьчыларның эше, һай, мөшкелдер. Алар утта яначак. **(28)** Әллә Без иман китереп, игелек кылганнарны Җир йөзендә бозыклык эшләгәннәр белән тиң күрәбезме? Яки *(Аллаһның җәзасыннан)* курыкканнарны юлдан язганнар хисабына кертәбезме?

**29.** *(Рәсүлем)* сина бу изге Китапны, аятьләребезне аңласыннар вә зиһенле кешеләр үгет-нәсихәт алсыннар, дип иңдердек.

**30.** Без Даутка Сөләйманны бирдек. Сөләйман бик тә яхшы хезмәткәребез иде. Хактыр ки, ул һәрвакыт Аллаһ юлында булды. **(31)** Ахшам намазы якынлашып килгәндә аңа *(җил җитмәс җитез)*, саф токымлы юртаклар китерделәр. *(Төп нөсхәдә: бер тоягы җирдә, өч тоягы һавадагы атлар, диелгән.)* **(32)** Сөләйман әйтте:

—Чыннан да, ат яратуым аркасында мин Аллаһны онытып җибәргәнмен *(ахшам намазына соңгардым)*. Кояш батканын да сизми калганмын,—диде. *(Атлар чабып, күздән югалгач әйтте)*—**(33)** Хәзер тагын аларны минем янга алып килегез,—дип ул атларын муеннарын сыпырып, аякларын сөя башлады.

**34.** Хактыр ки, Без Сөләйманны шулай сынап карадык. Тәхетнең өстенә аның мәет кебек жансыз-хәлсез гәүдәсен утырттык. Ул тәүбәгә килде һәм яңа безгә сәҗдә итте.

*(Али Тургут аңлатмасы: Сөләйман (с.г.с) каты авырудан соң шулай җансыз гәүдә кебек ябыккан була. Сәламәтләнгәч:)*

**35.** Сөләйман әйтте:

—Раббым, ярлыка мине. Миннән соң яшәячәк кешеләргә дә бирелми торган хакимлек бир миңа. Шик юктыр ки, Син һәрвакыт чиксез юмарт була килдең,—диде.

**36.** Шулай итеп, Без җилне Сөләйманга буйсындырдык. Җил ул теләгән якка, ул теләгәнчә йомшак кына исә торган булып китте. **(37)** Мәһабәт биек биналар җиткезергә сәләтле, дингезгә чумып, энҗе-мәрҗәннәр алып чыгучы җеннәрне, **(38)** чылбырлар белән богауланган җеннәрне дә аның әмеренә бирдек. *(М. Али нөсхәсендә бу җеннәрнең туры мәгънәсендәге җеннәр булмыйча, күчерма мәгънәдәге, ягъни башка халыклардан әсир алынган коллар икәнлеге әйтелә.)* **(39)**

—Менә, безнең юмартлыгыбыз шушы булыр,—дидек.—Теләсәң, *(бу байлыкны)* башкаларга тарат, теләсәң—үз яныңда тот. Синнән хисап соралмас. **(40)** Дөресе шулдыр ки, яныбызда аның өчен шәрәфле һәм затлы урын бар.

**41.** *(Рәсүлем)* колыбыз Әйюбне дә онытма, искә алып тор. Ул Раббысына:

—Хактыр ки, шайтан миңа авырлыклар һәм күп бәлаләр китерде,—дип ялварды. **(42)** *(Әйюбкә әйтелде):*

—Аягың белән тип,—дидек. *(Ул типте һәм ике чишмә бәреп чыга башлады.)*

—Менә, синең эчәреңә һәм юынырга салкын су,—дидек. *(Әйюб галәйһиссәлләм) салкын су эчкәннән соң сәламәтләнде.)*

*(М. Али бу аятькә яңача аңлатма бирә. Аныңча «җиргә аяк белән тибү» түгел, «үкчәләр белән атны әйдәкләү» икән. Ягьни, Аллаһ Әйюбкә атын куаларга куша, Әйюб исә, су тарафына тиз барып җитә.)*

**43.** Башында акылы булган кешеләргә гыйбрәт булсын өчен һәм рәхмәтебезнең киңлегенә үрнәк мисал итеп, аның гаиләсенә күп бала бирдек.

**44.** —Кулыңа бер учма үлән сабагы ал да, шуның белән *(хатыныңа)* сук. Антыңны бозма!—дидек. Чынлыкта, Без Әйюбне сабыр һәм тугры бәндә буларак беләбез. Ул гаҗәеп яхшы хезмәткәребез иде. Ул һәрвакыт Аллаһ юлында булды.

*(«Әйюбнең хатыны, Ягькуб кызы Ләйлә, хаста ире Әйюб алдында ялгыш эш кыла. Авыру Әйюб, терелгәннән соң, аңа йөз таяк суктырырга ант итә. Әмма хатыны Ләйлә аңа тугры хезмәт итеп, яхшы эшләр башкарган кеше иде. Шуңа күрә, игелекләре күп булганга, Җәнабе Хак йөз тапкыр таяк белән сугуны, ант бозмас өчен, үлән сабагы белән алыштырырга әмер итә. Әйюб авырттырмыйча гына, хатынын мәгънәви җәзага тарта»*

Хәсән Чантай тәфсиреннән)

**45.** *(Ий, Мөхәммәд)* куәтле һәм зиһенле бәндәләребез Ибраһим, Исхак белән Ягъкубны да исеңә төшер. **(46)** Без аларга Ахирәт йорты турында уйлanучы аеруча ихласлы кешеләр итеп яраттык. **(47)** Хактыр ки, алар—Безнең янбызда аерым урын биләүче игелекле бәндәләрдер.

**48.** Исмәгыйльне, Әльясаны һәм Зулкифелне онытма. Барысы да игелекле кешеләр иде. **(49)** Менә, бу аларны яд итү *(хөрмәтләп искә төшерү)* булды. Шунысы хактыр ки, тәкъвалар өчен киләчәктә Сәгадәт әзерләнгән. **(50)** Алар өчен генә ачыла торган капкалы Гаден җәннәтләре аларны көтә. **(51)** Алар анда кәнәфиләргә кырын ятып, җаннары теләгән җимешләр һәм эчемлекләр генә китертерләр. **(52)** Яннарында тыйнак карашлы үзләренә кулай яшьтәге гүзәлләр булыр. **(53)** Менә, Хисап көне килеп житкәч, сезгә бирелә торган нәрсәләр шулардыр. **(54)** Әлбәттә, бу—Без биргән ризыклар. Алар, беркайчан да бетмәс-төкәнмәс булыр.

**55.** Дөрес, анысы шулай булыр. Әмма азгыннарга хәтәр бер газап әзерләнгән. **(56)** Алар җәһәннәмгә керәчәк. Җәһәннәм исә бик тә хәтәр урын. **(57)** Аларның эчә торганнары кап-кайнар һәм эренле су булыр. Шуны эчеп баксыннар! **(58)** Шушы газапларга охшаш тагын башкалары да житәрлек булыр. **(59)** *(Инкарьчыларның башлыкларына):*

—Менә, сезнең белән бергә җәһәннәмгә керәчәк халыклар шушылардыр. Алар рәхәт күрмәсен. Аларга шул җәһәннәм уты хас,—диярләр. **(60)** *(Аларга ияргәннәр исә):*

—Юк! Сез үзегез рәхәтлек күрмәссез. Азгынлыкны безгә сез өйрәттегез. Аһ, нинди хәтәр урын бу,—дип әйтерләр. **(61)** Янә алар:

—Раббыбыз, моны *(азгынлыкны)* безгә кем китергән булса, шуларга ялкын эчендәге газапны икеләтә бир, дип Аллаһка ялварыр. **(62)** *(Инкарьчылар, ягьни җәһәннәмгә кергән Мәккә кяферләре):*

—Безгә ни булды? Дөньяда чакта яман саналган кешеләрне *(пәйгамбәрләрне)* биредә нигә күрмибез?—дип сорарлар. **(63)**—Без аларны мыскыл иткән идек түгелме? Әллә без аларның монда *(җәһәннәмдә)* икәннәрен күрми калдыкмы? **(64)** Менә шулай, җәһәннәмлеләрнең гауталашуы шулай булыр.

**65.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Мин бары тик бер кисәтүче генә. Бер Аллаһтан, бөтен нәрсәгә кодрәте житә торган бер Раббыдан башка тәңре юк. **(66)** Күкләрнең, Җирнең һәм икесе арасында булганнарның хуҗасы Раббы барысыннан да өстенләр. Ул чиксез ярлыкаучыдыр.

**67.** Әйт син:

—Бу—бөек хәбәр!—диген. **(68)**—Әмма сез аннан йөз чөерәсез. **(69)** Алар анда *(Гарештә)* бәхәсләшә икән, аларның ни турында сөйләшкәне хакында минем һичбер хәбәрем юк,—диген.

**70.** Бары тик кисәтүче булганым өчен, миңа вәхий ителгәнне генә сезгә җиткерүче,—диген.

**71.** Раббың фәрештәләренә әйтте:

—Чыннан да, мин балчыктан кеше ясаячакмын,—диде. **(72)**—Аны ясап бетергәннән соң, аңа рухыбыздан җан өргәннән соң, шундук аңа сәҗдә итегез,—диде. **(73)** Бөтен фәрештәләр дә берочтан сәҗдә итте. **(74)** Бары тик Иблис лә-гыйнь генә сәҗдә итмәде. Ул тәкәбберлек рәвешен алды да, кяферләрдән булды. **(75)** Аллаһ әйтте:

—Әй, Иблис! Үз кодрәтем белән барлыкка китергәнгә сәҗдә итүдән сине ни-нәрсә тыеп тора? Горурландыңмы син, әллә бөеклек шаукымы йоктымы сиңа?—диде. **(76)** Иблис әйтте:

—Мин аннан яхшырак. Син мине уттан яралттың; аны балчыктан гына,—диде. **(77)** Аллаһ әйтте:

—Алайса, чыгып олак моннан! Син ләгънәт ителгән булдың, ләгыйнь буларак таш атып куылачаксың. **(78)** Җәза көненә чаклы синең өстеңдә ләгънәтем торыр,—диде. **(79)** Иблис әйтте:

—Йа, Раббым, алайса, син янадан терелә торган Көнгәчә миңа дөньяда торырга мөһләт бир,—диде. **(80, 81)** Аллаһ әйтте:

—Ярар, тора бир,—диде.—Мәгълүм вакыткача!

**82, 83.** Иблис әйтте:

—Синең кодрәтең белән ант итәмен ки, мин аларны, Валлаһи, аздырачакмын. Әлбәттә, сиңа ихлас булганнардан башкаларын,—диде. **(84, 85)** Аллаһ әйтте:

—Хактыр ки, мин дөресен сөйлимен, сине һәм сиңа ияргәннәрнең барчасы белән җәһәннәмне тутырачакмын,—диде.

**86.** *(Рәсүлем)* әйт син:

—Бу эшләрем өчен мин сездән һичбер түләү таләп итмимен. Вәхий ителгәннәрдән башка, үзлегемнән мин һичбер нәрсә уйлап чыгармыйммын,—диген. **(87)** Бу *(Коръән)* халыкларга үгеттән башка нәрсә түгел. **(88)** Анда язылган хәбәрләрнең хак икәнлегенә әле сез соңрак ышанырсыз.

# 39—ЗҮМӘРА (ХАЛЫК ӨЕРЕ) СҮРӘСЕ

**Зүмәра сүрәсе 75 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. 71-73 нче аятьләрдә кяферләр белән мөэминнәр оештырган халык төркемнәреннән сүрәнең исеме килә. Зүмәра—төркем, өер, җәмгыять мәгънәләрен эченә алган сүз.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Бу Китап гыйззәт һәм хикмәт иясе Аллаһ катыннан иңдерелде. **(2)** *(Рәсүлем)* шөбһәсез ки, бу Китапны сиңа Хакыйкать буларак иңдердек. Шуңа күрә, син динне *(ихлас)* тот. Аллаһ ризалыгы өчен гыйбадәт кыл. **(3)** Аң бул! Пакь дин бары тик Аллаһтан гына килә. Аны инкарь итеп, үзләренә башка дуслар *(уйдырма илаһлар)* эзләп табучылар:

—Безне Аллаһка якынайтсыннар, дип кенә без аларга табынабыз, коллык итәбез,—диләр. Дөресе шул, Аллаһ *(мөэминнәр белән кяферләр арасындагы бәхәсне)* ахырына җиткезеп хөкем чыгарачак. Шик юк, Аллаһ ялганчы вә инкарьчыларны тугъры юлга бастырмас.

**4.** Әгәр Аллаһ берәр угыл теләсә иде, һичшиксез, ул Үзе яралтканнардан берсен сайлап алган булыр иде. Ул андый эшләрдән өстен. Ул—берәү генә. Ул—чиксез кодрәт иясе. **(5)** Аллаһ күкләрне вә Җирне Хакыйкать буларак яралтты. Төнне көнгә ялгый *(бу фасылда төн озая)*. Көнне төнгә катыштыра *(бу фасылда көн озая)*. Кояш вә Айны әмерендә тота. Аларның һәммәсе дә билгеләнгән вакытка чаклы йөзеп йөрер.

Аң бул! Аллаһ һәрнәрсәдән өстен һәм чиксез мәрхәмәтле.

**6.** Ул сезне бер жаннан *(Адәмнән)* үрчетте. Сонра аннан хатынын яралтты. Сезнең өчен мал-туарлардан сигез пар иңдерде. Сезне аналарыгызның карынында өч кат караңгылык эчендә яралтып, бүтән рәвешләргә кертеп, дөньяга чыгарды. Раббыгыз булган Аллаһ шулай кыла. Бөтен мөлкәт-байлык Аныкы гына. Аллаһның Үзеннән башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Шулай булгач, ничек итеп сез Хакыйкатьтән йөз чөерәсез?

*(«Аналык өч катлы була: корсак, аналык, яралгыны төреп алган элпә—соңгылык. Бүтән рәвешләргә кертеп: ир кешенең җенес орлыгы хатын аналыгына кереп, хатынның токым орлыгы белән кушылуыннан алып, туганына чаклы арада яралгы берничә рәвеш алып үсә. Сигез җанвар, дүрт пар: дөя, сыер, сарык, кәҗә».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**7.** Көферлек итәргә теләсәгез, әлбәттә, ихтыярыгыз: Аллаһ сезгә мохтаж түгел. Шулай да Ул бәндәләренең көферлегенә разый түгел. Шөкер итәчәк булсагыз, шөкерегез үз файдагызга булыр, Аллаһ сездән разый калыр. Башка кешенең гөнаһларын һичкем үз өстенә алалмас. Ахырда барчагызның да кайтарылышы бары тик Аллаһка булыр. Дөньяда ни кылдыгыз, барысы турында да Аллаһ сезгә Үзе әйтер. Күңелегездә нинди уйлар яшерелгәнен дөресе белән белеп торучы—Аллаһ Тәгалә.

**8.** Берәр кыенлык килсә, кеше бөтен барлыгы белән баш орып, Аллаһка ялвара башлый. Соңыннан аңа *(Аллаһтан)* берәр нигъмәт бирелсә *(бәладән котылса)*, элеккеге кебек, ул ялварганнарын оныта. Башкаларны да Аллаһ юлыннан чыгарыр өчен Аллаһка тиңнәр эзли башлый. *(Ий, Мөхәммәд)* андыйларга әйт син:

—Көферлегең белән бераз ләззәтлән! Әмма син барыбер ут эчендә калачаксың,—диген.

**9.** Ахирәт көненнән курыккан, Раббының рәхмәтен өмет итүче, төнге сәгатьләрдә сәҗдәгә киткән, аягүрә басып намаз укыган, гыйбадәт кылган кеше *(инкарьчы)* белән бер түгелдер, шәт? Әйт син аларга:

—Белгән белән белмәгән бер булырмы? Бары тик саф гакыл ияләре генә бу Хакыйкатькә төшенер,—диген. **(10)** *(Ий, Рәсүлем)* әйт син:

—Иманлы кешеләр! Раббыгыздан куркыгыз. Бу дөньяда игелек кылганнар өчен *(җәннәтләр)* нигъмәтләр бар. Аллаһның җирләре бик киңдер. Бары тик сабыр иткәннәргә генә бихисап әҗерләр булачак. **(11)** Әйт син:

—Мин Аллаһка, аның диненә ихлас инанучы буларак, гыйбадәт кылырга тәкъдирләндем,—диген. **(12)** Әйт син:

—*(Өммәтемдә)* иң беренче мөселманнарның берсе булу миңа тәкъдир ителде, диген. **(13)** Әйт син:

—Раббыга каршы мин баш күтәрсәм, хактыр ки, каты газапка дучар булачакмын,—диген. **(14, 15)** Әйт син:

—Мин динемдә ихлас кеше буларак, бары тик Аллаһка гына гыйбадәт кыламын,—диген.—Инде сез Аны инкарь итеп, теләгәнегезгә табынасыз.

Әйт син:

—Хактыр ки, югалтуларга дучар булганнар Кыямәт көнендә дә үзләрен һәм якыннарын да югалтуларга дучар итәчәк. Аң булыгыз! Бу бик тә хәтәр кайгы булыр. **(16)** Аларның өстендә уттан ясалган түшәмнәр, асларында уттан ясалган идәннәр булыр. Менә, Аллаһ шулай итеп куркыта. Әй, бәндәләрем! Гөнаһ кылудан куркыгыз, зинһар.

**17.** Тагуттан *(шайтаннан, потлар һәм сәнәмнәрдән)* качып, Аллаһка юнәлгәннәр өчен бер сөенеч *(җәннәт вә андагы нигъмәтләр)* бар. Шулай булгач, тугры бәндәләремнән *(сезгә җәннәт бакчалары булачак, дип)* сөенче ал. **(18)** Алар сүзгә *(китапларга)* колак салучылар һәм аның да иң татлысына *(Коръәнгә)* дикъкать итүчеләр. Менә шундыйлар Аллаһка тугры юл тапкан кешеләр булыр. Менә шундыйлар саф акыл ияләре инде. **(19)** Үзенә хак җәза хөкеме чыгарылган һәм утка ташланган гөнаһкярны коткарырга син алыныр идеңме *(Мөхәммәд)*? **(20)** Раббы газабыннан курыкканнар өчен берсе өстенә икенчесе корылган биналар булыр, асларыннан ермаклар агып тора торган зиннәтле урыннар хәзерләнгән.

Болар—Аллаһ вәгъдә иткән нигъмәтләр. Ул беркайчан да вәгъдәсен бозмас. **(21)** Күреп торасың бит, Аллаһ Күктән яңгыр яудырды. Аны җирдәге чишмәләргә юнәлтте. Соңра төрле-төрле төстәге игеннәр үстерде. Аннан соң алар корый, сап-сары була. Аннан соң алар кибеп бетә. Шик юк, бу эшләрдә акылы булганнар өчен сабаклар бар. **(22)** Берәр бәндәсенең күңел тәрәзәсен ачып, Аллаһ Ислам нуры иңдерсә, ул кеше Раббының нуры эчендә калыр. Аллаһны зикер итә алмаслык булып, күңелләре катканнарга языклар булыр. Көн кебек ачык, алар тугры юлдан язып, адашкан.

**23.** Сүзләрнең иң татлыларын *(аятьләрне)* бер-берсенә аваздаш итеп, Аллаһ бер Китап итеп туплады һәм *(бүлеп-бүлеп)* иңдерде. *(Коръәнне укыганда)* Раббыга тирән мәхәббәт тәрбия иткән кешеләрнең тәннәре чымырдап китәр, шуннан соң аларның тәннәре дә, күңелләре дә *(миһербан тулып)* Аллаһка юнәлер. Менә шушы Китап Аллаһ күндергән рәһбәрдер; *(рәһбәр—җитәкче, юлбашчы).* Ул *(шушы Коръән белән)* теләгән кешесен тугры юлга күндерер. Аллаһ юлдан яздырган кешене беркем дә тугры юлга алып чыга алмас. **(24)** Кыямәт көнендә чыраен газаплы уттан качырырга азапланган кеше *(белән саваплы кеше)* бер булырмы? Ул залимнәргә:

—Кылмышларына күрә, җәзасын да татыгыз,—дип әйтерләр.

**25.** Алардан элек яшәгәннәр *(пәйгамбәрләр)*не ялганчыга чыгарды һәм искәрмәгән җирдән аларга җәза килде. **(26)** Шулай итеп, Аллаһ аларга бу дөньяда ук җәзасын татыттырды. Ахирәт газабы аннан да хәтәррәк булачак. Их, алар шуны алдан ук аңлаган булса иде! **(27)** Хактыр ки, үгет алсыннар дип, Коръәндә инсаннарга һәр гыйбрәтле мисаллар китердек. **(28)** *(Гөнаһлардан)* саклансыннар дип, мөкәммәл гарәп телендә Коръән иңдердек.

**29.** Аллаһ ике кол турында мисал китерә. Колларның берсе үзара дус булмаган күп хуҗага хезмәт итә икән. *(Кайсысының әмерен үтәргә белмәенчә, йомышны башкаралмый кала һәм үзенә шелтә ала.)* Икенчесенең хуҗасы берәү генә, ди. *(Аның хуҗасының әмерен җиренә җиткезеп үти һәм гел мактала икән.)* Ике кол бертигез булырмы? *(Күп хуҗалысы мөшрик хәлендә. Бер хуҗалысы мөэмин хәлендә. Мөшрикләр күп илаһларга табына. Мөэминнәр исә бер Аллаһка коллык итә.)* Аллаһ кына мактауга лаек. Ләкин аларның күбесе бу турыда белми.

**30.** *(Мөхәммәд)* син, һичшиксез, үләчәксең, алар да үләчәк. **(31)** Ахырда, һичшиксез, сез дә Кыямәт көнендә Раббыгызның хозурына килеп басачаксыз. **(32)** Аллаһка каршы ялган уйдырган, үзенә китерелгән *(Коръәнне)* ялганга чыгарган залимнән дә залим кем бардыр? Кяферләрнең урыннары җәһәннәмдә булмый, кайда булсын!

**33.** Дөреслекне алып килгән вә аны тәкъдир итүче кешеләр дә бар. Яманлык кылудан ваз кичкән кешеләр менә шулар була инде. **(34)** Андыйлар өчен Раббы янында һәр нәрсә үзләре теләгәнчә мул булыр. Игелек кылганнарның бүләге менә шул булыр. **(35)** Шулай итеп, Аллаһ аларның *(фани дөньяда)* яшәгән вакытта кылган яман эшләрен дә каплаячак. Кылган игелекләренең иң яхшыларын гына сайлап, аларны бүләкләр.

**36.** Үзенең илчесен *(Пәйгамбәрне)* саклар-яклар өчен Аллаһ үзе житмимени? Сине башка *(уйдырма илаһ)*лар белән куркыталар. Аллаһ юлдан яздырган кешене беркем дә туры юлга кайтара алмас.

**37.** Аллаһ берәрсен тугры юлга бастырса, аны берәү дә юлдан яздыра алмас. Мотлак кодрәт иясе һәм *(дошманнардан)* үч кайтаручы—Аллаһ Тәгалә түгелмени?

**38.** Хактыр ки, алардан:

—Күкләрне вә Җирне кем юктан бар итте?—дип сорасаң, әлбәттә:

—Аллаһ бар итте,—дип әйтерләр. Әйт син аларга:

—Шулай булгач, әйтегез әле: Аллаһ миңа берәр төрле зарар кылырга теләсә, Аллаһны инкарь итеп, табынганнарыгыз Ул биргән зарарны китәрә алачакмы? Яки Аллаһ миңа рәхмәт әйләсә, алар Аның рәхмәтен юкка чыгара аламы?—дип сора. Әйт син аларга:

—Миңа *(ярдәм итәргә, мине сакларга)* Аллаһ житәр,—диген. Тәвәккәл итүчеләр бары тик Аңа инанып, аркаланалар.

**39.** Әйт син:

—Әй, халкым, сез үз хаҗәтегезчә кылыгыз, мин үз җаема эш башкарырмын,—диген. Озакламый барысын да белерсез: **(40)** үзен рисвай итәчәк газап кемгә киләчәк, чиксез газап кемгә булачак?

**41.** Хактыр ки, Без ул Китапны инсаннарга файда булсын өчен, Хакыйкать буларак, сиңа иңдердек. Кем тугры юлга басарга ихтыяр итә, бу аның үз файдасына. Кем юлдан язарга тели, аның да үз зарарына булыр. Син *(Мөхәммәд)* аларны ирексезләп, диңгә кертүче вәкил түгелсең.

**42.** Аллаһ кеше үлгәндә аның җанын алыр. Исәннәр йоклаганда, Аллаһ аларның рухын үзенә алып торыр. Шулай итеп, үлемгә хөкем ителгәннәрнең рухын үз янында калдырыр. Йокыдагыларның җанын мәгълүм бер вакытка чаклы тәннәренә кире кайтарып торыр. Шик юк, фикер йөртүчеләр өчен монда катгый гыйбрәтләр бар.

**43.** Әллә соң алар үзләренә шәфәгатьче итеп Аллаһтан башкаларны ялладылармы? Әйт син:

—Бер нәрсәгә дә көчләре житмәгән килешмә һәм акыллары житешле булмаса дамы?—диген. **(44)** Әйт син:

—Бөтен шәфәгать—Аллаһ хозурында. Күкләр вә Җирдәге бөтен милек—Аныкыдыр. Барыбер бөтенегез дә Аның хозурына кайтарылачаксыз. **(45)** Аллаһның бар икәнлеге турында сөйләгәндә, Ахирәт көненә инанмаганнарның йөрәкләре жу итеп китә. Аллаһтан башка *(пот)*ларның исеме телгә алынганда, аларның чырае яктыра. **(46)** Әйт син:

—Әй, күкләрне вә Җирне яраткан, яшерелгәннәрне дә, яшерелмәгәннәрне дә белүче Аллаһ, бәндәләрең арасындагы бәхәс сәбәпчесе булган нәрсәләрне Үзең ачыклап бирерсең,—диген. **(47)** Җирдәге бөтен байлыкка алар хуҗа булып, тагын шулкадәр байлык алар кулына керсә дә, Кыямәт көнендәге газаплардан котылыр өчен шул байлыкны да алар кызганып тормас иде *(ләкин ул байлык аларга файда китермәс).* Аллаһ аларның башларына да килеп карамаган җәзалар бирер. **(48)** Аларның *(дөньяда)* кылган яманлыклары *(Кыямәт көнендә)* урталага чыгачак, көлкегә чыгарган нәрсәләре үзләрен камап алачак. **(49)** Берәр кеше хәлдә калса, кеше Безне ярдәмгә чакыра. Соңыннан үзенә Бездән нигъмәт-муллык килсә:

—Бу миңа бары тик үземнең *(булдыклылыгым)* белемем аркасында гына килде,—ди. Дөрес, бу бары тик сынап карау гына. Ләкин аларның күбесе бу турыда белми. **(50)** Алардан элек яшәгәннәр дә шулай сөйли иде. Ләкин казанган байлыклары үзләренә *(Кыямәттә)* файда китермәс. **(51)** Кылган явызлыклары аларны җәзага ирештерде. Хәттин ашучыларның кылган яманлыклары үзләреннән башына төшәчәк. Бу мәсьәләдә Аллаһны бичара хәлдә калдырып, Аңа комачаулый алмассыз. **(52)** Үзе ихтыяр иткән бәндәсенә Аллаһ ризыкны мул бирер, теләмәгәненең ризыгын кисәр. Алар шуны да белмиләрме? Шик юк, иман китергәннәр өчен монда гыйбрәтләр бар. **(53)** Әйт син:

—Һәй, үз нәфесләре *(комсызлыклары)* аркасында хәттин ашканнар! Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәгез. Аллаһ *(тәүбә иткән)* барча гөнаһлыларны ярлыкаучы. Хактыр ки, Ул чиксез ярлыкаучы, хәтсез мәрхәмәтле. *(Ләкин бу: соңыннан тәүбә итәрмен, дип азгынлык кылып, хәттин ашарга ярый, дигән сүз түгел. Аллаһ барысын да күреп, белеп тора.)*

**54.** Сезгә газап килеп төшкәнчегә кадәр Раббыга юнәлегез. Аңа тәслим кылыгыз, *(вакытында тәүбә итмәсәгез)* соңыннан сезгә ярдәм булмас. **(55)** Сез, искәрмәстән, һич уйламаган яктан башыгызга җәза килеп төшкәнчегә кадәр Раббыгыз сезгә иңдергәннәреннән иң мөһабәтенә—Коръәнгә иярегез.

**56.**—Аллаһ алдында хәттин ашкан гамәлләрем өчен мин үкенәмен, миңа языклар булсын. Чыннан да, мин *(диние, Коръәнне)* мәсхәрә итеп көлгәннәр арасында идем,—дип үкенерлек булмасын. **(57, 58)** Яки:

—Аллаһ мине тугры юлга бастырган булса, әлбәттә, (гөнаһ кылудан) сакланган булыр идем,—дип яки газапны күргәч тә:

—Их, дөньяга кире кайта торган булса, мин гел игелек кенә кылыр идем,—дип кайгырырлык булмасын. **(59)** *(И, кяфер, дөньяга кире кайту булмас.)*

Аятьләрем сиңа килде. Син аларны ялганга чыгардың. Тәкәббер идең. Һәм инкарьчылардан булдың.

**60.** *(Ий, Мөхәммәд)* Аллаһ хакында ялган сөйләгәннәрнең чырайлары Кыямәт көнендә кап-кара булганын күрерсең. Масайганнарның урыны җәһәннәм түгелме?

**61.** Аллаһ саф-ихлас мөэминнәрне *(Кыяматтә)* коткарыр. Аларга һичбер бәла китермәс. Мөэминнәргә *(Кыяматтә)* кайгы ирешмәс.

**62.** Аллаһ барча нәрсәне юктан бар итүче—яралтучы. Аллаһ һәр нәрсә белән Үзе теләгәнчә идарә итә. **(63)** Күкләрнең вә Җирнең сер ачкычлары бары тик Аның хозурында. Аллаһның аятьләрен инкарь итүчеләр бар. Менә шулар инде хәтәр югалтуларга дучар кешеләр. **(64)** Әйт син:

—Әй, наданнар! Сез Аллаһтан башка нәрсәләргә коллык итүемне телисезме?—диген. **(65)** *(Мөхәммәд)* хактыр ки, сиңа да, синнән элек килгәннәргә дә шулай вәхий ителде:

—Шиксез, әгәр дә Аллаһка тиң санап, башкага табынсаң, кылмышларың, һичшиксез, бушка китәр вә син югалтуларга мәхкүм булырсың. **(66)** Әйе, син бары тик бер Аллаһка гына буйсын һәм шөкер итүчеләрдән бул. **(67)** Алар *(мөшрикләр)* Аллаһны чыны белән танып бетермәделәр. Кыямәт көнендә бөтен Җир йөзе Аның карамагында булыр. Күкләр Аның кодрәте илә *(кәгазь кебек итеп)* төрелер. Аллаһ мөшрикләрнең уйдырма тәңреләреннән бөек һәм кимчелексез.

**68.** Сур быргысына өрелгәч, Аллаһ исән калдырырга теләгәннәрдән башкасы, күкләрдә вә Җирдә ни булса—барчасы үләчәк, юкка чыгачак. Бераздан тагын икенче тапкыр Сурга өрелгәч, ни күзләрегез белән күрерсез, аларның *(үлгәннәрнең)* барысы да аякка басып, карап-көтеп торырлар.

*(«Беренче тапкыр Сурга өрелгәч, исән кала торганнар: Җәбраил фәрештә, Исрафил фәрештә, Газраил фәрештә һәм Гареш хезмәткәрләре, тагын җәннәт капкасында сакта торучы ридван фәрештәләре, җәннәтнең хәзинәсен саклаучы Малик, җәһәннәм сакчылары—зобанилар. Сурга беренче өрелештә бу дөньядагы тереклек бетә. Икенче тапкыр өрелгәч, яңадан терелү, тегe дөнья тормышы башлана».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**69.** Мәхшәр җире Раббының нуры белән яктыртылыр. Китап *(гамәл дәфтәре)* мәйданга куелыр. Пәйгамбәрләр һәм шаһитләр китерелер. Гадел хөкем башланыр. Беркемгә дә хаксызлык кылынмас. **(70)** Гамәленә күрә, һәркем төгәл әҗерен алыр. Аларның ни кылганнарын Аллаһ бик яхшы белә.

**71.** Имансызлар исә, төркем-төркем булып, җәһәннәмгә сөрелер. Ниһаять, килеп җитүгә ук *(тамуғның)* капкалары ачылып китәр. Зобанилар алардан:

—Сезнең арадан чыккан, сезгә Раббының аятьләрен укып биргән һәм бүген монда кавышачагыгызны кисәтеп куйган пәйгамбәрләр сезгә килмәдемени?—дип сорарлар.

—Әйе, килгәннәр иде,—диярләр.

Кяферләргә вәгъдә ителгән газап инде дөрескә чыкты. **(72)** Аларга:

—Эчендә мәңге калачак җәһәннәмнең капкасыннан керегез!—дип әйтелер. Масайган тәкәбберләрнең урыны бик тә хәтәр урын.

**73.** Раббыга ризасызлык белдерергә курыкканнар исә төркем-төркем булып, җәннәткә керер. Капкадан кергәндә аларга сакчылар әйтер:

—Сәлам сезләргә! Саф-пакь килеш килдегез. Инде мәңгегә калыр өчен оҗмахка керегез,—диярләр. **(74)** Алар:

—Безгә биргән антына тугры калган вә безне теләгән урыныбызга утыртачак, безне җәннәткә варис кылган Аллаһка—дан!—дип әйтерләр. Игелек кылганнарның әҗере никадәр гүзәлдер.

**75.** Фәрештәләрне күрерсең. Алар Раббыга мактау белән тәсбих әйтер өчен, Гарешне уратып алган булыр. Кешеләр арасында гадел хөкем тәмам! Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка—дан! Әлхәмдүлилләһи Раббил галәмин!

## Kitap küzətü
## Китап күзәтү

# ТӨРКИ СҮЗ СӘНГАТЕ КАЙЛАРДАН БАШЛАНА?

«Мәгариф» нәшриятында Казан дәүләт университеты профессоры Марсель Бакировның «Шигърият бишеге: Гомумтөрки поэзиянең ярлуы һәм иң борынгы формалары» дигән китабы басылып чыкты. Әйтергә кирәк, әдәбият һәм сәнгать белгечләренә, студентларга, укытучыларга һәм, гомумән, сүз сәнгате белән кызыксынучы киң катлау укучыларга адресланып чыгарылган бу хезмәт татар әдәбияты белемендә генә түгел, ә бәлки бөтен тюркология һәм ориенталистика өлкәләрендә зур вакыйга булып каралырга хаклы. Марсель Бакиров моңа хәтле күп галимнәрнең «теше үтмәгән» бик борынгы һәм бик катлаулы тарихка үтеп кергән, аны системалы рәвештә һәм тирәнтен өйрәнгән-тикшергән, фәнни нәтиҗәләр ясаган. Китапны каткат укып чыккач, авторның гаять киң эрудициясенә, катлаулы һәм четрекле мәсьәләләргә күпьяклы якын килеп, аларның «үзәген» тотып алу сәләтенә, аларны системалы итеп өйрәнүенә, тирән фәнни фикерләү осталыгына сокланмый кала алмыйсың. Минем фикеремчә, әлеге китап катлаулы мәсьәләләрне системалы итеп тикшерүнең бик матур бер үрнәге булып карала ала.




Нинди проблемалар күтәрә һәм нинди үзенчәлекләре белән аерылып тора соң бу олуг хезмәт? Шуларның иң әһәмиятлеләрен генә булса да атап китмичә, бу фәнни хезмәт турында якынча гына булса да күзаллау тудырып булмас шикелле.

Хезмәт, гомумән алганда, төрки поэзиянең ярлуын иң борынгы формаларыннан ук башлап өйрәнүгә багышланган. Әлбәттә, бу мәсьәләгә алынасың икән, ул, һичшиксез, тикшеренүче алдына үз чиратында гомумән борынгы сәнгатьнең, аерым алганда, поэтик сүз сәнгатенең генезисын-ярлуын, аның синтетик табигатен һәм формаларын өйрәнү мәсьәләләрен китереп куя. Монда инде галимнән киң эрудиция, тирән фикерләү сәләте һәм иҗади фантазиягә ия булу да сорала. Шуңа күрә, бөтендөнья фәне тарихында бу проблемаларны яктыртырга алынучы галимнәр саны бик аз һәм ул хезмәтләр төрле телләрдә язылганнар. Мәсәлән, рус филологиясендә шигырь сәнгатенең килеп чыгышын һәм борынгы яшәү рәвешләрен йола-җыр берлегенә нигезләп тикшергән иң беренче һәм бердәнбер олуг галим булып А. Н. Веселовский исәпләнә. Ул үзенең 1913 елда басылып чыккан «Историческая поэтика» исемле хезмәтендә иң борынгы булып саналган йола иҗатының аеруча киң таралган һәм барлык халыклар

БАКИРОВ, М. Шигърият бишеге: Гомум-төрки поэзиянең ярлуы һәм иң борынгы формалары.—Казан: Мәгариф, 2001.—343 б.

өчен да уртак-универсаль булып саналган төренә–«йола хорына» яки «хор синкретизмы»на игътибар итә һәм аның эченнән акрынлап лирик һәм эпик жыр-поэзия, шулай ук дружина жырчысы аерылып чыккан дигән караш үткәрә. Бу караш хәзерге көнгә кадәр әдәбият белеме буенча хезмәтләрдә күпләр өчен гомуми кабул ителгән теория булып исәпләнеп килде.

Икенче бер төрле теория авторы–француз сәнгать белгече С. Рейнак. Ул исә гомумән сәнгатьнең яралуын магия-ырым белән хезмәт-йола синкретизмына нигезләп аңлатучылар исәбенә керә һәм магия теориясенең «атасы» булып санала. Бу галим XX йөз башында түбәндәге фикерләрне әйтеп чыкты: борынгы сәнгать, шул исәптән сүз сәнгате магик ихтыяжларга нигезләнә, ягъни ул гамәли-практик максатларга магик сүз-поэзия, биюләр, магик ырым-йолалар ярдәмендә ирешергә омтылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән, ди. Узган гасырның 20-30 елларында бу теорияне Н. Марр, И. Иоффе, А. Гущин кебек Россия галимнәре дә яклап чыкты һәм алар әлеге теорияне үстереп, синкретик «хезмәт-магия процессы» сәнгатьнең иң борынгы жирлеге булган дигән концепция эшләделәр һәм аның кысаларына поэзия башлангычын да кертеп карадылар.

Ә татар галиме Марсель Бакиров, бу мәсьәләне тагын да тирәнрәк һәм системалы, күпьяклырак итеп өйрәнеп, А. Н. Веселовскийның да, С. Рейнакның да фәнни концепцияләре поэзия-шигырь генезисы мәсьәләсен уңышлы хәл итә алмыйлар, дигән фикергә килде һәм үзенең күпьеллык эзләнүләре нигезендә шушы ике теориягә алмаш-альтернатив яңа теория барлыкка китерде. Әлеге китап әнә шул яңа теорияне нечкәләп бәян итү һәм борынгы төрки поэзиянең эволюциясен һәм үсеш юлларын өйрәнү юнәлешендә язылган да.

Авторның яңа концепциясе борынгы поэзиянең һәм матди, һәм рухи-идеологик нигез-җирлекләрен исәпкә алуны күздә тота һәм нигездә шулардан үсеп чыга. М. Бакиров иң борынгы чорларда кешенең яшәешен һәм иминлеген тәэмин иткән һәм хезмәти, һәм гамәли эшчәнлекнең үзенчәлекле дәвамы булган йола-ритуаллар, мифологик идеология белән үрелеп, аерылгысыз бербөтенлекне тәшкил иткәннәр дип исәпли һәм нәкъ менә шушы йола-мифология синктеризмы борынгы шигъриятнең иң беренче җирлеге хезмәтен үтәгән дигән караш үткәрә. «Әлеге борынгы җирлекне, ягъни синкретизм төрен алганда,–дип яза М. Бакиров,–«йола» сүзен «мифология» сүзеннән алда куюыбызның сәбәбе, әлбәттә, йоланың яшәеш чыганагының нигезе булган хезмәткә аеруча якын торуында, хезмәт белән кеше арасында арадашчы ролен үтәвендә. Мифология исә, идеология күренеше буларак, әскормага ныграк тартымлык күрсәтә, һәм шуңа күрә ул безнең синкретизм төрен билгеләүче атамада «йола» сүзеннән соң килә *(русча–обрядово-мифологический синкретизм)»* (59 бит).

Барлыгы алты бүлектән торган әлеге китапның алдагы өч бүлеге тулысы белән авторның шушы яңа теориясен фәнни нигезләнүгә һәм раслауга багышланган. Галим биредә җәмгыятьтә барган эволюцион күренешләрне тарихилык принцибын кулланып өйрәнә. Моның шулай икәнлеген китаптагы бүлекләрнең исемнәреннән дә күреп була. Мәсәлән, китапның беренче бүлеге **«Хезмәт–башлангыч поэзиянең материаль нигезе»** дип атала һәм анда борынгы җәмгыятьтәге матди хезмәт белән рухи хезмәт берлеге, хезмәт шигъриятенең эволюцион баскычлары һәм хезмәт белән үрелгән борынгы синкретик поэзиядә текст һәм көйнең хезмәт процессыннан аерылып чыгуы мәсьәләләре карала. Икенче бүлек **«Шигъриятнең фикер һәм сәнгати җирлеге буларак мифология»** дип исемләнә һәм ул тулысынча борынгы җәмгыятьтәге мифология күренешен күпьяклы итеп анализлауга багышланган: биредә мифологиянең кайчан һәм нинди сәбәпләр аркасында барлыкка килүе, аның синкретик структурасы (ягъни мифологиянең тарихи үсеш процессында соңрак барлыкка килгән дин, сәнгать, фән һәм, әлбәттә, поэзия башлангычлары өчен иң борынгы җирлек булуы), аның тормышта тоткан урыны, вазифалары һәм роле күрсәтелә. Шушы ук бүлектә мифлар белән поэзиянең үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе карала һәм борынгы мифологик фикерләүнең сәнгати-шигъри фикерләү

төре формалашуга хәлиткеч йогынты ясаганлыгы, асылда поэзиянең барлыкка килүе өчен сәнгати җирлек булганлыгы исбатлана. Өченче бүлек **«Иң элгәрге шигъри сүз сәнгатенең синкретик табигате һәм морфологиясе»** дип атала. Нәкъ шушы бүлектә М. Бакиров үзенең А. Н. Веселовский һәм О. Рейнак теорияләренә алмаш-альтернатив булган «йола-миф берлеге—борынгы поэзиянең бишеге» дигән яңа теориясен бәян итә һәм аны фәнни нигезли.

Шунысы әһәмиятле, үзенең китабында М. Бакиров бу яңа теорияне нигезләп кенә калмый, ә йола-мифология синкретизмының структурасын, гомуми үзенчәлекләрен дә ачыклый, аның борынгы җәмгыятьтә үтәгән вазифа-функцияләрен дә бәйнә-бәйнә сөйләп-күрсәтеп бирә. Бирегә, мәсәлән, борынгы йолаларның күп төрле булулары гына түгел, ә аларның күптөрле вазифалы, ягъни полифункциональ булулары да, мифларның исә әлеге йола-ритуалларның сүз белән бирелгән эквивалентлары, үзенчәлекле сценарие-либреттосы ролен үтәүләре дә ассызыклап күрсәтелә. Бу фикерләр Африкада, Австралиядә, Алтайда, Себердә һәм башка төбәкләрдә яшәгән җирле төрки халыклар фольклорыннан алынган күп санлы мисаллар нигезендә дәлилләнә.

Болардан тыш, хезмәтнең бу бүлегендә мине, борынгы поэзиянең жанрларын һәм шигъри формаларын өйрәнүче кеше буларак, аеруча **«Иң элгәрге шигъри-поэтик жанр яралгылары һәм архаик жанрлар»** дигән бүлекчә кызыксындырды. Эш шунда ки, М. Бакиров монда, төрле төрки халыклар фольклорыннан күпсанлы мисаллар китереп, борынгы төрки чорга караучы барлыгы уннан артык иң архаик поэтик жанрларны аерып чыгара. Алар түбәндәгеләр: Аллаларга һәм илаһи көчләргә багышлап чыгарылган мактау-данлау җырлары—гимннар, ода-алкышлар, корбан-келәү бәйрәмнәре һәм календарь-хуҗалык йолалары вакытында башкарылган келәү-алкышлар, йола әйтешләре, Нәүрүз, Нардуган, Сөрән келәү-алкышлары, йола-уен җырлары, ырым-арбышлар, туй арбаулары, сыгыт-сыктаулар (алар үзләре биш төркемчәгә бүленә), каргышлар, антлар.

Моңа кадәр фәндә бу жанрлар турында бу кадәр тулы һәм әтрафлы мәгълүматлар бирелгәне, аларның жанр сыйфатлары үзәккә алынып тасвирланганы юк иде әле. Шулай итеп, М. Бакиров, түркология фәнендә беренче буларак, йола-миф берлеге җирлегендә барлыкка килгән иң элгәрге шигъри-поэтик жанр яралгылары һәм архаик жанрлар системасын реконструкцияли, ягъни яңадан барлап чыга.

Алга таба галим шигъри-поэтик жанр яралгыларының эволюцион үсешен түбәндәгечә аңлата: йола-миф синкретизмы эчендә һәм бер үк төрле ситуацияләр уңае белән чыгарылган поэтик әсәрләр үрнәгендә акрынлап йола белән бәйләнмәгән җыр-шигырьләр туу өчен дә җирлек әзерләнә. Мондый типтагы җыр-шигырь текстлары күпчелек очракта көтелмәгәндә яки теләсә кайчан килеп туа торган эмоциональ-психологик ситуацияләр һәм аерым очрак-хәлләр уңаеннан җавап-кайтаваз рәвешендә иҗат ителәләр. Шулай итеп, йола белән бәйләнмәгән җитди поэтик әсәрләр һәм төрле поэтик жанрлар тууга нигез салына: иң борынгы мәкальләр, лирик һәм тарихи җырлар, мөнәҗәтләр, бәетләр, эпос-дастаннар барлыкка килә. Китапта поэтик әсәрләрнең бу эволюциясе төрле төрки әдәбиятлардан алынган мисаллар белән дәлилләнә. Татар фольклорындагы ярым бәет, ярым баллада характерындагы атаклы «Сак—Сок» әсәре дә йола-миф синкретизмыннан өлешчә аерылган шигъри ядкярьләрнең классик үрнәге булып карала, киң Шәрекъ мифологиясе контекстында анализлана һәм аның башка халыклар белән дә уртак булган гомумкультура мирасының иң тирәндә ятучы катламнарыннан башлангыч алуы исбатлана.

Китапның ике бүлеге поэзиянең шуннан соңгы эволюцион үсеш юлын күзәтүгә багышланган. Мәсәлән, дүртенче бүлек **«Иҗади шәхес күпкырлы һәм күп вазифалы сүз остасыннан башлана»** дип атала. Анда йола-миф комплексын күмәк рәвештә тудырган һәм башкарган ыруг-кабилә коллективыннан ничек итеп шаман һәм җырау-шагыйрьнең аерылып чыгу процессы күзәтелә. «Акрынлап әнә шул бердәм һәм күмәк рәвештә башкарылган синкретик

комплекстан, дөресрәге синкретик йола-бәйрәмнәрне уздыручы ыруг-кабилә коллективыннан, оештыручы-башлап йөрүче шәхес аерылып чыга»,–дип яза М. Бакиров *(119 бит)* һәм ул шәхеснең төрле халыкларда төрлечә аталып йөртелүенә күп мисаллар китерә: һуннарда ул «кам», аннан соңгы төрки халыкларда шаман, җырау (йырау), акын, ашуг, чичән, шагыйрь, чәләби һәм башка исемнәрдә йөртелгән. «Шаманнар асылда язмадан башка эш итә торган, ягъни язмасыз культураның беренче шагыйрьләре булганнар»,–дип дәвам итә галим *(122 бит)* һәм шаманнар репертуарына киң туктала, төрле халыклардагы шаман эшчәнлеге белән бәйләнешле сүз осталары, борынгы чичән-җыраулар иҗатыннан күптөрле мисаллар китерә. Нәкъ менә шушы шаман-җырауларның аерылып чыгуы поэзия үсешендә зур үзгәреш-күтәрелеш китереп чыгара да: нәтиҗәдә борынгы фольклорда һәм соңга табарак язма культурада да сүз остасы һәм шәхси-индивидуаль поэтик иҗат барлыкка килә. Һәм шунысы әһәмиятле, кобайыр, толгау, тарихи җыр, тарихи кошык, дастан дип исемләнгән шигъри жанрлар да башлап чичән-җыраулар репертуарында формалаша.

М. Бакиров хезмәтенең тагын бер яңалыгы шунда–ул, татар әдәбияты тарихында беренче буларак, борынгы төркиләрдәге ораторлык сәнгате мәсьәләсен күтәрә һәм аның эволюциясен күзәтә. Һуннарда ук инде бу төр сәнгать формалашкан һәм шактый нык үсеш алган, дип күрсәтә галим. Аннары, ди ул, матур сөйләм традициясен борынгы төркиләр һәм аларның варислары дәвам иттергән. Китапта гомумтөрки ораторлык сәнгате традицияләренең күчемле-леген-дәвамлылыгын күрсәтеп, телеңгит, кыргыз, казакъ, якут, үзбәк һәм татарларда булган ораторлык сәнгатеннән күп мисаллар китерелә. Шул исәптән, оста-матур сөйләм традицияләренең «Угызнамә», «Котадгу белек» әсәрләрендә, татар әдипләреннән Кол Шәриф, Кадыйргали бәк, Батырша, Әбеннасыйр әл-Курсави, Сәгыйть Рәмиев һәм Һади Такташ иҗатларында ничек чагылыш табуы күзәтеп чыгыла.

Бу хезмәттә М. Бакировның галим буларак кыюлыгын һәм, әйтергә мөмкин, хәтта тәвәккәллеген раслый торган янә бер момент бар: тикшеренүче башкалар үтеп керергә батырчылык итә алмаган, күпләр өчен әле бары исеме генә билгеле булган ерак бабаларыбыз–һуннар чорына да мөрәҗәгать итә һәм эзләнүләр аны кытай, грек, латин, әрмән телләрендә теркәп калдырылган материалларга китереп чыгара. Бу юлы инде галим, шул телләрдәге язмаларны өйрәнеп, һуннарның алар аша килеп җиткән шигъри гыйбарәләре һәм сәнгатьчә сөйләм үрнәкләре турында, аларның борынгы жанр формалары хакында бик әһәмиятле һәм кыйммәтле нәтиҗәләр ясый; чөнки, галимнәр һәм информация теориясе раславынча, бер телдәге борынгы сөйләмне, мәкаль-әйтемнәрне, җыр-шигырьләрне тәрҗемә рәвешендә китереп җиткергән икенче телнең текстларында да төп информация, фикерләү үзенчәлекләре, метафорик образлар, нигездә, саклана лар икән. Шул алым белән автор кытай, грек, латин һәм әрмән телләрендә сакланган чыганаклардан күп өзекләр китереп, һуннар тудырган поэзиядә корбан-келәү йола-бәйрәмнәрендә башкарылган төрле ырым-догалар, алгыш-келәүләр, йола җырлары булганлыгын, шулай ук мактау-данлау җырлары–ода-алгышлар, хәрби җырлар, көтүче лирикасы, мәхәббәт җырлары һәм туган илне сагыну, читтә каңгырып йөрү, әсирлектә калу кебек темаларга багышланган лирик җырлар, ил-йорт һәм ыруг-кабиләләр язмышына бәйләнешле тарихи җырлар иҗат ителгәнлеген исбатлый. Ул гына да түгел, автор һуннар яшәгән биләмәләрдә эпик сюжетлы җиз тәңкәләр табылуына таянып, пратөрки бабаларыбызның–һуннарның хәтта героик эпос-дастаннары да булган, дигән караш үткәрә. Ахыр килеп, шушы ук бүлектә галим һуннарның матур сөйләү сәнгате, ягъни ораторлык сәнгатенә хас үзенчәлекләрне дә тикшерә һәм ораторлык сәнгатенең, бер яктан, шул чорның тел-авыз иҗатына, җанлы сөйләм культурасына, ә икенче яктан, күп җепләр белән кытайларның ораторлык сәнгате традицияләренә барып тоташканлыгын күп мисаллар белән дәлилләп күрсәтә. Шунысы кызыклы, күп чыганакларга таянып, М. Бакиров ораторлык сәнгате Азиядә

яшәгән көнчыгыш һуннарына гына түгел, ә көнбатыштагы Европа һуннарына да яхшы таныш булган, дигән нәтиҗәгә килә. Басым ясап әйтергә кирәк: тюркология өлкәсендә мона кадәр бер генә галимнең дә әле һуннар сүз сәнгате турында бу кадәр тирән тикшеренүләр үткәргәне һәм мондый гаять мөһим нәтиҗәләргә килгәне юк иде.

Монографиянең моннан соңгы бүлегендә автор борынгы төркиләр тормышында язу барлыкка килүе һәм аларның төрле графика-язулар кулланылуы күренешләрен яктыртуга күчә. Һәм бу мәсьәләне дә ул бик борынгыдан, шул ук һуннар дәвереннән үк башлап күзәтеп чыга. Хезмәтнең бу өлешендә автор, чит ил һәм безнең ил галимнәренең күпсанлы хезмәтләренә нигезләнеп, һуннарның рухи һәм язу культурасы турында бик кызыклы мәгълүматлар китерә, шул исәптән, «һуннарның ана телләрендә дини-язма әдәбияты формалашкан булган» дигән нәтиҗә ясый *(189 бит)*. Борынгы бабаларыбыз язма әдәбиятының ничек тернәкләнүен һәм эволюцион үсешен галим тарихи җирлеккә һәм мохиткә бәйләп күз алдына бастырырга тырыша. Ачыклап әйткәндә, ул һуннардан соң яшәгән борынгы төркиләрнең күп аллалыктан баш аллаunion тану дәрәҗәсенә күтәрелгәннән соң, берничә динне алмаштыруларына аерым-аерым туктала, аларның нинди дин тотуларына һәм нинди культура белән бәйләнешкә керүләренә карап, рун, манихей, согъди, уйгур, брахми язулары һәм Сүрия алфавиты кулланганнарын күрсәтә. Ә инде соңрак, төрки халыклар ислам динен кабул иткәч, Урта Азиядә һәм Идел-Кама буйларында гарәп алфавиты кулланышка кергән. Бу хәл, ягъни бабаларыбызның нинди дин тотуы, әлбәттә, борынгы төрки язма шигъриятькә үзенең билгеле бер «мөһерен» суккан. Шуңа нигезләнеп, М. Бакиров үзенең хезмәтендә борынгы төрки телле поэтик ядкярләрне алар тоткан диннәр—тәңречелек, будда, манихей, христиан һәм ислам диннәренә бәйләнешле поэзияләргә бүлгәләп чыга һәм һәр культура-идеология тәрәнә яки тибына бәйләнешле поэтик сүз сәнгатенең жанрлар системасын күпсанлы әсәрләр мисалында анализлый.

Китапның соңгы бүлеге дә тюркология фәнендә сирәк кузгатыла торган проблемага—борынгы төрки поэзиянең тарихи поэтикасы мәсьәләләрен карауга багышланган. Әйтергә кирәк, хезмәтнең бу өлеше үзе бер зур аерым фәнни тикшеренү рәвешендә күз алдына баса. Чөнки бу мәсьәләләрне дә автор бик әтрафлы һәм тирән итеп өйрәнгән. Мәсәлән, галим тарихи поэтиканың үсеш-үзгәрешен генетик-эволюцион планда да, шулай ук стадиаль-хронологик яссылыкта да ачыклауга зур игътибар бирә. Аерым алганда, ул мифология белән керешкән борынгы сүз сәнгатенең үсеш-үзгәреш юлында өч тарихи баскыч үтүен ачыклый һәм аларның архаик поэзиядә үзенчәлекле эз калдырганлыкларын аерым-аерым күрсәтеп бирә. Әлеге тарихи-эволюцион баскычлар түбәндәгеләр: 1) әйләнә-тирәдәге һәр нәрсәне табигать һәм хайван белән «үлчәү» яки чагыштыру-тиңләү—мифологиядәге физиоморфизм *(грекча physis—табигать+morphe—рәвеш, форма)* һәм тероморфизм *(грекча therion—хайван)* баскычларына туры килә; 2) бөтен нәрсәне кеше һәм аның сыйфатларына нисбәттә карау һәм бәяләү, ягъни антропоморфизм *(грекча anthropos—кеше)* һәм 3) һәр нәрсәне кешелек җәмгыяте белән нисбәттә карау, ягъни социоморфизм *(латинча socialis—иҗтимагый)*. Сурәтләү объектына һәм сәнгати образларга бәйләнешле югарыдагы үсеш-үзгәреш баскычларын анализлаганда галим борынгы һун һәм төркиләр поэзиясеннән тотемлаштырылган яки изгеләштерелгән бүре, марал, барс, ат, бер башлы канатлы елан-сазаган образларын аерып чыгара, шулай ук архаик шигърияттә 17 санының һәм ядаташның магик көчкә ия итеп каралганлыгына, сул якның өстен күрелүенә, күк-зәңгәр, яшел, ак төсләрнең яратылып кулланылуына, нур һәм башка милли-традицион образларга игътибар итә. Иң мөһиме, тикшерүче әлеге образлар һәм сыйфатлар бабаларыбызның этник культурасы һәм этник психологиясе белән бәйләнешле поэтик архетиплар һәм билгеләр булганнар дигән нәтиҗә чыгара. Болардан тыш, М. Бакиров төрки поэзиянең

тарихи поэтикасын тел күренешләренә нигезләп тә анализлый: эпитет, метафора, чагыштыру кебек тропларнын, калыплашкан формулаларның ничек яралганлыкларын һәм эволюцион үсеш юлларын күзәтә барып, аларны бүгенге көн поэзиясенә–М. Җәлил, һ. Такташ, Х. Туфан, Р. Харис, Роберт Әхмәтҗанов кебек шагыйрьләр иҗатларына китереп бәйли, димәк, тарихи поэтиканың нинди сыйфат сикерешләре ясавын да күзәтә.

Күренә ки, М. Бакиров күтәргән һәм тикшергән мәсьәләләр бик киң һәм катлаулы. Әлбәттә, мондый зур капиталь хезмәтне тудыру өчен (нәкъ менә тудыру, ә язу түгел!) авторга шактый еллар буена бик күп өлкәләрдә эзләнергә, казынырга, аларны үзләштерергә һәм тиешле нәтиҗәләр ясарга кирәк булган. Мондый хезмәт тудыру өчен ул әдәбият тарихы турындагы хезмәтләрне генә өйрәнмәгән, ә әдәбият белеменә чиктәш булган тарих, археология, этнография, тел гыйлеме, философия, эстетика, фольклористика, мифология, дин тәгълиматы, шигырь белеме, сәнгать тарихы, психология, культурология һәм башка фәннәр буенча язылган хезмәтләрдән һәм кульязма чыганаклардан да файдаланган. Галим кулланган әдәбият исемлегендә төрле өлкәләргә караучы 655 фәнни хезмәт күрсәтелүе әнә шуны раслап тора. Әлбәттә, бу хезмәтләр татар һәм рус телләрендә генә язылмаганнар. Алар арасында немец, инглиз, француз, поляк, үзбәк, казакъ, башкорт, төрек телләрендә язылган хезмәтләр дә бар. Безнең татар галимебез Марсель Бакиров исә барлык шул телләрдә язылган фәнни хезмәтләрне, кульязмаларны җентекләп өйрәнеп чыккан һәм нәтиҗәдә татар әдәбият белемендә генә түгел, ә бөтен тюркология һәм ориенталистика өлкәләрендә яңа сүз әйткән, үлемсез фәнни хезмәт тудыра алган.


Бу китапны җентекләп укып чыккач миндә туган беренче тәэсир шундый булды, бу хезмәт миңа А. Н. Веселовский, Г. В. Плеханов, А. Ф. Лосев, В. В. Бартольд, Л. Н. Гумилевлар язган капиталь, фундаменталь хезмәтләрне хәтерләтте. Ул бу хезмәткә, билгеле, дистә еллар буена алып барган фидакарь эшчәнлеге аркасында килде.

Инде авторга киләчәккә шундый теләк белдерәсе килә: бу хезмәтне тиз арада рус яки инглиз телендә дә чыгарырга кирәк. Ул чагында аның бөтен дөнья күләмендәге резонансы тагын да зуррак булачак. Дөрес, бу хезмәтне 1999 елда докторлык диссертациясе итеп яклаганда М. Бакиров аның 96 битлек авторефератын рус телендә чыгарган иде инде. Әмма ул бары 100 данәдә генә чыкты. Ә бу хезмәт фән дөньясына, һичшиксез, зуррак тираж белән таралырга тиеш.

Инде урынлы сорау туа: академик фәнни дәрәҗә бүгенге көндә кемнәргә бирелә? Минем фикеремчә, ул күптөрле фәннәр үзара очрашкан һәм тоташкан урында алып барылган, ул фәннәрнең алга таба үсешенә зур этәргеч бирә торган яңа концепция, яңа теорияләр барлыкка китергән менә шушындый капиталь фәнни хезмәт авторларына бирелергә тиеш. Марсель Бакировның бу хезмәте һәм аннан алдагы фәнни хезмәтләре әлеге таләпләрнең барысына да тулысынча җавап бирә, ә ул үзе, минемчә, Татарстан Фәннәр академиясенең академигы дигән фәнни дәрәҗәгә лаек. Фәнни хезмәтләргә лаеклы бәя шулай ук үз вакытында бирелергә тиеш. Шәт, минем бу сүзем татар җәмәгатьчелеге арасында яклау табар дип ышанасы килә.

**Әнвәр ШӘРИПОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

## Риза Шәфигә 80 яшь



Тезелеп кенә лә, тезелеп киткән тау сыртлары...
Тезелеп кенә, тезелеп үсә наратлар...

Шулай яза үзенең бер шигырендә, туып-үскән төбәген—Урал тарафларын яд итеп, инде ил агасы яшенә житкән яугир шагыйребез.

Әйе, сугыш дәһшәтләрен үткән, аннары офицер булып, 30 елы хәрби хезмәттә узган татар баласы шигырьгә дә әнә шул биеклектән—асыл ирләр һәм бөркетләр иле булган Уралдан килгән бит! Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылында туа ул. Әтисе дә чәчәнлек белән дан казанган кеше була. Ә инде абыйсы Исмәгыйль Шәфиев—шулай ук танылып килгән шагыйрь—сугышта ятып кала. Димәк, шагыйрьлек Риза агага эстафета булып күчә, аңа яшәү, көрәш бурычы йөкли.

Ә мәкалә башындагы шигырь строфасы болай тәмамлана:

Тезелеп кенә лә, тезелеп кире кайтмадылар
Тезелеп кенә, тезелеп үткән солдатлар...

Ул солдатлар, Идел, Уралның асыл ирләре, шагыйрь язганча, «тезелеп печән чапканнар», «тезелеп иген иккәннәр» ... әмма тезелеп илгә кайтмадылар—«тезелеп кенә, тезелеп калды һәйкәлләр». Ә бәлки, тезелеп кайтучы аккошлар, йә торналар төркеме, шуларның моңлы тавышы—жыр булып ингәнлер алар шагыйрь күңеленә? Чөнки Риза Шәфинең бөтен иҗатында—әнә шул кайтмый калган татар улларына тугрылык һәйкәлләре, алар эшен дәвам итәргә антлар, дәвамлылык турында фәлсәфә, «һәрбер йөрәк—граната!» дип язганыдай, «учлап зарлы йөрәкне, эзли адәм кирәкне»... Ә бу «кирәк» дигәне—әлбәттә, ил гаме, халык өчен яшәү, аның чын шагыйре булу омтылышы...

Әнә шуннан ул—жырда горурлык, үз-үзенә ышаныч, кайчак кырыслык, хәрбиләрчә төгәл һәм туры сүзлелек—кыскасы, әлеге ир-егет булып кала белү... Болар—аның Рим Хәсәнов көен язган «Торна чылбырлары һәм «Урал тауда былбыл сайрый», «Уза алмам язмыштан» кебек жырларында да—төп сыйфат.

Кыска шигырьләр, фәрдләр (ике юллыклар) дә раслый бу бай күңел эзләнүләрен, инде олпат аксакалларча, жиһан, ил, туган жир турындагы шигъри фикерләрен... Һәм шунсын да әйтергә тиешбез: шагыйрь, олыгайган саен, һаман миллиләшә, чын мәгънәсендә «татарча уйлый», көенә, яна: туган тел, халкыбыз язмышы турында әрнүле сүзләр таба. Әмма анарда нәкъ шигъри күзаллау:

Үз илемдә, үз телемдә
Илаһи изге догам,—

ди ул. Һәм Кояш та аны, инде сиксән ел буе!—үз теленда гена сәламли, назлы нурлар белән иркәли, шигыренә үтеп керә...

Бәхетле язмышлы шагыйрь ул, мөгаен, Уралның чал, мәгъруր кыясыннан күтәрелгән моннар иясе, түземле, горур ир. Урдмурт илендә—Воткинск каласында яшәсә дә, рухи мәркәзе, шигъри башкаласы Казаннан күңеле белән бер мизгелгә дә аерылмаган каләмдәшебез Риза ага! Халкыбыз да Сезлән риза-мәмнүн дип ышанып, «Казан утлары» кебек озын гомерле журналыбыз исеменнән котлау һәм сәламнәребез булсын бу!

**Радиф ГАТАШ**

## Локман Закировка 75 яшь



Локман Фатыйх улы Закиров 1928 елнын 18 февралендә Мамадыш районынын Түбән Ушмы авылында доньяга килгән. Шунда җидееллык мәктәпне, аннары Мамадыш педагогия училищесын тәмамлаган, дурт ел дәвамында мөгаллим булып эшләгәннән сон, язмыш җилләре аны чит якларга алып киткән. Ул хәрби училищены, Киев авиация институтын тәмамлаган һәм гомеренен ин асыл дәверен армиядә хезмәт итүгә багышлаган.

Ул пенсиягә чыккач кына матбугатта басыла башлады. Анын повесть-хикәяләре «Казан утлары» журналында, башка матбагаларда да донья күрде. Локман Закировнын әсәрләре торгынлык заманынын каралыгын фаш итеп язылган, язылу вакыты да - житмешенче, сиксәненче еллар. Гадәттә, анын хикәяләренә тормыштан алынган ситуация, сурәтнамә хас.

Сонгы елларда Локман Закиров кыска публицистик мәкаләләр яза башлады һәм алар Мәскәү һәм Казан газета-журналларында һәрдаим донья күреп тора, укучыларда зур кызыксыну тудыра. Аларда татар тарихына, татар мохитенә, урыс-татар мөнәсәбәтләренә, заманга яначa караш төсмерләнә.

Бу айда 75 яше тулу унаеннан, Локман Фатыйх улы Закировны күркәм бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, ана сәламәтлек, яна иҗат уныышлары телибез!

## Заһид Фәйзигә 70 яшь



Заһид Фәйзи (Заһид Батыр улы Фәйзуллин) 1933 елның 15 февралендә Башкортстанның Бакалы районы Иске Балыклы авылында—җырларга кергән Сөн буенда туган. Аның беренче иҗат үрнәкләре илленче елларда Бакалы район газетасы «Ленин байрагы»нда һәм республика газетасы «Кызыл таң»да күренә башлый. Бүгенге көндә ул—сигез повесть, дүрт поэма, күп санлы шигырьләр һәм хикәяләр авторы. Аның егермеләп шигыре күренекле композиторлар Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Сара Садыйкова, Сафиян Ибраһимов, Марс Макаров һәм Рамил Курамшиннар тарафыннан көйгә салынган.

Заһид Фәйзинең ике китабы бар: беренчесе—1991 елда басылып чыккан «Язмыш борылмалары», икенчесе—2002 елны дөнья күргән «Чуплектә» исемле җыентык.

З. Фәйзинең повестьлары тормыштагы үзенчәлекле вакыйгаларга һәм гыйбрәтле хәлләргә нигезләнгән. Аларда социаль-көнкүреш шартларына бәйләнешле рәвештә кешеләрнең рухи дөньясы, психологиясе һәм үзара мөнәсәбәте үзгәрүне күрәсең. Геройлар арасында бозыклыкка бирелеп җирәндергеч дәрәҗәдә түбән төшкән адәмнәр дә, яшәеш шартлары нинди булуга карамастан чын кешелек сыйфатларын саклап яшәүче югары әхлаклы образлар да бар.

Заһид Фәйзи—1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Каләмдәшебезне олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, аңа яңа иҗат уңышлары һәм сәламәтлек телибез!

*Юмор-сатира*

## Морад Дусай

# АЛАЙ ТҮГЕЛ, БОЛАЙ УЛ...

### Күтелмәгән сөенеч

Язучыларның Аккош күлендәге иҗат йортында җәйләрен яраткан эте Бим белән яшәп ятучы Мансур Вәлиевкә кемдер, туган көненә бүләк итеп, песи алып килә.

—Болай да, этле-мәчеле тормыштан туеп, урманга качкан идем—әйбәт булды инде бу,—дип «сөенгән» имеш Мансур Вәлиев.

### Сорап алу

Ләбиб Леронның студент чагы. Берзаманны бу гел кара күзлек киеп йөри башлаган. Хәтта ки кышын да кара күзлеген салмый икән бу. «Яшь ленинчы» гәзитендә бер фельетон, ике шигырь бастырырга өлгергән «даһи» егетнең, әнә шул рәвешле, башкалардан аерылыбрак күренәсе вә йөрисе килгәндер инде, күрәсең.

Ләкин сабакташ дуслары, нигәдер, Ләбибне аңлап бетермәгәннәр, дөресрәге, үзләренчә аңлаганнар.

—Ни булды сиңа? Әллә берәрсе күз төбенә кундырдымы?—диләр икән болар, аптырап.

—Соң, кем кундырсын инде миңа?!—дип, Ләбиб боларга күзлеген салып күрсәтә икән.

Әнә шулай, бу кара күзлеген сала-кия, сала-кия берникадәр вакыт үткән. Көннәрдән бер көнне Ләбиб тулай торак коридорыннан бара икән. Кинәт кенә ялт итеп бер ишек ачылып та киткән, шап итеп моның күз төбенә дә кундырган, мин сиңайтим!

—Сорап алгандай булды бу!—дип сөенгән имеш самими татар балаларының булачак язучысы.

### Коточкыч хәл

Арча педагогия көллияте шәкертләре берзаманны Гариф Ахуновны очрашуга чакырганнар.

Якташларыннан әдипкә сорау арты сорау явып кына тора икән.

—Ялангач кызлар сурәте төшерелгән гәзит-журналларда үз әсәрегезне бастырудан кыенсынмыйсызмы?—дип сорый бер туташ.

—Юк. Чөнки ул кызларга хәзер мин күлмәк киертеп карыйм...

—Гариф абый, бүгенге яшьләргә нинди бәя бирәсез?

—Хәзерге яшьләрнең кыяфәтләре дә, тәртипләре дә—күреп кот очарлык.

—Нигә?

Гариф Ахунов бу сорауны колак читеннән генә үткәреп җибәрә дә сүзен болай тәмамлый:

—Тагын да коточкычы... без инде сезнең кебек була алмыйбыз...

## Даһилар арасында

Илле яшьлек юбилей кичәсен бик зурлап уздыргач, Марсель Галиев туган ягы Азнакайга кайтып китә. Кайтып барышлый, Фоат Садриевны очрата бу.

—Бәйрәмеңә кеше килгән идеме соң?—дип сорый аннан Фоат Садриев.

Марсель Галиев исә, гадәтенчә, бик һавалы гына мактанып:

—Жиде йөз кешелек зал шыгрым иде. Казанның бөтен даһие килгән иде,—ди.

—Алайсам, берүзеңә генә бик кыен булгандыр инде,—ди Фоат Садриев.

## Күңелле булган...

Илһам Шакиров бер авылга концерт белән килеп төшкән. Әмма дә кинәт кенә авырып киткән бу. Шуннан колхоз рәисе:

—Илһам абый, концертыгыз булмаса-булмас... Сезнең белән бер табын артында утырсам, үлсәм дә үкенмәс идем,—дип, бик һәйбәтләп мәжлес әзерләткән.

Утыралар икән болар рәис өендә жырлашып... Бөтен авыл жыелып килгән!—Тәрәзәдән тыңларга...

Икенче көнне бу авыл халкы күрше авылныкыларга болай дип сөйли икән:

—Илһам Шакиров килгән иде безгә. Концерты булуын-булмады, әмма дә бә-әк күңелле булды!

## Пародия

—Бигрәкләр дә әйбәт пародия язгансың икән,—дип, Гөлшат Зәйнашева, чыгасы китабын исендә тотып, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире Рафис Корбанга телефоннан шылтыраткан.

—Минеке түгел бит ул, Гөлшат апа,—дигән аңа Рафис Корбан.

—И-и, алайсам... Әйтәм аны, бигрәкләр дә тозсыз чыккан,—дип сүзен тагын ялган киткән шагыйрә.

—Ә, туктале, тукта, Гөлшат апа, син кайсы газиттә чыкканын әйтәсең соң әле?

—Соң... шул инде... Теге Рифә Рахман турындагы пародияң инде—иллә дә шәп чыккан бит инде, балакаем. Искитмәле!

## Оныткан...

Маннур Саттаров, ашханәдә сыйланып утыручы Камил Кәримовның ашын бүлдереп, мона уч төбе кадәрле бер календарь бүләк итә.

—Мин сиңе, Маннур абый, унбиш елдан бирле беләм инде: беренче тапкыр бүләк бирүең. Ну, кысмыр да инде үзең...

—Моннан жиде ел элек, әле син «Чаян»да эшләгәндә, мин сиңа ике кәнфит биргән идем. Оныттыңдамыни?!—дигән аңа Маннур Саттаров.

## *Безнең календарь*

### Әминә Бикчәнтәеваның туубына 90 ел

Балалар язучысы Әминә Әхмәт кызы Бикчәнтәева 1913 елның 26 январенда Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә дөньяга килә. Бишбалта бистәсендәге татар мәктәбендә укыган чагында ук ул матур әдәбият белән кызыксына. Әдәбият түгәрәгендә, концертларда һәм стена газеталары чыгаруда актив катнаша. Тора-бара үзе дә шигырьләр һәм пьесалар яза. Шул вакытта мәктәптә әдәбият дәресләре алып барган шагыйрь Хәсән Туфан аның иҗади юнәлешенә зур йогынты ясый.

1934—1938 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген уңышлы тәмамлаганнан соң, "Яшь ленинчы" газетасы редакциясендә әдәбият бүлеге хезмәткәре, Актаныш, Буа районы мәктәпләрендә укытучы, Татарстан радиокомитетында балалар өчен тапшырулар бүлегендә һәм Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли.

Әминә Бикчәнтәева бөтен гомерен һәм иҗади сәләтен балалар тәрбиясенә багышлаган язучы. 1940 елда кече яшьтәге балаларга адресланган "Бүләк" исемле беренче шигъри китабы басылып чыккач, күренекле балалар язучысы Абдулла Алиш, бу китапның чынлап та балаларга зур бүләк булуын әйтеп, өлкә газетасы аша яшь авторны тәбрикли. Шигырьләрендә, күбесенчә, нәниләр турында яза, балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрнең, әле беренче елларын гына мәктәпкә килгән укучыларның көндәлек тормыш эпизодларын, уеннарын, үзара мөнәсәбәтләрен шигъри җанландырып, яшь буын тәрбиясенә бәйле күп кенә мөһим мәсьәләләрне күтәрә.

Аның шигырьләре балаларны үзара һәм өлкәннәргә карата әдәпле, итагатьле булырга өйрәтәләр, әйләнә-тирә табигатьне кадерли һәм саклый белергә өндиләр.

Ә. Бикчәнтәева—"Ана йөрәге" һәм "Мин аңлыйм сине" исемле повестьлар авторы. Яшүсмерләр тормышы материалына нигезләп язылган һәм шул ук балалар тәрбиясе проблемаларын үзәккә алган бу әсәрләрендә язучы кызыклы гына язмышлар үрнәгендә кеше шәхесе формалашуына хезмәт һәм эшчеләр коллективының хәлиткеч йогынтысы турында сөйли.

Ә. Бикчәнтәеваның балалар өчен кыска-кыска кызыклы хикәяләре дә бар. Бу жанрда аның "Хуҗа Насретдин балалар янында" дигән хикәяләр циклы аеруча яратып укыла. Фольклор герое Хуҗа Насретдинның мәзәклеген, тапкырлыгын, изге күңеллелеген автор балалар тормышы материалында шактый уңышлы итеп ачуга ирешә.

Әминә Бикчәнтәева—ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары авторы. Алар—"Бакча гөлләре", "Бүген һәм иртәгә", "Бүләк", "Дачада", "Күңелле сөйләшүләр", "Дәү әни", "Танышларым" һ.б. китаплар.

Ә. Бикчәнтәева—1958 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

### Хәкимҗан Халиковның туубына 70 ел

Танылган балалар шагыйре Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиков (1933—2002)—халкыбызга күп әдипләр биргән Казан артыннан. Арча районының Мамыш авылында туган Хәкимҗан 1948 елда Чембулат җидееллык мәктәбен, ә 1952 елда Арча педагогия училищесын тәмамлагач, озак еллар Иске Өҗем җидееллык мәктәбендә укытучы булып эшли. Читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый (1954—1960). 1963 елдан ул—Казанда яши; башта «Ялкын» журналы, аннан «Яшь Ленинчы» газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1979—1981 елларда ул—Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы

председателе; ә 1983 елдан «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр була.

Нәниләр өчен шигырьләре әүвәл күмәк китапларда басыла. 1969 елда «Йолдызлар ничәү?» исемле беренче мөстәкыйль китабы дөнья күрә. Аннары—«Шук бабай», «Уйныйсың киләме?» һ. б.—уннан артык китабы басылып чыкты.

Арада—«Иң шатлыклы көнем» (1983) кебек сайланма характердагы китабы да бар. Рус телендә «Конфетное дерево» (1977), «Где моя дорога» (1982) исемле китаплары да дөнья күрде—алар турында Мәскәү матбугатында да (В. Щербаков, Л. Лехтина, С. Вешнякова һ. б. мәкаләләре) искә алынды. Татарстанда исә шагыйрь иҗатына карата Б. Камалов, Р. Кукушкин, К. Кәримов, Ә. Мушинский, М. Сафин һ. б. мәкаләләре басылды.

1984 елда шагыйрьгә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

Хәкимҗан Халиков—1973 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

## Uqucı süze
## Укучы сүзе

* * *

Әссәламәгаләйкем, хөрмәтле «Казан утлары»!

Сезгә ерак Казакъстанның Алма-Ата өлкәсеннән Тикәле каласында көн күреп ятучы Мөсхәб Вәли углы Исхаков яза. Сезгә хатларны еш язам, аның өчен ачуланмагыз. Ерак-еракларда көн күрүче кан-кардәшләребезгә «Казан утлары» борынгы пайтәхетебез Казаннан килүче бер якты вә җылы нур бит ул. Шул нур яктысында күнелләребездәге бозларны эретәсе, азмы-күпме җылынасы килү дә табигый күренештер. Ә инде безнең хатларыбыз кадәри хәл шул нурларга тоташырга омтылудан да туадыр. Аңлыйм, Сезгә хат язучылар күптер. Минем кебекләр унарлап-йөзәрләп кенә түгел, меңнәрләп булыр. Сез бит Татарстан җөмһүриятенең үзәк журналы. Шуна да мин ул хатларыма җавап өмет тә итмим, бары тик Үзәк Азия кинлекләренә дә Сезнен тавышыгыз килеп житә дигәнне белдерергә теләүдән генә язам. Бу якларда Кытайдан кайткан татарлар бик күп. Алар адәм ышанмаслык авырлыклар кичерсәләр дә милләттән ваз кичмәделәр. Идел буеннан килгәннәр дә байтак. Хәзер тормыш бераз җайга салына башлауга «Казан утлары»н алдырырга теләүчеләр дә арта. Их, бер килеп чыксагыз икән Казакъстан якларына. Җаннарыбыз сафланыр, пакьләнер иде. Монысы инде чынга ашмас бер хыял гына булып калыр. Арабызда дәүләт чикләре ята. Хәер, кем белә, «Сабыр төбе сары алтын» дигәндәй, бәлки минем язганнарыма да кайчан да бер игътибар итәрсез әле.

Мин үзем Кытай Халык Республикасының Урумче каласында 1932 елның 8 декабрендә дөньяга килгән бер татар баласымын. Чит илләрдә туган, сөрелеп һәм сачылып йөргән милләттәшләребез турында шигырь юллары белән дә әйтәсем килә:

Суыкка күнгән, ачлыкка түзгән,
Хурлыкны күргән, башын имәгән,

Рухы сынмаган, шуна үлмәгән,
Канлы туфрактан терелеп чыккан—
Яшәү куәсен ятка бирмәгән.

Мин халкыбызның менә шундый бер даирәсе вәкиле булам инде. Сезнең журналның 80 еллыгын да күздә тотып бер шигырь дә язган идем. Аны да Сезгә юллыйм.

«Казан утлары»—татар дөньясы,
Әдәбиятның байлык оясы.
Аны белмәгән, якын итмәгән
Юктыр бу җирдә татар баласы.

Сиксән ел буе янып киләсең,
Кыел юлларны ярып үтәсең.
Көчләп, куркытып сынасалар да,
Тоткан юлыңнан юктыр китәсең.

Сине укысам, күңелем юана,
Зур ләззәт алам, чиксез куанам.
Әдәбиятның муллык дөньясы—
Көч алсын синнән татар баласы!

Кайнар сәламнәр күндерәм. Журналга да Казан яшенә җитүне теләп—

**Мөсхәб ИСХАКОВ.**
*Казакъстан.*

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары»!

Күңелемдә туган җан ачысын сүзләр белән аңлатып бетерә алмасам да, Сездә таяныч тоеп, ышаныч белдереп һәм инде күп еллар буе тупланган зур ихтирамым аркасында күңелемдәге шул ачыну тамчыларын язып җибәрергә булдым.

Җанымны иң борчыганы—соңгы вакытта матбугатта Татарстан атом электростанциясен төзү-төземәү турында югары җитәкчелектә башланган сөйләшүләр турындагы язмалар. Югыйсә, татар халкы күпләп яшәгән җирдә һәм Татарстан чигендә Башкортстан АЭСы төзелеп ята бит инде. Безгә тагын бер атом афәте кирәкмени?! Кирәк түгел бит! Дөньядагы цивилизацияле илләр берәм-берәм барысы да атом станцияләреннән ваз кичә бара. Аларның файдага караганда зыяны күбрәк икәнен хәзер сабый бала да бик яхшы белә бит инде. Зыяны аның безнең бүгенге буынга түгел, ә киләчәккә, балаларыбызга, оныкларыбызга тиячәк. Чиләбе өлкәсендәге Мөслим авылы фаҗигасе дөньяга чаң суга торган афәт бит. Ул хакта нишләп язмыйсыз? Халыкның күзе ачылыр иде. Аннан килеп, Татарстан болай да атом станцияләре камалышында калды лабаса. Ульян өлкәсендәге атом станциясе дә татар оясында. Безгә, бөтен җәмәгатьчелеккә чаң сугарга вакыт! Яңа афәтләрне шулай гына туктатып кала алырбыз дип беләм.

**Фазылҗан МИЛАЕВ,**
*Түбән Кама.*

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Мәшһүр сынчы Бакый Урманче 60 еллар башында мәрмәр таштан Тукай сынын ясаган иде. Ул сын берничә дистә ел Язучылар берлеге бинасында (Бауман урамы, 19 йорт) торды. Шул бюст-сынны урнаштырган көнне бер төркем язучылар фотога төшкәннәр. Утырганнар (сулган уңга)—Зыя Мансур, Әхмәт Исхак, Мирсәй Әмир, Бакый Урманче, Исмәгыйль Рәми, Сибгат Хәким, Нури Арсланов; басып торучылар—Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гали Хуҗи, Нурихан Фәттах, Мәҗит Рафиков, Салих Баттал, Нур Гайсин, Галимҗан Латыйп, Хәсән Сарьян, Нәби Дәүли, Котдус Дәүләтшин, Габдрахман Әпсәләмов, Самат Шакир. 1964 ел.*



*Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге. Уңнан сулга—Мирсәй Әмир (идарә рәисе), Зәки Нури (идарәнең җаваплы секретаре), Хәсән Сарьян (әдәби фонд директоры). 1965 ел.*



*Язучы Гариф Ахунов (сулдан икенче) һәм шагыйрә Саҗидә Сөләйманова әдәбият сөючеләр арасында. Казан. 1970 ел.*



*«Казан утлары» хезмәткәрләренең һәм авторларының төрек язучысы Яхья Акынгән белән очрашу истәлеге. 1991 ел.*

# БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Яшәү кануннары гади һәм кырыс: берәүләр дөньялыктагы вазифаларын башкарып Кояш астыннан китеп баралар, аларны бүтәннәр—яңалар алыштыра; гомерләр үткәч алар урынына да яшьрәк яңа буыннар килә. Канатлы тәгъбирдәгечә: кеше китә—җыры кала... Монысы инде язучы халкына турыдан-туры кагыла шикелле. Вакытлар узу белән, табигый, язучылар контингенты да үзгәреп, яңарып тора. Әдәбият мәйданына яңа көчләр килә. Кемнәр алар? Элгәргеләреннән көчлерәкләрме, кайтышракларммы? Булган яхшы традицияләрне үстереп, рухи хәзинәне баетырлыкларммы? Монысын инде Вакыт әйтәчәк, Киләчәк хөкем чыгарачак.

Инде ярты гасырдан артык Язучылар берлеге идарәсе каршында Кабул итү Коллегиясе эшләп килә. Аның хәзерге рәисе—Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин. Коллегия әгъзалары итеп шулай ук күренекле язучылар, халык абруен казанган билгеле шәхесләр сайланган. Коллегия карамагына кергән гаризалар, остаханәләрнең карарлары, өлкән язучыларның рекомендация-тәкъдимнәре даими үткәрелә торган җыелышларда җентекләп өйрәнелә, тикшерелә, фикер алышына, һәм нәтиҗәдә, демократик формада—яшерен тавыш бирү юлы белән теге яки бу авторның Берлеккә кабул итү-итмәү мәсьәләсе ачыклана.

Без киләчәктә Язучылар берлегенә яңа кабул ителгән әгъзалар турында журналыбызда кыскача белешмә биреп барырга ниятлибез. Декабрь ахырында, Яңа Ел алдыннан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Коллегия кабул иткән карарны раслады; берничә язучыга Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы дигән таныклык тапшырылды.

## Венера Якупова



*Якупова Венера Абдулла кызы—1959 елда Татарстанның Зеленодольск (Яшел үзән) районының Кызыл Яр авылында туган. 1981 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлаган. 1984—1986 елларда ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршында Югары комсомол мәктәбендә укыган.*

*Хезмәт юлын 1981 елда «Зеленодольская правда» газетасында хәбәрче булып башлый. Аннары 1986—1995 елларда «Комсомолец Татарии» («Молодежь Татарстана») газеталарында хәбәрче, бүлек мөдире, баш редактор урынбасары вазифаларын башкара. 1995 елдан бүгенге көнгәчә «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире.*

*Журналистика өлкәсендәге уңышлары һәм публицистик эшчәнлеге өчен Венера Абдулла кызына 1990 елда Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе, 1995 елда «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.*

*В. Якупова «Идел-Пресс» нәшриятында 2000 елда чыккан «100 историй о суверенитете» һәм 2001 елда дөнья күргән «Крымские татары,*

*или Привет от Сталина!» дигән китаплар, күпсанлы публицистик язмалар авторы.*

*Татарстан журналистлар берлеге оештырган «Бәллүр каләм—2001» иҗади бәйгесендә В. Якупова «Елның иң яхшы язмасы» номинациясендә җиңүче булды һәм аңа лауреат дипломы тапшырылды.*

## Ирек Сабиров



*Сабиров Ирек Нәгыйм улы—1950 елның 14 апрелендә Татарстанның Биектау районындагы Мәмдәл авылында туа. Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлаганнан соң, Казан химия-технология институтында белем ала, институтның «Кировец» газетасы эшчәнлегендә актив катнаша.*

*Институтны уңышлы тәмамлагач, И. Сабировны Чиләбе өлкәсендәге Еманжелинск шәһәренә, «Сигнал-Полимер» дәүләт предприятиесенә эшкә җибәрәләр. Биредә ул әлеге зур хәрби заводта гади мастердан баш инженер дәрәҗәсенә хәтле күтәрелә.*

*И. Сабиров Еманжелинск шәһәрендә татар-башкорт мәдәни үзәген оештыра, озак еллар аны җитәкли. Быелдан башлап ул Еманжелинск шәһәр башлыгының икътисад, сәнәгать сәясәте, сәүдә, инвестиция мәсьәләләре буенча урынбасар вазифаларын башкара.*

*1997—2002 елларда И. Сабировның татар һәм рус телләрендә берничә китабы дөнья күрде. Алар—«Яшим!», «Аваз», «Люблю и верю», «Сезон клубники и зарниц», «Апрель». Ул поэзиядә дә, прозада да уңышлы эшләп килә.*

*2002 елда Идел-Урал төбәгендәге төрле милләт язучылары катнашында Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә узган «Илһам чишмәләре» әдәби фестивалендә II урынга лаек була.*

*Аның әсәрләре «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел» журналларында даими басылып килә.*

## İctimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### КОНГРЕССНЫҢ КҮРКӘМ ГАМӘЛЕ

16 декабрь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Бөтендөнья Татар Конгрессының Башкарма Комитеты татар җәмәгатьчелеге өчен тантаналы кичә үткәрде. Кичә узып баручы ел нәтиҗәләренә багышланды.

БТК Башкарма Комитеты рәисе Ринат Закиров үз чыгышында елның истәлекле вакыйгаларын—III Бөтендөнья Татар Конгрессын, Бөтенроссия халык санын алуны билгеләп үтте. Алар татар халкын берләштерүнең мөһим факторлары булды. БТК җитәкчесе Башкарма Комитетның яна составы планнары турында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, абруйлы шәхесләр җитәкчелегендәге комиссияләрнең мөстәкыйль эшчәнлегенә аерым игътибар биреләчәк. Яшьләр белән эшләү төп юнәлешләрнең берсе булырга тиеш, шуна күрә Бөтендөнья татар яшьләре конгрессын үткәрү планда каралган.

ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әгъзам Гобәйдуллин ел нәтиҗәләрен чыгару традициясен хуплап, җыелганнарны якынлашып килүче бәйрәм белән котлады һәм Татарстаннан читтә яшәүче милли хәрәкәт активистларына республиканың дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Кунаклар өчен республиканың сәнгать эшлеклеләре, татар эстрадасы йолдызлары чыгыш ясады.

### ТАТАР ҖИРЕНДӘ «ПИРАМИДА»

Казан шәһәренең төзелеш тарихында күренекле вакыйга булды: 20 декабрь көнне «Пирамида» дип исемләнгән мәдәни-тамаша үзәге ачылды. Президент Минтимер Шәймиев бу көнне күренекле көн дип атады. Президент Татарстан Дәүләт Советы, республика Хөкүмәте һәм шәхсән үз исеменнән барлык татарстанлыларны шушы күренекле вакыйга белән тәбрик итте. Бу—гасырларга житәрлек Пирамида, ул безнең омтылышларның билгесе, дип искәртте республика башлыгы һәм шушы гүзәл корылманы төзүдә катнашкан барча кешеләргә рәхмәт белдерде. Минтимер Шәймиев шулай ук үзәкне төзегән «ТАИФ» компаниясенең ролен күрсәтеп узды. «ТАИФ» бүген республиканы социаль-икътисади үстерүнең 20дән артык юнәлешен тормышка ашыра.

Татарстан Президенты күп кенә архитекторларга, проектчы һәм төзүчеләргә дәүләт бүләкләрен тапшырды. Аерым алганда, «Пирамида» архитектурасы һәм дизайн авторлары Гөлсинә һәм Виктор Токаревлар Татарстан Президенты Указы нигезендә «Татарстан Республикасының атказанган архитекторы» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Мәдәни-тамаша залын ачу тантанасында Россиянең элеккеге Президенты Б. Ельцин, «ТАИФ» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры А. Шиһабетдинов, «Пирамида»ның проект идеясе авторы Р. Шәймиев һ. б. чыгыш ясады. «Пирамида» мәдәни-тамаша комплексының беренче тамашачылары алдында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, җырчылар Илһам Шакиров, Салават Фәтхетдинов, Альберт Әсәдуллин, шулай ук Валерий Леонтьев, «Тодес» балеты һ. б. чыгыш ясады.

«Пирамида» мәдәни-тамаша комплексын ачу тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан хакимияте башлыгы Камил Исхаков, Төркия Республикасының РФдәге Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе Куртулуш Ташкент, министрлык һәм ведомстволар җитәкчеләре, республиканың шәһәр һәм район хакимиятләре башлыклары, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

### ХАЛЫК ФРОНТЫ ТАЛӘБЕ

Татарстанның 25 милли оешмасын берләштергән Халык фронты уздырган конференциядә латин алфавитына күчү зарурлыгы турында резолюция кабул ителде.

Резолюциядән күренгәнчә, бу татар теле үзенчәлекләрен исәпкә алып, татар халкы интернет ярдәмендә дөнья фәнендә катнаша алсын өчен эшләнә. Моның өчен республика халкының татар милләте вәкилләре арасында референдум үткәрүе зарур. Россия Президенты Владимир Путин кул куйган һәм Россиянең бар төбәкләрендә кириллица язуын гына куллануны күздә тоткан «РФ халыклары телләре турында»гы законның 3нче маддәсенә «Өстәмәләр кертү турында»гы Федераль канунга җавап итеп, Халык фронты Татарстанда татар телен дәүләт теле буларак кабул итүне таләп итәргә мәҗбүр. Шул ук вакытта рус теле милләтара аралашу теле статусын сакларга тиеш. Оешмалар һәм учреждениеләрдә документларның, рәсми хатларның татар һәм рус телләрендә эшләнергә тиешлегенә дә басым ясала.

## ҺӘЙКӘЛ ОЕША БАШЛАДЫ

Кремль диварында (Колшәриф мәчете янәшәсендә) Казанны саклаганда һәлак булганнар истәлегенә куелачак һәйкәл үрнәге пәйда булды. Әлеге тәзелмә чын һәйкәлнең фанерадан һәм металлдан вакытлыча ясалган нөсхәсе. Һәйкәлләге шарның уелган җирендә Коръәннән бер аять язылачак: «Аллаһ юлында һәлак булганнар турында үлделәр дип сөйләмәгез. Алар исән, әмма сез аны аңлаучылардан түгел». Композицияне казанлылар хозурына тапшыруның максаты—төп вариант ясалганчы кинәшләр һәм өстәмәләр кабул итү.

## АЛГА КИТЕШ

8 декабрь Мәскәүнең татар җәмгыяте тарихына истәлекле көн буларак кереп калачак. Ул ярты гасырдан артыграк вакыт дәвамындагы пикетларга, митинг, листовка, низагларга йомгак ясады сыман. Чөнки бу көнне Кече Татар тыкрыгында урнашкан 8 нче йортта, халык теленә «Әсәдуллаевлар йорты» буларак кереп калган бинала, ниһаять, зарыгып көтелгән алтакта пәйда булды. Анда татар һәм рус телләрендә:

*«Мәскәү шәһәренең төбәк татар*
*милли-мәдәни мөхтәрияте*
*Татар милли-мәгърифәтчелек мәркәзе»*

дигән сүзләр уеп язылган. Әмма әле бу гамәл эш бетте дигән сүз түгел. 1999 елда ук, бу йорт татарларга бирелде, дигән карар чыгарылса да, әле аның татарныкы булып беткәне юк. Ләкин такта эленү үзе генә дә бу эшнең алга китүенә бер дәлил булып тора.

Тантаналы чараны милли-мәдәни мөхтәрият рәисе Рәсим Акчурин ачып җибәрде. Бу җыенда милләтебезнең Мәскәүдәге күп кенә билгеле кешеләре—Россия хөкүмәтендә департамент директоры булып эшләүче Фәрит Мөхәммәтшин, элеккеге обком секретаре Фикрәт Табеев, галим Илдар Үтәмешев, композитор Алмаз Монасыйпов һ. б. бар иде.

## РЕДКОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

Декабрь ахырында «Казан утлары» журналы редколлегиясенең чираттагы җыелышы булып узды. Ул узган 2002 ел эш нәтиҗәләренә багышланган иде. «2002 ел журнал өчен кирәкле хезмәт елы, юбилей елы булды»,—диде баш мөхәррир Равил Фәйзуллин. Ул ел агымында басылган, иҗтимагый әһәмияте зур булган әсәрләргә тукталды, журнал эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында сөйләде. Фикер алышуда редколлегия әгъзалары М. Госманов, Т. Миннуллин, Х. Миңнегулов, Г. Рәхим, Ф. Сафин, Ф. Латыйфи, Р. Шаһиева һ. б. чыгыш ясадылар. Җыелышта, шулай ук, 2003 ел өчен эш планы кабул ителде.

## ЖУРНАЛНЫҢ ЯҢА САНЫ

«Гасырлар авазы» фәнни-документаль журналының чираттагы саны дөнья күрде. 320 битле журналга Россия һәм Татарстан тарихы буенча 60 мәкалә һәм документлар җыелмасы кертелгән.

Авторлар арасында Татарстан, Төркия, Россиянең төрле төбәкләреннән күп хезмәт күрсәткән өлкән һәм яшь галимнәр бар. Журнал профессор Б. Солтанбәковның «Сарман кешеләре һәм эшләре» мәкаләсе белән ачыла. Мәкаләдә районның тарихчы архивчылар оешмасы эшчәнлеге, Сарман төбәген өйрәнүче Д. Гарифуллин тарафыннан төзелгән Татарстан Президенты М. Шәймиевнең, Татарстан һәм Россиянең халык артисты И. Шакировның шәҗәрәләре яктыртыла.

## ТОМЛЫК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

17 декабрьдә Татарстан Язучылар берлегендә әдәби тәнкыйть, проза һәм шигърият остаханәләренең берләштерелгән утырышы булды (җитәкчеләре Мансур Вәлиев, Мадинә Маликова, Зиннур Мансуров). Бу җыелыш «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы VI томы басылып чыгу уңаеннан оештырылган иде. Анда күп санлы иҗатчылар, галимнәр, әдәби тәнкыйтьчеләр катнашты һәм томның уңышлы яклары, шулай ук булган җитешсезлекләре турында җитди фикерләр әйттеләр. Әлеге томның фәнни җитәкчесе Ф. Мусин, аның ярдәмчесе Ф. Бәширов, авторлардан А. Әхмәдуллин, Р. Сверигин һ. б. үзләренең чыгышларында хәзер XX гасыр татар әдәбияты тарихына багышланган 3 томлык әзерләнә башлавын, бу җыелышта әйтелгән тәкъдимнәрнең анда искә алыначагына ышандырдылар. Бу сөйләшү материаллары журналыбызның алдагы саннарының берсендә биреләчәк.

## РӘССАМНЫ ИЛ ЗУРЛЫЙ

Журналыбызда язып чыккан илек иле—үткән ел мәшһүр рәссам һәм сынчы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдиновның уникаль альбом-китабы басылып чыкты. Бөтендөнья татарларының III конгрессы делегатларына, кадерле кунакларга сувенир-бүләк рәвешендә тәкъдим ителде ул альбом. Соңгы вакытта матбугат битләрендә дә, теле-радио тапшыруларда да бу хезмәт турында еш искә алдылар. Һәм бу табигый да, хезмәт үзе Илне зурласа, Ил иҗатчының үзен зурлый. 18 декабрьдә Түбән Кама шәһәрендә рәссамның әлеге альбом-китабын презентацияләү-тәкъдир итү кичәсе булып узды. Ә. Фәтхетдиновның иҗат бәйрәменә республиканың төрле шәһәрләреннән әдәбият-сәнгатьнең күренекле вәкилләре җыелды. Казанның үзеннән генә дә 30 га якын кеше килгән иде.

Кичәне Түбән Кама шәһәре хакимияте башлыгы И. Метшин ачып җибәрде. Кунакларның чыгышлары сәнгать осталарының җыр-биюләре белән үрелеп барды. Рәссам иҗаты турында Татарстан Министрлар кабинетының бүлек мөдире М. Таишев, Татарстанның халык депутаты, шагыйрь Р. Вәлиев, Культура министры урынбасары И. Ибраһимов, «Нижнекамскнефтехим»нең җа-

waплы хезмәткәре М. Галимуллин, Татарстан рәссамнар бүлегеннән Р. Имашев һ. б. сөйләделәр. Бу кичәдә, шулай ук, әлеге альбомның редакторы, Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин да катнашты һәм чыгыш ясады.

### ХӘТЕР ЯҢАРТУ

Бер төркем татар зыялылары язучы Газиз Кашаповның тууына 60 ел тулу уңаеннан Нурлат шәһәрендә һәм Аксубай районында булып кайттылар. Язучының туган авылы Яңа Үзинең мәдәният йортында искә алу кичәсе үткәрелде. Анда беренчеләрдән булып Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин сүз тотты. Бикә Рәхимова, Флера Тарханова, Нәбирә Гыйматдинова, Марсель Галиев, Резеда Вәлиева, Рәфкать Кәрами, Мидхәт Миңшин, Роза Туфитуллова һәм башка танылган әдип-әдибәләр үзләренең әсәрләрен укыдылар, истәлекләр белән уртаклаштылар. Авыл үзешчәннәре дә үз осталыкларын күрсәтте. Чаллы язучылар оешмасы башлыгы Вахит Имамов үзләрендә чыга торган «Мәйдан» журналының Газиз Кашаповка багышланган махсус санын авыл мәктәбенә һәм музейга бүләк итте. Соңыннан Аксубай һәм Нурлат районнары житәкчеләре белән бергәләп Казаннан, Чаллыдан килгән кунаклар Газиз Кашаповның каберенә барып чәчәкләр куйдылар. Әдипләребез Иске Кармәт авылында Хәсән Туфан музеенда да булдылар.

### БӨРКЕТ РУХЛЫ ШАГЫЙРЬ

Кабарда-Балкар Республикасының халык шагыйре, Ленин премиясе, СССР, РФ Дәүләт премияләре лауреаты Кайсын Кулиевның 85 еллык юбилее Россия күләмендә киң рәвештә билгеләп үтелде. Мәскәүнең Үзәк әдәбиятчылар йортында үткәрелгән кичәне РФ Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлекләренең Халыкара бердәмлеге һәм Россия Язучылар берлеге оештырды. Юбилей тантанасын кереш сүз белән С. Михалков ачып җибәрде. Аннары юбиляр турында төрле әдәбиятлар вәкилләре Д. Кугелтинов (Калмыкия), Е. Исаев, И. Машбаш (Адыгея), А. Дементьев, А. Сагратян (Әрмәнстан), В. Чхеидзе (Грузия), Т. Зумакулова (Кабарда-Балкария), Р. Бикбаев (Башкортстан) һ. б. лар сөйләде. Юбилей кичәсендә татар халкының Кайсын Кулиев шәхесенә һәм иҗатына карата булган олы хөрмәт хисләрен күренекле шагыйрь Ренат Харис җиткерде.

Кайсын Кулиев татар халкы өчен хөрмәтле кеше. Заманында күп кенә татар язучылары белән якыннан аралашып яшәде, Татарстанда үткәрелгән төрле әдәби бәйрәмнәрдә актив катнашты, татар әдәбиятын югары бәяләп пропагандалады.

### АБРУЙЛЫ ИҖАТ ИЯСЕ

Татар һәм рус телләрендә дөнья күргән утызга якын китап авторы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь, прозаик, драматург Әхсән Баянов декабрь аенда 75 яшь тулды. Шул уңайдан 9 декабрьдә К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында «Бир абруйлы гомер» дигән әдәби-музыкаль кичә үтте. Чын мәгънәсендә зәвыклы, зыялы кичә булып истә калган әлеге тантанада юбилярны Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, мәдәният министры И. Тарханов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Миңнуллин котладылар. Күренекле сәнгать осталары Ә. Баянов әсәрләреннән өзекләр күрсәттеләр, җырларын башкардылар.

### ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында күренекле язучы, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Мәхмүт Хәсәновның тууына 75 ел тулу уңаеннан «Хәтер яктысы» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

Анда әдипнең туган ягы Теләчедән, Азнакайдан килгән кунаклар да катнашты. Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Нурислам Хәсәнов М. Хәсәнов турында истәлекләр белән уртаклаштылар. Татарстанның атказанган артисткасы Люция Хәсәнова һәм Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев халык җырларын башкардылар.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Хәзерге милли әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәне өчен язучы, шагыйрь, «Салават күпере» журналы редакциясенең әдәбият һәм сәнгать бүлеге редакторы, җаваплы секретарь Леронов **Лемон Лерон улына (Ләбиб Леронга)** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Иләләр иясе. Автопортрет.

*Рәссам һәм сынчы Әхсән Фәтхетдинов эше.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Басыйр Рәфыйков.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Газинур МОРАТ. **Җәяүле кошлар:** Публицистик мәкаләләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.—223 бит. Тиражы—2000 данә.




Урта буын шагыйре Газинур Моратның шигырьләргә сыеп бетмәгән уй-фикерләре, сөенү-борчылулары, өмет-ышанычлары тупланган бу китапка. Егерме ел эчендә язылган илледән артык төрле күләмдәге язмалар. Ике бүлектән торган китапның яртылабын сәяси темалар тәшкил итсә, икенче—«Җыр фаҗигасе» дип исемләнгән өлеше әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗаты турында. Ә «Югалган көндәлектән» дигән баш астында бирелгән кыска язмалар бүгенге яшәешебезнең иң актуаль мәсьәләләрен яктыртуга багышланган.

«Хакны әйтергә дә хокук кирәк!» дип башлана китап. Шагыйрь хокукын яхшы тоеп, бик күп хак нәрсәләр турында әдипләрчә, талантлы итеп әйтә алган автор. Бу китап ил-халык, әдәбият, китап язмышы турында уйланучы һәркем өчен кызыклы һәм гыйбрәтле булачак.

Рәфкат КӘРАМИ. **Өзелгән чәчәк:** хикәяләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.—224 бит. Тиражы—3000 данә.




Язучы Рәфкат Кәрами әдәбият сөючеләргә дистәләгән повестьлары һәм романнары белән яхшы таныш («Дүрт кешелек каюта», «Капитан Хәкимов», «Сагышлы кояш», «Ындыр тулы кибән» һ. б.). Иң яхшы дигән әсәрләре—«Очар кошлар белән янәшә», «Каргышлы этаплар» иң әүвәл «Казан утлары»нда басылдылар. Ә бу китапка авторның төрле елларда язылган хикәяләре тупланган. Кече күләмле иллегә якын әсәр өч бүлеккә туплап бирелгән. Арада олыларга адресланган җитди, сагышлылары да, балаларга атап язылган үгет-нәсыйхәтләре дә, юмор яратучыларны күздә тотып язылган төртмәле һәм каһкаһәләре дә бар. Аларда—безнең заман, безнең тормыш, безнең яшәеш. Китап язучының 60 яше тулу уңае белән чыгарылган.

Индекс 73210



Басыйр Рәфыйков

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)